ISSN 0206—418

# КАЗАН УТЛАРЫ

3.1996



## СЕЗГӘ МӘДХИЯ

**Бәхетле яшәсен Идел-йорт,**
**Хәвефсез йокласын бәбиләр.**
**Язларны, назларны дөньяга**
**Сез бүләк иткәнсез, ӘНИЛӘР.**

**Гасырлар түрендә җемелди**
**Беләзек, хәситә, алкалар.**
**Сез дә бит, кояштай нур чәчеп,**
**Бизисез тормышны, АПАЛАР.**

**Без дә бит сөюгә сусаган,**
**Канатлы — безнең дә күңелләр.**
**Мәхәббәт бакчасы багында**
**Иң матур чәчкә сез, СЕҢЕЛЛӘР!**

*Рашат НИЗАМИЕВ*

* * *

**Язлар кайдан, кайчан, ничек башлана? Табигатьтә моның беренче билгеләре — кояшның мулрак елмая башлавы, карларның җепшеккә тартуы, күкләрнең тагын да зәңгәрләнеп китүе...**

**Календарьларда исә Яз — мартның беренче көненнән башлана. Татар халык календаренда да Март иң күркәм айларның берсе санала. Чөнки ул бездә, борынгы әби-бабаларыбыз тормышында озак заманалар буе яңа елның беренче ае булып йөргән.**

**Кояш календаре аңлатканча, яңа елның башы итеп көн белән төннең язгы тигезлеге вакыты (хәзерге 21 март) исәпләнгән. Татарлар аны «Нәүрүз ае» дип йөрткән. Бу — «яңа ел ае» дигән мәгънәгә туры килә.**

**Нәүрүз ае белән, дуслар! Һәр йортка күркәм мәхәббәт, гаилә бәхете, саулык-сәламәтлек, бай уңыш, бәхет-сәгадәт юлдаш булсын!**



# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

**ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:**

**ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ**

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**3**

**(880)**

**1996**

КАЗАН


## *Бу санда*

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР


Р. ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр . . . . 3
Р. АЙЗАТУЛЛИН. Ирекле тоткыннар. *Роман* . . . . 10
И. ИКСАНОВА. Мин. *Шигырьләр* . . . . 136


КЛАРА БУЛАТОВАГА 60 ЯШЬ


Р. ГАТАШ. Ничәдә син, йөрәк? . . . . . 113
К. БУЛАТОВА. Безнең гомер сирпелгән жир... *Шигырьләр* . . . . 114


ӘХМӘТ РӘШИТКӘ 60 ЯШЬ


М. ӘГЪЛӘМ. Хакыйкать эзләп . . . . . 120
Ә. РӘШИТ. Карлар ява . . . . . . . . 123


ХӘТЕР


Т. МӨБАРӘКОВ. Мөхәммәт Мәһдиев турында истәлекләрем . . . . 127


ӘДӘБИ МИРАС


Р. ИСЛАМОВ. Мисыр шагыйре Шәриф Амидле . . . . 140
Ш. АМИДЛЕ. Газәлләр . . . . . . . . 140


ПУБЛИЦИСТИКА


Мәхмүт ӘХМӘТҖАН. Галәм. Мәхәббәт. Гаилә. Балалар . . . . 144
Н. САБИРОВ. Мәмдәлләрдә генә утлар яна . . . . 156


ТАРИХЫБЫЗ СӘХИФӘЛӘРЕ


Н. ГАРИФ. Борынгы Чаллы . . . . . . . 174

Безнең календарь . . . . . . . . 185
Котлыйбыз . . . . . . . . . . . 186


ЕЛМАЕП-КӨЛЕП КЕНӘ...


Ә. САФИУЛЛИН. Әллә нишләде бу халык! . . . . 187

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан . . 190

*Баш мөхәррир*
**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**
**Нәҗип Бакиров**
**Тәлгат Галиуллин**
**Наис Гамбәров**
*(җаваплы сәркатип)*
**Миркасыйм Госманов**
**Аяз Гыйләҗев**
**Салих Маннапов**
**Туфан Миңнуллин**
**Хатип Миңнегулов**
**Ринат Мөхәммәдиев**
**Рашат Низамиев**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Булат Солтанбәков**
**Ренат Харис**
**Розалина Шаһиева**
**Харрас Әюпов**

Б е з н е ң а д р е с: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Т е л е ф о н н а р:
баш мөхәррир — 49-36-60,
баш мөхәррир урынбасары — 49-36-09,
җаваплы сәркатип — 43-56-12,
бухгалтерия — 43-56-12,

*бүлекләр:*

шигърият, фән,
сәнгать — 49-36-61,
чәчмә әсәрләр, хатлар,
тәнкыйть — 49-36-63,
корректорлар — 49-36-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: роман Р. АЙЗАТУЛЛИНА «Свободные пленные»; стихи Р. ФАЙЗУЛЛИНА, К. БУЛАТОВОЙ, А. РАШИТА, И. ИКСАНОВОЙ.
«Память»: статья Т. МУБАРАКОВА «Воспоминания о Мухамет Магдееве».
«Литературное наследие»: поэт Египта Шариф Амидле.
«Публицистика»: статьи Махмута АХМЕТЗЯНОВА посвящена актуальным проблемам нравственного воспитания; Н. САБИРОВА «Огни горят в Мемделях».
«Страницы истории»: статья Н. ГАРИФ «Древние Челны».
«Юмор-сатира»: рассказ А. САФИУЛЛИНА.
Наш календарь.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: «Натюрморт» — картина художницы Миляуши Нуруллиной; известный писатель, публицист Миргазиян Юныс.

## IN OUR ISSUE

«Prose and Poetry»: R. Aizatullin's novel «Free Prisoners»; the verses of R. Phaizullin, K. Bulatova, A. Rashit, I. Iksanova.
«Memory»: T. Mubarakov's article «Memoirs about Mukhamet Magdiev.
«Literary Heritage»: Eguptian poet Shariph Amidle.
«Publicism»: Makhmut Akhetzyanov's article devoted to the urgent problems of moral education; N. Sabirov's article «Lights burn in Memdel».
«The pages of History» N. Gariph's article «Ancient Chelni».
«Humour and Satire»: A. Saphiullin's story.
«Our calendar».
«The diary of the social and cultural life».
In our covers: Milyausha Nurullina's pieture «Still life»; well-known poet, publicist Mirgazian Yunis.

● Авторлар фикере редакция фикере белән туры килеп бетмәскә дә мөмкин.

● Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.

● Журналда басылган язмаларны күчереп басканда, «Казан утлары»ннан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри.

*Мөхәррирләр:* **Мансур Вәли, Рәдиф Гаташ, Шамил Маннапов, Шаһинур Мостафин, Тәүфикъ Әйди.**
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөлзадә Моратова, Лилия Гатауллина.
*Машинисткалар:* Флера Сабирова, Тәгъзимә Шиһабиева.

Производствога бирелде 31.01.96 ел. Басарга кул куелды 15.03.96 ел. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70 × 108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 11 379. Заказ Е-53.
Журнал Татарстан Республикасының Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында теркәлгән. Теркәлү таныклыгы № 7.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1996 ел.

# ШИГЪРИЯТ



## Равил Фәйзуллин

### ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

* * *

Минем таралган салларым бар.
Төшләремдә шуларны җыям,
берәм-берәм бүрәнәләп...
Үскән җирләренә илтеп
утыртамын мин аларны.
Төпләренә сулар сибәм,
ботакларын ябыштырам.
Яфракларын ялгау —
ансы яз эше.

Өннәремдә
гомрем буе җиһан буйлап
сүзләр җыям күңелемә.
Бәгырьләргә үтәрдәйләреннән
оран салам! —
Милләттәшләр, кан-кардәшләр
Җыелыр дигән өмет белән
Дәүләт дигән Сабантуйга.

*1995*

### Күрәм дә тирәмдә...

Белмим, ярсып чиккә җиткәч
кемнән ни-нәрсә чыга?
Минем — канлы яшем аша
күңелдән җәя чыга!

Бераздан күрәм тирәмдә
уйнавын сабыйларның...
угымны кире яшерәм.
Тынычлап кала җаным.

*1995*

## Гел туйлардан торган дөнья...

Яшәүме?
Туу дигән Үлем башының
бер мизгел хәрәкәт уены!
Бәби туе-сөннәт туе...
Кавышу-никах туе...
озату-күмү туе...

Әй, бәби, әй, сабый!
Әй, егет, әй, туташ!
Әй, кардәш, әй, җирдәш!..

...Көнелләрдән күчеп —
рәшәләрдә язып куелган (насыйпларга!):
Гомернең өч туе.
Гомернең өч туе.
Гомернең өч туе...

*1995*

## Ретро

*

Солдат атлары
бигрәк мескеннәр!
Ашарга сорап
шинель тешлиләр!..

*

Машиналылар
бигрәк күбәйде!
Төтеннәреннән
Күк түбәнәйде...

*

Рәсәйдә халык
бигрәк бәхетле!
Эчеп үләләр —
әҗәлне көтми...

*1995*

## Аккош күлен сагыну

Нарат исле талгын җилләрдә
Аккош муеннары иркәләнгән!..

Канатларында — салават күпере!

Йөзгеч тәпиләре — көзге булган
купшы алтын балыкларга!..

...Хәзер әнә этләр коена.
Колакларга вәхши рәнҗеш тула —
исерекләр сүгенүе белән
бульдог, овчаркалар һау-һавы...

*1995*

## Сорау

*Уянгач та бер хушаваз*
*гөл... гөл... гөл... гөл...—*
*күңелемә сарыла гел!*

Син кем миңа? Чын исемең ничек?
Син дип! —
үлеп терелимме яңадан?
(миңа бик кирәкме яңа дан?)

Мин җавап көткән арада
исте назлы саба җиле
бөтен тәнемне,
бөтен җанымны,
бөтен гомеремне аралап.
Бөтен үткәнемне яралап...

*1991*

* * *

Алма апай. Туган апай.
Матур апай. Чибәр апай. Бал апай...

Малай чакта
Кояш кебек апайларның
һәрберсенә гашыйк идек!

...Кайттым быел җәй авылга.
Капка төбендә утыра карчыклар.
Муеннары алда, җилкәләре — артта.
Куллары (гафу!) —
кипкән гөберле бака...

Ак яулыкларында — чәчәкләр.
Ә чыннары — бакчада ата.

Алма апайның итәгендә
зур бер матур алма ята...

*1995*

* * *

*«Күңелем Ленин белән сөйләшә»*
С. Хәким

Мин бүген сөйләшмим әле,
уйлана торган көнем.
Белмим бит ничек буласын
соңгы көн, соңгы төнем...

Мин бүген сөйләшмим әле,
уйлана торган көнем.
Белмим бит нигә әйләнер
Илем, Телем һәм Динем...

Мин бүген сөйләшмим әле,
уйлана торган көнем.
Белмим бит, бу уйланулар
әллә төш, әллә өнем?..

*1994*

## Ул чак... бу чак...

Ул чак юктан да бар ясап,
кызык-ямь таба идек.
Кызлар ярыктан да көлә...
Без дә шул чама идек!

Итәк җилпеп үткәннәргә
кызыгып чаба идек!

...Акча юк. Дөнья күргән юк.
Хыял — барсын тутырган.
Нинди тәхете бар Яшьлекнең —
барсында без утырган!

...Дәрман бар. Дөнья гизелгән.
Яшәлгән. Нигез корган.
Җәен баздагы кар кебек
булган акыл утырган.

... Таңны Шәфәкъ белән бутап
теземне кочаклап торам.

*1995*

## Әти яккан мунчада

Мунча иркен! Эссе! Пар шәп!..
Җәлләмичә якканнар!
Бер кырыйда сөялеп тора
яңа нарат такталар...

Тиз арада кипсеннәр дип,
әти керткән аларны.
Ясамакчы икән язга
умарта оялары.

Үз җаена кибәрләр дип,
әйтеп кара — ни файда?
Кабергә куяр ташын да
ясатып куйды алдан...
Кайчан вакыты җитәрен
белә бары бер Алла.

...Чабынам шашып! Борында —
себерке, нарат исе!
Такталарга карыйм: парда —
күренә күк корт күче.

Мунча шәп! Рәхмәт әтигә —
бик вакытлы якканга.
Ни тора анадан тума
аунавы бер ак карда!

*1995*

* * *

Өсте өстенә яуган карлар кебек
еллар ята
Яшәү кырымда...

Әй тузгыта Язмыш атлы Җил!

...Кояш төшеп ачылган җирдә
яшькелт үлән сабаклары,
яшәү суты калган тамырлар күрсәң —
алар минем хәтерем булып —
Кыска гына Озын Гомернең...

*1991*

* * *

Кичәрләр, дип, озак еллар күпер салдым.
Эш беткәндә карап баксам — елгам кипкән?..

Гомер буе нур чәчәм дип, җырлар яздым.
Томнар чыккач карыйм: укучы бар микән?..

## Инде Табигать тә ялгышамы?

Февральдә яшен күренде.
60 тагы 16 яшьлеккә үрелде.
...Октябрьдә салават күпере?!
Оялып күземдә эреде...

* * *

Хөкемдар булган бит әле
ата угыры булып...

Бөкередән тугандыр ул
бу кадәр «туры» булып!

* * *

Балдак киясе бармакка
чыкты сөял.
Кая барып сөялим?
Менә сөаль!

* * *

Без бу дөньяда бары кунак кына...
Ә кунак рәхәттә яшәргә тиешле!
Тик шунсы бар: Вакыт-чаманны бел! Җирдә
артык булып әрсез яшәү һич килешми!

## Урак белән Чүкеч

*(Авыл белән шәһәр)*

Шигъри тел — бездән.
Моңлы көй — бездән.
Ипи-сөт — бездән.
Яшь солдат — бездән.
Ә гәҗит — сездән!
...Дөнья — тубыктан.
Тубык — диңгездән!

* * *

Йәрминкәләр! Йәрминкәләр!
Кайсылары тәгәрәп төшәр
бу кызыл кәрҗинкәдән!

...Ниләр кылдыгыз? — дип бер көн
сорар бит Җир-Әнкә дә...

* * *

*Үпкән-кочкан —*
*җилгә очкан...*

Очуын очкандыр да...
тик җилләр кире китереп
янә бәгъремә сипкән!

Хәтеремә янә чиккән.

## Телефон

Сөйләш син сак-сак!
Нәкъ дөресен чак-чак...
Сары салам капкан
соры башлы ябалак
тора төнеңне саклап!

«Рух»ны саклап!

* * *

Академиклармы?
Бездә дә бар. Байтак алар:
әгъза да хакыйкый,
әгъза да хакыйкый...

Тик нишләптер юк арада
берәр Нәкый,
йәки Бакый,
йә Исхакый...

* * *

Күзләре — диңгез!
Чәчләре — кылган!
Курай эчендә —
нечкә елан!

Түз, Шагыйрь!
Елмай...



**Роберт Айзатуллин**

# ИРЕКЛЕ ТОТКЫННАР

РОМАН

Маңгаена төшеп торган каты чәчләрен Хәлимов сул кулы белән артка сыпырды, әмма бу мизгелләрдә дә карашын Сафиннан алмады. Аның һәр хәрәкәтен, йөзендәге үзгәрешләрен күзәтеп, көтеп утырган Ленар Сафин моны да игътибарыннан читтә калдырмады, әлеге алымының нәрсә аңлатуын чамаларга тырышты. Аның өчен бу мизгелләрдә бер нәрсә ачык мәгълүм иде: беренче секретарь үгет-нәсихәттән туйды! Килеш-кыяфәте дә шуны раслап тора. Кояшта янган каратут йөзе пешкән кысла төсенә кергән; яңаклары шешенгән кешенекедәй бүртенгән; күз кабаклары, калын иреннәре аска салынган; кысык күзләре, корбанына ташланырга әзерләнгән карчыганыкы күк, усал, шәфкатьсез карыйлар.

Ул монда беренче тапкыр гына түгел, бүлмә хуҗасының бу кыяфәтени чагылдыруын өйрәнеп өлгергән иде инде. Димәк, алда «давыл» көтелә. Хәзер ул кычкыра, өстәл төя, яный башлаячак. Ә аңа кадәр, «зилзилә» алдыннан, әнә шулай рәхимсез карашы белән тикшерә, сыный. Аңа бу төр имтихан вакытында үзен ничек тотарга кирәклеге дә билгеле: йөзеңне яшерергә, күз карашыңны читкә күчерергә ярамый — бетте дигән сүз. Һавадан куян өстенә атылырга әзер бөркеттәй, нәкъ шул мизгелне сагалый хуҗа. Йөзендә бер мускулың тартылса, карашың читкә тайпылганны сизсә, котырына башлый. Шуны тойганга күрә, Сафин, карашын бер ноктага, аның күз алмасына төбәп, коеп куйган сын сыман тәз утыра бирде.

Бу минутларда аны сынаучы да үзен киеренке халәттә сизә, бар куәтен туплап, җавап тотучыга басым ясарга, үзенең өстенлеген сиздерергә, аны шулай сүзсез генә ихтыярына буйсындырырга тырыша һәм уйлана иде.

Каршында утырган яшь кешене ул шактый өйрәнде, яхшы белә: теләсә кемгә яраган «ачкыч» аңа туры килми, кычкырып куркыта торганнардан түгел. Моны ул беренче күрүендә үк тоеп калды.

---

* Журнал варианты.

Роберт АЙЗАТУЛЛИН (1940) — *журналист, вакытлы матбугатта хикәяләре күренә килә. Журналыбызда беренче мәртәбә басыла. Норлатта яши.*

«Коммунизм юлы» колхозының икенче бригадасына район житәкчесе язгы чәчүнең иң кызган чагында барып чыкты. Кипшенеп өлгергән бер басуны, чәчәсе урында, тырмалап яталар.

— Син нәрсә эшлисең, малай? — дип кычкырып салды ул, аның бригада агрономы икәнлеген белешкәч.— «Балчыкка чәчкән — кенәз»,— дигәнне ишеткәнең юк мәллә?

— Малайлар ыштансыз була, Хәким Нурович,— диде теге аның йөзенә туры карап.— Мин бу жир өчен җаваплы кеше.

— Ә нигә чәчмисез, дым югалтасыз; — агрономның каушап калмавы, әдәп белән генә аңа төрттереп алуы аны йомшарырга мәжбүр итте.— Монда алабута гына үстермәкче буласызмы әллә? — дип, аны үзенчә, икенче яктан чәнчеп алды.

— Монда еллар буе алабута түгел, солыча үстергәннәр,— дип төзәтте аны Ленар гап-гади генә.— Быел аны бетерү өчен көрәш башладык.

— Әмма кырда солыча юк, дым парга әйләнә бара.

— Бөтен бәла да шунда шул, әлегә юк, ә иген чәчкәч, аннан элек шыта да басуны каплап китә, ашлыкка үсәргә ирек бирми.

— Ни өчен? — дип сорарга мәжбүр булды ул тәмам сабырланып. Агроном сөйләгәннәр аның өчен яңалык иде.

— Әйдәгез, моны урынында аңлату ансат,— диде ул һәм, аннан рөхсәт тә сорап тормастан, басу эченә кереп китте, куллары белән җирне актарырга кереште. Өске катламны каеруга нечкә аксыл, озын тамырларны өзми генә аралады.— Менә күрәсезме, алар бүген-иртәгә борын төртергә тора, бөртектән иртә шытачак. Без тагын ике-өч көн көтәбез, ул тишелгәч, культиватор белән сөреп, тамырларын төптән кистерәбез һәм чәчәбез. Ул чакта бодай алдан тишелеп өлгерә, солычага үсәргә ирек бирмәячәк.

Өлкәдән солычага каршы мондый алым белән көрәшү турында бүген дә күрсәтмә юк иде әле. Ул чакта яшь агроном моңа үз белдеге белән алынган иде. Хакмы ул, түгелме — билгесез.

— Бу адымны кем тәкъдим итә? — дип сорады ул.

— Мин Казагыстанда, Акмула өлкәсендә хезмәт иттем, шунда күреп кайттым.

Аның өчен бары да берьюлы аңлашылды.

— Менә нәрсә, тәти егет,— диде ул тавышын күтәрми генә.— Басу сиңа сынау кыры түгел. Әгәр бу участоктан уңыш янәшә басуларныкыннан ким чыкса, партбилетсыз калачагыңны белеп тор.

— Партбилетны да алырсыз, кирәксә, эшемнән дә куарсыз,— диде Сафин тәвәккәл генә.— Уңыш җыйганда үзегезне чакырырмын.

Хәлимов чакырганны көтеп тормады, колхозларга барган-кайтканда, юл уңае туры килгән саен, әлеге басуга сугыла узды. Егет (хәер, аның хатыны, малае да бар икән инде) хаклы булып чыкты.

Көзен колхозның баш агрономын идарәгә күчергәч, бушаган урынга аны куярга тәкъдим итте. Ленар Сафин эшне оештыра белә икән. Шуңа тәмам инангач, «Маяк»ка тәкъдим итте. Гаҗәп ки, яшь агроном баш тартты: мәҗбүри эшләргә тиешле өч елы җәен тула, ул Казанга китәргә җыена икән.

Әмма Хәлимов үзе тапкан, әзерләгән сәләтле яшь белгечне алай тиз генә кулдан ычкындырырга исәпләми иде: Сафин ишеләр җирдә чәчелеп ятмый. Ул аны тагын да зуррак һәм авыррак колхозга — «Таң»га куюны күздә тотып, кайтарып җибәрде. Анда хисап җыелышы узып өлгергән, аның артыннан ук яңа рәис китерү килешми, кулай вакытны әзрәк көтәргә кирәк иде.

Күп көтәргә туры килмәде һәм ул Сафинны кабат чакыртып алды.

— Әйдә, болай килешәбез, Ленар,— диде секретарь сабыр, басынкы һәм үтенүле тавыш белән.— Син «Таң»га бар, өч ел эшлә. Колхоз исәбенә Наратлыда йорт сал.

Ике сәгатькә якын сузылган бу әңгәмә барышында Ленар күп төрле вәгъдәләр ишетте, әмма бусы телгә алынмаган иде әле. Беренче секретарь аңа ташлама ясыймы?

— «Таң»да, үзегез беләсез, болай да эш бармый, миңа үз йортым артыннан йөрергә вакыт булмаячак.— Турыдан-туры баш тартуны ул килештермәде, сәбәп тапкан булды.— Колхозчылар да моны дөрес аңламаячак.

— Ну, анысын үзең карарсың.— Хәлимов, әйттем исә кайттым, дигәндәй, бу юлы аның белән бик тиз килеште.— Мин моны сиңа барлык шартлар тудырылуын искәртеп әйтүем. Теләсә нинди ярдәм кирәк икән — туры үземә керерсең, уңай хәл итәргә ышандырам. Күтәрәмгә калган ат хәлендәге бу колхозны торгызып, урта куллар рәтенә чыгарсаң, әйткән иде диярсең, сигезенче бишъеллык йомгаклары буенча Ленин ордены синеке.

«Шөһрәт белән дә кызыктырмакчы була»,— дип уйлап куйды Ленар. Тик аның үзенә моны әйтә алмый иде, чүбек чәйнәү санаса да, үз дәлилләрен яңа баштан кабатлады.

— Хәким Нурович! Минем фәнни эшкә күчәргә җыенуым Сезгә күптән билгеле. Югары уңыш бирә торган яңа сорт бодай чыгару турында мәктәптә үк хыяллана идем. Институтның тәҗрибә хуҗалыгында урын бар. Бер үк вакытта фәнни эш белән дә шөгыльләнергә исәп. Минем анда эшләвем илгә файдалырак икәнен сез дә аңларга тиеш. Шуңа күрә мин «Таң»га бара алмыйм.

Хәлимовның күзләре тагын кискенрәк кысылды, озын ак кашлары борын өстенә кадәр сузылды, йөзен юри читкә борып, күзенең агы белән генә аңа карап тора башлады. Үзен колхозга кодалаучының халәтен тоеп, Ленар әлегә кадәр телгә алмаган соңгы дәлилен дә китерәсе итте.

— Анда бара алмавымның тагын бер сәбәбе бар, Хәким Нурович,— беренче секретарь тавышлана, яңый башлаганчы аңа моны җиткереп калу кирәк иде.— Яшьли сөйгән кызым анда. Аның белән янәшә торып эшләве, яшәве дә бик авыр булачак миңа. Шуны да исәпкә алсагыз иде.

Хәлимов, ышаныргамы, юкмы, дигәндәй, аңа сәерсенеп карап торды.

— Кияүдәме?

— Кияүдә,— диде Сафин, аны-моны уйлап тормастан.

— Бик яхшы. Пичәтен сугып, хуҗасына тапшыргансың, молодец. Бу очракта син түгел, ул оялырга тиеш. Билгеле, синнән түгел, иреннән.

Ленар Сафин, гүя, күсәк белән ордылармыни, миңгерәүләнеп калды. Кемнән-кемнән, әмма партиянең районда иң җаваплы урынын биләгән, йөзләрчә, меңнәрчә кеше язмышын хәл итүче җитәкче авызыннан, асылына да төшенеп тормастан, мондый әшәкелекне ишетүне башына сыйдыра алмый торды.

— Тик бер нәрсәне исеңдә тот,— дип дәвам итте ул баягы салкынлык белән.— Хәзер аның белән бәйләнмә. Югыйсә, элекке гөнаһларыңның да калкып чыгуы бар.

Хәлимов аңа психологик басым ясаганда кичерешләрен тышка чыгармаска тырышкан Ленар бу минутта кызыл чөгендергә охшап калган, яңаклары уттай яна иде. Тетрәнүдән айнып өлгермәгән килеш, ул бер хәрәкәтсез, ни дә булса әйтергә сәләтсез халәттә утыра бирде. Бу мәсьәләгә беренче секретарьның мөнәсәбәте шундый булгач, ул аның аңлатмасын тыңлап та тормаячак, колагына да элмәячәк. Белеп тора: бу тарихның очына чыгарга түземе җиткән очракта да, мәсьәләгә икенче күзлектән карап, аны янә көлкегә әйләндерәчәк.

Ул дәшми калырга мәҗбүр иде, бары, ризасызлыгын чагылдырып, аскы иренен генә тешләде. Үзе өстәл башында утыручыдан күзен алмады, тагын ниләр буласын көтте. Үгет-нәсихәтнең вакыты үтте. Бу сүз сөрешеннән дә ачык сизелә иде.

Ул дөрес чамалаган булып чыкты.

— Да, синең дә планнарың бар, әмма КПСС райкомын бүген синекеннән мөһимрәк планнар борчый,— диде секретарь тавышын күтәрмичә генә. Ләкин әлегә кадәр сакланып килгән үтенү нотыкларының әсәре дә калмаган иде инде анда.— «Таң»га председатель кирәк. Сиңа анда ничек тә барырга туры килер.

«Башланды»,— дип уйлады Ленар эченнән генә. Хәзер аңа авыз ачарга да ирек бирмәячәк. Алда куркыту, кимсетү, мыскыллау юлы белән «эшкәртү» генә калды. Хаксызга аларын ишетү күңелгә авыр, хурлыклы булса да, хәзер күнегеп килә, кем әйтмешли, беренче тапкыр гына түгел инде, түзә. Институтка китү өчен котылуның бердәнбер әмәле шул. Кышын аны «Маяк»ка рәислеккә кыстаганда да нәкъ шулай булды. Алдан оештыру бүлегендә, аннан беренче секретарь бүлмәсендә үгетләделәр. Ризалык бирмәгәч, теленә ни килсә, шуны әйтеп, катлы-катлы сүгенеп, куып чыгарды соңгысы. Тагын шушы кәмит оештырылачак инде хәзер. Кичә бүлектә, бүген монда, үтенеп кыстап та бармагач, башыннан сыйпап кына чыгарып җибәрмиләр инде. Ул моңа рухи яктан күптән әзер. Аксы, хурлык булса да, ялынып, җибәрүне сорап утырудан җиңелрәк тә әле, мескенләнергә туры килми. Кычкыра икән — кычкырсын, бу — көчсезлеге билгесе генә, ояты үзенә.

Ленар үзе өчен хурлыклы бу чишелешне көтеп арган иде, вакыйгаларны тизләтәсе итте.

— Мин соңгы сүземне әйттем.

Гаҗәп: секретарь кабынып китмәде, тынычлык саклады.

— Так, так.— Хәлимов тавышын күтәрмәде, әмма сүзләрен теш арасыннан сөзеп чыгара башлады.— Демократик централизмны санга сукмыйм, дисең инде. Учти, монын зыяны бик зурдан тимәгәе.

Моның кисәтү икәне ярылып ята иде. Ул Сафинның моны ничек кабул итүен күзәтә башлады. Тагын күпмедер күзгә-күз терәп тын утырдылар.

Бу юлы әлеге уен озакка бармады. Хәлим аннан үзе туйды, башын читкә борды, янә, инде ничәнче тапкыр, аның хисап карточкасына үрелде.

— Кая, партбилетыңны бир әле,— дип боерды ул. Үзе анкетадан башын да күтәрмәде.— Партия дисциплинасына буйсынырга теләмәүче егетне КПСС членлыгына кем алды икән?

Бу аның алдында яткан анкетадан да билгеле, юктан сылтау, йомыркадан җөй, бәйләнергә җай эзләү генә иде.

Беренченең соңгы соравы аны беркадәр сәерсенергә мәҗбүр итте, сагаеп аңа карады: чын «зилзилә» кайчан башлана соң? Тик хәзер моны чамаларлык түгел. Хаким Нурмөхәммәтович документны алу өчен дә башын күтәрмәде, әңгәмәдәше йөзендәге үзгәрешләрне күрмәде, күзлеген борын очына атландырып, анкетага төбәлеп утыра бирде.

Ленар партбилетын аның алдына куйды һәм уйлана башлады. Ул аның нәрсәсен тикшерә? Аңа кадәр бүлектә нокта, өтеренә кадәр энә күзеннән үткәрделәр, өйрәнделәр бит инде. Аннан берәр төрле ялгыш эзләделәрме? Хәрби часть партбюросына сорау ясатмакчыლармы? Бу аңа нәрсә бирә? Ул бит шпион түгел, кемлеге билгеле, туганнары шушы районда. Әтисе әсирлектә булган өчен бәйләнмәкчеләрме әллә? Ләкин ул моны яшермәде, кандидатлыкка кергәндә үк әйтте. Аңа ышанмасалар, ул чакта ук үткәрмәгән булырлар иде.

— Тикшерделәр инде,— дип куйды ул, сабыр канаты сынып.— Анда барысы да тәртиптә.

Тикшерүче аны, гүя, ишетмәде, билет битләрен актарды, исәп карточкасы белән чагыштырган булды һәм, чак кына сулга үрелеп, аны сейфка ташлады. Ишеген ябып бикләде, ачкычын кесәсенә үк салды.

Яшь белгеч моны исе китеп күзәтеп утырды, авыз ачып әйтергә сүз тапмады. Янмый торган шкафны бикләгәч кенә аның нияте тәгаен ачыкланды. Ул моны партия билетын алганын, кире кайтармаячагын сиздерү өчен эшләде. Бикләмәсә дә, тарткалашып ала торган документ түгел ләбаса.

— Бар кайт.— Ул әле генә күпме киеренке сөйләшү алып барган әңгәмәдәшен, гүя, онытты, эшлекле кыяфәттә сводкалар кенәгәсен алдына ачып салды, кызыл карандашын саннар баганасы өстендә йөртә, кайберләрен билгели башлады.

Ленар беравык шуны күзәтеп, үзенең бу хәлен уйлап утырды. Бәхәсләшү, тагын бер кабат аңлатырга тырышып карау файдасыз, дәлилләр китерелеп бетте инде. Сорау — хурлык, андый йомшаклыгын сизсә, ялындырачак, мыскыллаячак, анда да шартларына ризалашсаң гына, бирәчәк.

Ул тавышсыз гына урыныннан торды, дәшми-тынмый чыгарга борылды.

— Риза булсаң, килерсең.— Артында аның кеткелдәп көлгәне ишетелде. Аска карап, игътибарын кәгазьгә туплап утырган кыланса да, аны күзәткән, көткән икән.— Риза булмасаң, килеп тә йөрмә, шуның белән карьераңа тәре тамгасы салынган сана.

Сафин, бу мизгелләрдә аның йөзен бик күрәсе килсә дә, тиешсез санады, саубуллашып та тормастан, чыгып китте.

* * *

Кабул итү бүлмәсендә көтүчеләр, ишектә аны күргәч, башларын чайкап, сәгатьләренә күз салып алдылар. Тик ул боларны күрмәде, монда барлыкларын да тоймады, күзен кан баскан үгез кебек аска карап, берәүгә бер сүз дәшмичә, яннарыннан узып китте. Ишекне тышкы яктан япкач кына, барыннан да элек, тирән бер тын алды, кулъяулыгын чыгарып, яңакларын, муеннарын ышкыды. Җәя бавыдай тартылган мускуллары кинәт йомшап төште. Тик Ленар, гарьләнүдән , моны да, аяклары кая басканны да сизмәде.

Бүген ул биредә сөйләшү җитди, киеренке буласын алдан белеп, үз сүзендә ахырынача торырга рухи яктан әзерләнеп килгән иде. Андый очракларда, ризалык бирмәсә, шәхси эше райком бюросында тикшерелүе, шелтә бирүләре, хәтта партиядән чыгаруга кадәр барып җитүләре дә ихтимал икәнлеге аңа мәгълүм иде. Әмма ул үзен якларга, институтка китсә, партиягә, илгә күбрәк файда китерәчәген исбатларга, шуңа башкаларны да ышандырырга исәп тотты. Бюро бер Хәлимовтан гына тормый, арада үзе сайлаган юлның дөреслеген аңлаучы, яклаучы табыласына өметләнде.

Ләкин бөтенесе һич уйламаганча килеп чыкты. Башлык бернинди кагыйдәләр, әдәп, форма өчен генә булса да устав таләпләрен дә саклап тормады. Ул гына түгел, балалар белән шаяргандай, төп башына утыртты. Мондый кәмитнең максатын Ленар һич аңлый алмады: ни өчен шулай алдап эш итәргә? Аңа мораль йогынты ясар өченме? Хокукы чиксез икәнен сиздерү өченме? Мөгаен, шулайдыр. Артыннан мыскыллы көлеп калуы шуны аңлата.

Ленар Сафин, Хәлимовның үзен тыңларга, аңларга теләмәвенә таң калды. Сөйләргә сүзе, ышандырырга дәлилләре җитәрлек иде югыйсә.

Ул, әтисеннән яңарак туып кына калган малай, сугыш чорының бар авырлыкларын үз җилкәсендә татыды. Үзен-үзе белә башлаган көннән тамагы туярлык ашаганын хәтерләми — ачлыкка киселеп үсте. Әнисе, аны башкача саклап калыр әмәле югын белгәнгә, үзе үлгәнче имезүдән аермады. Колхоздан арып-талып, ач кайткан әнисенең буш имиләрен кан чыкканчы суыра торган иде сабый.

Әнисе 1946 елның кышында вафат булды. Малай үзләренә өйдәш кергән тол Гайшә апа кулында калды. Хатын аны, биш яшьлек Ленарны, хәер теләнергә авыл өстенә чыгарып җибәрергә гадәтләнде. Ятимне кызганалар, бер йорттан да буш чыгармыйлар диярлек, муенына асылган чүпрәк букчасына алабута күмәче, көлчә, бәрәңге, хәллерәкләре берәр

күкәй дә сала иде. Гайшә апасы белән аның кызы Фәйрүзә дә ул кайтарган ризык исәбенә җан асрады.

Бер елдан соң әтисе кайтып төште. Кулы имгәнгән, аягы чатан әсир язын авыл көтүен алды. Улын булышырга үзе белән ияртеп йөри башлады. Ленар көне буе мал-туар артыннан йөгерә, хәле бетсә, сахрада ук йоклап ала. Авыр, бик авыр иде, әмма авыл аларны туендыра килде.

Авылның ничек икмәккә тилмергәнен шулай татып үсте ул. Үзләренә һәм башкаларга да җитәрлек икмәк үстерү турында шул чактан ук уйлана иде.

Мәктәптә төгәл фәннәрдән аңа тиң укучы юк иде. Ул чакта яшерен күз атып йөргән кызы Гөлфия дә, укытучысы Нурия апа да аңа математика факультетына керергә киңәш бирделәр. Әмма егет күңеленә алдан киртләп куелган максатына тугрылыклы калды, агрономлыкка укырга китте. Яңа сорт бодай үстерү өчен аңа диплом гына җитми, ныклы белем кирәк иде.

Шуларны Хәлимовка аңлатырга иде аның нияте. Ул да кеше, хәленә керер дигән өмет белән килде райкомга. Кызганыч, башлык аның сүзләрен колагына да элмәде, кичерешләрен дә күрмәмешкә салышты.

Ленар партиягә ихлас күңелдән ышана. Аның программасын да, устав таләп иткән өчен генә түгел, чын күңеленнән таный. КПСС халыклар тигез, тату, бәхетле яши алачак коммунистик җәмгыять төзү өчен көрәшә бит. Коммунизм — муллык, иҗади ирекле хезмәт хөкем сөрәчәк җәмгыять. Барлык илләрнең хезмәт халкы гасырлар буе шул хакта хыяллана. Ул үзе дә шул изге, бөек максатка ирешү өчен хәленнән килгәнчә көчен кызганмый эшләргә, көрәшергә әзер.

Партия әгъзасы булу өчен Ленар рухи яктан мәктәптә үк әзерләнә башлады. Институтта партия сафларына керү ансат түгел, студентлар арасыннан бик сирәкләрне, комсомолда һәм башка җәмгыять оешмалары эшендә үзен һәрьяклап күрсәткәннәрне генә кабул итәләр иде. Ул шундый бәхетлеләр арасында булды, солдатта хезмәт иткәндә кулына партия билеты алган минутларны гомеренә истә калырлык, мәңге онытылмаслык вакыйга итеп санады, сабыйларча самимилек белән сөенде.

Ул институтка әйләнеп кайткач, КПСС Үзәк Комитетының авыл хуҗалыгы белгечләрен авылга җибәрү турында карары чыкты. Ленар моның белән килеште: авыл әзерлекле, белемле кадрларга мохтаҗ, алар анда бик кирәк. Диплом алганда, бу карар үзенә турыдан-туры кагылгач кына, күңелендә беренче тапкыр шөбһә уянды. Ул институтта калырга, аспирантурада укырга, бер үк вакытта өйрәнү хуҗалыгында тәҗрибәләрен башлап җибәрергә җыенган иде. Институтны кызыл диплом белән тәмамлады, кафедрада калырга беренче кандидат иде. Әмма, чыгышы авылдан булган өчен, партком карары нигезендә, аны мәҗбүри рәвештә авылга җибәрделәр.

Юк, авылдан качарга, җиңел тормыш хакына шәһәрдә төпләнергә дигән уй аның башына да килеп карамады. Тәҗрибәләре уңышлы барып чыкса, баш-күз алгач, берәр хуҗалыкны үзенә мөстәкыйль тәҗрибә участогы итәргә, шунда торып эшләргә дә исәпләп куйган иде. Ләкин аны аңлау кая — тыңларга да теләмәделәр: партия карары һәм коммунист өчен закон. Ә ул карар нигезендә аңа кимендә өч ел анда эшләргә кирәк иде.

Күңеленнән бу карарны гаделсез санаса да, сорт сынау тәҗрибәләрен авылда ук башлап җибәрергә исәп тотып китте ул. Бер яктан бу уңай да әле: колхозда эшләп тормыш тәҗрибәсе туплаячак, анысы беркем бирә алмый торган хәзинә. Галим буласы кешегә авылны, игенче хезмәтен якыннан белү зарури.

Әмма Ленар ике нәрсәгә гарьләнде. Кафедрада аның урынына авыл тормышын китаплардан гына укып белгән, практик эшләрдә гел Ленар ярдәменә мохтаҗ курсташы Шәүкәт Нәбиевне калдырдылар. Тумышы Казаннан булган өчен. Моның белән ул һич ризалаша алмады. Кафед-

рада Ленар калса, күпкә отышлы, җәмгыять өчен файдалырак булыр иде. Галимнәр арасында моны аңлаучылар бар иде, тик партия карарына каршы килеп, сүз әйтергә берсе дә җөрьәт итмәде.

Аңа кадәр өч ел солдатта хезмәт иткән вакыты да фәнгә омтылган егет өчен җилдә очкан гомер иде. Тормыш тәҗрибәсен шактый туплап өлгергәнгә, ул калган елларында икеләтә куәт белән эшләп, артта калганнарын куып җитәргә исәпләгән иде. Ләкин бер нәрсәне игътибарга алмаган булып чыкты. Партия нормалары бүген дә аны үз кысаларыннан ычкындырмый икән. Быел, китәр чагы житкәндә генә, моны кабат татыды. Райком секретаре аңа чат ябышты. Алдан бер, аннан икенче колхозга рәислеккә кыса башлады. Аның шәхси планнары турында ишетергә дә теләмәде, партия исәбеннән төшермәячәкләрен алдан ук искәртеп куйды. Аннан төшмичә, уңай бәяләмә китермичә, институтка документларны да кабул итмиләр.

Яшь белгеч ике ут арасында калды: нәрсә эшләргә тиеш? Ризалык бирсә, китә алмый. «Рәислеккә кермим», дисә, мөгаен, партиядән чыгарырлар. Бу — институт, күңелдәге якты хыяллар белән гомергә саубуллашу дигән сүз; партиядән куылганны фәнни эшкә якын да җибәрмиләр. Бер-берсенә бәйләнгән бөҗра шикелле бу, һич очын таба алмыйсың. Бер яктан карасаң, Ленар ирекле; икенче яктан — ирексез, төрмәгә ябылмаган тоткын шикелле. Шулай булгач, кем соң ул? Математика законнарына таянып фикер йөрткәндә, аның кемлеге ике сүзнең суммасына — ирекле плюс тоткынга тигез була. Менә сиңа мә? «Мин — ирекле тоткын!» дип кычкырып әйтеп салганын сизми дә калды ул.

Ленар үзенең бу ачышына үзе дә гаҗәпләнә һәм курка калды, күзәтүче булмасын дип, ашыгып, як-ягына күз салды. Ул инде машинасы янына җитеп килә, тирә-юнендә кеше-мазар күренми иде.

Соңгы көннәрдә үзен өзлексез борчып торган соравына кабат әйләнеп кайтты: партиядән чыгарсалар, язмышы ни белән бетәр? Яшьлек хыяллары челпәрәмә килмәсме? Колхозда фәнни хезмәт белән шөгыльләнү өчен шартлар юк: кишәрлекләп җир бүлмиләр; тиешле ашламаларны нормалап кертә алмыйсың; технология сакланмый. Соңгы өч елда ул моны үз җилкәсендә татыды, алдына куйган максатына ирешә алмады.

* * *

Шифаханәгә дә кереп чыгасы бар иде аның. Миңнегөл икенчегә бәби тапты. Кичә аны күрсәтмәделәр, хатыны белән тәрәзә аша гына сөйләште.

Ленар хатыны ята торган палата кырына килде. Әни кеше бала имезеп утыра иде, ирен күргәч, сикереп торды.

— Малайны күрсәт, малайны! — дип кычкырды ул тәрәзәгә авызын куеп.— Динарны!

— Менә кара, нәкъ үзең инде,— диде Миңнегөл, баланы тәрәзә каршында тотып.

Әнисе белеп әйтә: аныкы шикелле чак кайтарма борын, чем-кара күзләр, йөзе генә кып-кызыл. Әти кеше аңа шактый озак һәм дикъкать белән карап торды. Кәефе күтәрелеп китте, авызы ерылды. Улын әйләндергән булып кыланды. Тик бу хәлләр озакка бармады, кырыс карашлы шәфкать туташы керде дә нәниләрне алып чыгып китте.

— Йә, үзең ничек инде? Безне күрергә генә килдеңме, әллә тагын чакырдыларммы? — Миңнегөл, форточка аша ире сузган күчтәнәчне кабул иткәнче ук, үзен барыннан элек борчыган соравын бирде.

— Чакырдылар,— дип кычкырды Ленар.

Хатыны капны тиз генә үрелеп алды, эчендә ниләр барына күзен дә салып тормастан, тумбочка өстенә төртте һәм кабат баягы урынына әйләнеп килде:

— Китәсеңне әйткәнсең ич?

Ире аскы иренен тешләде. Яңарак йөзендә балкыган якты нурлар сүрелгән иде инде.

— Ул хакта авыз да ачтырмыйлар.— Шуны раслау, хатынына төшендерү өчен кулын ук селтәп җибәрде.— Сүз «Таң» турында гына бара.

Миңнегөл иренең гадәтләрен үзләштереп бетергән инде, эшне, Ленар әйткәнче үк чамалаган иде. Ире йөзендәге күләгә аңа да күчте. Иреннәр тоташкан җирдәге борчактай кызыл башлы миңе көрән төскә керде, бит алмасындагы бәхет уентыгы югалды.

— Бу ничек була инде? — Күңелсез хәбәрнең беренче тәэсирләреннән айнып, ул телгә килде.— Конкурска документларыңны кайчан илтәсең?

— Характеристика бирмиләр.

Хатынның бит мускуллары тартышып куйды, күңеле пошаманга төште. Елап җибәрергә дә әзер иде.

Ул форточка янына ук килде, куллары белән рамга тотынып, аяк очларына күтәрелде.

— Син теләсәң дә, мин председательлеккә китүеңә риза түгел,— дип, элек тукыганнарын иренең исенә төшерде.— Анда бер барып эләксәң, тиз генә ычкына алмыйсың.

— Аңлаттым,— диде Ленар, кашларын сикертеп. Хатынының өйрәтүләренә аның эче поша, саруы кайный инде. Башка чакта булса, икенче төрлерәк сөйләшер иде дә, монда, шифаханәдә борчыйсы килмәде — өзлегүе бар. Шуңа сабырлык белән очлады.— Кешене тыңлыйлармы соң анда?!

— Бу ничек була инде? — Миңнегөл иренең үзе турында ни уйлавын күз алдына да китермәде, һаман бер тирәдә әйләнә бирде.— Көчләп җибәрергә закон юк. Үзең риза булмасаң, берни эшләтә алмаслар.

Ленар яхшы аңлый: Казанга китәр җай чыкканда иренең авылда калырга ризалык бирүе белән беркайчан килешмәс хатыны. Ул — Казан кызы. Әти-әнисе анда, билгеле инде, алар янына кайту өчен җаны фида. Инде җай чыккан, иренә эш мәсьәләсе дә, нигездә, хәл ителгән. Үзе өчен уйламый да: инженер-химик һөнәренә Казанда эш бетеп торамы?!

— Эшләтерләр,— дип куйды ире.

— Әй, син әйтмәдең бит әле, бүген нәрсә белән бетте? — дип исенә төшереп, ашыгып сорап куйды ул.

— Ризалык бирмәдем, ачуланып чыгарып җибәрделәр,— диде ире теләр-теләмәс кенә.— Әлегә шул.

Миңнегөл ирен тагын бер тапкыр кисәтергә кирәк тапты.

— Син теләсәң нишлә, мин бармыйм. Камышлыга ике аягымның берсен дә атламыйм. Нигә икәнен үзең беләсең. Котылыр әмәлең булмаса әйт: теләсә кая җибәрсеннәр, тик анда түгел. Минем соңгы сүзем шул: син анда икән — мин әниләргә кайтып китәм.

Миңнегөлнең Камышлыга барырга теләмәве Ленарның сыйныфташы Гөлфиягә бәйле иде. Ул иренең егет чагында, Гөлфияне яратып йөргәнен белә, әле дә аны көндәше итеп күрә иде...

— Ярар, мин китим әле,— диде Ленар. Күңеле тынгы тапмый иде аның бүген, үзен кая куярга да белми иде.

Райком бюросы утырышына чакырылган Ленарны беренче секретарь кабинетында аягүрә каршылады.

— Йә, Ленар, ничек йокладың, нинди төшләр күрдең? — диде ул нәзакәтле төстә. Әйтерсең, кичә ике араларында дустанә аңлашу гына булган, бүген шуннан соңгы очрашу инде.

— Төш күрергә вакыт тимәде...— диде Ленар, йокламаганын сиздермәскә тырышып.

— Әйе, нервлар нык синең.— Хәлимов йомшак келәм өстеннән тәмәке тарта-тарта йөренә бирде.— Дөресен әйткәндә, көнләшерлек тә. Кушканны көтми эшли, үзеңне лаеклы тота да беләсең. Син теләсә кем

кубызына бии торган бәндә түгел. Дөрес эшлисең. Алда мине генә тыңла, үсәргә мөмкинлекләрең зур синең. Уважаю мин сине.— Ул аның җилкәсенә кулын салды.— Йә, ничек, уйладыңмы?

Ленар җавап бирергә ашыкмады, үзенең хәлен бүгенге шартларга куеп чагыштырды. Үз-үзенә ясаган нәтиҗә аяныч иде, күңелендәге соңгы өмет чаткылары сүнде. Көтү бүлмәсендә кайсы кая стенага сөялеп баскан, юан корсаклы агайларның берсе дә аның кайда эшләп, нинди файда китерүе турында уйлап та карамаячак, ул сүз башласа да, аның файдасына тел тибрәтмәячәк — үзләре өчен куркалар. Шулай булмаганда сигез кеше аягүрә басып, тавышы ишетелүдән куркып, чакырганын көтәрләр идеме? Монда Хәлимов — бердәнбер хуҗа һәм, башкаларныкы кук, Ленарның язмышы да аның бер сүзенә бәйле. Бу йортта шундый язылмаган законнар хакимлек итә.

Ул үзенең хаклыгын исбатлый алмады — җиңелде. Китсә дә,калса да бу шулай. Әмма хурлыклы рәвештә районнан сөрелгәнче монда эшләсә, аңа буйсынган хәлдә дә, көрәшне дәвам итү, хаклыгын исбатлау өчен мөмкинлеге кала әле. Ул үзен тиешенчә тотты, партбилет сорап килмәде. Моны аның хуҗасы да танырга мәҗбүр булды. Аңа билгеле ташламалар да ясады. Тагын да юл бирер чамасы сизелә.

— Бер шартым бар,— диде ул.

— Нинди? — дип ашыгып сорады хуҗа.

— Үземчә, мөстәкыйль эшләргә юл куйсагыз, барам.

Хәлимов, күзләрен зур ачып, күпмедер мизгелләр аңа карап торды.

— Менә бу егетләрчә. Молодец!

Хәлимов борылып өстәле янына килде, төймәгә басты. Ишектә сәркатип күренде.

— Бюро членнары керсеннәр, Надя!

* * *

Алдан бөтенесе шома, планлаштырылганча барды. Мостафа Талиповны, халык аннан туеп беткәнлектән, берниндй тоткарлыксыз эшеннән бушаттылар.

Хәлимов кабат мөнбәр артына чыкты, райком бюросының алмашка Сафинны тәкъдим итүен белдерде, тормыш юлы белән таныштырып узды, агроном буларак эшчәнлегенә югары бәя бирде. Аның артыннан сүз алган күрше колхоз рәисе Гәрәев, парторг Харисов та аның адресына җылы сүзләрне кызганмадылар. Президиум өстәле артында утырган булачак рәисне бастырып, халыкка күрсәтеп тә алдылар. Бөтенесе тоткарлыксыз үтте, уңай, кире якка да сүз кыстыручы табылмады. Тавышка куйдырып аласы гына калган иде.

— Бәлки сорауларыгыз бардыр? — дип куйды Харисов, бу эшнең телсезләр җыенына охшап калуына эче пошып.

Шуны гына көткәнме, әллә бу очраклы тәңгәл килү идеме, шуның арты ук пенсионер Зыятдин бабай торып басты.

— Җәмәгать, минем иптәш Хәлимовка бер соравым бар. Безгә, аллага шөкер, предларны бик мактап китереп торасыз. Алар киләләр, симерәләр, байыйлар, Наратлыда ташпулат салалар. Колхоз, халык турында уйламыйлар да, теләмиләр дә. Менә тагын япь-яшь, мыегы да чыкмаган малай китергәнсең. Әйтмим, бәлки ул яхшыдадыр. Аның да туган авылы бар. Аны тотып шунда куйсагыз, безгә дә үз кешебезне сайлатсагыз булмый идеме? Чит кеше, ни әйтсәң дә, чит инде, авылның эте дә авылга карап өрә. Халыкка да уңай, колхозга да файда булыр иде, бәлки?!

— Бик дөрес, бик дөрес! — дип кычкырдылар төрле яктан.

Шуннан башланып китте буталыш: үз кешебезне сайлыйбыз да вәссәлам!

Халык таләбе буенча сайлау да үткәреп карадылар. Ленарны колхоз куштаннары, Назыймны механизаторлар, Гамирны — нәселе ишле туган-тумачалары яклады.

Төрле төркемнәр арасында бәхәс өч сәгатьтән артыкка сузылгач, һәр якның, аккош, чуртан һәм кысла кук, үзенә таба тартуына төшенгәч, ир-ат халкы кисәтүләрне санга сукмыйча, рөхсәтсез генә тәмәке тартырга чыгып йөри башлаганны күргәч, беренче секретарьдан рөхсәт сорап, Харисов, ниһаять, тәнәфес игълан итте. Халык белән бергә, ул да кузгалды. Тик, бар халык урамга агылганда, Гөлфия Сәйфетдинова, сәхнәгә таба атлады. Аңа тәнәфестә ничек тә ире белән сөйләшеп калырга кирәк иде: Назыйм булдыра алмый, фамилиясен исемлектән төшерергә тиеш.

Тәнәфес алдыннан партком әгъзаларын, идарә членнарын сәхнәгә чакырдылар. Назыйм, идарә әгъзасы, баш белгечләр кебек, иң алгы рәттә утыра иде, шунда күтәрелде.

Сәхнә артында берәү дә юк иде. Алар мондагы бердәнбер бүлмәдә булырга тиешләр. Ул шул ишек төбенә килде, колак салып тыңлап карады. Эчтә тавыш-тын ишетелмәде, барысы да җыелып өлгермәгән бугай. Тәвәккәлләп тотканы тартты, эчкә узды һәм ишек төбендә катып калды.

— Син егеткәй, моның өчен башың югалачагын аңлыйсыңмы, юкмы? — Райком секретаре бүлмәне яңгыратып кычкырды һәм сталгә китереп сукты. — Мин сине шундый пред ясармын, районнан эзең үк суыныр. — Ул, ачуыннан буылып, инде салмак кына өстәлгә төеп торды һәм өстәде. — Партбилетыңны алып озаттырам мин сине моннан.

Хәлимов ялгызы өстәл артында утыра, башкалар исә, ике рәткә тезелеп басканнар да, катып калганнар. Сафин һәм Гәрәев кенә бу төркемнән читтә тәмәке төтәтәләр.

Беренче мәлдә ул югалып калды, хәрәкәтсез торды. Эшнең асылына төшенеп, ире бушаганны сәхнә артында көтәргә булып, чыгарга җыенган иде, киңәшмәне алып баручы аны күреп алды.

— Нәрсә анда катып калдың, уз.

Хәлимов аны чакырылганнарның берсе итеп кабул итте булса кирәк, шулай дип боерды.

Гөлфия уйланып калды. Кемлеген аңлатырга керешсә, аңа да кычкырып салачак. Ул кирәкмәгән җиргә тыкшынырга тырышкан кеше булып чыга. Максатын төшендергәнне тыңлап торырга, күренә ки, вакыты юк. Монда хәзер ниләр булганын белеп калу теләге дә зур иде. Үзе өчен ул дәшми калу, тәнәфес беткәндә шыпырт кына залга чыгуны кулай санады.

— «Кермим» дип күз алдыгызда берничә тапкыр әйттем бит, Хәким Нурович. — Тынлык урнашкан арада Харисов сак кына үз сүзен кыстырды.

— Акланып маташма, җыелышны әзерләмәгәнсең, моны мин сиңа напомню еще. — Башлык, карчыга карашы белән, парторгны янә күздән үткәрде һәм, кинәт, икенче якка борылды. — Син үзең ничек уйлыйсың, Ленар, безгә бу кыен хәлдән ничек чыгарга?

— Ничек тә уйламыйм, Хәким Нурович, — диде Сафин бер дә исе китмичә генә. — Боердыгыз — килдем, сайласалар — эшлим, сайламасалар, тагын да яхшы, кайтып китәм. — Һәм, тынычлап, тәмәке тартуын дәвам итте.

Гөлфия сыйныфташының үз язмышына шулай битарафлыгына хәйран калды. Ярты көн дәвам иткән җыелыш барышында да колхозчылар аның исемен катнаштырып тел чарладылар, «яшь», «мыегы да чыкмаган», «килмешәк» белән сыйладылар — йөзендә бер мускулы да тартылмады, чырае да үзгәрмәде: әйтерсең, боларның берсе дә аңа кагылмый, башка берәүгә юнәлдерелгән иде. Ә ул Ленарны белә, үзен җәберләтә торганнардан түгел, кирәк икән, утка керергә, суга төшәргә дә әзер. Сүзгә дә кеше кесәсенә керми, кирәген, кем булуына карамастан, йөрәге-

нә ярып сала торганнардан. Шуңа да ул аның җыелышта сүз алуын, үзен кимсетүгә карата мөнәсәбәтен белдерүен көтте. Ләкин ул кузгалмады, һәйкәл сыман утыра бирде.

Ленар тәмәкесен тартып бетерде, тирә-ягына каранды. Төпчеген ташларга савыт эзли икән. Аңа якын гына торган чиләкне күреп, шунда килде.

— Исәнмесез, Гөлфия! — Беренчегә комачауламас өчен, ул акрын гына эндәште: — Кәефләр ничек?

— Исәнме, Ленар,— диде ул да чак ишетелерлек итеп.

Гөлфиягә авылдашын якыннан күзәтергә мөмкинлек туды. Аның озынча түгәрәк йөзендә, киң маңгаенда бернинди үзгәреш тә сизмәде. Кояшта каралган чыраеннан моны ачыклавы кыен да иде. Элек муенына кадәр төшеп торган дулкын-дулкын кара чәчләрен нык кыскарткан, бары шул, шомырт күзләре һаман сынап карыйлар.

Гөлфиягә Ленарның бар көч-кодрәте күзләрендә тупланган шикелле. Яшь чакларында карашып утыра торганнар иде. Аның күзләрендә күңелдә илһам уята торган энергия, йөрәктәге салкын бозларны эретә алырлык җылылык, җанны үзенә тарта торган магнит кыры да бар төсле. Аның биотоклары көчле бугай, бер карашы белән кыз күңелендә туган үпкә, юшкыннарны юып кына ала торган иде. Хәзер дә шулай микән?..

Тагын ишек шыгырдады. Анда тагын бер идарә әгъзасы — савымчы Саимә Мөхлисова пәйда булды. Бая аны көткәннәр булса кирәк. Хәлимов аны шул кеше дип саташтырган, мөгаен.

Савымчы тын гына Гөлфия янына килеп басты.

— Син шуны аңла, Ленар.— Башлык тагын аңа мөрәҗәгать итте.— Үткәрә алмасак, райкомга да, сиңа да хурлык. Әйдә җыелышны ачуга сүзне үзеңә бирәбез. «Сайласагыз кулга-кул тотынып эшләрбез»,— диген. Гомумән, бу яктан сине өйрәтеп тору кирәкми, ситуацияне үзең аңлыйсың.

— Кызганыч,— диде Сафин беравык уйланып торгач,— минем салпы якка салам кыстырып кына максатка ирешеп булмый.

— Нәрсә, зал каршына чыгып басарга куркасың мәллә? — Хәлимов аның горурлыгында уйнап карарга булды. Моны ул, аптыраган үрдәк арты белән күлгә чума дигәндәй, башка чара тапмаганга тәкъдим итте.

— Эш минем курку, курыкмавымда түгел, Хәким Нурович,— диде Сафин, көттереп тормастан.— Бүгенге шартта ул хәләт узды. Мин, алтын таулары вәгъдә итсәм дә, халык: «Председательгә керү өчен ничек тырыша»,— дип кабул итәчәк. Мин алдан вәгъдә өләшмим, күрәләтә үземне андый кыен хәлгә дә куя алмыйм. Икенче ягы да бар: минем чыгыш хәлне тагын да катлауландырыр гына.

— Ленар дөрес әйтә,— дип куйды Әхмәдулла Хаҗиевич.

— Менә тамаша! — Хәлимов урыныннан торып китте.— Районда ун ел эшләп, мондый хәлгә тарыганым юк иде әле.— Ул бүлмә буйлап арлы-бирле йөренеп алды. Борчылуы йөзенә чыккан иде. Кысан урында килеп сарышлый Гәрәев каршына туктады.— Йә, тупиктан ничек чыгабыз. Давай, юлны тап.

— Минемчә, хәзер күп сүз урынсыз. Төпле фикер әйтә ала торган берәү генә чыгыш ясасын. Сүзенә халык ышанырлык, авторитетлы иптәш кирәк, әлбәттә.

— Бу дөрес фикер,— диде беренче җанланып һәм шундук Харисовка борылды: — Йә, кемне бирәсең, Гамир?

Парторг та тоткарлыксыз җавап бирде:

— Нургаяз Мәүлетов сөйләсен менә, башкалар чыгыш ясады инде. Мактаулы механизатор.

— Кит аннан! — Мәүлетов, кызуланып, кулын ук селтәп җибәрде. Тик шунда ук сабырланып дәвам итте: — Мин Ленар яклы. Ләкин монда безнең эше орды-бәрде сүзе белән генә булмый, башы эшләгән кеше кирәк.

— Ә кемнән була?

— Моны минем хатын булдыра алырга тиеш,— диде Сәйфетдинов. Барысы да карашын аңа борды.

— Чынлап та, ул булдырыр.— Сораучы булмаса да, Мәүлетов тә фикерен белдереп куярга ашыкты.

Бүлмәдәге төп хуҗа моны ничек кабул итүе әле билгесез булса да, барысы да иркен сулап куйды. Бу секретарьның да игътибарыннан читтә калмады.

— Кем ул? Кайда? Нинди кеше? — Хәлимовнең коткаручыны тизрәк күрәсе килде, җавап та алып тормастан, кискен итеп боерды.— Хәзер үк табып китерегез!

— Монда ул. Менә! — Харисов Гөлфиягә төртеп күрсәтте.— Укытучы, пропагандист. Чынлап та халык аңа ышана.

— Так, так.— Хәлимов ашыгып тәкъдим ителгән хатын каршына килеп басты, аны баштанаяк күздән кичерде.— Булдырырсыңмы, Гөлфия сеңел?

— Әзерләнмәгән килешме? — Шактый көттереп, ниһаять, сорап куйды ул.— Уйларга кирәк.

— Шулай...— Ханымның нигездә ризалык бирүен күреп, җитәкче йомшый төште.— Әйдәгез, утырыгыз әле, бергәләп киңәшик.

Ул әңгәмәдәшенә генә эндәштеме, әллә бу башкаларга да кагыла идеме, ачыклап торучы булмады, күпмедән бирле хәрбиләрчә үрә катып басып торучылар аның теленнән ычкынганны файдаланып калырга ашыктылар, кайсы кая артын төртте.

— Минемчә, иң алдан без Сәйфетдинов белән үз кандидатураларыбызны алырга тиешбез,— дип башлады Харисов.— Ялгыз калса, Ленар Салихович үтәр.

— Юк, юк, алай булмый.— Гөлфия беренче тәэсирләрдән соң фикерен туплап өлгерде, аңа каршы төште.— Сез чыгып белдердегез бит, халык аны исәпкә алмады. Башкача кирәк.

Аның фикеренә кушылучылар табылды.

— Тавышланмагыз әле.— Секретарь, таләпчән укытучы кебек, аларны тиз туктатты.— Гөлфия сөйләсен.

— Алай ясалма килеп чыга,— дип, фикерен ялгады хатын.— Халыкны башкача ышандыра алсам гына.

Беренче секретарь парторгка карады:

— Халык таралганчы башларга кирәк.

Харисов залга ашыкты.

* * *

Тәнәфестән соң да, Харисовның кисәтүләренә, тамак кыруларына карамастан, залда тынлык урнашмады. Колхозчылар берсенберсе уздырырга тырышып, үзара бәхәсләшә бирде. Парторг шул ыгы-зыгы арасында Гөлфиягә сүз бирелүен хәбәр итте.

Гөлфия җәһәт урыныннан торды һәм мөнбәргә таба атлады. Залдагы берәүгә дә карамаска тырышты. Йөрәге, дулкынланудан, леп-леп тибә, туфля үкчәләре идән такталарына бәрелеп шак-шок тавыш бирә, шул аваз колак барабаннарында яңгырый. Үзе өчен үтә җаваплы минутлар җиткәнен сизсә дә, башында һаман төпле бер фикер дә юк әле. Бу, билгеле, күңелне куркыта, икеләндерә.

Зал аңа илтифат итмәде, шаулаша, һәркем үзенекен турылый бирде. Ул бер нәрсәне ачык аңлады: иң элек залдагы тавышны туктатырга, тәртип салырга кирәк. Шунсыз максатка ирешү турында уйларга да ярамый, сүзләре стенага атылган борчак шикелле генә булачак.

Чыгышын шул, күңелендә туган борчулы хисләрдән башлады.

— Иптәшләр! Мине, укытучы буларак, бер нәрсә бик борчый. Монда күпме укучы — безнең балаларыбыз утыра.— Бу чынлап та шулай иде. Беренче секретарь алдында зал тулы күренсен өчен, Харисов күрсәтмәсе нигезендә, мәктәп бакчасына эшкә килгән өлкән сыйныф укучыларын да китереп утырттылар. Болай да шук үсмерләр клубтагы шау-шуны теләп куерта, шуннан тәм таба. Ул шуны күздә тотты.— Аларга нинди тәрбия бирәбез? Кем ни тели — шуны эшли: урыннан кычкыра, кул чаба, авылдашына сөйләргә ирек бирми. Безгә балалар ияр*ә*: аяк тибә, сызгыра, әти-әнисен авыз да ачтырмый, шулай трибуна артыннан куып төшерә. Шулар хакында уйлаган кеше юк, балалар тәртипсез, дип зарланучы күп. Үзебез үрнәк күрсәткәч, аларга нинди үпкә?! Моның ояты, беләсегез килсә, беренче чиратта, үзебезгә. Шуны аңларга вакыттыр инде.

Кайнарланып, бер сулыштан бушатып ташлады ул бу фикерләрен. Яңаклары алсуланып чыкты, муен, чигәләрендә тир тамчылары пәйда булды. Гайрәт белән әйтелгән ялкынлы сүзләре, һава дулкыны белән кушылып, мәдәният йортының иң аргы почмакларында да көчле яңгырады. Залдагылар моны — педагогның кичерешләрен, үзләренең хаталарын да тиз аңладылар, әле сәхнәгә, әле үзара карашып алгаладылар, акрынлап тындылар. Моны күреп, ул күкрәгән тутырып бер тын алды, яңакларына төшкән чәчләрен колак артына шудырды, үзе залдан күзен алмады. Барысының да игътибары сәхнәгә юнәлгән.

Аның беренче бурычы үтәлде. Бу хәл аңа куәт өстәде, илһамланып дәвам итте:

— Колхоз члены булмасам да, коммунист буларак, председатель мәсьәләсе буенча үз фикеремне белдерәм. Монда бу постка өч кеше тәкъдим ителде. Мин аларның өчесен дә яхшы беләм...

Хәзер, бер эзгә төшкәч, алар турында иркенләп сөйләргә мөмкин иде, ләкин ул сүзне кыска тотарга кирәген бер мизгелгә дә исеннән чыгармады. Халык арыган, ачыккан, ә ачның ачуы яман, шуңа сузмыйча, иң кирәклесен һәм мөһимен генә җиткерүне мәслихәт санады.

— Беренче кандидат — үз ирем. Ул — дипломлы инженер, белеме җитәрлек, ләкин холкы белән бу эшкә бармый.

Аның соңгы сүзләре колхозчыларга ошап җитмәде, бер мәлгә тынып торган халык, умарта оясыдай, янә гөж килә башлады.

Гөлфия үзенең бу чыгышы турында авылдашлары ни уйлаганны чамалый иде. Ул райком кушуы буенча сөйли. Хәлимов, билгеле инде, үзе теләгән кешесен сайлату ягында. Шуңа күрә аны яклауны кандидатларның берсенең хатынына йөкләткән. Ул башкаларны, шул исәптән ирен дә кире кагып, читтән китерелүчене үткәрергә тырыша. Ире булдыра алмавы хакында белдерүе моңа дәлил булып тора.

Аның бу ниятен сизеп алган халык «баш күтәрә» — ялт-йолт карана, тавышлана башлады.

Укытучы иң җаваплы минутлар җиткәнен йөрәге белән тойды. Ул аларны тынычландыра алмаса, башкалар кебек, үзен дә мөнбәрдән «алкышлап» озатачакларын, каш төзәтү урынына күз чыгарасын, аңа өмет баглаганнарның ышанычын аклый алмасын, рәис сайлауны тагын да катлауландырып җибәрәсен чамалады. Куркуыннан тәннәре чымырдады, миендә берсен-берсе куа-куа төрле фикерләр дә йөгерешә. Ул шулар арасыннан иң кирәклесен, бәлки әле бердәнберендер сайларга тиеш иде.

— Мине дөрес аңлагыз, иптәшләр! — Ихласлыгын күрсәтү өчен сул кулын йөрәге турына куйды.— Минем дә председатель хатыны булып дәрәҗәле йөрисем бик килә. Ләкин, җан тели дә ястык җибәрми,— диләр. Тормышка аек акыл белән карарга кирәк. Аның булдыра алмаганын сез үзегез дә яхшы беләсез, ул — юаш.

— Монысын дөрес әйтәсез, сеңел.

Гыйлаҗ абый шулай дип кычкырды. Аны хуплап, кул чабучылар табылды. Аның җаны табанына төшеп китте: сәхнәдән «олылап» озатулары мәллә?

— Ирек бирегез кешегә, безнең файдага сөйли бит,— дип кычкырды Кадыйр абзый,— шау-шуны күмәрлек итеп.— Фикерен әйтеп бетерсен.
Моны үз араларындагы кешедән ишеткәч, колхозчылар ана колак салды.
— Гамир Садыйкович — авылдашыгыз, бергә эшлисез, аны миннән яхшырак беләсез, шуңа аның турында сөйләп вакытыгызны алмыйм. Тагын бер кандидатка — Ленар Салиховичка хас һәм алдагы иптәшләр тукталмаган аның кайбер сыйфатларына гына кагылып узам. Ул беркайчан хәйләләми, күзеңә карап турысын әйтә: йә «бар», йә «юк».
— Шулай кирәк тә! — дип кычкырды бер агай. Күрше бригададан бугай.— Мостафа кебек алдап йөрткәнче, лучше «юк» дисен.
Залда бәхәс кубарга торса да, куркыныч узды, халыкта кызыксыну уянды. Аңа форсатны кулдан ычкындырырга ярамый, ашыгырга кирәк. Колхозчыларның түземе һәр минут өзелергә мөмкин.
— Былтыр җәй мәктәп эшләре буенча ронога барган идем. Мөдир кабинетына Сафин килеп керде. Председатель урынына калган чагы икән. «Коммунизм юлы» колхозының Кызыл Яр поселогында алты бала калган башлангыч мәктәпне ябарга җыенганнар. «Җиде яшьлек баласын чит авылга озатып килгән колхозчының эшкә күңеле ничек ятсын? Бу авылның бөтенләй таралуы дигән сүз бит,— дип, мөдиргә чат ябышты. Шуннан соң ниләр булгандыр — мин белмим, ләкин анда мәктәп бүген дә эшли...
— Әйе, мин моны әйтергә оныткан мын, Гөлфия сеңел бик дөрес тотып алган.— Беркемне кисәтми генә Хәлимов урыннан кушылды: — Ул чакта Сафин миңа да нәкъ шул мәсьәлә буенча керде, шул дәлилләрне китерде. Мин мәктәпне яптырмаска күрсәтмә бирдем.
Гөлфия, район башы сүз алгач, бүленеп калды, аның сөйләп бетергәнен көтте. Моны күреп, Хәлимов аңа эндәште:
— Дәвам итегез, сеңел.
— Сафинның ронодагы сүзләре турында бергәләп уйлап карыйк әле. Рәис урынына вакытлыча калган, сез әйтмешли, анда да «килмешәк кеше», колхозчының кайчан күңеле эшкә ятуы, баласы, ул яшәгән авылның киләчәге өчен дә борчылган. Сүзен дә иткән. Безнең Зәңгәр күлдә мәктәпне япканда җитәкчеләребез шул хакта уйлап караса, поселок бүгенгедәй ташландык хәлгә калмас иде. Безнең колхозга да шулай кеше турында кайгыртучы җитәкче кирәк. Мин Ленар Салиховичның шундый буласына ышанам. Тагын бер нәрсәне өсти алам. Ул — энергияле, белемле, үзенә һәм башкаларга да таләпчән. Эшли һәм эшләтә ала торган кеше.
Зал аның белән сөйләшә башлады.
— Безнең Гөлфия молодец ул,— диде тагын берсе.— Кемнең кемлеген йөзенә карап, ярып сала.
— Дөрес әйтәсең, Ислам, югыйсә ничә сәгатьтән бирле саламнан кибәкне аера алмый утырабыз бит менә.
Зал тагын шау-шуга күчте. Сәйфетдинова күңелендә булганнарын бушаткан иде инде, залны күзәтеп тоткарланды.
— Син сөйләгәннәр безнең файдага.— Зыятдин карт, бүген инде ничәнче мәртәбә, торып басты.— Честно гына тагын бер сорауга җавап бир әле, сеңел: Сафин яшь кеше, рәис итеп сайланса, Мостафа кебек, борынын күтәрмәсме? Бездән үч алмасмы?
— Мин фикеремне әйттем, Зыятдин бабай. Аны авылдаш, классташ буларак та беләм. Ул юаш түгел, алдыңда турысын әйтә, арттан сөйләргә калдырмый. Тыйнаклыгы бар, кешегә кешечә карый.— Ул тукталып калды, төшәргә җыенды, ләкин шулчак тагын бер фикер исенә төште.— Тагын бер нәрсәне игътибарга алуыгызны үтенәм. Яңа гына клубның арткы бүлмәсендә сүз булды. Сорап килмәгән, сайламасак үкенми, канәгать булып кайтып китәчәк, моны ул яшермәде дә. Шуның өчен җыелышта да сүз сорамый. Югыйсә, мин ышанам, сезнең, безнең белән уртага

салып сөйләргә сүз табар иде. Бу уңайдан мин үз фикеремне кабатлыйм: председательгә тәкъдим ителгәннәр арасында ул белеме, сәләте, кешелеклеге ягыннан да иң лаегы. Сайламасак, соңыннан үкенмәбезме икән?!

Зал уйлана иде. Гөлфия, чыгышы тәмам икәнен сиздерү өчен, президиум ягына күз салды. Сафин, күзләрен кысып, чыраен бозып, аңа карап тора иде. Карашлары кисешкте, ул, куркып, йөзен читкә борды.

— Җәмәгать, мине тыңлагыз әле! — Зыятдин карт һаман басып тора иде. — Татарга салма ашагач акыл керә, диләр. Гөлфия сеңел китергән мисал чынлап та уйланырлык бит. Сафин иптәшнең Кызыл Яр мәктәбен саклап калуы турында әйтүем. Читтән килсә дә, халыкны чит күрмәгән, димәк. Мин аның мондый икәнен белмәгән идем. Минемчә, безгә кирәк кеше булып чыга иптәш Сафин. Гөлфия — акыллы хатын, кеше сүзенә генә иярми, үз башы белән эш йөртә, кирәксә-кирәкмәсә мактамый да. Мин аңа тулысынча ышанам. Яшь рәис акыл туплап өлгергән күренә. Мин алдан аңа шикләнеп караган идем, әмма, менә шулай аңлатып биргәч, фикеремне үзгәртәм, иптәш Сафинны яклаячакмын. Башкаларны да аңа тавыш бирергә чакырам.

Ул арада сугыш инвалиды, тома сукыр Сөнгатулла абзый күтәрелде.

— Гөлфия сеңел, мин бая яшь рәискә каршы тавыш биргән идем. Инде миңа нишләргә?

— Председатель сайланмаган бит әле. — Сөенеченнән хатынның авызы колак артына җитте. — Сайлау вакыты җиткәч, аны яклап кул күтәрерсез.

— Алай икән, тавышка куйдыр, — диде инвалид. — Без Сафин яклы.

Ниса апа, хатыны, аның җиңеннән тартты. Ире башын иде, ул аңа ашыга-ашыга нидер аңлатырга керешкте. Гөлфия, күпмедер вакыт шул мәзәк хәлне күзәтеп басып торды. Кайда икәнен хәтерләп, төшәргә җыенган иде, сәхнә ягыннан фамилиясен ишетеп, сискәнеп китте, тавыш килгән якка борылды.

— Иптәш Сәйфетдинова. — Эндәшүче беренче секретарь иде. — Тавышка куйдыр, тавышка, — диде ярым пышылдап.

Укытучы бер мәлгә югалып калды. Аптырамаслык та түгел: ул гади чыгыш ясаучы, җыелышны алып баручы вазифасын башкарырга вәкаләте юк, моның ярау-ярамавын да белми.

— Иптәш Сәйфетдинова, — Хәлимов, аның хәләтен чамалап, инде бөтен залга ишеттерерлек итеп кабатлады: — Колхозчылар сездән Сафинны председатель итеп сайлау мәсьәләсен тавышка куюны сорыйлар — сузмагыз.

Ниһаять, Гөлфия аның тимерне кызуында сугарга ашыгуын аңлап алды.

— Иптәшләр! Кем дә кем «Таң» колхозы председателе итеп иптәш Сафинны сайлыйбыз ди, шуларның кул күтәрүләрен үтенәм.

Үзе, мөнбәр артындагы кичерешләре, дулкынланулары белән барын оныткан иде, тавыш бирергә хокукы булмаса да, беренче булып кулын күтәрде. Бу юлы Сафинны зур күпчелек яклады. Кайсыдыр, президиумдагыларның берсе, кул чаба башлады. Зал аны күтәреп алды.

Халык тынычланып өлгергәнче үк, яңа рәис парторг колагына нидер пышылдады. Бу шунда ук залга билгеле булды, Харисов, тамагын кыракыра, аңа сүз бирелүен белдерде.

— Җыелыш озакка сузылды, сез дә ардыгыз, күбегезне эш тә көтә. Шуңа күрә, эшкә кагылышлы сүзләр күп булса да, бүген калдырып торыйк. Колхоз белән танышкач, урак алдыннан бригада җыелышлары үткәрербез, шунда алар хакында конкрет сүз алып барырбыз.

Ул бик кызу тотты. Залга күз сирпеп алды да шул ук кызулыкны дәвам итте:

— Әмма сезне бик борчыган, һәр чыгыш ясаучы телгә алган ике мәсьәләгә карата үземнең фикеремне бүгеннән үк ачыклап узуны кирәк саныйм. Мал азыгы белән эш болай. Сез минем исемне төрләндергәндә

исәпләп утырдым. Җиребез күп, колхоз, авыл малларына да артыгы белән житә. Алдан җыеп алабыз, кыр эшләреннән бушагач, эскерттән һәркемгә бүләбез.

— Һәркемгә кемнәр керә инде? — дип сорады залдан берәү.

— Механизаторлар, терлекчеләр керәме?

— Мин ачык әйттем шикелле,— диде Сафин залга карап.— Алар да, укытучылар, пенсионерлар да керә. Элеккечә кырда салам яндырулар булмый, билгеле. Утын белән кыенрак. Алдан һәр йортка бер йөк кайтарабыз.

— Ә чират ничек? — дип сорады Сөнгатулла абзый.— Безгә, инвалидларга, буламы?

— Бүгенге көндә кемнең ягарына бер дә юк — шуңа иң алдан,— диде рәис, көттермичә.— Гомуми чиратны бригада җыелышларында үзегез раслыйсыз. Утын кыенлыгыннан чыгу өчен безгә бүгеннән үк баллонлы газ кертү эшенә керешергә кирәк.

— Алдан ук шуларны әйткән булсагыз, валлаһи, үзегезне әллә кайчан сайлап куйган булыр идек,— диде Сөнгатулла абзый, һәркемгә ишетелерлек итеп.

— Ышаныч күрсәтеп сайлавыгыз өчен рәхмәт. Мин аны аклау өчен бар тырышлыгымны куячакмын.

Ул, җәһәт атлап, урынына барып утырды. Колхозчылар парторгның белдерүләрен тыңлаган арада, Хәлимов, чак иелеп яңа рәис колагына пышылдады:

— Иртәгә актив җыелышыннан соң миңа кер. Партбилетыңны алып китәрсең.

* * *

Колхоз рәисе яныннан чыккач, Назыйм иркенләп тын алды, тәмәке кабызды һәм тәмләп тартырга кереште. Теге, икесе дә егет чагындагы бәрелеш хакында Ленар бәлки оныткандыр да инде, ә ул күпме курку кичерде бүген. Хәзер генә исенә алды: аның Назыймга үпкәләр урыны да юк, Гөлфияне үзе ташлады ич.

...Солдаттан кайткан Назыйм түгәрәк йөзле, зәңгәр күзле, уймак авызлы Гөлфиягә беренче күрүдә үк гашыйк булган иде. Үтә чибәр кыз чая да булып чыкты, танышкач ук кисәтеп куйды: егете бар. Назыйм моны игътибарга алмады, бию кичәләреннән, кинодан чыккач, тагылып аны озата торган булып китте.

Тәкәббер, горур кыз белән ике арадагы элемтәләрне саклауга җайлы сылтау табылды. Бер шимбәдә Гөлфияне, үтенеч буенча, туган авылы Каенсарга озатып куйды. Икенче вакыт, чакырганны көтмәстән, дәресләре беткән җиргә килеп җитәргә күнекте.

Ленарны, солдатка киткәнче, беренче тапкыр читтән генә күрде Назыйм. Бәйрәм тирәләрендә ялга кайткач, Гөлфияне каршыларга килә торган иде ул. Андый көннәрдә кызның кош тоткандай, канатланып йөрүен күрә иде. Егете янында чагында Назыйм аларны борчымады, икенче кавалер булып тагылмады. Бу хакта аны Гөлфия — әллә юри, әллә чын — кисәткәне бар: егете көнче...

Ул, бәрелеш булган көнне, Гөлфияне авылга атна арасында озатты. Ни өчен ашыгыч кайтуының сәбәбен яшермәде кыз. Ленар иртәгә солдатка китә, аны озата барырга ял алган икән.

Гөлфияне өйләре турында машинадан төшереп калдыргач,— ул чакта Назыйм баш инженер, иске булса да машинасы бар иде инде — күрше колхоздагы хезмәттәше янына сугылды. Ансы күршесен, гадәт шундый, буш кул белән генә җибәрмәде, кибеткә барып килде. Телләре язылып китте, шактый вакыт узып өлгерде.

Ул караңгы төшкәч кенә кайтырга чыкты. Гөлфияләр яныннан узганда берсекөнгә аны алу өчен кайчан килергә икәнен сорарга керде.

Гөлфия, аны күргәч, бер мәлгә өнсез торды.

— Керергә ярыймы, Гөлфия? — диде ул кызның хәләтен чамалап.

— Кергәч ярый инде,— дип төрттерел алды ул.

Әлегә кадәр Назыйм аларга чакырганда да керми торган иде. Кәефләнеп алгач, кыюланып китте. Кызның салкын каршылавын да игътибарга алмады, әрсезләнеп барды.

— Шулай мәрхәмәтсез булырсың икән. Сусадым, су гына бир әле?

— Утыр! Чәй эчкәч китәрсең.

— Бик кыстасаң, эчми дә булмас.— Ул инде чама чиген узганын үзе дә сизде, ләкин теле кытыклый бирде. Кызның чәнчеп алуы да тәэсир итмәде, өстәл янына килеп утырды.

Гөлфия аңа чәй агызып бирде. Әнә шул арада Ленар килеп кергәнне алар сизми дә калдылар.

— Чәйләрегез тәмле булсын! — диде егет.

— Бергә-бергә булсын,— диде Гөлфия.— Уз, утыр, Ленар.

Егет тә кыстатып тормады. Кыз аның алдына да чәйле чынаяк куйды.

— Кунакка килдегезме, Назыйм? — Ленар аңа сөзәргә теләгән үгез булып карады. Әңгәмә куркыныч төс алу ихтималын тоемлап, Гөлфиянең йөзе кызарып чыкты.

— Синең кебек мосафир.— Аның да мин-минлеге уянды.— Шуннан ни әйтерсең?

— Монда, Гөлфия алдында, аңлашып булмый,— диде Ленар.— Әйдә, чыгып сөйләшәбез.

— Беркая чыкмыйсыз, Ленар.— Гөлфия кабынып килгән бәхәскә чик куярга теләде булса кирәк.— Сүзегез бар икән, монда сөйләшегез. Назыйм хәзер китә.

Назыйм айнып киткәндәй булды. Ул сөеп йөргән кызының таләбен үтәргә дә әзер иде, әмма Ленар туктатты.

— Хәзер Назыйм беркая да китми.— Ул урыныннан сикереп торды, кашын-күзен җимереп бер аңа, бер Гөлфиягә карап алды.— Мәсьәләне хәл итмичә беркая китми.

— Дөрес әйтәсең,— диде Назыйм да. Ленарның бу хакта сүз кузгатуын урынлы санады. Аның күңелендә дә сары су шактый җыелган иде. Гөлфиянең, ике ел артыннан йөреп, йөрәктә өмет чаткысы уятырдай бер җылы сүз дә ычкындырганы юк; үзе араны да кырт кисми — Ленар югында озаттыра; вальс бииләр, кино карыйлар. Шуңа Ленарны куәтләде: — Араларны ачыкларга бик вакыт.

— Йәле, бире кил,— дип катгый боерды Ленар һәм кулы белән урын күрсәтте. Гөлфия аның әмерен карусыз үтәде, икесе каршына мичкә килеп сөялде.— Хәзер барысын ачыклыйбыз.

Гөлфия өнсез басып торды. Горур, егетләр белән үзен гел һавалы тотарга күнеккән кыз рухи халәте белән мондый сөйләшүгә әзер түгел, аның өчен өстенә тау ишелгән кебегрәк иде. Шулай үзеннән сорамый-нитми, теләгән белешмичә ике егет аның язмышын хәл итәргә кереште. Кыз моны башына сыйдыра алмый иде, шикелле. Болай эредән кубып сөйләшүгә ул гына түгел, Назыйм да тотынмас иде, әмма Ленар кузгаткач, моннан читтә кала алмады. Бу минутта башкача үзенә ни эшләргә кирәген, тиешен бүген дә тәгаенли алганы юк әле.

— Йә, кайсыбызны сайлыйсың, сайла! — диде Ленар дорфа гына.

Назыйм килеп кергәч үк, яшьләргә комачауламас өчен, Гөлфиянең әнисе Фәһимә апа, бәйләвечләрен тотып, зал якка чыккан иде. Бу якта гадәттәге сөйләшүләр генә бармаганын ишетеп, ишекне ачты. Ленар — ул кай арада ишек янына барып өлгергәндер, Назыйм күрми дә калды — дорфа гына этеп, аны кире бүлмәсенә кертеп җибәрде, шапылдатып ишекне япты. Гөлфия куркуыннан дер-дер килә иде, әнисен яклап сүз дә әйтә, урыныннан да кузгала алмады.

Кызның хәле мөшкеллеген сизеп торган Назыйм, аны бу газаплардан тизрәк коткару өчен, үз сүзен тизрәк әйтүен кирәк тапты:

— Мин аңа бүгеннән өйләнергә риза. Гөлфиягә бу күптән билгеле.

Чынлап та, ике араларында бу хакта байтак сөйләшкәннәре бар иде, гәрчә кыз, әдәп белән генә, кире кага килде: әле укыйсы бар, кияүгә чыгарга җыенмый, янәсе...

— Юк, юк.— Гөлфиянең күзләреннән яшь атылып чыкты.— Юк, Назыйм, сиңа кияүгә чыгарга мин мәңге риза түгел.

Ул чакта хәзерге хатыны моны чын күңеленнән әйттеме, кызулык белән ычкындырдымы, әллә яраткан егете алдында акланырга тырышуы булдымы — анысы бүген дә сер. Сорап оялтырга йөрәге җитми. Чынын барыбер әйтмәс тә иде.

— Турысын әйт, Гөлфия! — Аның сүзләре Назыймны нык гарьләндерде, күңелендә пыскып кына булса да сакланып торган өмет чаткыларын да сүндерде. Хәзер аның өчен югалтасы югалган инде, бәхәсне куертып җибәрде.— Ленарны яратасың, димәк?..

Ике егет арасында калган кызның курку кичергәнен Назыйм күреп тора иде. Ул көндәшләрне тизрәк тынычландыру, мөнәсәбәтләрне ачыклау өчен «әйе» дигәнне белдереп, башын кагып куйды.

— Телеңнән әйт — кайсыбызны? — дип боерды Ленар.

— Сине яратам, Ленар,— дип, Назыйм алдында танырга мәҗбүр булды кыз.

Назыймның да гайрәтләнеп җиткән чагы иде. Күңелен хурлану хисе биләп алды:

— Алай булгач, син өйлән,— дип китереп куйды.

— Юк, юк, мин сиңа чыга алмыйм, Ленар,— диде кыз ашыгып.

Ул минутларда аның моны ни өчен әйткәнен тикшереп, ачыклап торучы булмады — ярсулары баштан ашкан иде. Хәзер, еллар үткәч, уйлап куя: Гөлфия моны иртәгә солдатка китә торган егеткә чыга алмавын белдерү өчен әйткән булырга тиеш. Моңа бүтән төрле аңлатма юк иде.

— Юк икән, бу йорттан икебез дә китәбез.— Ленар ишекне терәп торуын ташлады, искәрмәстән аның җиңеннән тартты. Назыйм моны көтмәгән иде, чайкалып китте, кулы Ленар чынаягына кагылды. Ансы тәгәрәп идәнгә төште, ватылды.— Әйдә, Назыйм...

* * *

Ул кич күңелсезлек белән тәмамланды. Чыккач алар нык якалаштылар: Назыйм көндәшенең борынын канатты, күз төбенә тондырды; Ленар аның бер тешен сындырды. Әмма нәкъ шул кич аның файдасына тәмамланды, бәхетенең башы булды. Ленар шул кичтән Гөлфияне ташлады, төп көндәше юлдан читкә тайпылды. Ләкин хәзер, кулында киң мөмкинлекләр булгач, Назыймнан үч алмасмы? Бүген булмаса иртәгә, берничә айдан, берничә елдан соң?..

Ул күңеленнән моңа күпме вакыт узганын исәпләп чыгарды. Тугыз ел үткән икән. Ленарның ачулары басылырга тиеш. Үзенең хатыны да чибәр: аны ярата, ихтирам итә, дип, сөйлиләр.

Ләкин, теләсә ни булсын, аларның икесенә бер түбә астында эшләве кыен. Дөрес, Ленар монда озак эшләргә җыенмый, имеш. Колхозны аякка бастырса, Хәлимов аны җибәрергә ризалашкан, диләр. Тик болар — кеше сүзе, имеш-мимеш кенә ич.

Шактый көттереп килгән Нургаяз, күрешә дә, тәкъдим иткәнне көтмәстән, янәшәдәге урындыкка төртелде. Урындык, центнердан артык йөк баскач, үзенчә шыгырдап алды.

— Ленар эшне колачлы җәелдерергә исәпли. Нидән башларга да белә: кирпеч заводын салуга килү белән кереште. Төзелеш материалы

үзебездә булгач, эш барачак. Аның планнар зурдан, берсе артыннан берсе исәпләп куелган, тик аны монда озак тотмаслар,— диде ул.

— Нигә?— Назыйм белмәгәнгә сабышты.— Алай җәелдерә алса, аңа юл ачыла гына.

— Монда күп тормый ул. Югарырак күтәрүләре бар. Аннан бигрәк Казанга, институтка китүе мөмкин. Ул яңа, әле беркайда үстерелми торган бодай сорты чыгару белән җенләнеп яши. Өч елдан соң Хәлимов җибәрергә вәгъдә иткән.

— Ул хакта минем дә ишеткән бар.— Инженерның эченә җылы йөгерде. Бер елга куян тиресе дә чыдый, диләр. Өч елы да санаулы вакыт, күпмесе узды да инде, аңа кадәр генә түзәргә була. Эшен тәмам җайга салса, бәлки алданрак та китәр әле.

* * *

— Утка чыдам кирпечләрсез икегез дә минем күземә кайтып күренмәгез.

Кызарынган-бүртенгән баш бухалтер Рабига, председатель кабинетыннан чыгарга ашыкмады.

— Ул балны мин ничек списать итәм?— дип сорады, рәискә туры карап.— Элекке рәис андый эшкә юл куймый иде.

— Ансы сезнең кайгы,— диде Сафин бухалтерга.— Әмма, бер банка бал кызганып, мин утка чыдам кирпечләрсез калуга юл куймыйм.

— Бу закон бозу була. Икебезгә дә шелтә бирәчәкләр.

— Алда шелтәләр күп булыр әле безгә. Шуны исегездә тотыгыз, Рабига апа: аны списать итмәсәгез, креслогыз белән сезнең үзегезне списать итәргә туры килер.

Баш бухалтер күзләрен челт-челт йомып алды. Нидер әйтергә җыена, тик үзен тыеп тора иде бугай.

— Ул балны кем илтә?

— Үзегез поезд белән илтәсез. Командировычныйга исәп тотмагыз — үткәрмим.

— Мин бараммы?— дип кабатлап сорады бухгалтер Сәлмәнова.— Отчетка әзерләнгәндәме?

— Мин аңлаешлы әйттем: кирпечсез күземә күренмисез. Минем күрсәтмәне тагын бер үтәмәсәгез, башкача сөйләшербез. Минем, Талипов кебек, сезнең ризалыкны сорап торырга теләгем дә, вакытым да юк. Ике тәкә башы бер казанга сыймас. Мин берәүгә дә баш өстемнән йөрергә ирек куймыйм. Алай ошамаса, үзегезгә карарсыз. Аңлашылдымы?

Сәлмәнова боларны дәшми генә тыңлады һәм, рәиснең сүзе беткәнен белгәч, тын гына чыгып китте.

* * *

Кабинетына Гөлфия килеп кергәч, Ленар Сафин якынга, утырышлар үткәрә торган өстәлнең бер почмагына, аңа каршы утырды.

— Күренгәнең дә юк,— диде ул үз итеп.— Хәлләрең ничек, Гөлфия?

— Хәлләрне күреп тордыгыз инде,— диде хатын үтә салкынлык белән.

— Алай дисең инде.— Ленар аның кинаясен сизде, әмма күпме еллар узгач, ун ел гел бер парта артында утырган сыйныфташы белән аулакта очрашу минутларында моңа игътибар биреп тормады. Теге җыелыштан соң ук ул шулай бер якыннан торып сөйләшү, аңлашу өчен аны көткән иде, тик үзен сайлаткан элекке дустының аралашырга теләге юклыгын

тоемлаганга, аны чакыртмады, җай чыкканын көтте. Әңгәмәдәшенең бүген дә андый катлаулы, четерекле темага кереп китәргә теләге күренмәвен белсә дә, вакытны кулдан ычкындырмаска, күңелендә туган фикерләр белән уртаклашырга булды.— Бу эштә шулай, Гөлфия: юаш булсаң — басалар, усал булсаң — асалар. Шуларны яхшы белгәнгә мин бу хезмәткә алынмас өчен җан талаштым, классташым тырышып-тырышып шул камытны минем муенга киертте...

Гөлфиянең яңаклары алсуланып чыкты. Ленар аны йомшак сөйләп катыга утырта түгелме? Аның рәислеккә үтүенә ул гаепле булып чыга. Ә ул үзе әлегә кадәр, шома сайлатканы өчен тыштан булмаса эчтән, Ленарны аңа рәхмәт әйтер дип йөргән иде. Клуб мөдире бүлмәсендә әйткән сүзләрен дә тыйнаклыгы билгесе дип кенә кабул итте.

— Нигә? — дип сорады ул кызуланып.— Председатель итеп сайлауга үзегез дә каршы идегез бит. «Сорап килмәдем, әмма, бер тотынгач, хәлдән килгәнчә тырышырмын»,— дидегез. Ялгышканмын икән, гафу итегез.

— Шулай, классташ,— диде Ленар.— Мин килергә теләмичә соң чиккәчә тартыштым.

Хәзер, рәиснең үзен сайлауга карата чын фикерен белешкәч, ашыгычлык белән ясалган кайнар чыгышның хата икәнен аңлады Гөлфия. Тик ул үзен элекке дусты алдында гына гаепле санады. Ләкин тормыш хакыйкате дә бар бит әле. Ул бер нәрсәне ачык белә: Сафин өч кандидат арасыннан иң уңышлысы һәм халык өчен дә иң кирәклесе иде. Шуңа ул аны ихлас күңеленнән чыгып яклады да. Хәзер, бу мәсьәләгә әйләнеп кайткач, үзе өчен мөһим кайбер нәрсәләрне ачыклауны кирәкле санады.

— Сез алай дисез икән, минем Сезгә сорауларым да бар. Тик мин аларны үпкәләмәс булсагыз гына бирә алам.

— Сорагыз,— диде Ленар тоткарлыксыз.— Берне түгел, унны. Безнең арада үпкәләш була алмый. Хәтер калдырырга булса, мин Сезне бу әңгәмәгә чакырмас та идем.

— Дөресен генә әйтегез әле: райком Сезне председательлеккә тәкъдим итеп хата эшләдеме? Шулай саныйсыз икән, мин Сезнең ул фикерегез белән беркайчан килешмәячәкмен.

— Мин үз-үземә бәя бирмим, аны башкалар эше,— диде Ленар.

— Ләкин сорау куелган икән, җавабы булырга тиеш. Сезне бу яктан хаклы дип саныйк.

— Шулай булгач, хата юк, минемчә,— дип ашыгып ялгап китте Гөлфия.— Зур корабка зур диңгез кирәк. Дөрес, сезнең ул эшкә алынырга теләгегез булмавы ихтимал, ләкин райком сәләтегезгә тиң хезмәткә җибәргән икән, мин моны хаклы дип саныйм. Чыны шулайдыр бит?

Рәис башын чайкап куйды.

— Шулаймы, түгелме? Менә бергәләп ачыклау өчен мин үзеңне күптән көткән дә идем инде.

Гөлфия аның бу сүзләрен эчке курку белән кабул итте. Күңеле сизде: алда катлаулы, авыр аңлашу көтә аны. Тик, Ленарның ашыкмавын күргәч, түзмәде, үзе башларга мәҗбүр булды.

— Әйе, мин Сезнең яшьлектә яңа сорт бодай үстерү турында хыялланганыгызны беләм.— Ул инде ике арада бу аңлашуда сүз ни хакында барасын чамалаган иде.— Ә бу хезмәтегезне халык өчен дип санамыйсызмы?

— Күпмедер дәрәҗәдә файда китерәмдер, билгеле.

— Шулай булгач,— диде хатын, җанланып.— Кеше бер эш турында хыяллана, көтмәгәндә икенче тармакта сәләте ачыла. Сезнең белән дә шулай килеп чыгар, бәлки.

— Минем мондагы хезмәтем бер колхоз белән генә чикләнә. Яңа сорт бодай исә, әгәр аны үстереп алалсам, илгә, дөньяга файда китерер иде.

— Тыйнаксыз соравым өчен гафу итегез, Ленар Салихович.

— Ленар. Монда бит беркем юк, ачыктан-ачык сөйләшү генә. Шартым да бер генә: ни уйласаң — шуны әйтеш.

— Мин үзем дә шуны сорамакчы идем әле. Болай булгач, соравымны турыдан-туры бирәм. Турысын әйт әле: дөньяга танылган, дәрәҗәле галим буласың килә инде, гади колхоз председателе генә түгел?

Сафин чыраен сытты. Укытучы да сагая калды.

— Дәрәҗәгә омтылсам, үз җаемны гына кайгыртсам, тормышым да башкача булыр иде. Син тәкъдим иткәнчә, читтән торып физматка керсәм, шул җәйне үк син миңа кияүгә чыгар, бүген бер мәктәптә эшләп, уртак балаларыбызны үстереп ятар идек. Ышанам: бу көнгәчә директор булыр идем, тормышыбыз да житеш булыр иде. Үзем турында гына уйласам, монда килмәс өчен шулкадәр тарткалашыр идемме?! Булган дәрәҗәм җитмәс идеме?! Җил уңаена гына атласам, моннан да югарырак үрләтүләре дә бар. Ләкин мин алай булдыра алмыйм.

— Ни өчен? — Гөлфия Ленарның сүзе бетмәвен, сәбәбен аңлатачагын белеп торса да, үзе дә сизмәстән сорады моны. Аның хисләре ташуын, ихлас күңелдән эчен бушатуын аңлый иде. Ул сөйләгәннәрнең күбесе аның өчен яңалык түгел. Әмма соңгысы, аның үзе өчен дә иң мөһиме — «алай булдыра алмыйм» билгесез иде.

— Беләсеңме, Гөлфия, мин сиңа нинди зур бурычлы.

— Нинди бурыч ул?

— Хәтерлисеңме, мине авыл халкы ничек саклап калды? Үзенә юк чагында, ятимне кызганып, авызыннан өзеп, ипи, бәрәңгесен бирә торган иде. Күптән инде шул бурычны түләр вакыт җитте.

— Алай санасаң, күпләр күпләргә бурычлы инде. — Аңлашу торган саен катлаулана, күңелдә тирәнрәк эз калдыра барса да, хәзер ул аңлы рәвештә әңгәмәне тирәнәйтә, аңа каршы дәлилләр куя барды. — Алар да түләргә тиеш. Ләкин ничек? Ни күләмдә?

— Моңа үлчәү юк. Ләкин шуны онытмаска кирәк: ул чакта игенче безгә намусы кушканча арттырган. Без дә аңа вөҗдан кушканча әҗәтне кайтарырга тиеш. Кем ничек һәм никадәр булдыра ала. Минем үземнең ачлыкка интеккән вакыттагы нәзерем бар: үземне коткарып калучыга, ягъни авыл халкына хезмәткә бөтен гомеремне багышларга. Шуңа, синең белән үпкәләшеп булса да, авыл хуҗалыгы институтына киттем.

Гөлфия җилкәләрен җыерып куйды. Чынлап та, ул чакта ике араларында бу хакта сүз күп булган иде.

— Ул чакта моны нигә сер ясадың инде? — дип сорарга мәҗбүр булды ул.

— Мине дөрес аңламаган булыр идең.

— Ә хәзер аңларлык дәрәҗәгә кадәр үсеп җиттем буламы? — дип, күңелсез генә көлемсерәп куйды Гөлфия.

— Хәзер моның безнең язмышларга йогынтысы була алмый, сукмаклар аерым. Сиңа шул вакытта ни уйлаганымны, нәрсәдән чыгып эш иткәнемне белдерү өчен генә бу.

— Нәзерең үтәлә бит. — Гөлфия Ленарга бүленгән сүзне хәтеренә төшерү өчен ярдәмгә килде.

— Намус төшенчәсен исәпкә алмасаң, шулай, — дип кырт кистереп җавап бирде әңгәмәдәше. — Икенче ягы да бар. Илгә икмәк җитми, капиталистлардан сатып алабыз. Халык саны арткан саен икмәккә мохтаҗлык үсә барачак. Ә мин эзли торган сорт ихтыяҗны тулы канәгатьләндерергә мөмкинлек бирер иде.

— Нинди сорт соң ул?

— Бер орлык күп башак бирә торган сорт.

— Ә андый бодай буламы соң? — дип гаҗәпләнде Гөлфия.

— Булырга тиеш.

— Капиталистлар шулай үстерәмени? Аны үстерү өчен ниләр таләп ителә?

— Үстермиләр. Аның бернинди методикасы да юк, һәр адым саен билгесезлек. Ләкин үз тәҗрибәмнән алынган бер нәрсә бар: яз башы коры килгәндә бодай орлыгы бер башак шыттыра. Соңрак көчле яңгырлар башланса, төптән яңа башаклар чыгара. Урак чорында аптырыйсың: алдан үскәне коелырга тора, ә соңгысы җитлекмәгән. Хәер, анысы икенче мәсьәлә. Димәк, бодай бер орлыктан күпләп башак бирә. Ләкин ни өчен гадәти шартларда түгел, аерым очракларда, аерым шартларда гына бирә? Менә шуны ачыкласаң, бу эш алга китәргә тиеш. Моңа агрономның көче генә җитми, физик, химикларны да тартырга кирәк. Әмма төп көч — агроном. Аларны эзләүгә, үзләштерергә минем гомер генә дә җитмәскә мөмкин. Ә син дәрәҗә турында сүз алып барасың.

Шактый сүзсез утырды Гөлфия.

— Алда бернинди өмет, төгәл нәтиҗәләр күренмәгән үтә авыр ул эшкә алыну нигә кирәк иде инде? — дип сорамый булдыра алмады.

Ленарның җавабы алдан әзер иде.

— Без икмәк кытлыгына торган саен тирәнрәк батабыз. Барыбызны да урманда адашканнар итеп күз алдына китер. Кая барабыз — билгесез. Шулчак мин юлыбызның баткаклыкка илтүен белдем, ди. Ул чагында мин ни эшләргә тиеш? Моны юлдашларымнан яшерергәме? Бу бит — хыянәт. Алар, алар белән бергә үзем дә һәлак булачакмын. Әйтсәм, без туктарга, юнәлешне үзгәртергә йәисә яңасын эзләргә, котылу чарасын күрергә тиешбез. Шул юлны башкалардан алдарак эзләп барам икән — халык алдында йөзем ак, элек миңа бирелгән әҗәтне тулы кайтарам булып чыга. Юк икән — мин сатлык җан.

Ленар тынып калды. Гөлфия башын чайкап алды. Сафинның үз-үзенә шундый кискен, рәхимсез бәясе күңел кылларына нык чиртте. Ленар фикере белән килешми булдыра алмады ул. Һәм тагын бер нәрсәне ачык аңлады. Элек күңелендә гел изге уйлар, ачык максатлар, якты киләчәк кенә күзаллаган яшьлек дусты, алар очрашмый яшәгән елларда, кискен үзгәрешләргә дучар булган. Гөлфия моның сәбәпләрен эзләп карады, тик күңелендә борынлаганнары болганчык су шикелле иде, анык бер фикергә дә килә алмады.

— Күрүеңчә, максатым ачык булса да, шул юнәлештә эш башлый алмыйм, мин бәйле кеше, — диде Ленар аның уйлануларын сизгәндәй. — Үз ирегем белән китә, теләгән җиремдә эшли алмыйм. Институтны тәмамлагач, мәҗбүри рәвештә авылга җибәрделәр. Өч елымны тутырганда гына монда китереп тыктылар.

— Килергә теләмәсәң, ризалык бирмәскә иде. — Үзенең дә моңа турыдан-туры катнашы булган укытучы хатын шуннан артыгын әйтә алмады. Сайлау көнендә аның үзен тотышы аңлашылып җитмәсә дә, моның сәбәпләрен, аның үзенең теләү-теләмәвен тәгаен ачыклау мөмкин булмады, бик ашыгыч иде, җай чыкмады. Хәзер, ул чактагы гафиллеге өчен җавап бирәсе булгач, үзен аклау өчен бердәнбер дәлилгә таянды. — Ризалык биргәнсең бит.

— Ул минем партбилетны сейфка бикләп куйгач.

— Ничек? — дип гаҗәпләнеп сорады Гөлфия. Партбилетны алу партия җыелышы, райком бюросы карары нигезендә эшләнә. Партиядән чыгарсалар, монда китермәсләр иде. Шул фикерләре бергә буталды, ул аларның очын, бәйләнешен тапмады, ачыклау өчен үзеннән ашыгып сорарга мәҗбүр булды. — Үзе генә алдымы? Алай тиеш түгел бит.

— Тиеш түгел нәрсәләр бик күп, — диде Ленар. — Ләкин ул алды да бикләде.

— Ничек булып бетте инде?

— Җыелыштан соң кайтарып бирде. Ләкин бу хәлне үзгәртми, минем партиягә булган ышанычымны арттырмый.

Пропагандист ханым шактый уйланып утырды.

— Партия — чорыбызның акылы, намусы һәм вөҗданы, илебезнең барлык алдынгы көчләрен туплаган отряды. Ул оешканлыгы, бердәм тупланганлыгы белән көчле.

— Ул көчне син, әлбәттә, демократик централизмда: азчылыкның күпчелеккә буйсынуында, югары оешмаларның карарларының түбәндәгеләре өчен мәҗбүрилегендә күрәсең инде.— Сафин боларны киная белән санады, үзе әңгәмәдәшеннән күзен алмады, моны ничек кабул итүен тикшерә торды.— Һәм мин, беләсең килсә, шул таләпләрнең корбаны, ирекле тоткын.

Гөлфия тел кыймылдатырга да сәләтсез иде. Партия эшенә ихлас бирелгән, ул нык ышанган, башкалар өчен үрнәк санаган намуслы коммунистларның берсе авызыннан моны ишетү аны хәйранга калдырды.

— Син ни сөйлисең, Ленар...— диде як-ягына карангалап. Гүя, аларны тыңлаучы бар иде.— Кеше ишетсә...

— Мин кемгә ни сөйләгәнемне яхшы беләм,— диде Сафин рәсми генә.— Серем сыймасына ышанмасам, сөйләмәс идем, чөнки болар минем уйларым, шәхси нәтиҗәләрем генә.

— Синнән моны көтмәгән идем,— диде әңгәмәдәше әзрәк аңга кергәч.— Болай булгач, ничек инде?

— Нәрсә? Ташлап китәр, сине халык алдында уңайсыз хәлгә куяр дип куркасыңмы? — Сафинның тавышында кырыслык, кискенлек ярылып ята иде.— Алай куркырлык булгач, яклый торган кешеңне яхшылап белмәгәч, халык алдында күккә чөеп мактамаска иде, иптәш Сәйфетдинова.— Ул әңгәмәдәшенең куырыла баруын күреп тавышын йомшарта төште, ак тешләрен күрсәтеп елмайган итте.— Бер нәрсәне исегездә тотыгыз: мин килергә теләсәм-теләмәсәм дә, ризалык биргән кеше. Халык ышанычын аяк астына салырга хакым юк, кулымнан килгәннең барын эшләрмен. Моны сиңа сөйләвем ничек килүем турындагы хакыйкатьне җиткерү өчен иде. Моннан соң минем сукмак нинди юнәлеш алыр — вакыт күрсәтер. Мин үзем теләгән хезмәтне башкара алмый торган ул вакытны әрәмгә уздырасым килми, йөкләнгән постта сыныйсым, колхозда хезмәтне оештыруны үзгәртеп карыйсым, теге, алда әйткәнемчә, котылу юлын эзлисем килә. Шуның өчен ахыр чиктә бу хезмәткә алындым да. Хуҗалык итүнең яңа формаларын кертергә исәп. Минем бу сынау, тәҗрибәләрем ни белән бетәр — тәгаен үзем дә әйтә алмыйм. Ләкин бу эшнең файдасын, кирәклеген күреп, аны яклаучылар табылыр дип ышанам. Ничек кенә булмасын, син — шуларны алдан ук белеп торучы бердәнбер шаһит.

Гөлфия кулъяулыгы белән мангаеннан ага торган тирләрен сөртте, яңакларын сыпырды, мамык шәле астыннан шуып чыккан чәчләрен җыештырды. Бер яктан ул канәгать иде. Сафинның колхозга рәис булып килүе халык өчен файда, моны ул үзе, авылдашлары да тоеп өлгерде инде; алда да җиң сызганып эшләргә нияте бар. Шул ук вакытта, икенче яктан, күңелендә җитди шөбһәләр дә уянды. Ленар һаман да буйсынмас бунтарь икән. Бу, бер яктан, файда, үз сүзен итәчәк, куйган максатына ирешү өчен берни алдында да тукталып калмаячак. Тик моның хәтәр ягы да бар. Кызу канлы Ленар йә бик абруйлы җитәкче булып чыгар, йә шул юлда муенын сындырыр...

* * *

Ленар яныннан тирән эчке кичерешләр белән чыкты Гөлфия, өенә кайткач та әлеге сөйләшү тәэсиреннән айный алмады. Ире һәм балалары йоклагач, алдагы көнгә план язарга дип дәфтәрен ачып куйды, тик кулына ручкасын алырга ашыкмады. Әлеге уйларыннан аерыла алмады. Теләмәде дә...

Гөлфия төскә чибәр. Кыз чагында аңа сүз кушучы егетләр аз булмады. Ләкин күңеле Ленарны гына якын итте. Күрше егете, оста гармун-

чы булганы өчен генә түгел. Аңа күз атучы егетләр арасында җыр-биюгә осталар, алтын таулары вәгъдә итүчеләр, колы булырга әзерләр дә күп иде. Ленар вәгъдәләргә саран, төче телләнми, ясалма кыланмый, үзен мескен тотмый. Шул яклары белән аның күңелендә алдан урын алды бугай. Юк, алай гына түгел икән. Аның өчен үзенең дә җаны фида иде. Моны ул очраклы белде.

* * *

...Алар сигезенче классны тәмамлаган җәйдә мәктәптә беренче тапкыр хезмәт бригадасы оештырылды. Кукуруз чәчү кертелеп килә иде. Әлеге бригада «Таң» колхозында шундый бер басуны карарга тиеш иде. Авылдан китмәннәр алып килеп, чүп үләннәрен утарга алындылар.

Көндезге эссе башлангач, Чирмешәндә су кереп, тулай торакка кайтып ял итә торганнар иде. Ул көнне дә, сәгать тулгач, кайтырга чыктылар. Гөлфия, торактагы бүлмәләренә куярга дип, юл буендагы буй урманнан чәчәкләр җыйды, аны кульяулыгы белән урап тотты.

Ял вакытларында, иптәшләреннән күреп, чигәргә өйрәнгән иде. Тәүге яулыгын күңеленә иң якын кешегә бүләк итәргә дип ниятләгән. Шуңа чәчәк атып утырган гөл рәсеме астына: «Истәлек өчен Гөлфиядән» дип язу да төшергән иде.

Аның күңелендә бу яулыкның иясе бар иде инде. Ул аны Ленарга бүләк итәргә тиеш иде. Тик кичә үпкәләштеләр. Гамир аны кинога чакырды: «Бүген клубта Һиндстан фильме булачак, барабызмы, Гөлфия?» — диде җир китмәнли-китмәнли. Моны аның икенче ягында торып эшләүче Ленар да ишетте. «Синең белән бармый ул»,— диде эшен бүлмичә генә.

Гөлфиянең Ленарга җен ачулары чыкты. Гамир белән барырга болай да исәбе юк иде, әмма аның өчен бүтән кеше җавап биргәнгә гарьләнде. Аңа берәр каты сүз әйтергә дә ниятләгән иде, өлгерми калды. «Синнән сорыйдыр шул, көтүче»,— диде Гамир, Ленарның әтисе белән элек көтү көткәнен искә төтып. «Ә син, үзеңнең кемлегеңне онытма: безнең паекны ашап симергән күсе»,— дип кычкырды Ленар. Гамирның әтисе мәктәптә хуҗалык мөдире, укучылар арасында әнә шундый сүзләр дә йөри иде.

Гамир хурланудан бүртенеп чыкты, китмәне белән кизәнде. Ленар да каршы куйды. Тимерләр чыңлады, аның өстенә китмәннәрдән туфрак коелды. Алар, эш коралларын сөңгеләр күк терәп басып тора бирделәр, икесе дә юл бирергә теләмәде.

Кинога кызлар, егетләр бергә бардылар. Егетләр татуланып өлгергән, ике араларына урын да әзерләп куйганнар иде. Гөлфия, юри, алар янынннан үтеп, кызлар арасына кереп утырды.

Кайтканда да Ленар белән сөйләшмәде, Гамир белән генә, юктан сәбәп табып, көлешкәләп алгалады.

Чәчәк җыя-җыя, ул иптәшләреннән артта калган иде, аларны зур күпергә кергәндә генә куып җитте. Бу күперне, язын да сүтмәгәнгә, аннан урман ташучы машиналар йөргәнгә авыл халкы шулай, башкаларыннан аеру өчен, «зур күпер» дип исемләгәннәр.

Күпер уртасына җиткән бере туктала барды. Анда йонлач бер абзый култыкса өстендә, шуннан суга чумарга җыенган. Гөлфия килеп җитүгә, агай кулларын алга сузды, иелде, аяклары белән этелеп аска очты.

Ул да, башкалар күк, култыксага таянып, судан теге абзыйның калкып чыкканын көтә башлады. Моннан суга кадәр унбиш метрлар, диләр. Аска карагач, чынлап та баш әйләнә.

— Букетың бик матур, миңа бүләк ит әле, Гөлфия,— диде Гамир. Өмет итми инде, төче телләнә генә.

— Менә бу абый кебек сикерсәң, букет синеке.

Гөлфия аның моннан сикерә алмаганын белә. Малайлардан берсенең дә сикергәне юк. Ул, Гамирга тапкыр җавап тапканына сөенеп, аңа көлемсерәп карады.

— Әсфат абый десантчы бит ул,— диде Гамир акланып.— Унҗиде тапкыр парашют белән сикергән.

— Булса ни,— диде Гөлфия һәм егетнең акланганын көтмәстән, су өстеннән колач салып йөзеп баручы теге абзыйны күзәтергә кереште.

— Нишлисең? Юләрләнмә,— дигән калын тавыш ишетелде күпер өстендә. Бары берьюлы шунда таба борылып карадылар. Ленар чишенгән инде, култыксага үрмәли иде.

Гөлфия Ленарның ниятен аңлап алды: үзен күрсәтәсе килгән. Хәзер ул култыксага күтәрелә. Исәп белән эшләгән, аның: «Сикермә, Ленар!» — дигәнен көтә.

Ләкин ул моны әйтергә ашыкмады: үзе менгән — үзе төшсен. Хәленнән килмәгәч, әтәчләнеп үрмәләмәсен. Ул әле аны, төшкәч, билгеле, үчекләп, үртәп җанын алачак, кичәге сүзләре өчен дә каруын кайтарачак.

Ленар култыксага менеп басты. Аяклары сизелер-сизелмәс калтырый, менә-менә кире төшәчәк. Ул шуны көтте.

Егет кинәт алга таба авыша башлады, аяклары белән этелде һәм уктай аска атылды.

Ул су астыннан шактый озак чыкмый торды. Малайлар, куркышып, яр буена йөгерделәр. Коты алынган хәлдә кыз да аларга иярде.

Су кырыенда аны сырып алдылар, сораша башладылар. Ул да, этелеп-төртелеп малайлар арасына керде.

— Гафу ит, Ленар. Мин шаяртып кына әйткән идем бит.

— Мин дә шаяртып кына сикердем лә!

Барысы да туйганчы бер көлештеләр.

— Кара, кара, гафу үтенеп кенә котылмакчы,— диде берсе, көлеп туйгач.— Китер әле монда букетны.

Гөлфия букетны Ленарга сузды. Бу минутта аңа булган үпкәсе дә җуелган иде инде, кулъяулыгын да алып калмады...

Алар аннан соң да үпкәләшми тормадылар. Ленар кызу, ул усал, үзенекен итәргә тырышалар иде. Ленар кыз сызган юлдан гына бара торган түгел иде. Урта мәктәпне тәмамлагач та ике араларында җитди үпкәләшү булып алды. Гөлфия, ачлы-туклы студент булып йөргәнче, читтән торып укырга керергә үгетләде. Кияүгә чыгарга да риза иде. Ленар үги әнисе каршына өйләнеп кайта алмый — Гайшә карчык тотмый, кыз ягында торырга да риза түгел — йортка керми. Чит бер авылга китү ягында иде Гөлфия. Егет үзенекен итте, агрономлыкка торып укырга китте, аны Казанга чакырды. Анысына Гөлфия риза булмады — бармады. Туй билгесез вакытка кичектерелде, вәгъдәләр генә торып калды.

Ул солдатка китәсе кичтә тавыш чыкты, тагын үпкәләштеләр. Егетләр чыгып киткәч, кыз чаршау белән бүленгән ятагына капланып, кем гаепле, кем хагын аерып тормастан, туйганчы үкседе. Калган вакытта төн буе урын өстендә ишелде: уңга, сулга, чалкан ятып карады — йокы алмады. Өстенә көтмәгәндә ябырылган хәсрәт турында уйланды да уйланды.

Ленарның көнче икәнен белә иде ул. Бу гадәтен өнәмәсә дә, күңеле аны үз иткәч, кире кага алмый иде, көнчелекне ярату билгесе санады. Кичке ызгыш никадәр зур булмасын, ике араларында килешү булачагын, аның дуамаллыгын гафу итәчәген алдан ук ачыклап куйган иде.

Йокысыз төн узды, таң атты. Ул такта сәкесеннән торды, пәрдә читен ачып, урамга күз төшерде. Күңелгә шом сала торган тонык, шыксыз иртә иде бу. Күк гөмбәзе тоташ кара болыт эчендә, акрын гына көзге салкын яңгыр сибәли.

Башы авырта, йөрәге чәнчи, күңелендә бушлык иде аның. Бөтенесен уйсыз-нисез генә эшләде: күлмәген киде, тузгыган чәчләрен җыештырды. Көзгегә күз салды һәм куркып китте. Бер төн эчендә суырылып төшкән,

шиңеп коелырга җыенган чәчәк шикелле калган. Кыз юынырга чыкты. Шулчак урам яктан җыр, музыка тавышлары ишетелә башлады. Ул, битен аннан-моннан гына сөрткәләп, урам якка үрелде, күзәтергә кереште.

Солдатка китүче яшьләр җырлый-җырлый соңгы тапкыр урам әйләнәләр иде. Иң алдан кыңгыраулы тальян гармунында уйнап Ленар бара. Башкаларга кушылып җырлый да үзе.

Алар турына җиткәч, төркем туктады. Ленар гармунын уйный-уйный алар капкасына юнәлде. Моны күреп, озата йөрүче малай-шалай аңа капкаларны ачарга ташландылар.

— Фәһимә апа, Гөлфия кайда?— диде егет, гармун тавышын баса төшеп.

— Камышлыда.

— Ничек алай?..

Ленар моны: «Ул калырга тиеш иде бит»,— дигәнрәк мәгънәдә әйтте, билгеле. Әмма нәфрәте ташыган әнисе утка керәчин сипте.

— Егете килеп алды...

Тынып калган гармун шыңшып куйды. Гөлфия, курку катыш кызыксыну белән, сак кына алар баскан якка күз сирпеде. Ленар сул кулын тальяныннан ычкындырган, балчыклы аяклары белән лас-лыс басып залга кереп бара. Күз төпләре каралган, яңагында тиресе суелган. Борылса, аны күрәсе иде. Шуннан куркып, ул янә мичкә сыенды.

Ленар ул йоклый торган бүлем чаршавы читен ачып карагач, кире борылды бугай, тагын акрын гына гармун шыңшырга кереште. Ул көчәя, ераклаша барды. Урамнан көчле җыр агылып керә башлады.

— Синең чиккән кулъяулыгың
Минем күкрәк кесәмдә.
Сагынган саен карармын
Кайда гына йөрсәм дә.

Гөлфия бермәл аңын җыя алмый торды. Ул аннан таныш урам көйләренең берсен көткән иде. Ә моның сүзләрен хәтеренә төшерә алмый интекте.

Чү, бу бит аның кулъяулыгы турында! Аңа атап җыр җырлый егет.

И-их! Әгәр моны белгән булса, әнисенең сүзен тыңлап качып кала идеме соң?! Нигә шулай килеп чыкты соң әле бу?! Тукта! Тукта! Әле бит соң түгел. «Киенә идем»,— дияр.— Әни сиңа нык үпкәләгән, шуңа дөресен әйтмәгән»,— дияр.

Юк, ул шуннан артык түзәргә булдыра алмый иде, ашыгып зал якка атлады, аяк астын күрмичә, Ленарның итек эзләрен таптады. Кием шкафын ачып, мамык шәлен, көзге пальтосын алды.

— Син кая?— дип сорады артыннан кереп җиткән әнисе.

— Озатырга,— диде ул телен көчкә әйләндереп.

— Бар шул, бар,— диде әнисе тешләрен кысып.— Кичә алай мыскыллады, бүген болай.— Ул балчыклы идәнгә төртеп күрсәтте һәм өстәде.— Аннан тегеләй үк итеп җибәрер. Үзе ише тиле-миле малай алып калырсың.

Гөлфия кичәдән бирле кайгы, кичерешләрдән арына алмый, башы тәмам каткан, моңа каршы ни әйтергә, ни эшләргә дә белмәде. Киеп өлгермәгән пальтосы иңбашыннан шуып төште, үзе хәлсезләнеп караватына утырды, аннары, үксеп мендәре өстенә үк капланды.

Озата баручылар шул көнне үк кайтарып җиткерделәр: Камышлы юлы аермасына җиткәч, Ленар машинаны туктаткан. Шоферның юл урап йөрмәсен белгәч, машинадан сикереп төшеп, җәяү кереп киткән. Артыннан куып җитеп утыртып алып киткәннәр...

Башта ул Ленарның тиз көндә гафу үтенеп хат язасына шикләнмәде. Берничә хаты килмичә җавап язмаска эченнән карар да биреп куйды. Әзрәк интексен, акылга утырсын. Ә ул, гүя, аның ниятләрен белеп торганмыни, бер хат та язмады. Үги сеңлесе Әнисәнең мәктәптә иптәшләренә сөйләвеннән ишетеп, Казагыстанга әләгүен белде. Өйләренә та-

гын хат, беренче фотосы да килгән иде, ләкин аңа — юк. Көннәр узган саен Гөлфиянең өмете кими барды һәм бервакыт тәмам юкка чыкты.

Ленар солдатка китәсе көнгәчә ул язмышы хәл ителгән санап йөрде. Кияве, ире буласы кеше билгеле иде. Алар Каенсар мәктәбендә үк дуслаштылар. Холыклары аркасында вак-төяк бәхәсләр тугалый торса да, бер-берсеннән аерылуны күз алдына да китермәделәр. Дуслык хисләре торган саен тирәнәя барды, ялкынлы мәхәббәткә әверелде. Шулай еллар буе дәвам итте.

Аралары кинәт өзелгәч, ул киләчәге турында еш уйлана башлады. Шунда гына үзе өчен гаҗәеп бер яңалык ачты. Еллар буе янууларын, көюләрен, сагынуларын, сөюләрен, иркәләшү һәм назлануларын сызып ташласа, яшьлеге буш, шәрә каен шикелле килеп чыга иде. Шуңа аның күңелендә үкенү, рәнҗү, тагын әллә ниләр уянды, егетенә булган үпкәсе кабарды.

Күңелендәге бушлыкны кем тутырыр? Үз-үзенә бу сорауны ул еш бирә, аңа, билгеле инде, җавап таба алмый, йөрәге сызлана. Аның иң курыкканы: хәзергә билгесез егет Ленарны алмаштыра, йөрәктә аның урынын яулый алырмы? Бу сорауга Гөлфия ул чакта да, хәзер дә җавап таба алганы юк.

Ул чакта ук кыз күңеле бер нәрсәне ачык аңлады: ул бүтән берәүне дә Ленарны яраткандай ярата алмаячак. Шулай да үзенә сүз кушып караган егетләр арасыннан күңеленә пар эзли башлады.

Уйланмаслык та түгел, аңа егерме тула иде. Кияүгә чыгар вакыты җиткән. Моны ул үзе дә аңлый. Аны бер нәрсә генә куркыта. Китаплардан укып, сөйләүләрдән ишетеп белә: беренче мәхәббәт онытылмый, диләр. Әмма, Ленарны оныта алмам, диеп ул гомер буе кияүгә чыкмаска тиешмени?! Уйлана торгач, үзен тынычландырырга тагын бер җавап тапты: беренче яраткан ярлары белән кушылучы бик сирәк, берсенең дә сагышыннан үлгәне юк, имеш. Әнисе әйтүенчә, өйләнешкәч, ирдән якын кеше булмый ул.

Кемгәдер барыбер кияүгә чыгасы. Үз гаиләсе булса, мондый билгесезлек күңелне тырнамас, йөрәк янулары басылыр, тормыш үз эзенә төшәр шикелле.

Гамир тәкъдим ясагач, аны пошаманга салган тагын бер нәрсә алдына килеп басты. Ул Ленар белән вәгъдәләшкән, ике ара ачыктан-ачык өзелмәгән бит. Гамирга ризалык биргәнче шуңа ачыклык кертәсе бар.

Гөлфия кияүгә чыгарга җыенуын белдереп, аңа хат язды. Тик аның адресы юк иде. Ленарның үги әнисеннән, сеңлесе Әнисәдән кереп сорарга җөрьәт итмәде: ялына дип кабул итүләре бар. Башка кешеләр аркылы эш йөртергә дә шикләнде. Гамирга барып ирешсә, оят: икейөзле килеп чыга бит.

Уйлана торгач, кабат бер үк фикергә әйләнеп кайта иде ул. Яратса, күңелендә булса, алты ай язмый торыр идеме? Ул аңа ышанмый, бәлки Казанда кызы да бардыр әле. Шулай булмаса, ничек болай араны кинәт өзәргә иде икән?

Шул фикерендә тукталып калды. Калганы бик ансат хәл ителде. Үзенә үпкәләсен, ул аны вәгъдәсез санарга хакы юк.

Адрессыз хат берничә көн кесәсендә йөри иде. Мондый нәтиҗәгә килгәч, башкалар кулына эләккәнче, ул аны вак-вак кисәкләргә ерткалап, чүп савытына ташлады. Шул көнне кичен, Гамир кабат сүз кузгаткач, әти-әнисеннән рөхсәт сорарга киңәш бирде.

* * *

Ике авылда ике йорт ашыгыч кына туйга әзерләнә башлады. Ә авылда бер йорттагы яңалык сәгате-минуты белән бөтен урамнарны әйләнеп чыга. Алар язмышына кагылышлы хәбәр дә шулай тиз таралды.

Шул көннәрнең берсендә,— бүрене сагынсаң алдыңа килә, диләр бит,— мәктәптән кайтышлый, Җәвидәне очратты.

— Гөлфия апа, сине Гамирга кияүгә чыга диләр, шул дөресме? — дип сорады Җәвидә.

Гөлфиянең теле тотлыкты, берни әйтә алмый басып тора бирде. Гамир белән мөнәсәбәтләре булганлыгын белә, бу хакта сөйләшү, аңлашу, ачыклау кирәген аңлый иде. Бу уңайдан аның ни өчен Җәвидәгә өйләнмәвен сораганы да булды. Гамир, тирәнгә китеп тормастан, үпкәләшүләрен белдерде. Сүз җае чыккач: «Ленар белән синең күк»,— дип тә кыстырды. Гөлфия, бу мәсьәләдә сораулары тагын булса да, артыгын төпченмәде, алсуланган яңакларын читкә борды. Туйны ашыктыргач, имеш-мимешләрне ачыклап өлгерми, аңа ризалыгын бирергә мәҗбүр булды. Өйләнешкәнче вакыт бар, җай китереп бу хакта янә бер сөйләшерләр әле. Андый җай әлегә кадәр чыкмады. Җәвидә белән аңлашырга туры киләсен ул күз алдына да китермәгән иде.

Җәвидә аның боларны уйлап торуын күздә тотмый, җавапсызлыкны үзенчә аңлаган иде.

— Ул — бер елдан бирле минем ирем, өйләнәм, дип алдады. Туйны суза килде. Мин аның юк сылтаулар уйлап чыгаруын сизенә идем. Димәк, ул сиңа өйләнергә исәп тоткан икән?

Гөлфиянең сүз катарга көче юклыгын күреп, Җәвидә шуларны тезде дә тезде. Аннан ялваруга күчте.

— Гөлфия апа, кыз башың белән шуңа әрәм буласыңмы? Синең Ленарың бар, ул Гамирга алмашкысыз. Минем хәлне үзең аңлыйсың, башка чарам юк, балабыз туарга тиеш. Син, зинһар, аның төче теленә ышанма, безне калдыр. Туачак балабыз хакына үтенеп сорыйм.— Ул тирә-ягына каранып алды, сукмактан килүчене күрде һәм тавышын йомшартып, ашыгып сүзен очлады: — Кара аны, үзең теләп баш тартмасаң, иремне тартып ала дип, мәктәбеңә, хәтта ронога барачакмын.

Кичен алар Гамир белән клубта очраштылар. Егете кинодан соң биергә калырга теләгән иде дә, аның чыкканын күреп, иярергә мәҗбүр булды. Сүзгә сүз ялгый алмый аның фатиры капкасы төбенә кадәр җиттеләр. Егет аны кочарга үрелде.

— Кагылма,— диде Гөлфия, йөрәгендә ташыган нәфрәтен шул бер сүзенә туплап.

— Ни булды? — диде Гамир, сабырлык сакларга тырышып. Аның да күңелсезлекне сизеп торуы чыраеннан билгеле иде.

— Җәвидә очрады,— диде ул, кияве булырга тиешле кешенең йөзенә туры карап. Тик Гамирның какча йөзеннән кичерешләрен аңларлык түгел иде.

— Шуннан,— диде ул исе китмәгән кыланып.— Харап икән, кем очраган. Әнә нигә кәефең киткән икән. Ул нәрсә әйтмәс. Синең өчен хәзер аның сүзе түгел, минеке закон булырга тиеш. Мин бит сиңа өйләнәм.

— Икенче хатынлыккамы? — дип сорады ул мыскыллау тонында.

— Мин — булачак ирең,— диде Гамир салкын канлылык саклап.— Синең авыздан бүтән андый сүз чыкмасын. Югыйсә, мин дә каршы сорау куя алам.

— Әйдә, куй,— диде ул кайнарланып.— Бүген безнең араларда сер калмаска тиеш.

— Ленар белән булганнан соң, бу темага сөйләшү үзеңә үк уңайсыздыр ич?

Гөлфияне бизгәк тоткан шикелле булды.

— Ленар белән ни булган? — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды.

— Сез — Ленар, мин Җәвидә белән,— диде Гамир җан өшетерлек салкынлык, битарафлык белән. Тимер ныклыгы бар икән үзендә.— Бергә бер.

Гөлфия хәйран калып басып торды. Аның мие бер нәрсәне эшкәртеп бетерә алмады. Бу ничек була инде: үзе шулай саный, үзе аңа өйләнергә җыена. Бу бит кеше акылына сыймый. Ул аңа ташлама ясыймы?

— Балаң буласы икән, Гамир, ятим итмә,— диде акылын җыеп.

— Син нәрсә? — Аңа хәзер генә башына барып җитә башлады. Аңлап алды һәм өстәде.— Аңа өйләнергә дисеңме?! Миңа кызлар да бетмәгән. Әгәр син вәгъдәңне бозасың икән, мин барыбер Ленар алырлыгыңны калдырмыйм.

Гөлфия ул чакта Гамирның турыдан-туры этлек эшләвеннән нык куркып йөрде. Барыннан элек аулакта туры китереп көчләве мөмкин санады, саклык чаралары күрде. Куркулары бушка гына булып чыкты. Гамирның башында бөтенләй башка мәшәкатьләр иде.

Ул сүзен итте, аның белән билгеләнгән көндә үк райкомолның хисап бүлегендә эшләүче Надяга өйләнде. Кыз бай нәселдән иде, бик зурлап туй үткәрделәр. Бәйрәмнәр узуга, егет райкомолга инструктор булып күчеп китте.

Аның мәктәптән китүенә сөенеп бетә алмады Гөлфия. Вәгъдәсеннән баш тарткач, икесенә бер коллективта эшләве кыен иде.

Тик иртәрәк сөенгән булып чыкты. Аның хәле, уйланмаган җирдән, катлауланып китте. Авылда аның турында гайбәт таралды. Урам хәбәрен түкми-чәчми ташучы хуҗабикәсе Мәликә апа аның дәрестән кайткан җиренә бер төрле яңа хәбәр әзерләп куйган иде: туйны Гамир киреләгән, Ленар алдаган булган икән, шуңа алмаган һ. б. Кысыр хәсрәт күршекүлән, таныш-белешләрнең дә тел-тешенә керде, читләтеп һәм турыдан-туры моның хакында беренче авыздан сүз ишетергә, кайгысын уртаклашырга теләүчеләр дә табылды. Шулардан туеп, ул велосипед белән көн саен авылга кайтып йөри башлады. Гайбәт авылга да ияреп кайткан булып чыкты.

Туйның сүтелүен, бу күңелсез хәбәрдән соң, бигрәк тә өйдәгеләр авыр кичерде. Әнисе, бер яңа хәбәр ишеткән саен, чәпчеде: «Йөргәнен белгәнсең, ризалык биргәнче ачыклыйсың калган, вәгъдәләшкәч, ирнең толы юк, чыгасың булган».

Тыштан сиздермәсә дә, әтисенең дә чырае гел караңгы. Эштән кашын-күзен җимереп кайта да, туйга дип әзерләнгән әче балга ябыша.

Шундый көннәрнең берсендә, кичке ашка утыргач кына, көтелмәгән кунаклар — бәйрәмчә киенгән Нәгыйм абзый, Зәйтүнә түти, Назыйм килеп керде. Гөлфия аларның нинди йомыш белән йөрүен ишектән күренгәч үк аңлады. Бер генә нәрсәгә гаҗәпләнде: Назыйм аны бу хакта искәртмәде дә. Үз сүзе үтмәсен алдан белгән дә, аларны ярдәмгә алып килгән. Бу аның күңелен шундук суытып җибәрде.

— Килегез, кунаклар, түрдән узыгыз, табынга рәхим итегез,— дип башлады тамагын чылатып, телен чарлап өлгергән әтисе.— Мактап кына йөрисез икән әле. Әнисе, кунакларга аш сал, әче бал чыгар.

— Узарга дип килдек әле, Шакир туган.— Нәгыйм абзый кыстатып тормады, түргә узды.

— Мактамаска! Мактарлык та бит! — Зәйтүнә түти дә үзен сиздереп сүз кыстырды, иреннән калышмыйча, читекләренең кәвешләрен салдырып, әнисе һәм аның белән ике куллап күрешеп, табын тирәсенә урнашты.— Макташып кына яшәргә кирәк биш минутлык бу дөньяда.

Әтисе ир-атларга бал салды, очрашу хөрмәтенә эчәргә тәкъдим итте. Берсе дә кыстатып тормады.

Назыйм солдаттан кайткач ук, Гөлфиядән үзенә кияүгә чыгарга берничә тапкыр сорады. Кыз кире кага килде. Ләкин егет аны ташламады, тагылып йөри, ара-тирә үтенече хакында исенә төшерә торды.

Әче бал банкасы тиз бушады. Моны күреп, әтисе тагын сорады.

— Кирәкми, Шакир туган, әзрәк бу балны да авыз итеп карыйк.— Назыйм абзый, мәрхүм, өстәл өстенә аракы чыгарып утыртты, шундук бүлеп тә чыкты.

— Тукта әле, нигә болай кунаклар исәбенә сыйланабыз соң әле? — дип сорады әтисе. Йомышларын сизә иде, билгеле, аларга сүз башларга җай бирде, мөгаен.

— Сезнең алма кебек кызыгыз бар. Безнең Назыймга әнә өйләнер чак җиткән.— Зәйтүнә түти кулай мизгелне кулдан ычкындырмады.

— Туганлашып җибәрикме әллә, дип киңәшкә килдек, Шакир кордаш,— диде Нәгыйм абзый, карчыгы сүзне эзгә салып җибәргәч.— Шул теләкләр чынга ашсын дип тотыйк булмаса!..

— Ходайның, «амин» дигән чагына туры китерсен, илаһи,— диде Зәйтүнә түти. Күпмедер тынып торды да тагын башлады: — Теләгегез бик изге, бик изге, туганлашып гел бергә-бергә яшәргә Ходай шулай язсын иде. Назыйм тәүфикълы, инсафлы, сабыр. Күңеле гел синдә, Гөлфия кызым. Моны без әйтмәсәк тә, беләсең.

Аның әти-әнисе үзара карашып алдылар, икесе дә ахырдан күзләрен аңа төбәде. Егет белән кызлары арасында нинди сүз — белмиләр бит әле.

Иң алдан Зәйтүнә түтинең сабырлыгы бетте, сүзен кыстырып куйды:

— Уйламый, киңәшми эшләнә торган эш түгел, без бүген җавабын гына ишетеп китсәк тә риза.

— Без ни әйтик, Нәгыйм кордаш? — Әтисе, бер тапкыр авызлары пешкәч, җавап бирергә ашыкмады.— Эш яшьләрнең үзләреннән тора. Үзара килешкән булсалар...

Гөлфия дәшмәде, урыныннан торды. Зур яктагы үз бүлменә кереп бикләнде. Шуның белән эшне беткәнгә санады.

Кече якта беравык тынлык урнашып торды. Аны Зәйтүнә түти бозды:

— Шакир, Фәхимә, карагыз әле. Назыйм килде-китте малай түгел. Институт дипломлы, азып йөрми, кеше баласын елатканы юк. Булмас та, Алла теләсә. Эше абруйлы, колхозның бөтен машинасы аның кулында. Сезне дә, безне дә ташламас. Теләсәләр, башка чыгарлар, без йөдәгән картлар түгел әле.— Аның сүзе шул урында өзелеп торды, аннан булачак биана улына эндәште: — Син, егет кеше, безнең сөйләшкәнне тыңлап утырма, кызың янына кер, сөйләш, аңлат. Кызларда әзрәк назлана, ялындыра торган гадәт була инде ул. Кадерен белә төшәрсең.

Назыйм, кереп, аның агач караватына янәшә утырды. Кече яктагылар,— аларга комачауламас өченме, әллә үзләре аерым сөйләшергә теләделәрме,— ике арадагы ишекне ябып куйдылар.

— Гөлфия! Мин синсез яши алмыйм. Сине бәхетле итәр өчен бөтенесен эшләрмен...

Ул ялына, Гөлфия исә башын аска иеп тыңлап утыра бирде: ак та, кара да димәде.

Шыгырдап ишек ачылды, кече яктан гөлдер-гөлдер сөйләшкән тавышлар ишетелә башлады. Сүзләреннән аңлашылганча, ул якта уртак фикергә килгәннәр иде шикелле.

— Сез нәрсә, буласызмы анда? — Әтисе аларга эндәште.— Табын янына чыгыгыз әйдә.

Назыйм хәлне аңлатырга алар янына чыгып китте. Аңа алмашка әнисе кереп җитте.

— Кызым, без риза, эш үзеңнән тора.— Кодалаучылар ишетмәсен өчен, ул пыш-пыш кына сөйләде.— Вакытың җитмәгән түгел, синең кебек чакта минем балам — Әмир абыең кулымда иде инде. Әллә ниятлисеңме? Назыйм болай акыллы, сабыр күренә.

Элек әнисенең беркайчан кыстаганы булмады, аны бу җитди мәсьәләдә ашыктырмады. Бу юлы кодалар ягын каера.

Бернинди дә җавап ишетмәгәч, әнисе аны үзенчә аңлый, икеләнә дип уйлый.

— Балам, кыз кадере, үзең беләсең, кыл өстендә...— Мәкальнең икенче өлешен әйтеп бетерми, әмма Гөлфия аның ни уйлаганын, ни әйтергә теләгәнен аңлый.— Тәвәккәллисеңме әллә?

Бер авызы пешкәч, Гөлфиянең кияүгә чыгарга теләге юк иде. Ленар белән бәйләнешкә ачыклык кертергә, тәмам аерылышсалар гына кияүгә чыгарга исәп тотты. Шуңа әнисенең үгетләренә каршы дәшмәде.

Әнисе тагын әзрәк көтте дә, кергәндәге кебек, шыпырт кына чыгып китте. Гөлфия берни уйларга сәләтсез иде, тын гына утыра бирде.

Шапылдап ишек ябылганга ул сискәнеп китте. Ни уйларга да өлгермәде, аның чаршавын берәү тупас кына тартып ачты.

— Йә, кызым, синнән җавап көтәләр. Чык та соңгы сүзеңне әйт. Тавышын күтәрмәсә дә, әтисенең канәгать түгеллеге ярылып ята иде.

— Әйтәсен әйттем, әти,— диде Гөлфия көчкә-көчкә. Ул тулып җиткән, менә-менә үксеп җибәрергә әзер иде.

— Алай кырт кисмә әле, кызым,— диде әтисе.— Элек килгәннәрнең берсенә дә кысмадык, ихтыярыңа куйдык. Хәзер бит хәл үзгәрде.

— Нәрсә үзгәрде соң?— Әтисенең тел төбендә ни ятканын сизсә дә, аңламаганга сабышты.

— Балалар кебек кыланма, сиңа акыл теше чыккан инде.— Әтисенең үпкәләве сизелә иде.— Ленар дидең, көтүче малай булса да, каршы килмәдек, ә нәрсә килеп чыкты?

— Нәрсә?— ди сорарга мәҗбүр булды ул сулуына кабып.

— Белмиләр дип санама: ташлады.

— Кем әйтә?

— Бөтен авыл сөйли.

— Авыл сөйләр ул,— диде Гөлфия бүтән сүз тапмастан.

— Сөйли шул,— диде әтисе кызуланып.— Шуны белгән дә, Гамир да киреләнгән, диләр.— Эштә халык күз ачырмый. Шакир кода, туйлар ничек узды?— дип көләләр. Чык син, кызым, чык, ә!

— Аңа ничек чыгыйм?— Гөлфия Назыймны яратмавын әйтмәкче иде, әтисе аны шундук бүлде.

— Аңа чыксаң да ярый, ул сабыр.

Моны ишеткәч, Гөлфия тәннәре кызышуын тойды. Әтисенең тел төбе тәмам аңлашылды. Әнә ни өчен ул гайрәтләнеп кергән, нәрсәне ачык әйтәсе килгән булган. Ата белән кыз арасында бу хакта сүз булуы мөмкин түгел саныйлар, әмма аның күрмешедер инде; бу — башыннан узган хәл. Чөнки әтисе исерек, ни сөйләгәненә хисап тотарлык түгел, яраган-ярамаган чамалаудан узган иде. Башында бер генә нәрсә бөтерелде: кызын ничек тә тизрәк кияүгә бирү, гайбәттән котылу. Моны ул хәзер шулай уйлый. Шагыйрь әйткән бит: «Шәрабның көче әйтеп бетергесез зур: иң акыллыларны да җырларга, биергә мәҗбүр итә, еш кына әйтелмәве хәерлерәк булган сүзләрне дә теленнән ычкындырта. «Әтисенең ул кичтәге кыланышларын ул шуның белән генә аңлата ала иде.

Ул чакта әтисе аның бәхетенең тамырларын рәхимсез теле белән таптады.

— Син ни сөйлисең, әти?— дип җан ачысы белән кычкырып җибәрде Гөлфия.

— Мин түгел, авыл сөйли,— диде әтисе алдын-артын уйлап тормастан.— Чыгарлыгы калмаган, шуңа Гамир алмаган, диләр.

Шул сүзләр аның язмышын хәл итте. Кычкырып елаган тавышка бүлмәгә әнисе, Зәйтүнә түти килеп керде.

— Ярар, кызым, туган йорттан чыкканда барыбызга да шулай авыр булган инде ул.— Булачак биана аның елавының сәбәбен ачыклап торырга җыенмый иде, тиеш булганча юатты. Гөлфия бу вакытта тыела алырлык халәттә түгел иде. Күз яшен тыйса да, чит кешеләр алдында әтисе белән булган сөйләшүне кабатларга йөрәге җитмәс иде.

— Елама, балам, елама,— дип сөйләнә-сөйләнә әнисе үксергә керешге.

Әтисе, күзләрен зур ачып, читкәрәк китеп басты, бүтән кысылмады. Әмма Гөлфиянең язмышы нәкъ менә шушы көнне хәл ителде.

* * *

Ул килеп кергәндә Гамир Җәвидә белән көлешә-көлешә ни хакындадыр сөйләшеп утыра иде. Аларны икесен бу хәлдә очрату күңелгә ничектер ят, уңайсыз иде: тәне бер эсселәп, бер суынып алды. Җәвидә урынында булса, ул Гамир каршына килеп үзен шулай тота алыр идеме икән?! Бу — Гөлфия өчен күнел кабул итә алмаслык хәл.

Теге чакта Гамир башкага өйләнгәч, Җәвидә баласын алдырып чыккан, диделәр. Шул җәйдә үк ул Акбуа техникумына укырга керде. Аны тәмамлап кайткач, «Коммунизм юлы» колхозына эшкә билгеләнде. Өйләнешкәч ире Камил дә шул колхозга барып урнашты. Озакламый аерылышулары да билгеле булды. Ә хәзер Җәвидә монда ни эшләп йөри икән?

— Таныш бул, Гөлфия, райкомның яңа инструкторы,— диде Гамир, исәнләшкәч.— Безнең партоешмада политукуларның торышын тикшерергә килгән. Бер очтан бригадаларда йомгаклау дәресләрендә дә катнашачак.

Гөлфия өчен бу, билгеле, көтелмәгән яңалык булды: әнә кем аның эшен тикшерәчәк. Ул гарьләнүдән кашларын җыерды, ләкин тыштан моны сиздермәде.

— Бик яхшы,— дигән булды.

Мәктәптә Җәвидәнең иң яратмаган фәне тарих иде, хәзер ул сәясәтче булып киткән. Ниләр сорашыр, ничек тикшерер икән — карап карыйк.

— Утырыгыз, Гөлфия Шакировна.— Җәвидә үзенең роленә кай арада кереп өлгергән, инде боера да белә. Тавышыннан ук үзен эре тотканлыгы чамалана. Әле кайчан гына очрашкан чакларында үзен авыл кешеләре кебек гади генә тота иде, аңа да якын итеп «Гөлфия апа» дип өндәшә торган иде. Бу юлы беренче сүзеннән үк сөйләшү рәсмилек алды. «Сәнәктән көрәк булгач, шулай икәне билгеле»,— дип куйды эчтән генә Гөлфия.

Ул өстәлнең икенче ягына, каршыларына утырды.

— Кая, журналыңны бир әле монда.— Гамир Садыйкович авылда берсе белән дә «Сез» дип сөйләшми, аңа да шулай гына эндәшә. Моңа һәркем күнеккән инде.

Колхозның партоешма секретаре Гамир Харисов кыш дәвамында әллә ничә кабат тикшергән журналны янә күздән кичерә башлады. Җәвидә үзенә шөгыль тапты, юл сумкасыннан папка, аның эченнән блокнот һәм бер бит кәгазь алды. Соңгысы ике дистәгә якын сорауны эченә алган белешмә-анкета булып чыкты. Ул шуннан сорауларны берәмләп укый һәм блокнотына җавапларны яза башлады.

— Сез кайчан туган әле, Гөлфия Шакировна? — Ул үзенең элекке укытучысының ризасызлыгын тоеп өстәде: — Елын беләм дә, монда аен, көнен дә сораганнар,— дип акланды Җәвидә — Университетны кайчан тәмамладыгыз әле?

— Алтмыш алтының җәендә.

Җәвидәгә сорау алу ошый идеме, анкетадан башын күтәрмәгәнгәме, әллә бурычын шулай нөктәсенә кадәр үтәргә тырышуы идеме — бер үк тонда дәвам итте:

— Һөнәрегез?

Соңгысы Сәйфетдинованың тәмам ачуын кабартты. Талиповны колхозга рәис итеп сайлагач, аның дәресләрен алып баруны Гөлфиягә йөкләгәннәр иде. Җәвидәне унынчыда шулай берничә ай укытып калды ул. Укучысы да аны белә, билгеле, шулай да төпченә. Үзен күрсәтәсе киләме?

— Тарих укытучысы.

Җәвидә бусын да теркәп куйды.

— Пропагандистлык стажыгыз күпме әле?

— Барлыгы тугыз ел. Соңгы дүрт елда партия мәгарифе челтәре пропагандисты.

— Быел нинди курс өйрәнәсез?

— Менә программасы.— Гөлфия тикшерүчесе алдына кулындагы китабын куйды: — Шуннан күчереп алырсың.

— Миңа пропагандистның үз теленнән ишетү мөһим,— дип үҗәтлек күрсәтте Җәвидә.

— Бөтендөнья социалистик системасы.— Гөлфия, Җәвидәнең төпченүенә гарык булса да, җавап бирергә тиеш иде.

— Син башка колхозларга баргач төпченерсең.— Гамир Садыйкович, ниһаять, түзмәде, искәртәсе итте.— Монда авылдашларың эшеннән тырнак астыннан кер эзләмә.

Инструктор югалып калмады.

— Партия эшендә авылдашлык була алмый, Гамир Садыйкович. Бирегә килер алдыннан Хәким Нурович шул хакта махсус кисәтте. Миңа сезнең партоешмада бу эшнең куелышы турында объектив мәгълүматлар кирәк. Кайтып шуны хәбәр итәргә тиешмен.

Моны ишеткәч, Харисов бәхәс куертып тормады: һәммә сүзнең Хәлимовка барып ирешүе ихтимал иде. Ул читкәрәк китте, тәмәке кабызды. Инструктор исә эшлекле бер кыяфәттә журналны өйрәнергә керешге.

— Өч занятиегез пландагыдан ким чыга. Аларны ни эшләтәсез?— Инструктор вазифасына тугрылыгын күрсәтә бирде.— Өстәмә занятиеләрне кайчан үткәрәчәксез?

Гөлфия күзләрен кысып, аңа ачуын яшереп тормастан сөзәргә җыенган үгез шикелле карады. Маңгаенда җыерчыклар хасил булды.

— Чәчүгә чыккач,— диде дорфа итеп.— Кыр станында, халык төшке ашка җыелгач.

Җәвидә аның үрсәләнүен тавышыннан, тышкы кыяфәтеннән дә аңлады. Ләкин ул белешмәсендә занятиеләрне киметеп күрсәтә алмый, бу аның ниятенә керми. Үзенең якташларын башкалар арасында ким күрсәтергә дә исәбе юк. Шулай булгач, бер генә юл кала.

— Анысы Сезнең эш,— диде ул җитди генә. Уйлаганын турыдан ачып бирә алмый бит ул, башкача сиздерәсе итте.— Мин бер генә нәрсәне беләм: журналда тагын өч занятие чагылырга тиеш. Ул чагында мин, партоешмада политукулар тулы һәм эчтәлекле үтте, дип белешмәгә кертәм.

Ул,— белгәнгә белек, чыгарып селек,— аңларлык итеп әйтте. Шуннан чыгып Гөлфия апасы үзе карусыз эш итәргә тиеш.

— Аңа гына эш калса.— Харисов, тәмәкесен тартып бетереп, алар янына килеп җитте. Ни эшләргә кирәген, читләтеп, шомартып тормастан, турыдан күрсәтмә бирде: — Гөлфия, тагын өч дәрескә журналыңны тутыр.

— Өстәмим,— дип киреләнде кинәт пропагандист. Аның кыш буе тырышканы бер тиен дә тормый, яхшы эшләүче итеп күренү өчен белешмәгә тагын нидер өстәп язу гына кирәк. Ул бер нәрсәне аңлый алмый: үтмәгән өч дәресне өстәүдән кемгә нинди файда? Шуңа, тикшерүчедән турысын сөйләп кенә котылып булмасын чамалап, котылу әмәлен тапты.— Артта калган темаларны чираттагы дәресләрдә кушып өйрәнә бардык — программа үтәлде, монда сәгатьләр саны гына чыкмый. Бөтен ялгыш шунда гына.

— Шул хатаңны хәзер төзәтәсең дә эш тә бетә.— Инде партком секретаре инструкторга кушылды.— Шулай бит, Җәвидә Хаяровна.

Ул инструкторга шулай олылап эндәште. Хәлимовның Җәвидәне ни өчен үз канат астына алуын белә иде ул. Шулай булгач аның янында үзеңне тота белү мөһим. Җәвидәнең беренчегә мондагы сөйләшүләрне вак-төягенә кадәр кайтып хәбәр итүе бар, аңа сак булырга, хата ясамаска кирәк.

— Минем хата ясаганым юк,— диде Сәйфетдинова элеккечә катгыйлык белән.— Билгеләнгән көнгә әзерләнеп килләм, занятиеләрне даими

үткәрәм. Минем бу эшем ошамый икән — алмаштырыгыз, пропагандистлыкны сорап алмадым.

— Син нәрсә, Гөлфия? — Аның артык сөйләп җибәргәнен күреп, парторг ашыгып әңгәмәгә кушылды: — Синең, районда алдынгы пропагандистлардан берсенең, мондый сүзләр сөйләве килешмиме. Син аларын калдырып тор. Монда бит рәсми сүз бара.

— Мин сезнең мактаулы пропагандист икәнлегегезне беләм, Гөлфия Шакировна.— Сәйфетдинованың соңгы сүзләре инструкторны сагаерга мәҗбүр итте.— Әмма кимчелекләрне күрсәткән өчен үпкәләмәскә, аны вакытында төзәтергә кирәк. Партия шулай таләп итә.— Әңгәмәдәшенә ташлама йөзеннән өстәп куйды: — Кимчелекләрдән беребез дә азат түгел, һәркемдә бар. Шул исәптән Сездә дә.

* * *

Җыелыш тәмамлануга, Җәвидә колхоз рәисе белән бергә аның кабинетына кереп китте. Гамир аны үзе белән Наратлыга ала кайтырга исәпләп куйган иде, көтәргә булды. Үз кабинетында гәзитләр караштырып шактый утырды — ул чыкмады. Түзмәде, рәис янына керде. Җәвидә бүген авылда куна икән.

— Шулай, Ленар Салихович, мин Сезнең һәр адымыгыз хакында аңа хәбәр итеп торырга тиеш,— диде Җәвидә, бүленгән әңгәмәгә әйләнеп кайтып.

— Маҗаралы романдагы кебек бу,— диде Сафин әңгәмәдәшенә сынаулы караш ташлап.— Чекистлар шпионнарны күзәткән шикелле. Ни өчен минем арттан шундый күзәтү оештырганын хәзер үзеннән белешәбез.

Җәвидә алдан кызарды, аннан агарды, ахырдан көл төсле күгәрде. Бу хакта ул Ленарның үзенә әйтергәме, юкмы дип күп баш ватты, үзен аның урынына куеп карады хәтта. Моны ошатса-ошатмаса, кабул итсәитмәсә дә, ул аның исәпләре буенча, аны сатмаска тиешлегенә күңеленнән ышанды һәм серне ачарга булды.

— Мине аның хөкеменә тапшырасыз, димәк.— Җәвидәнең тавышы калтырый, йөзе үпкәдән, ачудан тонык, борчулы иде. Хәзер аның өчен бөтенесе барыбер, беткән баш беткән, турысын әйтеп калырга ашыкты.— Моның өчен сез, әлбәттә, аның алдында зур ихтирам казаначаксыз. Ул үзе дә, Сезгә булган салкынлыгы да шунда ук юкка чыгар. Сезгә ул сайлаганда вәгъдә иткән яшел урам ачылачак. Ә мине кандала урынына сытачак.

Боларны ул бары бер максаттан — Ленарның намусын, вөҗданын уятуга өмет итеп тезде.

— Сез моны хәзер түгел, алдан уйларга тиеш идегез, иптәш Низамова.— Сафинның тавышында кырыслык ярылып ята, мәрхәмәт өмет итәр урын күренми.— Җиде кат үлчә, бер кат кис, диләр бит.

— Минем хата, Сезгә артыграк ышанганмын, белеп җиткермәгәнмен, намусыгызны югалтмаган санаганмын,— диде Җәвидә еларга җитешеп. Йөрәген үкенү хисе телгәләде.— Шалтыратыгыз. Тик артымда түгел, алдымда.— Бусы да батучының саламга ябышуы иде, бәлки алдында мондый этлеккә йөрәге җитмәс. Артында, хатын-кыз өстеннән бигрәк тә, әләкләп йөрмәскә тиеш, аны үзе өчен түбәнчелек санар.

— Анысын мин кайчан телим инде.— Сафин кискенлек сакласа да, тавышында йомшаклык сизелә инде. Ләкин рәис телефонга ябышты.

Җәвидә аның кулларыннан күзен алмады. Коты очып аппаратта Хәлимовның калын тавышы ишетелгәнен көтте. Бөтен тәнен эчке калтырау биләп алды. Ул номер җыеп туктагач көткән мизгелләрнең һәр секунды минут, сәгать кебек коточкыч озак тоелды аңа.

— Алло, кайсыгыз әле бу? Илдар, синме?.. Мин әле, әтиең. Чакырма, мин озакламый кайтам.

Җәвидә хисләрен яшереп маташмады, авызын зур ачып, күкрәген киереп сулады. Аңлады: Сафин аны юри өркеткән, икән.

— Нәрсә? — Сафин һаман житди кала бирде, йөзе тоньк иде. — Син бу алымың белән мине «калфак» астына тыкканыңны уйладыңмы соң? Тотык ясаганыңны уйладыңмы, шайтан алгыры!

— Нинди калфак ул тагын? — Җәвидә алдагы курку хәленнән дә айнып житмәгән иде әле, яңа гаепләү ишетү аны кабат шиккә төшерде — Мин аңламыйм. Нинди тотык ул?

— Мин генә түгел, үзең дә заложник, шуны һаман аңламыйсың, ә?

Җәвидә, «юк» дигәнне белдереп, башын чайкады.

— Уйламыйча эшләсәң, авырмыйча үләрсең, диләр.

— Аңлатып сөйләгез зинһар, Ленар Салихович. — Ул Сафин сүзләренең мәгънәсенә төшенеп җитмәсә дә, хәзер аны сатмасын чамалады.

— Монда аңламаслык нәрсә бар? — диде Сафин. — Аның алдында икебез дә тозакта: мин сине, син мине теләгән чакта сатарга мөмкинбез.

— Мин Сезне берничек тә сата алмыйм. — Хәзер рәис әйткәннең мәгънәсе аңа барып җитте. — Бу хәлдән соң бигрәк тә.

— Хатын-кыз сатып абруй казану ирлек түгел. — Рәис тә бу мәсьәләгә карашын ачыклап узды. — Андый кәсеп белән көн күрү — түбәнчелек.

— Котымны алган идегез, ант әгәр. — Җәвидә, куркулары узгач, ачылып китте. — Бу сабагыгызны гомер онытасым юк.

— Шулай, Җәвидә, икенче вакыт уйнап сөйләгәндә дә уйлап сөйлә. — Ул урынына барып утырды, уйлана бирде. — Беренче секретарьның артында үзе хакында ни сөйләүләрен белергә теләвен аңларга була. Әмма чибәр хатынның бу адымы уйланырга урын калдыра. — Сез аның белән күптәнге дуслар бит, югыйсә.

— Дуслар, — диде Җәвидә үрсәләнеп һәм иреннәрен бөреп куйды. — Мәхәббәт тә диярсез тагы. — Рәиснең чәнечкеле сүзләре канына тоз салды аның, тыелып кала алмады, ни уйласа шуны ачып салды. — Чынында исә без партноменклатура казаны тирәсенә сыенган күселәр.

— Партия штабында тикмәгә генә утырмыйсың икән, философиядән лекция укырлыгың бар. — Сафин баягыча үчекләү тонында дәвам итте. Аның өчен дә гаҗәпләнер нәрсәләр күп иде, Җәвидә бүген көтелмәгән, хәтта күз алдына китермәгән яктан чишелде бит. Мондый кискен борылышның сәбәпләрен белү теләге туу табигый иде. Шуңа күрә сорауны кабыргасы белән китереп куйды. — Башлагансың икән очына чык: үзең дә номенклатура казаны тирәсенә сыенган күсе булгач, ни өчен шулай кинәт кенә хуҗаларыңны сатарга булдың әле?

Шактый тын утырды Җәвидә. Катгый сорауга төгәл җавап таләп ителгәнен ул яхшы аңлый иде.

...Җәвидә бу уйланып калган мизгелләрдә Хәлимов белән ничек «дуслашып» китүләрен күз алдыннан кичерде. Ул «Коммунизм юлы» колхозына зоотехник булып урнашкач, озак та үтми, фермага райкомның беренче секретаре килде. Терлекчеләр белән бик игътибарлы кыланды, кемгә ни кирәге белән дә кызыксынды. Җәвидә, ятып калганчы атып кал, төлке тун турында телгә алды. Хәлимов аны каштан-күздән кичерде һәм шимбә көнне янына килергә кушты. Җәвидә оялып калмады — барды. Ул аны тиз һәм җылы кабул итте, райпо складына алып китте. Аның мондый йомышка үзе йөргәненә гаҗәпләнгән иде, сәбәбен соңрак аңлады.

Райпода райком работниклары өчен махсус склад бар икән: арзан бәягә кыйммәтле тун алды. Хәлимов, юл уңаеннан, аны авылларына кертә үк калдырырга булды. Юл буе карт төлке, затсыз мәзәкләр сөйләп, капшанып барды. Машина авылга кермичә умарталыкка узып китте. Җәвидә иләмсез юан, авызыннан хәмер исе килеп торган бу ир-атның ни өчен тун кайгыртып йөргәнен юлда аңлады, әмма каршылык күрсәтмәде, түзәргә булды. Башында бүтән планнар туды...

— Номенклатура өстенлекләреннән файдаланган өчен мин түләп киләм,— диде Җәвидә.

— Намусың белән,— дип ачыклап узды Сафин.

— Әйе.— Аның алдында сүз уйнатып маташмады, шулай да яңаклары алсуланып чыкты. Әңгәмәдәше агулы укларны берәм-берәм җибәрә торса да, аның хаклыгын аңлый, уртак фикергә шуның аркылы гына килергә мөмкин икәнен дә истә тота иде.— Әмма хәзер белдем, ул гына да җитми икән әле, башкаларны да сатып яшәргә тиешмен. Үз намусым өчен үзем җаваплы, ләкин хыянәткә намусым җитми, вөҗданым кушмый.

Сафин ике кулы белән чигәләрен кыскан хәлдә утыра бирде.

— Шулай,— дип куйды аннан үз алдына сөйләгәндәй.— Сәер генә килеп чыга бу. Соңгы тапкыр беренче янында булганда мин Гамирны бездән алу мәсьәләсен кабыргасы белән куйдым.

— Нигә?— Җәвидә өчен бу яңалык булды, билгеле, Хәлимов бу хакта аның ишеләргә белдереп тормый.— Партком секретарьлары арасында ул булдыклылар рәтендә йөри ич.

— Булдырамы, юкмы — анысы икенче мәсьәлә.— Ачыклыкка киткәч, Низамовадан яшереп маташмады.— Ул — минем арттан куелган күзәтүче. Талиповны ычкындырды, ләкин мин аңардан гына алдата торганнардан түгел әле.

— Кайдан беләсез?

— Корыла торган кирпеч заводыбызга Акташтан рельслар, вагонеткалар алыр өчен арзан гына бәягә бер түшкә ит җибәрергә туры килде. Аны идарәдән өч кеше белде: мин, Рабига апа һәм Гамир. Халык контроленнан килеп, икебезгә шелтә чәпәделәр, Гамир читтә калды.

— Андый очракта, билгеле инде, материаль җаваплыларга җәза бирәләр, парторгны катнаштырмыйлар. Аңа шелтә бирмәгәнгә шикләндегезме? Гамирны яклап әйтүем түгел, ләкин, аңлавымча, бу законлы күренеш.

— Ә беренче моны кайдан белгән?

— Ул да белгәнме?

— Контролерлар аның күрсәтмәсе буенча килгән, мин моны читләтеп кенә ачыкладым. Шуннан тагын өчебез бергә чакта ялган хәбәр җибәрдем — анысы да Хәлимовка барып ирешге. Моны кем эшли — аңлашыладыр?! Хәер,— Сафин тавышын үзгәртеп өсти куйды.— Анысы ул кадәр түгел, Гамирны мин мәктәптән үк беләм. Башкасы уйландыра.

— Нәрсәсе мөһим?— дип ашыгып сорады Җәвидә.— Нәрсәсе уйландыра?

— Харисов китеп тә өлгермәгән, миңа инде яңа шымчы билгеләнгән.— Сафин кашларын җыерды, маңгаенда сырлар хасил булды.— Гүя, мин бер секретный завод җитәкчесе инде.

— Әйе,— дип ризалашты Низамова.— Хәким Нуровичта ул гадәт бар. Аның турында артында кем ни сөйли — барын белеп торырга ярата. Кем шундый мәгълүматны күбрәк бирә — шул почетта. Аппаратта шуның буенча ярыш. Мин анда намуслылар эшли дип торам, анда шулайрак яулана икән абруй.

— Бик хәтәр уенга кушылып киткәнеңне аңлыйсыңмы соң?— Ленар аны тагын бер кабат кисәтәсе итте.— Уенның озакка сузылуы бар һәм син аннан бары эштән китеп кенә котыла аласың.

Низамова ахырынача чишелде.

— Тиз генә китәр исәбем юк әле.

— Шулай эшләү кызыкмыни? Бу бит ут белән шаяру дигән сүз.

— Хикмәт анда гына түгел,— диде Җәвидә тоткарлыксыз.— Ләкин Сездән яшерен түгел, ул өстенлекләрдән тиз генә баш тартырга исәбем юк. Минем әле фатир аласым, аны тиешенчә җиһазлыйсым бар. Райкомның җыештыручысы да ике бүлмәле квартираны чиратсыз ала: минем

моңа хакым юкмы? Икенчедән, минем анда эшләвемне кайберәүләр өчен кирәк саныйм.

— Кемнәр өчен ул, мәсәлән?—Сафин аның кемне күздә тотуын чамаласа да, моны теленнән ишетәсе килде.

— Районадагы иң югары җитәкчеләр фикерен белеп тору Сафинга да зыян итмәс, минемчә.—Моны Җәвидә яшереп, урап торуны кирәк тә тапмады.

— Мин андый хезмәтегездән баш тартам, ханым,—диде Ленар моңа каршы.

Җәвидәнең кәефе кырылды.

— Ышанмыйсызмы?—дип сорарга мәҗбүр булды ул йөзе шиңгән кыяфәттә.

— Миңа нинди мөнәсәбәт булуын Сезнең ярдәмнән башка да чамалыйм: әле, вәгъдәләр биреп китергәч, турыдан миңа басым ясаганы юк, утлы күмерне башкаларга тоттыра,—диде Сафин салмак кына.—Бусы — мәсьәләнең бер ягы. Артымда кем ни сөйләгәнне тыңлап, гайбәт җыеп утырырга теләгем, вакытым да юк.—Ул урыныннан торды, өстәле артыннан чыкты, аның турына килеп тукталды һәм кинәт тагын бер сорау бирде.—Җәвидә, Сез бит боларны минем үземә хәбәр итмичә дә, теләктәш, фикердәш булып яши ала идегез. Үзегез өчен дә тынычрак булыр, баш түбәгездә кылыч асылынып тормас иде. Серне ачырга нәрсә мәҗбүр итте?

— Кайберләрен әйттем инде.—Ул Ленардан күзен алмады.—Боларга өстәп, Сезне мин белгән кешеләр арасында намуслы һәм тормышка төптән караучы коммунист саныйм. Шул кадәресе җитәрме?!

* * *

Җәвидәне Ленарга ачыктан-ачык мөрәҗәгать итәргә этәргән тагын бер һәм төп сәбәп бар: ул аңа гашыйк иде. Билгеле инде, Ленар бу хакта белсә дә, аңа моны турыдан-туры әйтергә килешми, оят та.

...Ул сигезенчегә кергәндә мәктәптә соңгы елын укучы Ленарны комсомол комитетыннан класс вожатые итеп билгеләделәр. Ленар аларның укуы, җәмәгать эшләре белән гел кызыксынып торды. Уеннар, спорт ярышлары оештырганда да параллель класслардан калышмаулары өчен янып йөрде. Концертлар әзерләгәндә ул — баянчы, Җәвидә төп җырчы иде. Җәвидә аңа очрашуларының беренче көннәреннән үк гашыйк булды, сагыш утында йөрде. Ленарның исә классташы Гөлфия белән дус икәнен белсә дә, өметсез шайтан дигәннәр, аны үзенә каратырга тырышмады түгел, күп көч куйды. Ленар битараф калды, бу Җәвидәнең йөрәгенә ялкын гына өсти иде.

Унтугызынчы майда, пионерия көнендә, бөтен мәктәп «Үрдәк күле» аланына бәйрәмгә барды. Тантаналы линейкадан соң алар төнбоеклар үсә торган күл буена килеп чыктылар. Җәвидә аны үзе чакырды.

— Ленар абый, күр әнә никадәр төнбоек монда,—дип, кулы белән көмеш төсле ялтыраган күл өстенә төртеп күрсәтте.

Төнбоеклар чынлап та күп иде. Куаклар каплаган су өстендә, башларын игән аккошлар шикелле утырган чәчкәләрнең хозурлыгына сокланып басып тордылар алар.

— Ленар абый, өзеп бир, ә?—дип ялварулы карашын егеткә төбәде кыз.

Моның өчен чишенеп салкын суга керергә кирәк. Егет чәчәкләрне алып чыкканда туңып куырылган, бөтен гәүдәсе калтырана иде.

— Ай, рәхмәт, Ленар абый, мең яшә,—диде Җәвидә сөенеченнән баскан урынында сикергәләп.

Ленар дәшмәде, ашыга-ашыга киенүен генә белде. Ул киенеп килгәч, тын күл өстен күзәтеп шактый тордылар. Җәвидә янәшәсендә күгәреп

басып торган егеткә бар кайнарлыгын бирергә дә әзер иде, тик егет үзенә орынып торган беләкнең җылысын да, йөрәге аша чыккан эссе сулышын да тоймый иде шикелле...

Аулактагы бу очрашуны ул гомерендә күп тапкырлар исенә төшерде. Исәр вакыты узгач, тормышында төрлесен татып карагач, аңлады: Ленарга ихтирамы вакыт узган саен арта бара иде. Хәлимов аңа Ленарның һәр адымын күзәтүне, сөйләгәнен, хәтта уйлаганын хәбәр итеп торуны йөкләгәч, күңелендә ташыган хисләре тышка бәреп чыкты, серне аның үзенә чиште.

* * *

Ленар Миңнеголне йортлары янына кадәр озата килде. Хушлашыр минутлар җиткәч, театр фойесындагы күк, кинәт кысып алды, иреннәреннән бер суырып үпте. Миңнегол бу юлы бернинди каршылык күрсәтә алмады.

Әнисе Зөбәйдә аны ишек төбенә үк килеп каршылады, кичегүенең сәбәбе белән кызыксынды. Миңнегөл трамвай килми торуга сылтады.

Шул кичтә Миңнегөл үзендә рухи үзгәреш, күңелендә ялкын кабынуын тойды. Иртән юксыну, сагыну хисе белән уянды. Ленар аны очрашырга кинога чакыргач, өзеп җавап бирмәгән иде, иртәгесен үкенеп тә куйды: әгәр килмәсә?

Кич җитүен түземсезләнеп көтеп алды.

Көн саен кинога дип ялгыз гына чыга башлаган кыз күңелендәге үзгәрешләрне иң элек әнисе сизенде һәм бер көнне, ул институттан кайткан җиргә, абыйлары да җыелып куйган иде. Әнисе кичә Миңнегөлне куян бүрекле берәү кинодан соң озата килгәнен әйтүгә, өйдә зур тавыш чыкты. Кызны төрлечә үгетли башладылар. Тиз генә элек йөргән егете Вилне, аның әти-әнисен чакырып керделәр. Шунда ук гариза язып, аннан да кул куйдырдылар. Иртәгә төштән соң яшьләр өйләнешер өчен гариза илтергә тиешләр иде.

Миңнегөл алар ихтыярына буйсынган булып кыланды. Аның бүтән чарасы юк, каршы килсә, бүген үк аларны бергә ябып куюлары бик ихтимал.

Иртән әтисенең машинасы белән Вил аны институтына озатты. Кыз исә бераздан әйләнеп тә чыкты һәм Ленар янына ашыкты, өйдә ниләр булганын яшерми сөйләп бирде.

Алар шундук Ленарның туган авылы Каенсарга чыгып киттеләр. Шәһәрдә язылышуны көтәргә кирәк, аларга мондый мөмкинлек калдырмаячаклар. Авылда язылышу бик ансат, таныклыкны сәгате-минуты белән тапшыралар.

Аларны озатып кайткач кына Ленарның курсташы Шәүкәт Миңнеголләрнең өенә шалтыратты, аның кияве белән берничә көнгә авылга китүен хәбәр итте.

Үги улының искәртми-нитми килен алып кайтуын күргәч, Гайшә түти биттән-төстән калып мич артына кереп китте, аннан торып кына телләнде: «Өйләнүен өйләнгәнсең дә, ничек туй уздырасын уйламагансың». Миңнеголнең күзләреннән мөлдер-мөлдер яшь тамуын күргәч, әтисе Салих абзый, рәхмәт төшкере, кычкырып салды: «Син, хатын, телеңне тый, кеше баласын елатма. Бурага дигән акчаны тотам, әмма кеше алдында ким-хур булмабыз».

Кич иде инде, язылышырга барып өлгермәделәр. Гайшә түти тагын бер яңалык казып чыгарды. Никахсыз кушылу — гөнаһ, ул үз йортында зина кылдырмас. Анысына ризалашырга туры килде. Ленарның үги сеңлесе Әнисә чаптырып кына мулла урынында йөрүче картны алып килде.

Иртәгесен авыл Советына барып язылыштылар. Тагын бер кич кунып, Казанга әйләнеп кайттылар. Тулай торакта тыйнак кына туй

үткәрделәр. Ленар дәүләт имтиханнары тапшырганда аның бүлмәсендә яшәделәр. Ике иптәше башка курсташлары янына сыенды, аларга урын бирделәр.

Ул авылга киткәч, Миңнегөл әниләренә әйләнеп кайтты, имтиханнары тәмамланганчы шунда торды. Дипломын алгач ук авылга, ире янына китеп барды.

...Зур якта бала елаган тавыш ишетелде, кыз һәм егет чакларының соңгы көннәре турында истәлекләргә чумып, бер-берсенә сыенышкан ир белән хатынны бүгенге чынбарлыкка әйләндереп кайтарды.

Миңнегөл, сак кына этелеп, иренең кочагыннан чыкты.

— Ленар, кулларым камырлы, баланы ал, зинһар.

— Хәзер алам, карчыгым.

* * *

Идарә һәм парткомның берләштерелгән утырышы тәмамланып килә иде инде.

— Менә нәрсә, иптәш Зәбиров,— диде Сафин, кирпеч заводы директоры тынып калгач.— Киләсе атнага планлаштырылган барлык бу эшләр бер-берсенә тыгыз бәйләнгән. Заводның яндыру мичен җомга көн җибәрә алмасак, безнең бүген корган планнар челпәрәмә киләчәк.

— Ничек инде ул алай?— Котдус Бариевич аны аңлап җиткермәде. Әмма рәис белән килешмәве ачык сизелә иде.— Сез, Ленар Салихович, гел ашыктырасыз, гел басым ясап киләсез: «әйдә», «әйдә». Без ул көнгә өлгерә алмыйбыз. Кирпеч яндыруга бер-ике көн кичегеп керешсәк, берни үзгәрми, минемчә.

— Синеңчә, үзгәрми, минемчә, үзгәрә,— диде Сафин директорга усал карап.— Шуннан соң ук хатын-кызлар чөгендерне кабат сиракләүгә төшә, эшләүчеләр кими. Ул көнне сынап калдырсак, эшне теләсә кайчан дәвам итәргә мөмкин. Аны сынамый торып үзебездә, аннан районда сабан туена туктасак, эш ярты юлда кала.

— Ике көнгә соңарабыз, бары шул,— диде Зәбиров.

— Сабан туй узуга, сезгә булышучы механизаторларны печәнгә алабыз, бу сиңа билгеле ич.— Сафин бәхәсләшергә урын калдырмый бастырып сөйли бирде.— Үзеңдә калган эшчеләр белән генә заводны җибәрү ай буена сузылачак. Мин моңа юл куя алмыйм.

— Әйтергә ансат ул, үтәргә кыен.— Зәбиров һаман үзенекен турылады.— Шул кадәр эшне кыска вакытта башкарып чыгып булмый.

— Аңлашылды,— диде Сафин тамак төбе белән.— Синең эшчеләргә мин барып наряд бирәм. Һәм ышанам: билгеләнгән вакытка өлгерәчәкбез.

Зәбиров рәискә кырын карап куйды, алсуланган яңаклары тартышып алды.

— Анда кем барса да, ул срокка җитешә алмый,— диде ул аңа каршы.— Эш күләмен үзегез беләсез.

— Беләм, яхшы беләм. Белгәнгә күрә әйтәм дә. Йә, сөйләп күрсәт әле, бу көннәрдә эшне ничек оештырмакчы буласың?

— Ничек дип...— Директор рәиснең соравын аңлап җитмәде, аңа сәер карап куйды.— Гадәттәгечә. Яндыру мичененң түбәсен ябасы. Яндыру форсункалары куясы. Алары беткәч, вагонеткаларны йөртү өчен юллар сузасы. Янган кирпечне саклау өчен амбарның нигезе генә салынган әле.

— Аңлашылды.— Кулын селтәп аны бүлдерде рәис.— Эшне берсе артыннан икенчесен генә түгел, берьюлы һәр тармакта алып барырга кирәк. Кайту белән Камилгә булышчылар бир. Вагонеткалар йөртү өчен юл сузуны киптерү келәтләре ягыннан башларга кирәк.

— Анда минем кешеләр җитми, һәммәсенең башлаган эше бар,— диде Котдус.

— Сез һаман бер нәрсәне аңламыйсыз, Котдус Бариевич.— Ленар катгыйлык белән дәвам итте: — Сезнең карамакта илледән артык колхозчы. Кайсы эшең беренче чиратта — шунсын эшләт. Мичтән чыккан кирпеч өчен келәт зарури түгел әле, кирпечне мичтән үк алып китә барачаклар. Һәм, гомумән, заводта хезмәтне оештыру буенча мин наряд биреп утырырга тиеш түгел, моны Сез башкарырга тиеш. Үзегез белеп эшләргә вакыттыр бит инде.

— Безгә форсункаларны Назыйм кайчан куя?

— Анысын үзеннән сорагыз инде,— диде Сафин.— Назыйм янәшәндә утыра.

— Форсункалар кайтарылган, ягулык цистернасыннан мичкә торбалар сузылган,— угольниклар гына юк,— диде Сәйфетдинов.— Форсункаларны беркетү өчен шулар җитми.

— Газ кертү өчен кайтарылган угольниклар бар ич, аларны куегыз,— диде Сафин таләпчән тавыш белән.

— Алар газ кертү өчен дә җитми.

— Аңа кадәр тагын табарсың, монда эш беренче чиратта.

— Алай икән, бүген форсункалар әзер булыр. Тик газны ашыктырмагыз.

— Аны мин түгел, халык ашыктыра.— Сафин аңа усал карап алды.— Ярар, ул хакта аерым сөйләшербез.— Ул бүлмәдәгеләргә күз йөртеп чыкты.— Завод буенча бөтенесе ачыкланды шикелле. Инде сабантуй программасы белән дә танышып үтик. Гамир Садыйкович, аңа хәзерлек ничек бара?

— Спорт төрләре, уеннар буенча җаваплы кешеләр билгеләнгән. Көрәш, концерт программасы буенча да хәзерлек бара. Кирәк икән, аларны аерым тыңлый алабыз.

— Комиссия членнарының бәлки сорау, үтенечләре бардыр? — Сафин алар утырган якка карап әзрәк көтеп торды.— Юк икән һәркем үз урынында булсын. Бу безнең өчен иң киеренке атна. Үзенә йөкләнгән эш өчен һәркем шәхсән җавап бирәчәк. Сораулар юк икән, эшкә!

* * *

Рәис кабинеты бушады, анда райком инструкторы Җәвидә Низамова гына калды. Җәвидә колхоз партия оешмасына кураторлык итә. Моннан тыш Хәлимов аны бу кохозга җәйге чорга райком вәкиле итеп тә билгеләгән иде.

— Йә, комиссар, эшне нидән башлыйбыз? — Сафин юри аңа тартгереп алды, үзе сак елмайды.— Безгә нинди яңа күрсәтмәләр алып килдегез?

Җәвидә, Хәлимов аңа зур вәкаләтләр бирсә дә, Сафин янәшәсендә үзен табадагы балык хәлендәрәк сизә иде. Бу юлы да рәиснең чәнечкеле сүзләрен игътибарга алмаган булып кыланды, җитди генә итеп сүз башлады.

— Мин сезнең эш алымын күзәтеп утырдым.— Җәвидә утырыш барышында күңелендә туган тәэсирләре белән уртаклашты.— Кирпеч заводы директорына, мәсәлән, каты да кагылмадыгыз кебек, әмма ул үзенә нинди басым төшкәнен сизеп тора. Назыйм да үзен киеренке тота. Гамир да шулай ук. Миңа бүтән персидәтелләр үткәргән нарядларда күп катнашырга туры килде — мондый киеренкелекне генә сизгәнем булмады.

— Кара, кара.— Сафин кызыксыну күрсәтеп, гәүдәсе белән алгарак иелеп утырды.— Җәвидә дә уйланырлык күзәтүләр ясап килә икән. Бу кадәре минем өчен яңалык әле, көтмәгән идем. Йә, минем алардан нинди аермам бар?

— Талиповны һич аңлый алмадым. Бригадирлар, белгечләр бирәр эшлекле тәкъдим кертсә, асылына төшенмичә, ачуланып ташлый, кешенең күңелен биздерә иде. Күпмедер узгач, нигә аны гамәлгә ашырмыйсыз дип бәйләнә, әмма көткән нәтиҗәгә ирешә алмый иде.

— Ә Гәрәев?

— Ул өстән ни кушсалар, шуны үтәүче иде. Мөстәкыйль эшләргә теләүче булса, аның белән килешә алмый, теләсә нинди юл белән аннан арыну чарасын күрә иде.

— Әйе, Гәрәевтә ул сыйфатлар тулы чагыла: һәрчак ул гына хак,— диде Сафин аның белән килешүен белдереп.— Моннан тыш ул хәйләкәр дә. Үзбаш эшләргә яратуымны белгәч, беренчегә мактап, мине тизрәк үз яныннан озатты.

— Үзеннән күп белүчене, билгеле, яратмый инде,— дип куйды аны җөпләп Җәвидә.

— Мин исә цех башлыкларын, бригадирларны мөстәкыйль эшләргә өйрәтә алмый интегәм. Хәрбиләр шикелле гел боерык үтәргә генә күнеккәннәр. Талипов аларны мөстәкыйль фикерләүдән читләштереп бетергән. Зәбиров, мәсәлән, әмердән башка, кайсы эшне алдан үтәргә кирәген белмиме? Белә, әлбәттә. Ләкин икеләнә: ул кушса, мин аның күрсәтмәсен үзгәртермен шикелле тоела.

Райком белән хәбәрләшә торган телефон аппараты шалтырый башлады. Сафин төребкәне кулына алды.

— Сафин тыңлый... Исәнмесез, Хәким Нурович... Эшләр болай әйбәт кенә бара...

Элемтәдә беренче секретарь иде. Җәвидә аның рәис белән нинди темага сүз алып баруын дикъкать белән тыңлады. Сафин белән янәшә генә утырганлыктан, беренченең һәр сүзе аңа ачык ишетелә иде.

Ул, гадәт буенча, терлекчелекнең торышын сорашудан башлады. Колхозда сөт сату планын үтәү белән хәл быел да катлаулы иде. Шул хакта рәискә аның белән җитди аңлашырга туры килде.

— Быел планны без үти алмыйбыз әле,— диде Сафин акланып тормастан.— Фермада брак сыерлар күп. Өстәмә сыерлар алырга абзарда урын юк. Киләсе елга ферманы киңәйтү, яңа абзар салу кирәк безгә. Шунда гына планны тотрыклы үтәп барачакбыз.

— Колхоз сөте белән үти алмасаң, күрше Куйбышев өлкәсе авылларыннан май сатып алып тапшыр,— диде кырыс тавыш белән Хәлимов.— Әмма план үтәлгән булсын. Гәрәев әнә шулай эшли.

— Бу бит күз буяу, Хәким Нурович,— диде Сафин.— Бер кило майны ун сумга алып, өч сумга сату.

— Үз сөтең булмагач, шулай туры килә.— Хәлимов, Җәвидә аны сынап өлгерде инде, сүзен һич тә бирмәячәк, үзенекен турылаячак. Ленар аңа ни дияр бит? Сүз куертмаса ярый инде.

— Без быел планны үти алмыйбыз.— Рәис тә үзенекен дәвам итте.— Аның каруы киләсе елга яңа абзар өлгергәч, быелгы бурычны да артыгы белән тутырачакбыз.

— Син...— Хәлимов китапка язылмый торган сүз кушып җибәрде,— бер аягың колхозга кергән, икенчесе юк әле, үз характерыңны күрсәтмәкче буласың.

— Сез мине куйганда «мөстәкыйль эшләргә ирек бирәбез», дидегез, Хәким Нурович.— Сафин беренченең сүзенә йомшап төшмәде, элекке фикерендә кала бирде.— Килешкән срок әле узмаган.

— Теләгәнчә эшлә, анысы синең эш,— диде Хәлимов бастырып кына.— Безгә планны үтә. Теләсәң ничек!

— Хәким Нурович, без быел сабан туе үткәрәбез.— Сафинның бәхәсне тагын да катлауландырасы килмәде, сүзне икенче темага борды.— Шимбә көнне Сезне дә бәйрәмгә чакырабыз.

— Синең...— ул телеңдә еш яңгыраган баягы сүзен кабатлады,— бөтенесе киресенчә: алдан хәл итәсең, аннары безгә хәбәр итәсең.

— Үзебездә үткәрелә торган чараны үзебездә хәл итәсе инде аны.— Сафин салкын канлылык белән сөйләшә бирде.

— Районда минем рөхсәттән башка бер чара да узарга тиеш түгел, Сафин,— диде Хәлимов, тамак төбе тавышы белән. Җәвидә аның кычкырына башларга әзер икәнлеген чамалады. Тик бу юлы зур давылсыз узды.— Үткәрегез.

— Сез киләсезме соң? — Сафин, шайтан тарагымны бир, дигәндәй, моның белән генә дә чикләнмәде, соравын кабатлады.

Беренченең бу сөйләшүдән кәефе кырылган иде, моны Җәвидә яхшы сизде. Хәзер ул йә кычкырып салачак, йә торебкәне ташлаячак. Тик ул ялгышты.

— Карарбыз,— диде Хәлимов килешү тонында.— Алдан әйтеп булмый әле.

— Хәтәр сөйләшәсең беренче белән, бик хәтәр,— диде Низамова — Гәрәев, аңа нинди якын торса да, мондый тонда гәпләшергә батырчылык итми.

— Алар кеше алдында бер, артында икенче төрле. Мин аңа бик якын булырга өметләнмим.

— Бу юлы ул сиңа юл бирде, әмма моның өчен башка төрле ысул белән үчен кайтарачак. Ул үзенә каршы төшкәнне беркайчан кичерә алмый.

* * *

Ашханәдә чәйләп чыккач, Ленар Тирән Күл бригадасына барачагын белдерде. Кирпеч заводында көн саен булса да, Зәбиров белән иртәнге сөйләшү аның тынычлыгын алды. Урында барын яңадан барлыйсы, эшне тизләтү өчен чараларын кабат тикшереп чыгасы иде. Бүтән эше булмагач, Җәвидә тагын аңа иярде.

Формаль санаганда, завод эшли инде, кирпеч сугу ике атналап элек башланды. Аннан чыккан кирпечләрне киптерү амбарларына кертеп, такта киштәләргә тезә баралар.

Завод ишек алдына кергәч, Җәвидә Ленарга тагылып йөрмәскә булды. Машинадан төшүгә, Сафин яндыру миче ягына китте. Ул исә кирпеч сугу цехына юнәлде.

— Исәннәрмесез, балалар,— диде ул русчалап.— Эшләр ничек бара?

Кирпеч сугу өчен шәһәр мәктәбенең тугызынчы класс укучылары килгән иде. Алар эшне уңышлы гына башлап җибәрделәр.

Кирпеч сугу аның өчен кызыклы эш тоела. Трактор үзле сары балчыкны махсус чокырчыкка этеп төшерә. Икенче яктан ком агып төшә, шулар бергә катнаштырып изелә. Әзер измә махсус сызык буенча пресскискечкә керә.

Җәвидә транспортер тасмасы буенча килә торган кирпечләрне вагонеткага төяп торучы кызлар янына тукталды. Алар килгән һәр кирпечне чиратлашып алып баралар, вагонга рәтләп тезәләр, шул арада күзләренә төшеп йөдәткән чәчләрен кул сырты белән генә артка сыпырырга да вакыт табалар.

Җәвидә завод төзелеше белән даими кызыксынып килде. Завод проектын Камил үзе әзерләде. Сугу цехыннан киптерү амбарларына, аннан яндыру миченә эзлекле кертә баруны, Акташтагыдан аермалы буларак, ул үзе тәкъдим итте. Хәзер аның вариантының отышлыгы һәркемгә аңлашыла. Эчтән ул элекке ире Камилне кызганып куйды: башы бар, кулы алтын, тик эчсә — акылы юк, холкы яман.

Вагон этүче кызларга кушылып, ул да киптерү амбарына килеп керде. Амбар бик гади итеп корылган. Ул зур китапханәне хәтерләтә: һәркайда озын рәтләр булып киштәләр сузылган, тик аларда китап урынына — кирпечләр.

Икенче, төзелеп бетмәгән амбар янында берничә ир-ат шпал өстенә яңа рельслар беркетеп тора иде.

* * *

Камышлыда сабан туе унда гына башланса да, райком секретаре Хәлимов Нәбиевкә иртән алтыда ук китәчәкләрен искәртеп куйды: өлкә комитеты инструкторы беренче секретарының эш көне кайчан башланганны белеп калсын; югыйсә, Казандагылар эшкә килгәндә район җитәкчеләре эшләп арган була инде.

Нәбиев килешенгән вакытта аның кабинетында иде инде.

— Йә, Наратлы районыннан алган тәэсирләрегез ничек? — Машина кузгалып киткәч, Хәлимов кунакка шул сорауны бирде. — Ошадымы безнең яклар?

Нәбиев, шушы район партия оешмасына кураторлык итүче инструктор, монда беренче тапкыр килде. Хәлимов аның бабасының өлкә җитәкчеләре белән тыгыз элемтәдәге галим икәнен белә иде. Нәбиевнең терәге нык, аның белән элемтәләрне нормаль сакларга, акрынлап ныгыта барырга кирәген әллә кайчан билгеләп куйган иде Хәлимов. Нәбиев Сафинның курсташы икәнлеген, ул аны сабантуйга чакырганын белгәч, үзе дә барасы итте. Сафин, йөгән кимәгән кырыкмыш тай, кирәген-кирәкмәгәнен ычкындырмасын тагын. Дөрес, Сафин янында аның үз кешесе — Низамова бар, әмма...

Нәбиев җавап бирергә ашыкмады. Моны сизеп өлгергән Хәлимов ярдәмгә килергә булды.

— Гәрәевта ничек, ошадымы соң?

— Кыр эшләре әйбәт кенә бара, — диде инструктор сак кына. — Терлекчелек планнарын үтәү буенча да борчылырлык урын күренми.

— Ә борчылырлык нәрсә генә бар соң? — Хәлимов сагая калды. — Ул бөтен республикага үрнәк булырлык. Председателе — СССР Югары советы депутаты.

— Мин анда сөтчелек комплексы белән таныштым, — дип куйды өлкә вәкиле.

— Заманча шәһәрчек. — Хәлимов тагын түзмәде, үз фикерен кыстырып куясы итте. Кала түрәсенең үзен күрсәтәсе килә, ахрысы, кимчелек эзләгән була. Әмма ун елдан артык беренче секретарь кәнәфиендә утырган Хәлимовны бу гына куркытмый, билгеле, каладан килгән зуррак түрәләр белән дә көрешкәне, аңлашканы бар аның. Бусы белән дә уртак тел табасы алдан ук ачык. Вакыты җиткәч, бөтенләй икенче төрле сайрый башлаячак әле Нәбиев. Әмма вакыйгаларны ашыктырырга теләми иде, беренче сорады: — Аның нәрсәсе ошамады?

— Аны төзү өчен күп акча тоткансыз, көч куйгансыз, әмма сөтчелек комплексы тулы куәтенә файдаланылмый. Мәсәлән, саву цехы корылган, ләкин ул эшләми. Силос башнялары да файдаланылмый.

— Безнең район өчен чынлап та удар эш участогы булды ул. — Хәлимов сүзне кайдан башларга белә иде. — Колхозара төзелеш оешмасы биш ел гел шунда гына диярлек эшләде. Секретарь артына борылды, кулын кәнәфиенә атландырып куйды, үзе Нәбиевкә туры карады. — Дөрес, безнең шартларда кайбер нәрсәләрне тулы файдаланып булмый. Әмма алар берсе дә буш тормый. Сез әйткән саву цехы, мәсәлән, ярдәмче бина итеп кулланыла. Алары да кирәк бит. — Хәлимов тукталып торды, әңгәмәдәшенең сүзен көтте. Җавап ишетмәгәч, ышанычлы рәвештә дәвам итте: — Ләкин шуны да онытмаска кирәк, Шәүкәт Сабирович, КПСС Үзәк Комитетының махсуслаштыру турындагы карарына безнең район беренчеләрдән булып конкрет эш белән җавап бирде. Әйтегез әле, андый комплекслар тагын ничә районда бар?

— Анысы дөрес.— Нәбиев райком секретареннан бу кадәр үк кискенлек көтмәгән иде, йомшап төште.— Мин моны, анда кимчелекләр дә бар әле, дип кенә искәртүем.

— Шундый зур объектны корганда андый гына житешсезлекләр булыр инде.— Әңгәмәдәшенең фикере үзгәрүен Хәлимов та сизде, тавышы басылды.— Әмма мине икенче нәрсә кызыксындыра: бу комплекска карата Сездә алдан ук кире фикер туган сыман. Телефон белән сөйләшкәндә дә һаман гел комплекс турында төпченә киләсез ич.

— Алай уйлавыгыз ялгыш фикер, Хәким Нурович.— Нәбиев тагын аның алдында кыен хәлгә калмас өчен ашыгып ачыклык кертергә мәҗбүр булды.— Үзем күрмәгән комплекс турында алдан нәтиҗә чыгарганым булмады. Комплекска дистәләрчә миллион акча тыктылар, алар үзен акламый дип күп яздылар. Шуның өчен үз күзләрем белән барып күрдем.

— Кемнәр яза соң?

— Анонимщиклар, билгеле.

— Аноним хатның урыны чүп савытында.

— Ләкин алар хаклы, Хәким Нурович,— диде өлкә вәкиле.— Саву цехы эшләми, силос башнялары буш тора.

— Кимчелексез булмый инде,— дип килеште беренче.— Аның каруы без республикада беренче төзедек. Так что, син анда шефларың алдында бу хакта бик киңәймә.

Вәкил аның белән бәхәсләшеп тормады.

— Сафинның эшләре ничек бара, Хәким Нурович? — дип сорады ул бераздан.

— Баргач үзең күрерсең,— диде, аннан юлдашының өлкә вәкиле икәнен исәпләп, шомартып җибәрде:— Мин алдан ачыклап куйсам, сиңа кызыксынырга да берни калмас.

— Җитәкче буларак аны белмим,— диде инструктор,— әмма агроном буларак, аңа тиңнәр бик сирәк.

— Ничек алай? — дип сорады Хәлимов белмәгән булып.

— Берчак профессор Шәрәпов безне институтның тәҗрибә хуҗалыгына алып барды һәм сораша башлады: кайсы культура кайчан чәчелгән? Без дәшмибез, чөнки алай ачыклавы бик кыен. Ленар билгеләп чыкты, көнгә-көн туры килде. «Шөкер, өйрәткәнем бөтенләй бушка китмәгән икән әле, арагызда җиргә хуҗа булырлык бер кеше бар икән»,— дип безне оялтты.

— Әйе, ул яктан аңа сүз әйтергә урын юк,— дип килеште район җитәкчесе.— Җирне чынлап белә ул.

«Таң» колхозына керә торган юл аермасында аларны Сафин һәм ярышташлары Гәрәев каршылады. Хәлимов гадәт куйган: һәр рәис аны шулай юл чатында каршылый. Гәрәевка да шунда булырга алдан ук кисәткән иде.

— Син кирпеч заводыңны кайчан эшләтә башлыйсың инде? — Кул биреп күрешүгә, Хәлимовның беренче соравы шул булды.

— Без анда кичә беренче тапкыр кирпеч яндырып карадык,— диде Сафин.

— Син нәрсә...— Хәлимов шунда ук кабынып алды.— Нигә миңа хәбәр итмәдегез?

Сафин аңа гаҗәпләнеп карады.

— Бу хакта Харисов сезгә хәбәр иттем диде.— Сафин беренченең күзенә туры карады.— Аннан завод безнең өчен генә мөһим объект бит, Хәким Нурович.

— Тыйнакланып маташма,— дип каршы төште Хәлимов.— Район колхозлары арасында заводы булган бердәнбер хуҗа син хәзер. Башкалар да синнән үрнәк алырга тиеш. Шунлыктан, сабантуй узгач, рәсми ачу үткәрәчәкбез. Районның бөтен җитәкчеләре катнашында.— Ул артына борылып карады.— Гәрәев, кайда син?

— Мин монда,— диде Гәрәев һәм аның каршына чыгып басты.

— Син... ничә елдан бирле кирпеч заводы төзү турында хыяллана-сың.— Хәлимов аңа каш астыннан гына карап торды.— Гогольның Маниловы шикелле.— Ул Нәбиевкә сак кына төртеп алды.— Ну сөйләнүдән ары узганың юк. Сафин менә бер ел тулыр-тулмас эшли, заводын хутка да җибәрде.

— Утка чыдам кирпеч табып булмый,— дип акланды Гәрәев.— Мастеры да юк.

— Менә Сафиннан сорашасың калган,— дип төрттерде Хәлимов.— Ул синең кебек минем авызга гына карап тормады, юлын үзе тапты.

— Ленар Салихович, син ничек алдың ул кирпечләрне?

— Бер машина кирпеч — бер шелтә,— диде Сафин.— Бәясе шундый.

— Минем курсташ үгезне мөгезеннән эләктергән, димәк.— Әлегә кадәр тыңлап кына торган Нәбиев сүзгә кушылды.— Дөрес башлагансың, Ленар, шулай дәвам ит!

— Әйдә, минем машинага күчеп утырыгыз.— Хәлимов өлкә вәкиленә карап куйды.— Колхоз белән танышуны заводтан башлыйбыз инде, Шәүкәт Сабирович.

— Тик ул бүген эшләми,— диде Сафин ашыгып.— Сабан туе, бар халык бәйрәм итә.

— Алардан башка да карый алабыз без. Килештекме? — Хәлимов ниятеннән баш тартмавын сиздерде.— Заводны күргәнебез бар.

Сафин завод белән таныштыруны балчык измәсе катнашмасы әзерләүдән башлады. Аннан сугу станогын карадылар, линия буенча киптерү амбарларына, яндыру цехына килеп җиттеләр. Рәис эш барышына кагылышлы аңлатмаларны бирә барды.

— Запас рельсларың да калган икән әле.— Гәрәев мичтән тышкы якта яткан шпал, рельсларга күрсәтеп.— Боларын миңа бирәсеңме әллә, Ленар Салихович?

— Монда әле безнең яндырылган кирпеч саклау амбары да булачак,— дип аңлатма бирде Сафин.— Аңа хәзергә кул җитмәде. Көзгә кадәр салачакбыз. Шуның материаллары болар.

— Рельс, шпалларны мин дә сорап караган идем, сатмыйбыз диләр.— Гәрәев сораша бирде.— Сиңа биргәннәр менә. Ничек, танышлык беләнме?

— Мине дә колач җәеп көтеп тормыйлар иде анда,— диде Сафин.

— Икәү генә сөйләшербез әле, бәйрәмнәр үткәч.

— Син, егеткәем, исеңдә тот, бөтенесе законный булсын.— Хәлимов Сафинга кырын карап куйды.— Югыйсә, үзең беләсең, законны саклаучылар шәфкать күрсәтмәс.

— Майламасаң, материал табып булмый, Хәким Нурович.— Сафин яшереп-батырып маташмады.— Әмма алар барысы документлар белән рәсмиләштерелгән.

— Ә мичен кем ясады? — Башкалар тынып калганны күргәч, Гәрәев янә сүз катты.

— Проектлаучысы, салучысы да Камил Низамов.

— Нинди Низамов ул? — Гәрәев аңламады, сорарга мәҗбүр булды.

— Сезнең элекке шофер. Җәвиданең элекке ире.

— Ул мич чыгара беләме? — Кем икәнлеген ачыклагач, Гәрәев гаҗәпләнә калды.— Ничектер моңа ышанасы килми. Алкоголик бит ул.

— Әмма аек чагында башлы егет ул. Төзүчеләр институтының дүртенче курсыннан киткән. Менә дигән архитектор чыккан булыр иде үзеннән.

— Институттан куылганын мин дә ишеткән идем,— диде Гәрәев исе киткән кыяфәттә.— Мин аны механическийдан дип торам. Аны кире бир син миңа, Ленар Салихович. Завод салганчы төзүче инженер итеп алырмын үзен.

— Үзе белән сөйләшерсез инде.— Сафин мәсьәләгә карата фикерен ачыклап куйды.— Тели икән, барсын.

— Син риза булсаң, бармый кая китсен.
— Минем ризалыкның бернинди роле юк монда.
— Ничек инде? — Гәрәев йөзендә гаҗәпләнү чагылды. — Колхозчыларыңны үз кулыңда тотмасаң, нинди председатель инде син?
— Син тәҗрибә алмашырга үзең генә килерсең, Гәрәев. — Ике рәис арасындагы сүзнең озакка сузылуы райком секретаренең эчен пошырды, әңгәмәгә чик куйды. — Йә, үзеңнән арткан кирпечне кая куярга җыенасың, Сафин?
— Быел ярты миллионнан артык яндырып өлгерсәк ярар иде, — диде Ленар уйланып. — Киләсе елда миллионга житкерергә исәп тотабыз. Кирпечкә сорау күп: ферма каралтылары, алардан да элек торак йортлар төзисе. Колхозда эшче көчләр житми, фатир булса, яшьләр авылда калырга риза. Шәһәрдән кире кайтырга теләк белдерүчеләре дә бар.
— Әйе, синең төзисе күп, — дип килеште аның белән беренче секретарь. — Заводыңны үзеңдә корып дөрес эшләдең. Инде иренмичә төзергә генә.
— Бу уңайдан Сезгә бер үтенеч бар иде, Хәким Нурович. — Секретарьның кәефен чамалап, Сафин форсаттан файдаланып калырга ашыкты. — Камышлыда колхозара төзелеш оешмасының филиалын оештырырга. Оешма башлыгы Хафизов белән бу хакта сүз булды, ул риза.
Көтелмәгән бу үтенеч Хәлимовка ошамады, ул кашларын җыерып куйды.
— Нинди тузга язмаган фикер ул? Нинди филиал ул тагын? — диде төксе генә. — Хафизов шулай һәр колхозда филиал ача башласа, оешма таралачак дигән сүз. Мин аңа моны төшендереп күрсәтәчәкмен әле!
Фикерен дә тыңлап бетермәстән беренченең каршы төшүе үзе өчен күңелсез сөйләшүгә китерүен чамаласа да, Сафин башлаган темага әңгәмәне дәвам итәсе булды. Өлкә вәкиле барында Хәлимов барыбер тугарылып төшмәс. Нәбиевнең, кирәк була калса, яклаячагына да ышана. Идеясенә Хәлимов ничек караса да, башлаган фикерен әйтеп бетерергә тиеш бит ул.
— Һәр колхозда түгел, бездә генә, — диде Сафин тыныч кына.
— Сез нәрсә, аерым шәп колхозмы? — дип дорфа гына бүлдерде аны беренче секретарь.
— Хафизовта безнең колхоздан 27 кеше эшли, аларны иртән махсус автобус килеп ала, кичен китереп куя. Алар иртә белән планерка беткән җиргә Нарατлыга баралар, аннан кабат Камышлыга кайталар. Алар эшкә керешкәнче төш житә. — Сафин Хәлимовның үзенә ачулы карап торуын сизсә дә, ашыга-ашыга сөйләвен белде: — Бездә торып кына төзесәләр, күпме вакыт эшкә сарыф ителәчәк, күпме ягулык һәм башкалар янга калачак.
— Син моны үз каланчаңнан чыгып кына бәялисең, билгеле. — Рәис кыска пауза ясаган арада Хәлимов үз фикерен такт белән генә кыстырып куйды. Нәбиев алдында кискенлек белән аны бүлдермәде. — Алар монда гына эшләсә, башка колхозларда төзелеш бөтенләй тукталып калсынмы? Сине бер үз колхозың гына борчый, мин исә район масштабыннан чыгып эш итәргә тиеш.
— Хәким Нурович, сез мине тыңлап бетермәдегез бит әле. — Сафин беренченең кәефен бозасын чамаласа да, үҗәтлек белән дәвам итте. — «Таң» колхозы районда иң эре хуҗалык. Биредә төзисе нәрсәләр күплеген үзегез дә әйтеп, алай гына да түгел, таләп итеп тә торасыз. Елына бернчә объект төзү зарури. Мин тәкъдим иткән вариант, экономик яктан отышлы булу өстенә, төзүчеләр арасында торак мәсьәләсен хәл итүгә дә булыша. Төзүчеләрнең күбесе авылда калырга риза. Төзү оешмасында торакка чират берьюлы егерме кешегә кими.
— Ә башка колхозларда кем төзи? — Хәлимов күзен-кашын җимереп аңа карады. — Шул ягын уйладыңмы соң?

— Бездә бит Хафизовның бер бригадасы гына.— Сафин һаман бирешергә уйламады, фикерен дәлилләүне белде.— Анда берничә йөз тәзүче эшли. Башкаларны башка колхозларга җибәрергә. Минемчә, хезмәтне рациональ оештыруның иң отышлы юлы шул.

— Минемчә, акыллы фикер,— дип куйды Нәбиев.

Хәлимов аңа күз агы белән генә карап алды да, рәискә таба борылды.

— Менә нәрсә, үскәнем.— Хәлимов ирен чите белән чак кына елмайды. Соңгы сүзе кимсетү өчен әйтелгән иде: рәисне малай-шалайга тиңләп авызын каплыйсы итте. Үзе Сафинны күзәтте: шуны аңлармы икән?! Аның йөзенә кызыллык җәелүен күреп канәгать тавыш белән өстәлде:— Син, әйдә, һәр эштә үзеңә киртек киртләргә тырышма, ул барып чыкмас. Гомуми нормалар, законнар нигезендә эшлә. Шул нормаларга сыеша алмасаң, райком каршында партия уставы буенча җавап тотарга туры киләсен онытма.

— Бу хакта беренче шелтә чәпәгәндә үк кисәттеләр инде, Хәким Нурович.— Сүзләре райком секретареның канына тоз саласын белсә дә, Сафин дәшми кала алмады.— Мин үземнең эшләрем, адымнарым өчен җавап тотарга һәрчак әзер.

Хәлимов бәхәс куертып торуны теләмәде. Башкалар да дәшмәде.

Алар янына «Москвич» белән Харисов килеп туктады.

— Йә, комиссар, синең эшләр ничек?— Хәлимов парторгны баштанаяк күздән кичерде.

— Сабан туена әзерләнәбез, Хәким Нурович,— диде Харисов.

— Ул — сабан туен оештыру буенча җаваплы.— Сафин, беренченең аңа бүтән сораулары булмавын чамалагач, үзе сүз катты.— Сүзегез булмаса, аны җибәрикме әллә, Хәким Нурович? Бәйрәмне тиешенчә әзерләсен.

Хәлимов Сафинга күз сирпеп алды һәм бер сүз белән генә җавап кайтарды:

— Барсын.

Хәлимов «Таң»га, сабан туе караудан бигрәк, берничә мәсьәләне хәл итү өчен килгән иде. Колхозда эшләр барышын үзе тикшереп кайтуны максат итеп кую өстенә, башка төр планнары да бар иде. Күңелендә Харисовны «Каенсар» колхозына рәис итеп күчерү фикере туды. Парторг үзе аңа бүтән эш бирүне сорап керде, Сафин белән килешә алмавыннан зарланды. Сафинның парторгны санга сукмавы турында башкалар авызыннан да ишеткәне бар — аларны аерырга карар кылды. Колхозга яңа партком секретаре кирәк булачак. Бу мәсьәләне Сафин белән киңәшеп хәл итү кирәк, югыйсә Гамир кебек тагын алмаштырырга туры килүе ихтимал. Бу мәсьәләләрне, гадәттә, райкомның инструкторлары, бүлек мөдирләре аркылы хәл итәләр, аңа шуннан соң гына катнашырга туры килә торган иде. Бу юлы барысын ул үз кулына алырга булды. Сафин ачык, төгәл исәп белән эш йөртә. Бусы бер хәл, көндәшен колхоздан күчерүгә ул үзе ничек карар? Үзен өнәмәсә дә, бу мәсьәләдә Сафин фикерен белешергә тели иде Хәлимов.

— Без Харисовны сездән алырга булдык,— диде ул Ташлы яр җәйләвен карап йөргәндә. Үзе Сафиннан күзен алмады: рәис моны ничек кабул итәр?— «Каенсар»га хуҗа кирәк бит. Син моңа ничек карыйсың?

— Анысы мине кызыксындырмый.

— Ничек инде алай?— диде беренче секретарь төксе генә. Тавышында шелтәләү яңгырады.— Сине санга санап киңәшәләр, ә син?!.

— Минем фикер кызыксындыра икән, әйтәм, тик ул Сез көткәнчә булмаячак. Мин көшкелләнергә күнекмәгән.

— Көшкелләнмә, дөресен әйт.

— Отышлы вариант түгел.

— Үзең аны яратмагач, шулай санийсың, димәк.

— Ул — аппаратчы,— диде Сафин, икеләнеп тормастан.— Райкомда теләсә кайсы бүлекне җитәкләргә мөмкин. Әмма колхоз йөген тартырга әзерләнмәгән ул.

— Ну и ну! — Хәлимов чыраен сытты.— Шулай саныйсың икән, фикереңне исбатлап та күрсәт инде.

— Гамир Харисов кешеләрне куркытып кына эшләтә ала. Ләкин андый замана узды.

— Чү, чү, егет! — Башлык аны шундук бүлде.— Син үзең дә шул калыптан тегелгән бит.

— Әйе, без барыбыз да бер җептән үрелгән чыбыркы. Ләкин мин үз алымымның яраксызлыгын, зарарлылыгын күрәм, аңа соңгы чик буларак барам. Үгетләп үтәмәгәнгә боерам. Моның мин теләгән нәтиҗәгә китермәгәнен беләм, җитәкчелек итүнең башка юлларын тапканчы коллективны туплап тоту өчен кулланам. Харисов боларны аңлаудан бик ерак тора, боеруны төп эш алымы итеп саный. Безнең аерма шунда. Ул кушканны үтәүче буларак билгеле. Колхозда башыңны эшләтсәң дә, бик таманга килә әле. Һәм тагын бер нәрсәне истән чыгарырга ярамый. Әгәр эшең барсын дисәң, ашчы казан янында кайнашкан кебек, колхозның да гел үзәгендә булырга, халык белән бергә яшәргә, уй-теләкләрен белеп торырга кирәк. Гамирда ул сыйфатлар юк һәм моны аңларга теләге дә юк. Ул монда килеп-китеп эшләп йөрүче вакытлы кеше. Шулай булгач, аны никадәр тизрәк алсагыз, шулкадәр файдалырак.

Сафин элек тә, хәзер дә Харисовтан арынырга теләвенең төп сәбәбен — Җәвидә әйткәнен ача алмый иде. Хәер, инде мәсьәләгә бер ачыклык кертелгәч, бу кадәресе дә бик җиткәнен аңлый иде.

Хәлимов күпмедер уйланып торды. Рәис белән килешә алмавының сәбәпләре бар, ул да аны үзендә генә сер итеп саклый иде.

— Да, сезнең икегездә дә амбиция көчле, бер казанга сыя алмыйсыз. Сезне аеру — иң кулай юл. Ярар, бу мәсьәләне азакка хәл ителгән саныйбыз. Инде партком секретарена кемне тәкъдим итәсез?

Сафин әңгәмәдәшенә янә сәер карап алды.

— Моны коммунистлар үзләре хәл итсен.

Беренче секретарь, канәгатьсезлеген сиздереп, кашларын сикертте.

— Син, әйдә, һәр юлы минем белән качышлы уйнама.— Ул ачуын яшереп тормады.— Тегесе ярамый — яңасын инде үзең сайлап аласың. Ләкин белеп тор, сиңа киләчәктә дә партия кадрлары белән уйнарга ирек куелмас. Моны алдан ук кисәтәм!..

* * *

Хәлимов партком секретарьлыгына Сәйфетдинованы куюны күздә тотып килде. Теге чакта, җыелышта йөгәннән ычкынган, хәтта аның сүзенә дә колак салмаган, аларның ярты көн дәвамындагы үгетен колакларына да элмәгән халыкны тәртипкә чакырып, райком теләгән кешене сайлата алган хатынның зирәклеген, акыл белән эш йөртүен шунда ук күреп алды, үзенең мыегына чолгап куйды. Кайту белән анкетасын соратып алды. Университетның тарих бүлеген тәмамлаган, партия мәгарифе челтәре пропагандисты. Ронодан да аның турында гел җылы сүзләр генә ишеттерделәр. Күрмичә торганнар, бүгеннән әзер партия хезмәткәре.

Аны шундук резерв кадрлар исемлегенә кертеп куярга боерды. Райкомолда икенче секретарь кыз кияүгә чыккач, аны чакырттылар. Җай чыгу белән партия эшенә күчерүне күздә тоттылар. Ул, балалары яшьлеккә сылтап, баш тартты. Аның дәлилләре нигезле дә иде, андый хатын нинди комсомол башлыгы булсын инде. Бу юлы артык кысмадылар да, райком игътибарында икәнлеген сиздереп кенә куйдылар.

Ул аны җәйгә чыккач күчерергә исәп тоткан иде. Ләкин күздә тотылмаган хәлләр бу планга үзгәреш кертергә мәҗбүр итте. Харисов үзе, хатыны аркылы да «Таң»нан күчерүне сорап йөдәтә башлады. Сәбәпләре янә рәискә бәйле иде. Гамир үзара килешә алмауларын мәктәптән үк бер-берсен өнәмәүләре белән аңлатты. Сафин да үз дәлилләрен тапты, күчерүне яклады.

Авырлык белән китергән, инде эшне җайга салып килә торган рәисне алмаштыру турында уйларга да туры килми. Ул янә парторг турында баш вата башлады.

Шулчак аны мавыктыргыч идея биләп алды. Хәзер бу колхозның алдагысы өметле, аны киләчәктә Казаннан килүче-китүчеләргә күрсәтү өчен база хуҗалыгы итәргә була. Бу кадәренә ул шикләнмәде. Һәм бу колхоз икенче ягы — хатын-кыз парторгы белән дә аерылып тора ала бит. Андый хуҗалыклар Татарстанда да бик сирәк, бармак белән генә санарлык. Моның өчен хәзерлекле кадры да урында.

Район газетасы мөхәррирен чакырып, Сәйфетдинованың эш тәҗрибәсен киң яктырткан мәкалә әзерләргә кушты. Бусы җәмәгатьчелек фикерен әзерләп кую өчен кирәк иде. Элек авылда гына билгеле укытучының исеме район күләмендәге киңәшмәләрдә мактап телгә алына башлады.

Сафинның аңа каршы килмәячәге алдан ук төсмерләнә иде. Моны ул, ни өчен икәнен ачмастан, үзеннән дә белеште, башка юллар белән дә тикшерде.

Бүген янә парторг хакында сүз кузгаткач, Сафин авызыннан нәкъ аның фамилиясен ишетәсенә алдан ышанып килде. Рәис сәбәп таба башласа, аны бөгәргә әзер иде. Шуңа күрә бу эшне ярдәмчеләре аркылы башкартмыйча, алдан үзе алынды. Көтмәгәндә Сафин аны акылга утыртты.

Ул моның өчен Сафинның үзен дә «өйрәтеп алырга» әзер иде, ләкин бу мизгелдә кәефләрне бозу урынсыз санады: рәис аның көпчәгенә таяк тыгарга, планын гамәлгә ашыруга киртә ясарга мөмкин. Эредән кубып сөйләшмәүнең тагын бер сәбәбе — янында кунак бар, аңа сиздерергә ярамый. Казанга кайткач, җитәкчеләре алдында сүз кузгатуы бар. Ул Сафинның шәриктәше, аның файдасына сүз тамызуы бик мөмкин. Ә рәис белән бу кыю фикере өчен башка урында, башка вакытта теләгәнчә «аңлашыла» ала.

Колхоз җитәкчесенең фикере аның планнарына каршы килми дә бит әле. Аны гамәлгә ашыруны ул, үз мөмкинлегеннән баш тартып, аның ихтыярына куйды. Бу эшне ансатландыра да әле. Харисов аркылы берәрсенә аны күрсәтергә әйттереп кенә куясы.

Тик аңа кадәр чибәр хатынның ризалыгын алып куясы бар. Бусы аның өчен катлаулы эш саналмый, ул кушкач, хатын беркая борыла алмый. Сафин кадәр Сафинны бөккәнне, ул хатынны гына ихтыярына буйсындыру — вак эш.

— Исәнмесез, Гөлфия сеңел.— Райком секретаре аның белән олыларча, ике куллап күреште, дустанә елмаеп куйды.— Кәефләрегез ничек?

— Бәйрәмчә, Хәким Нурович.

— Сез гел алгы сызыкта,— диде район башлыгы хатынның күңелен күтәрү өчен.— Җыелышта, чөгендер кырында да, инде сабан туенда да.

Харисов алар тынып торган арада үзенең биредә артыклыгын сиздереп алды.

— Мин китим инде, Хәким Нурович. Озакламый бәйрәм башлана, аны ачу миңа йөкләнгән.

Башлык, ризалыгын белдереп, башын кагып алды. Аның төп игътибары укытучы хатында иде хәзер.

— Үзебезгә калса, тырышабыз инде,— дип куйды Гөлфия. Беренче секретарь сүзләреннән аның йөзенә алсулык иңгән иде.

— Яхшы, бик яхшы,— диде Хәлимов.— Йә, сез сайлаткан председатель ничек эшли? — Ул, әңгәмәне тыңлап торучы юкмы икән диптер инде, тирә-ягына күз салды. Якында кеше-фәлән юк иде.

— Сезнең сорауга кыска гына җавап бирү кыен, Хәким Нурович.— Күпмедер уйланып торгач, Гөлфия шулай дип куйды.

— Сез иркенләп сөйләгез.— Хәлимов аны тыңларга әзерлеген сиздереп алды.— Безнең вакыт бар әле.

— Сафин килгәнгә ел да тулмаган әле.— Сәйфетдинова ашыкмыйча һәр сүзен бизмәнгә салып сөйләде.— Беренче карашка үзгәрешләр кирпеч заводы гына булса да, Ленар Салихович халыкны кузгатты.

— Ничек кузгатты? — Хәлимов юри аны аңламаган булып кыланды, гаҗәпләнгән булып күренде.— Нәрсәне күздә тотып әйтәсез?

Гөлфия беренче секретарь тарафыннан үзенә шундый игътибарны күреп җәелеп сөйләп китте.

— Талипов, белүемчә, чөгендер сирәкләргә, ындыр табагында эшләргә халык сорап райкомнан чыкмый иде. Шәһәрдәгеләр безгә килеп эшли, авыл халкының бер өлеше исә балтасын кыстырып шабаш кәсебенә чыгып китә торган иде. Быел шабашчылар авылда калды. Колхозчылар башка эшләргә дә теләп тотындылар. Җитәкче өчен иң мөһиме шул, минемчә.

— Әйе, син моны дөрес тойгансың, Гөлфия.— Хәлимов канәгать булып аны хуплады.— Алай булгач, миңа тагын бер нәрсәне ачыклауда да булыш әле, Гөлфия сеңел, халыкны үз ягына ничек аударды ул? Сафин кызу канлы, таләпчән дә бит.

— Сафин, дөрес, кызу канлы, әмма артын исәпләми генә эшләми инде. Ачу кумый, шунда әйтә, шунда ук яхшылап дәшә. Кешене тиң күреп сөйләшә. Халыкны мал азыгы, утын белән тәэмин итте.

— Талипов вакытында да халык ягулыксыз тормады ич,— Хәлимов белә торып каршы төште.

— Анда аерма зур, Хәким Нурович,— диде укытучы хатын җитди кыяфәттә.— Бер машина утын өчен Талипов үз каршына берничә кабат килергә мәҗбүр итә иде. Бер әмерен үтәмәсәң, шуның белән икенче юлы битәрли. Минем ирем, баш инженер, утынга машина сорап аның каршына керергә шүрли иде. Сафин исемлек төзетте, чиратка куйдырды, махсус бригада оештырды. Син эштә буласың, өең янына утынны китереп бушатып китәләр. Пенсионер, укытучыларны да терлек асрарга үзе үгетли: авылда торып мал асрамаган нинди гаилә ул, янәсе. Талипов ялындырып абруй казанырга тырышты, халык йөз чөерде. Сафин чөгендер эшкәртүдә булышуны сорап мөрәҗәгать иткәч, берәү дә каршы килмәде. Гомерендә беренче тапкыр ир-атлар да кулына китмән алды.

— Аны барыбер усал диләр бит.

— Усал икәнен үзегез дә беләдегез ич, Хәким Нурович, үзегез тәкъдим иттегез.— Гөлфия сак кына елмайды.— Җыелышта мин дә яшермәдем. Усал булса да, халык аңа килә, элекке рәисне күргәндәге кебек, урамның икенче ягына чыгарга тырышмый. Эшләгән кешегә бер дә усаллыгы тими аның.

— Классташ булгач, мактап үтердең инде үзен.— Хәлимов, соңгы сүзләре әңгәмәдәшенең кәефен төшермәс өчен, моны шаяртып әйтүен сиздереп әкрен генә көлемсерәде.

— Юк, мин ни булганын, чынын сөйлим, Хәким Нурович.— Сәйфетдинова аның тонын кабул итмәде.

— Сөйләгез, сөйлә, мин шаяртам гына,— диде Хәлимов та җитдиләнеп.— Һәм тагын бер соравыма җавап бирегез әле. Фермалар кору буенча күпме эш көтә, Сафин кирпечне халыкка таратырга җыена. Сез,— ул беренче тапкыр шулай күплек затында аңа эндәште,— моны ничек бәялисез?

— Мин аның бу фикерен хуплыйм, Хәким Нурович.— Сәйфетдинова эчкерсез иде.— Колхозчылар кирпечтән үзенә йорт сала, авылда төпләнә,

димәк. Үзе сала, туганына булыша, колхоз ярты бәясен түли. Мәүлетов дигән механизаторыбыз нигезен салып та куйды инде. Йорт салырга булмаса, Наратлыга күчәргә җыенган иде. Үзенә булгач, һәркем тырыша, тиз һәм яхшы эшли.

— Әйе-е,— дип сузды Хәлимов.— Күп мәсьәләдә сезнең фикерләр уртак икән. Киңәшәсез, сөйләшәсезме?

— Болар хакында безнең ике арада сүз булганы юк.— Гөлфия бу юлы да ни булганын белдерде.— Мин бит идарәгә еш барып йөрмим, бик сирәк очрашабыз. Анда да хәлләрне өстән-өстән сорашудан ары узган юк. Кыскасы, күңелемнән ни уйласам, шуларны гына әйттем.

— Яхшы,— дип куйды Хәлимов бераз тынып торгач.— Тик бу сөйләшү безнең ике арада гына калсын. Сафин ишетсә, борынын чөя башлар. Масаерга иртәрәк әле аңа.

— Мин Ленарның андый гадәтен сизгәнем юк,— диде Гөлфия.

— Мин гомумән әйтәм,— диде Хәлимов.— Бу сөйләшүне әлегә беркемгә дә ачма. Эштәге сер дигән нәрсәне беләсеңме?

— Сернең андые да буламыни?— Моны Гөлфия чынлап ишеткәне юк иде.— Мин шәхси, хәрби серләрне генә белә идем.

— Инде менә эш серен дә белдегез,— дип янә көлемсерәде Хәлимов.

Сәйфетдинова сәгатенә күз салып алды.

— Сез ашыгасызмы?— Хәлимов аңа сораулы караш ташлады.— Берәр ашыгыч эшегез бармы?

— Минем анда алмашчым бар,— диде Гөлфия.— Хәзер сабан туе башлана. Сез көрәш өлешендә катнашсагыз гына диюем.

— Хуҗалар үзләре анда, алар аны миннән башка да ачарлар.

Тагын күпмегәдер тынып калдылар.

— Әйтегез әле, Гөлфия сеңел, Сафин ни өчен Харисов белән килешми? Алар да классташлар бит, югыйсә.

— Бу мәсьәләдә мин сезгә төгәл җавап бирә алырмынмы, белмим.— Көттереп кенә Сәйфетдинова шулай диде.

— Сез алдагыча, үз фикерегезне әйтегез,— диде Хәлимов.— Әлегә кадәр фикерләрегез төпле булды бит.

Беренче секретарь сорауга ачыклык кертсә дә, уйлана калды Гөлфия.

— Ике араларында шәхси берни дә юк дип саныйм. Минемчә, Гамир Садыйкович бүгенге шартларда үз урынын таба алмый.

— Бу ничек була инде?!— Беренче секретарь әңгәмәдәшен төшенеп җитмәде.— Колхозда парторгның урыны, эше дә билгеле.

— Ленар Салихович цех системасы кертте, һәркемгә бурычны конкрет, төгәл куя, таләп тә итә белә. Хәзер колхозда шулай эшлиләр. Гамир Садыйковичның гадәте — кушканны эшләү, ягъни наряд буенча эшләү.

— Әйдә, әйдә, дәвам итегез.— Хәлим моңа охшаш фикерне Сафиннан ишеткән иде инде, ачыклык кертәсе итте.— Парторгка председатель наряд бирергә тиешме?

— Элек бу бездә шулай иде,— диде Гөлфия.— Харисов, гадәттә, сөтчелек өчен җавап бирә килде. Сафин ул тәртипне үзгәртте. Ферма өчен тулысынча зоотехник җаваплы. Харисовка эш калмады.

— Башка парторглар нәкъ шуннан зарлана,— дип куйды Хәлимов.— Үз эшләрен башкарырга вакыт калмый. Ә ул эш таба алмыймы? Ничектер башка сыймый бу? Парторгка колхозда эш беткәнме?

— Ул җыелышлар үткәрә, беркетмәләрен яза, билгеле. Калган вакытта үзенә урын, эш таба алмый. Сафин исә андыйларны үзенә якын итми, һәркемгә хезмәтенә карап кына бәя бирә. Ике араларындагы салкынлык шуннан килә, дип уйлыйм.

— Кызык,— диде беренче секретарь.— Ә Сез партком секретаренең эшен ничек күз алдына китерәсез?

— Уйлаганым юк,— диде Гөлфия тиз генә.— Бәлки аңа Сафин кулы җитмәгән берәр тармакта эшкә алынырга кирәктер. Әйтик, фермаларда ике сменалы эш оештыру, яисә анда ял бүлмәләре булдыруга алыну

мөмкин. Сафин андый идеяләрне кире кага торган кеше түгел, һәр яңаны тотып алырга омтыла.

— Дөрес фикер йөртәсең, сеңел.— Хәлимов аның фикере белән шунда ук ризалашты.— Шуңа күрә Сезне менә шундый эшләрне оештыра ала торган партком секретаре булырсыз дип саныйбыз да.

— Ми-не-е? — Сәйфетдинова бер мизгел авызын ачкан хәлдә аптырап басып торды. Бу, билгеле, аның өчен һич көтелмәгән яңалык иде, кабатлап сорады.— Мине партком секретаре итепме?

— Әйе, Сезне,— дип ачыклык кертте райком секретаре.

— Күз алдыма да китерә алмыйм.

— Иң мөһиме — халык Сезгә ышана, Гөлфия сеңел.— Хәлимов үз фикерен дәлилләп мисал китерде.— Председатель сайлаганда моны күрсәтте инде. Һәм тагын бер мөһим фактор: Сафин яшь, кызу холыклы. Сез төптән уйлап, ашыкмыйча эш итүчән кеше, педагог. Колхозга аның энергиясен йөгәнләрлек парторг кирәк.

— Ул чыгымчылап куйса? — диде Сәйфетдинова көлемсерәп.— Холкын төрле яклап күрсәтергә мөмкин. Мин генә тезгенли алмам.

— Акыл белән әйткәнне тыңлый ул.— Райком секретаре Сафинның кемлеген белсә дә, ул кадәрен аңа чишә алмый иде. Рәискә сайлаганчы Ленар белән ничек изаланганын Гөлфия белми дип санады, әлбәттә. Үзе өчен җиңелү белән беткән очракны Сафин хатынына сөйләсә генә.— Без сине һәр мәсьәләдә якларбыз, аңа артык узынырга юл куймабыз.

— Булмас эш бу, Хәким Нурович,— диде Гөлфия.

— Ни өчен? — дип ашыгып сорады Хәлимов.— Балаларың янында кайнанаң бар.

— Сәбәбе шунда гына булса, әйтеп тә тормас идем.

— Тагын да җитдирәк нинди сәбәп булырга мөмкин? — Беренче секретарь аның расланмаган дәлилен укытучының җаваплырак эшкә күчергәндәге гадәти тарткалашуы гына итеп санады. Ниятеннән ваз кичәргә җыенмый иде.— Бу безнең әле шартлы сөйләшү генә, ләкин беренче секретарь буларак шуны әйтә алам: мин бер сүз кузгаткач, аннан кайта торган гадәтем юк. Так что, колхозның партия комитетын җитәкләргә әзерлән.

— Ләкин бу мөмкин түгел,— диде Гөлфия авыр көрсенеп.

— Мин Сезнең хакта болай дип уйламаган идем.— Хәким Нурмөхәммәтовичның хәтере калды, йөзе шунда ук төкселәнде.— Сафинны сайлаганда кайнарланып сөйләгәч, аңа таяныч булырлык төпле фикерле кеше итеп санаган идем мин Сезне. Колхозда уңай үзгәрешләр күренә башлагач кына Сез куак астына сызасызмы?

— Мәсьәләне шулай каттый куясыз икән, мин бер серне чишәргә мәҗбүр булам,— диде Гөлфия кызу-кызу.— Без яшь чакта Ленар белән вәгъдәләшкән егет һәм кыз идек. Моны ирем дә белә. Бүген аның янына эшкә күчү безнең гаиләнең җимерелүенә китерәчәк.

* * *

Концерт тәмамланганда сабан туеның да азагы якынлашып килә: ат чабышлары узган, спортчылар бүләкләрен алып бетергән, озын колга башындагы әтәч төшерелгән, бар халык көрәш бара торган түгәрәк тирәсенә бөжралап баскан иде.

Гөлфия дә шунда ашыкты: бәйрәмнең азагын булса да күреп каласы килә бит. Шунда, түгәрәктән читтәрәк, аягына көчкә басып торган ирен күреп алды. Бәйрәм узгач, бирелә үзләре өчен мәҗлес оештырыла иде, шуны көтәргә дә түземлеге җитмәгән, тыгынып, кубенеп куйган, мәгънәсез. Ул аны мәйданнан бушаган әйберләрне клубка илтергә җыенган йөк машинасына этеп-төртеп утыртты да, шоферы Марстан өйләренә кертеп калдыруны үтенде.

Мәйдан тиз бушады.

* * *

Сафин белән Харисов район кунакларын озата киттеләр.

— Әйдәгез, без утыра торабыз,— диде профком рәисе Сираев ике төркемгә бүленеп баскан ир-ат һәм хатын-кызларга карап.— Алар озакламый кайтып җитәрләр.

Хатын-кызлар, бер-берсенә карашып, озын өстәлнең бер ягына урнаштылар. Ир-атлар каршы якка утырды.

— Җәмәгать, бер минутка тынлык.— Сираев һаман утырмаган иде әле, шул килеш стаканын кулына алды.— Хәзер авылларда сабан туе үткәрү онытылып бара иде инде. Быел милли бәйрәмебезне кабат үткәрдек. Сезнең тырышлыгыгыз белән ул күңелле узды. Шулай булгач, аны билгеләп узсак та ярый. Йәле тотыгыз стаканнарыгызны. Бәйрәм хөрмәтенә җибәрик!

Төш инде күптән узган, бәйрәм оештырып йөрүчеләр ачыккан иде, барысы да кашык, чәнечке алды, сыйланырга кереште. Беравык өстәл тирәсе тын торды. Тик бу озакка бармады. Әзрәк тамак ялгап алгач, эчкә җылы йөгергәч, табын җанланды. Сираев стаканнарга тагын эчемлек бүлеп чыкты.

Бәйрәм кызып җиткәч кенә хуҗалар да кайтып төште. Рәис машинасын күргә, Гөлфиянең күңеле күтәрелеп китте. Әлегә кадәр бу мәҗлестә аңа нидер җитми иде.

Ленар гармунның каешларын ычкындырды, иңенә элде һәм уйнап җибәрде. Үзе салмак кына атлый, дәрт белән гармун күреген тарта. Хәтфә аланга, бөтен Чирмешән буена күңелләрне кытыклап, сихри моң тарала. Табын янындагылар, ашау-эчүне бүлеп, тынып калдылар. Гөлфия дә, бар дөньясын онытып, таныш, күңеленә якын көйне тыңлады. Күңеле ерак яшьлек елларына әйләнеп кайтты.

Ленар нәкъ аның каршына кереп утырды. Очраклы идеме бу, сайлап утырдымы, Гөлфия чамалый алмады.

Сафин үзеннән ни көтелгәнен сизеп тора иде, тальянын куймыйча гына торып басты.

— Монда тостлар әйтелгәндер инде,— диде ул стаканын кулына алып.— Мин аларны кабатлап тормыйм. Күңелле үтте бәйрәм. Аны оештыру, үткәрүдә хөрмәтле хатын-кызлар күп тырышлык куйды. Бу тостны мин алар хөрмәтенә күтәрергә тәкъдим итәм.

— Йәле, Гөлфия, гел Назыймга гына бәйрәм димәгән.— Стаканын куйгач, бер хатын күршесенә ябышты.— Елга бер безгә дә ярар. Тот әйдә, бу юлы хәрәмләшми генә җибәрик әле!

— Әйдәгез, кызлар, бер җырлап утырыйк әле.— Сафин гармунын янә кулына алды, телләренә баскалап көй эзли башлады.— Ниндине уйнарга?

Бер башлагач, барысының да теле язылды, җырладылар да җырладылар. Күмәкләп җырлап туйгач, аерымга күчтеләр. Ленар тирләп-пешеп гармунын тартты. Гөлфиягә дә чират җитте. Ул күңеленнән «Керфекләрең нигә кара?»ны җырларга исәпләде. Яшь чакларында икәү генә булганда Ленар аннан гел шуны җырлата торган иде. Егетләр-кызлар кичке уеннан таралгач, Каенсар күле буендагы каеннар янында таң атканчы сөйләп серләре, җырлап җырлары бетми торган иде. Үзүзләренә нык ышанган, киләчәкләрен гел ачык, кояшлы гына итеп күргән егет һәм кыз татлы хыяллар диңгезендә йөзделәр. Бервакыт күңеленә шөбһә кереп: «Нигә һаман бер җырны җырлатырга кыстыйсың? Аерылырбыз дип куркасыңмы әллә?» — диде ул көлеп.— «Көен яратам мин аның һәм башкаручысын». Шул сүзләрдән исәр булып, күңелен тырнаган шикләрне онытып, йөрәгеннән ташып чыккан хисләрен шул җыр аша сөйгәненә ирештерә килде. Ул еллардан бер нәрсә сер булып калды: Ленар чынлап шул көйгә гашыйк идеме, әллә?.. Юк, ул чакта Ленар аны, бары аны гына ярата иде. Җәвидә, алардан ике класска түбән укучы кыз

аңа хисләрен белдергәндә дә, ул аны гына яратты, Гамир белән узышаузыша аңа гына шигырьләр яза иде.

Гөлфия татлы һәм ачы яшьлек хатирәләрен искә алган мизгелләрдә Ленар ул көткән көйне уйный башлады. Гөлфия музыкаль тактны көтеп алып җыр сузды. Үзе җырлады, йөрәген кайнар ялкын телгәләде, миен гел бер уй бораулады: ул кызмача баштан яшь чакларын искә аламы, әллә?!..

Ленар уйнавын дәвам итте. Гөлфия якты хатирәләрен искә алып утыра бирде.

Менә Ленар да, моң тавыш белән аланны яңгыратып, җыр сузды.

— Каенсар буенда каеннар
Яшьлеккә кайтара күңелне.
Каеннар төбенә безнең дә
Мәхәббәт ялкыны түгелде...

Күз карашлары очрашты. Гөлфия Ленар күзләрендә дәрт, сагыш, моң һәм яшь чагында аны исәр итә торган илаһи көч — мәхәббәт ташуын тоемлады. Бу мизгелләр аның өчен һаман сихри, һаман татлы, һаман изге иде. Шул хисләрдән исереп, карашын аннан ала алмыйча, суларга да җөрьәт итмичә утыра бирде.

Гөлфия, исенә килеп, карашын күчерде, табындашларына күз салды. Барысы тын калып җыр тыңлый иде. Алар Гөлфия күңелендә нинди өермә уйнавын сизгәннәр шикелле тоелды. Оялып башын аска иде, яшьләре атылып чыкмасын өчен күзләрен каты итеп йомды, үзен кулга алырга тырышты.

Мәҗлес дәвам итә иде әле...

* * *

Ленарның эчендә өермә котыра иде. Юл буе Хәлимов белән ике арада булган сөйләшүне уйлап кайтты...

Беренче секретарь бу юлы аны, гадәттә булмаганча, җылы каршылады, өченче срокка сайлануы белән тәбрикләде, кулын кысты, алдагы планнары белән кызыксынды.

Хәлимовның үзенә сәер мөнәсәбәтен гел тоеп торганлыктан, мондый форсатны икенче озак көтәргә туры киләсен чамалый иде, еллар буе күңелендә яшәгән, әллә ничә кабат тикшереп, сынап-санап караган фикерләрен ачып салды. Бүгенге колхоз, никадәр тырышсаң да, зыянга гына эшли, дәүләт алдында гел бурычлы булып кала. Бу мәңге шулай кала алмый, чаралар күрергә: авыл хәзинәсенә бәяләрне арттырырга кирәк; моннан тыш авылда ризык эшкәрту цехлары ачу, дәүләткә әзер ашамлык озату отышлы — табыш житештерүчегә калачак: «Таң»да ярдәмче хуҗалыклар шактый зур керем бирә — аларны үстерү зарур: җирнең уңдырышлылыгын күтәрү өчен аренда формасын кертү мөһим — ул игенчедә җиргә чын хуҗа булу хисен яңадан торгызырга тиеш; гомумән авыл хуҗалыгына мөнәсәбәтне үзгәртергә, аңа савым сыер итеп кенә карамаска, житәкчелек рәвешен үзгәртергә, хуҗалыкларга мөстәкыйль эшләргә ирек бирергә кирәк.

Хәлимовның озак тыңларга яратмавын алдан белә иде, боларны шулай берничә җөмләгә сыйдырды. Үзе Хәлимовтан күзен алмады. Аның нинди темага гәп коруын сизүгә, Хәким Нурмөхәммәтовичнең кәефе кырылды, йөзе караңгылана барды. Ул моны күреп торса да, тукталып калу турында уйламады да. Бу хакта барыбер сөйләшергә, ачыклык кертергә кирәк бит. Хәлимов аны институтка да җибәрми, тынычлап эшләргә ирек тә бирми. Болай мәче-тычкан уены чиксез дәвам итә алмый, чик булырга тиеш. Ул моңа алдан әзерләнеп килде.

Хәлимов кинәт урынынннан күтәрелде, бүлмә буйлап атлап китте. Сафин әңгәмә шулай бик кыска гына тәмам булганын аңлады, аягүрә басты һәм көтә башлады. Үзе шул арада бүген аңа сөйләгәннәрен күңеленнән кичерә, мие аша сөзә бирде. Бүген сөйләгәннәрнең бере дә Хәлимов өчен яңалык түгел, җае чыккан саен сак кына өлешләп аңлата килгән иде аңа. Ул чакта Хәлимов җитди сүздән читләшә: йә әңгәмәне икенче темага бора, йә ишетмәгәнгә сабыша, йә ишетсә дә, аягүрә хәл ителми торган мәсьәләгә сылтап, җаваптан кача килде. Бүген ул аннан болай гына котыла алмасын белә, конкрет җавап бирергә тиеш иде.

— Мин сине күптәннән сынап киләм.— Ул утырышлар үткәрү өчен куелган озын өстәл башына җиткәч туктады, шулай диде һәм күрсәткеч бармагы белән аны үзенә чакырды.— Монда сөйләгәннәрнең берсе дә син хәл итә торган нәрсәләр түгел. Юк белән баш ватканчы, кайт та колхоз эшләре белән шөгыльлән.

Ул аңа, бар усаллыгын туплап, каш астыннан карап тора башлады, җавабын көтте. Аңа да кире чигенер урын юк иде инде.

— Болар нәкъ без хәл итәргә тиешле проблемалар,— диде ул, аннан карашын алмыйча гына.— Тормыш беренче чиратта шуларны хәл итүне алга куя. Сездә яклау тапмасам, мин боларны югарырак җитәкчеләр алдында куячакмын.

— Минем районда эшлисең, яшисең килсә, артыңны кысып утыр. Ипи карточкаң безнең кулда икәнен онытма.

— Күрәгең таза булса, тизәкнең беткәне юк, Хәким Нурович,— диде Ленар үзенең уеннан кире кайтмаганлыгын, курыкмаганлыгын сиздерү өчен.

Юл буе шул күңелсез сөйләшүне хәтере аша кабат үткәреп кайтты. Беренче аны мөстәкыйль эшләгәне өчен болай да өнәми иде, әмма адым саен шелтә бирсә дә, рәсми элемтәләр яшәп килде. Хәзер, болайга киткәч, үзе һәм бөтен аппараты аңа каршы ябырылачак. Әмма ул бу вариантны көткән иде дә бит: юраганы раска чыкты, бары шул.

Идарәдә аны Нургаяз көтеп утыра иде.

— Синең вариантны башлыйбыз, Нургаяз.

— Алай икән, хәзер мин барам да үземнең иптәшләр белән сөйләшәм.

— Сөйләшегез, экономист белән килешү шартларын әзерләгез. Уртак фикергә килгәч, бергәләп җыелыш уздырырбыз.

— Алай булса мин китәм.— Нургаяз рәискә сораулы караш ташлады. Анда мине көтәләр.

Шулчак кабинет ишеге ачылып китте. Ул карашын керүчегә юнәлдерде: Гөлфия икән.

— Сөенечкә ни бирәсез, Ленар Салихович?— Гөлфия көләч күңел белән рәискә карады һәм күрешергә дип кулын сузды.

Сафин өчен бу кадәресе көтелмәгән хәл иде, күзләрен зур ачып, сынап аңа карап торды, күрешергә ашыкмады.

— Сөенчесе нидер бит әле,— дип куйды, шулай да урынынннан торды.

— Бүген иртән авыл хуҗалыгын үстерүдәге хезмәтләре өчен зур бер төркемнең орден, медальләр белән бүләкләнүен хәбәр иттеләр. Хәлимовка Герой, Гәрәевкә Ленин ордены. Безнең районнан Сезнең исемне дә атадылар, нинди бүләк икәнен генә әйтеп тормадылар.— Ул бик канәгать булып рәиснең кулын кысты.— Анысы иртәгә гәзитләр килгәч ачыкланыр. Мин Сезне ихлас күңелдән котлыйм, Ленар!

Рәиснең йөзе яктырып китте. Гөлфиянең кулын кыскан хәлдә күпмедер мизгелләр аңа карап торды.

— Сөенчегә ни бирергә инде?— Ул үз алдына сөйләгәндәй әйтә куйды.— Бергә юарга инде — шул. Коньяк дисәң хәзер үк тә була. Көтелмәгән кунаклар өчен дип алып куйганы бар.

— Син бигрәк тә инде.— Гөлфиянең кәефе шәп иде, авызы колак артына кадәр житте.— Безнең ишеләр шампан шәрабыннан да исерә.

— Анысы да була,— диде рәис ризалашып.— Тик бүген кул астында юк. Бер җае чыгар әле.

— Шаяртып кына әйтәм, Ленар Салихович.— Гөлфия житди тонга күчте.— Минем өчен хезмәтләрегезне күрүләре, бәяләүләре кыйммәт. Югыйсә теге чакта... Председательгә сайланганда тарткалашканыгыз өчен, Хәким Нурович үч алачак, иркенләп эшләргә ирек бирмәс, дигән идегез бит. Шикләнүләрегез акланмады, димәк.

— Ул мәсьәләгә кем ничек карый бит,— диде Сафин житди генә. Йөзендәге якты нурлар шунда ук юкка чыкты. Әңгәмәдәшенә карап күпмедер тын торды һәм кулы белән йомшак кына өстәлгә сугып куйды.— Ике арадагы мөнәсәбәтләрне ул да мин генә беләм.

— Барыбер инде,— дип каршы төште Гөлфия. Күңелендә туган фикереннән тиз генә кире кайтырга җыенмый иде ул.— Үч тотса, бүләк бирдермәс иде.

— Ачмасаң күренми, сөйләмәсәң беленми, диләр бит,— диде ул, күпмедер уйланып утыргач.

Гөлфия аның бүләккә үзе көткәнчә сөенмәвен алдан ук сизде. Хәзер дә аннан күзен алмады, хәлен аңларга тырышты. Карашлары очрашты.

...Егет һәм кыз чакта алар шулай бер-берсеннән күзләрен алмый карашып торалар иде. Ул чакта Ленарның карашы сөйкемле, җанга җылы, күңелгә хис бирә торган иде. Бүген андагы салкынлыкмы, усаллыкмы — ни икәнен аңлый алмады,— җанын өшетеп алды. Ул карашын читкә борды.

— И-их, Гөлфия! — Ленар авыр сулады, кулларын өстәл өстенә куйды. Белепме, белмичәме — алар Гөлфиянеке өстенә туры килде. Гөлфия секунд эчендә кызарып чыкты, кулын итәге өстенә күчерде.

— Председатель хезмәтенең авырлыгын, беренче белән мөнәсәбәтләрнең катлаулылыгын сөйләгәнем генә юк.

— Читтән караганда бары әйбәт шикелле бит.— Гөлфия ни уйласа, шуны әйтте. Хәзер, аннан ишеткәнен исәпкә алып, хәленә керешүен сиздерәсе килде.— Алар ничек икәнен белмим, мин нормаль санап килдем. Теләгәнчә эшлисез, моңа ирек куя, минемчә.

— Аны күпләр шулай саный, чөнки тирәндәрәк ниләр барын күрмиләр.

— Сез бик хисчән кеше, Ленар.— Ул күңеленә килгән беренче фикерне әйтте.— Бәлки, шулай тоела гына торгандыр?

— Киресенчә, мин инде ул әйткәннәрне игътибарга да алмаска тырышам. Хәлимов иң арттагы колхоз председателенә дә миңа бәйләнгәндәй каныкмый. Алдынгы саналсам да, һәр киңәшмә саен беренче чиратта миңа эләгә — дәшмим. Шелтә бирәләр — килешәм. Планны арттыра баралар — үтим. Колхоз файдасына күбрәк эшләп калу өчен шундый уен уйнарга мәҗбүрмен. Үзем һаман да тоткын: теләгән вакытта эштән чыгарырга, яисә башкача җәзаларга мөмкиннәр.

— Мин аңламыйм Сезне, Ленар. Еллар буена сузылган андый уен булмый бит инде.

— Нигә булмасын, була. Булмаса, боларны сөйләп торыр идемме?

— Алай икән, бу соравым өчен гафу ит, ул сине ничек эшеңнән алмый?

— Беренчедән, мин колхоз йөген әйбәт тартам: планнарны үтим. Ачуланалар — дәшмәскә тырышам, хисләремне яшерәм. Шуңа билгеле дәрәҗәдә мөстәкыйльлегемне, ярдәмче цехлар ачуымны, шелтәләр чәпәп булса да, кичерә килде. Болар миңа нигә кирәк диярсез? Үземнең җитәкчелек итәргә сәләтлелегемне расларга, хуҗалык итүгә нинди үзгәрешләр кертергә кирәген практикада исбатларга тиеш идем. Селекция, яңа сортлар белән шөгыльләнә алмагач, авылга, халыкка хезмәтемнең файдасы

шул булсын өчен тырыштым, уен уйнадым. Ул мине үзенең шартларын кабул иткән санап килде.

— Тоткын хәлендә яшәгәнче, эшләгәнче, башка хезмәткә күчә алган булыр идегез бит. Гафу итегез, китәргә үгетләвем түгел, шәхси фикерем генә. Сезнең урында мин булсам, шулай эшләр идем.

— Үзем өчен генә яшәсәм, күптән шулай иткән булыр идем. Әмма миңа хуҗалык итүнең бу алымын куллануның зарурилыгын исбатлау өчен колхозда калуым кирәк. Миңа башлаган эшләремнең тагын күпмедер өлешен булса да башкарып өлгерергә кирәк.

— Нигә шулай дисез? — дип аптырап сорады Гөлфия. — Куркыныч шулай якынмы әллә? Ул Сезне чыгарырга җыенамы? Андый исәбе булса, бүләккә тәкъдим итәр идеме? Бүләкләү аның тәкъдименнән башка үтми бит.

— Бүләккә ул, беләсегез килсә, өстән киңәш иткәч керттерде. Ә куркыныч якынмы, еракмы дигәндә, эш болайрак тора: бүген әле яңа гына яныннан кайттым. Хуҗалыкны тагын да үстерү юллары турында тәкъдимнәр белән кергән идем. Иң мөһиме — хупламады, үз әмере буенча гына эшләргә икәнен янә ачыктан-ачык искәртте, кисәтте. Мин хәзер ике юл чатында: йә анынча, йә үз юлым буенча китәргә тиеш. Шуннан чыгып язмышым да хәл ителер. Моңа озак вакыт кирәкмәс дип уйлыйм: икебезнең дә карашлар тәмам ачыкланды инде.

Сафинның Хәлимов белән катлаулы үзара мөнәсәбәтләре турында кабат сүз кузгату Гөлфия күңеленә каткан кутырны кубарган шикелле тәэсир итте. Берничә көн шул сөйләшүдән калган авыр тәэсирләрдән айный алмый йөрде: эче пошты, үзен кая куярга белми интекте, уң күзе тартты. Ленар язмышына ул беркайчан битараф карый алмады. Дус булып йөргән чаклары хакында әйтеп тормастан, аралары бозылгач, аерылышкач та, аның турындагы хәбәрләрне кызыксыну белән кабул итә килде. Сафин колхозга килгәч, беркемгә сиздермәсә дә, яхшысына сөенде, яманына көенде. Колхозда эшләр җайга салына барган саен үзендә эчке күтәренкелек көчәюен тоя барды. Килгәч беренче аңлашудан соң туган борчулары хәтерендә еллар буе сакланса да, томан артында кала барды. Һәм менә сиңа иске авыздан яңа сүз: шик, шөбһәләре кабат калкып чыкты.

Шулай эче пошып йөргәндә аяк астыннан башка хәсрәт килеп чыкты — Наратлыга барган җиреннән Назыйм айныткычка эләкте.

Ул эшенә җыенып торганда Наратлыдан шалтыраттылар, Назыймның исерек хәлдә милициягә кителүен хәбәр иттеләр. Гөлфия елап җибәрде.

Башка көннәрне, ире эшкә киткәч, алдагы көннәргә планнар яза, йә булмаса гәзит-журналлар караштыра торган иде, бүген берсенә дә кулы ятмады, күңелендә ут уйнады. Назыйм хата өстенә хата эшләде. Кичә керсә, гаебен өстенә алса, кабатламаска сүз бирсә, Сафин, ачуланса да, аның алдында артыгын әйтергә вөҗданы кушмаган булыр иде. Сүзен санламагач, ачуы кабарган гына, билгеле. Андый чакта сүз өчен кеше кесәсенә кереп тормый, әдәп тә сакламый инде, теленә ни килгәнне ычкындыра: түзсәң түз, түзмәсәң... Назыйм, мескен, яман булса да, үз ире ич, башкалар барында аның алдында ничек җавап тотар, ничек түзәр?!

Бүген ул балаларын да көндәгедән иртә уятты. Зөһрәне бакчага иң беренче булып кертеп калдырдылар да мәктәпкә юнәлделәр. Хезмәттәшләре күзенә күренү оят иде аңа: сораша, төпченә башласалар, ни диясең? Оятын кая куясың?

Укытучылардан берәү дә килеп җитмәгән иде әле. Ул классына чыкты, укучылар белән политдәрес үткәрде. Дәрес башланырга берничә минут кала гына укытучылар бүлмәсенә әйләнеп керде.

Бәхете, ул көткән сорауларны биреп интектермәделәр. Моңа вакыт та калмаган, һәркемнең уенда чираттагы дәресе: журнал ала, әсбапларны

барлый, хәстәрле. Ул да, исәнләште дә, үзе кирәсе класс журналын алып, кыңгырау тавышын ишетүгә, ишеккә юнәлде.

Дәресләрдә дә ире турындагы уйлар күңеленнән чыкмады. Шуңа сәгатьләре бетүгә, башка көннәрдәге кебек, соңгы дәресләрне көтеп тормады, өенә ашыкты.

Назыйм караңгы төшкәндә генә кайтты.

— Син кая югалдың бүген? — Гөлфия, гомере булмаганны, аны ишек төбенә үк килеп каршылады.— Бәрәч, тагын эчкәнсең икән. Булсаң да булырсың икән. Шул хәлләрдән соң да.— Ул, әйтер бүтән сүз таба алмыйча бүленеп калды.

— Әз генә ул, карчык.— Назыймның шелтәләүгә исе китмәде.— Яңа эшне юып алырга туры килде.

— Нинди яңа эш ул тагын? — Гөлфия хәйран калып иренә карады. Инженердан чыгарасыларын көткән иде ул, әмма түбәнрәк хезмәткә күчерүне хурлык татыган ир-ат ничек юсын инде.— Кая күчерделәр? Кем итеп?

— Нефтьчеләрнең автотранспорт идарәсенә механик булып урнашам. Бөтенесе сөйләшенгән, килешенгән.

— Ә без? — Сөйләшми, киңәшми эшләнгән бу эш Гөлфиянең җен ачуларын чыгарды. Тик аптырау халәтендә озак кала алмады, исенә килеп сорады.— Ленар кудымыни?!

— Кумады,— диде ире теләмичә генә.

— Син, тинтәк баш, безне уйладыңмы соң? — Гөлфия күркә булып кабарды, кызарып чыкты.— Хәзер без нишләргә тиеш? Ничек яшәргә? Шуларны уйладыңмы соң ичмасам?

— Уйланган, барысы уйланган.

Гөлфия Назыймның җавабы ничарадан бичара гына икәнлеген ачык аңлады. Дуамаллык белән эшләмәсә, тормышларында мондый зур үзгәреш кубарганда хатыны белән киңәшмәс идеме? Үзенә эш сөйләшкән дә бөтенесе шуның белән хәл ителгән. Гөлфия кайда урнашыр? Балалар нишләр? Хәер, Илһам авыр булса да, урысчага күнәр: зиһене бар. Зөһрә нишләр? Аңа бакча булырмы? Алар кайда торырлар?

Гөлфиянең тамагына төер килеп тыгылды, әйтер сүзен әйтә алмыйча ире яныннан борылып китте.

— Күрмешем булган инде, мәхлүк, сиңа чыгып башымны бәйләдем,— дип сөйләнә-сөйләнә үкседе ул.— Ишем түгелен дә белдем.

— Елама, карчык.— Назыйм чишенеп өлгергән иде, аның янәшәсенәрәк килеп басты.— Бары да җайланыр. Миңа тулай торактан урын бирәләр. Куна калган очракларда, төнге смена чакларында. Ә болай Наратлыга барып эшләүчеләр белән кайтып йөрермен. Фатирга чиратка куярга булдылар.

Ул кулын хатынының иңбашына салды.

— Кит, кагылма миңа.— Гөлфия чыелдап кычкырып җибәрде, гадәти булмаган тавышына үзе дә гаҗәпләнде.— Китәсең икән, бөтенләй кит, мин беркая да бармыйм.

Ул кухня ягына узды. Карашы урамга төште. Председатель машинасы каршы якта, капка төпләрендә тора: димәк, өйдә. Аның каршына керү авыр-оят, ләкин ни булганын ачыкламыйча да булмый. Исерек ире үзен акларга әллә ничә сәбәп табачак.

Дәшми-тынмый гына йортта кия торган курткасын бөркәнде дә аларга кереп китте.

— Әйдә, уз, Гөлфия.— Миңнегөл, аны күргәч, урыныннан күтәрелде.— Мактап йөрисең икән әле, утыр табынга. Илдар, бар, апаңа теге бүлмәдән урындык алып чык.

— Уз, Гөлфия, утыр.— Сүзгә Ленар да кушылды.— Сезнең белән сөйләшәсе дә бар әле.

— Кыстамагыз әле, зинһар, тынычлап ашагыз.— Ул Илдар китергән урындыкны өстәлдән читкәрәк күчереп куйды һәм утырды.— Бүген барыбер аш үтми.

— Ир-ат язмышында андый гына «ЧП» була инде.— Сафин аштан бушаган тәлинкәсен хатыны ягына этеп куйды һәм аңа таба борылды.— Колхозда төрлесен күрергә туры килә. Аның өчен борчылма, Гөлфия, үзе кайгырсын.

— Борчылса, мондый хәлгә төшмәс тә иде,— диде Гөлфия.

— Ә ул үзе кая соң әле?— Сафин хатыны сузган чынаякны кабул итеп алды да дәвам итте.— Кичә алай юк, бүген болай юк.

— Үзем дә шуны белешергә кергән идем әле. Иртән көндәге вакытта чыгып китте. Кудыгызмы? Болай гадел булмый бит инде. Инженердан алсагыз, башка эш бирегез.— Гөлфия кычкырып елап җибәрде, үзе сөйли бирде:— Ул бит үзе генә түгел, гаиләсе, балалары да бар.

— Тынычлан әле, Гөлфия.— Сафин чәй эчүен бүлеп, чынаягын алдына куйды.— Мин бүген аны күрмәдем. Сездән сорамакчы идем әле.

— Димәк, ул Сезнең белән сөйләшми генә эшләгән.

— Нишләгән?— дип ашыгып сорады Сафин.

— Наратлыдан эш сөйләшеп кайткан.

— Эше булыр аның.— Кинәт барлыкка килгән тынлыкны Сафин бозды.— Авызы үзе белән бармаса икән.

— Сиңа кая эшләргә була, мәктәптәме?— Әлегә кадәр әңгәмәгә катнашмый утырган Миңнегөл сорау бирде.— Фатир ягы ничек?

— Нинди фатир? Нинди эш?— Гөлфия кашларын җыерды.— Кайтып-китеп эшләп йөрмәкче.

— Йокы биреп кайгы алу шул була инде,— диде Сафин.— Куркып колхоздан ук кача, димәк.

— Белмим.— Гөлфия Назыймның ниләр уйлап колхоздан китәргә җыенуын чынлап та белми иде.— Иртән берни әйтми чыгып китте. Яңарак кайтып керде, шулай ди.

— Ә син үзең моңа ничек карыйсың инде?

— Ничек дип!— Гөлфиянең моңа җавабы юк иде.— Торыр урының, эшең булмагач.— Ул тагын уйлана калды.— Шуның өчен киңәшкә кердем дә инде. Колхозда калса әгәр?! Бәлки башка эш бирерсез.

— Килсен, бу хәлләрдән соң баш инженер булып кала алмый. Анысын алдан ук әйтәм. Ә кайда эшләр — үзе белән киңәшкәч, хәл итәрбез.

— Ә ул китәм дисә?— дип аптырап сорады Гөлфия.— Бәлки, партучеттан төшермәскәдер?!

— Алай бәйләп куярга ул бит эт түгел, Гөлфия.— Сафин чәен йотып куйды.— Гомумән, калса — кумыйм, китсә — тотмыйм. Китә калса, бәлки перевод белән кабул итәргә сөйләшә торгандыр. Чакыртып алган белгеч санала. Үзенә эшкә урнашуда, фатир алуда, башкасында да кирәге чыгарга мөмкин. Бәлки, берничә ай эшләп акылга утырып кайтыр? Колхозда эш бетеп торганы юк. Гомумән, сөйләшегез, үзегез хәл итегез...

* * *

Гөлфия никадәр үгетләсә дә, елап, әрләп, янап караса да, ир ирлеген итте, бу юлы фикереннән кайтмады.

Назыймның эше сменалы иде. Иртән йөргәндә очраклы машиналар белән китә, әмма икенче, өченче сменада куна калырга туры килә. Колхоздагы хезмәте белән чагыштырганда аның өчен күпкә җиңел, ул канәгать иде. Ләкин моның икенче ягы да ачыкланды: Гөлфия өчен яңача шартларга күнәргә кирәк иде. Ирсез кунуы гына бер хәл, юлдашка балалары бар, йорт, мал-туар тоту мәшәкатьләре тулысы белән аның өстенә авып калды.

Ул көнне дә Назыйм дежурга киткән иде. Гөлфия сыер савып, сарыкларны ябып керде дә, план язарга утырды. Шулчак электр хисаплагычы янында нидер чырт итте һәм, кинәт өй эче караңгылыкка чумды.

Каршы якка күз салды — анда бар, димәк, үзләрендә генә сүнгән. Ул куыксыз лампага ут элдерде, залга чыгарып куйды. Карангыда балалар курка, тонык ут булса да ярап торыр. Аңа утны көйләтер өчен кеше эзләргә кирәк иде.

Курткасын киеп урамга чыгып китте. Шулчак капкадан Ленар килеп чыкты, машинасына таба юнәлде.

— Күрше ни эш бетереп йөри? — диде ул, аны күреп.

— Тагын пробка янып чыкты, ут юк, шуны көйләргә ир-ат эзләп йөрим.

Ул машина урындыгын күтәреп нидер казынды һәм аның янына килде. Кулында отвертка иде, шуны алган икән.

— Кая, нәрсә булган икән анда? — Ул лампаның сүрән яктысында пробканы борып алды, отверткасын аның урынына тыкты. Бүлмәгә гөлт итеп ут кабынды.

— Кая, пычак китер әле, Гөлфия. Иренә әйт,— диде Ленар үткәргечне чистарта-чистарта. Урындыгыгызны ныгытсын, бик каты шыгырдый.

— Йөз әйткән инде,— диде Гөлфия аның сүзен җөпләп.— Мин оста түгел, ди. Телевизор ничә атна Казанны күрсәтми, аңа да белгеч кирәк.

— Кем генә соң ул? — Сафин «жучок»ны көйләп бетерде, отверткаиы алды һәм урынына пробка борды. Ут яңадан кабынды.

— Рәхмәт инде, Ленар Салихович.

Ул түргә узды, телевизорны кабызды. Төрлечә боргалап, көйләп карады. Экранда сурәт әле югалды, әле чыкты, тик экран сикерә бирде.

— Кечкенә отверткагыз бармы? — дип сорады ул.

— Ниндирәк кирәк соң?

— Тегү машинасыныкы булса да ярый.

Сафин шуның белән экран астындагы тишеккә тыгылып боргалый башлады. Экранда сурәтләр ачыкланды, тотрыкланды.

— Ура! Әни, кара, күрсәтә,— дип кычкырып җибәрде Илһам.

Ленар чыгарга җыенды. Гөлфия озатырга булды, алдан кузгалды. Чоланда, әллә лампочкасы янган инде, ут кабынмаган иде, икесе дә караңгыда калдылар.

Гөлфия утсыз күнекмәгән иде, сакланып барып ишек янына килеп житте, капшанып келәне тапты, аны өскә күтәрде. Ишекне ача алмады, үз гәүдәсе белән аны каплап тора иде. Ул читкә тайпылды, гәүдәсе белән борылды. Шулчак кайнар сулыш тойды, Ленар йөзгә-йөз аңа килеп бәрелде.

Бер мәл алар шул халәттә катып калдылар. Гөлфия Ленарның кайнар иреннәре яңагын пешерүен генә тойды.

— А-ай! — дип шыыырт кына әйтә куйды ул һәм, акылына килеп, ишекне ачып җибәрде. Ленар читкәрәк тайпылды һәм, берни булмагандай, яктылык төшкән баскычка чыкты.

— Бик зур рәхмәт инде, Ленар Салихович.— Кыен хәлдән чыгу өчен ул теленә килгән беренче сүзләрне кабатлады.

Сафин дәшмәде, баскычтан төште һәм урамга чыгып китте.

Ул капканы тышкы яктан япкач кына Гөлфия баскычтан төште, капканы бикләде. Әйләнеп кергәч, көзгегә күз салды: яңаклары кояшта пешкән алмадай янып тора иде.

* * *

Бик ярап куйды әче бал. Анасы янына мунча якканда гына килә торган Назыйм ишекне еш ача башлады. Мунчадан чыккач та, хатыны балаларны юган арада, берәр банканы бушатып куя, бик канәгать булып китә.

Әмма килененнән килгән саен чырае карала бара. Бер килүендә түзмәде, малаен эчертеп җибәргән өчен каты-каты әйтеп, чәйгә дә утырмый-

ча кайтып китте. Билгеле инде, ул өстенә алмады, антлар тотты. Килене Гөлфия моңа ышандымы, юкмы — әмма мунча ягырга килми башлады. Кешеләр аркылы белде: күршеләренә йөри башлаганнар икән. Ходай орган, Иблис кавеменнән булган бәндә, аңа оныкларын күрергә дә калдырмады тәки.

Килененә булган ачуы әче камыр кебек кабарды аның. Аннан ничек тә кару кайтарасы иде бит. Тик ничек? Күпме баш ватса да, бер әмәл дә таба алмады. Күп вакыт уйланып йөргәч, бернәрсәне исенә төшерде.

Мунчаны да үзе ягарга гадәтләнде. Пары әрәм булмасын өчен Мәстүрә карчыкны да кызы Саимә белән чакыра башлады. Бер иләшкәч, эштән буш чагы булса, булышырга Саимә дә керә торган булып китте. Ара-тирә аңа да бал салып биргәли. Саимә бик ошатты, мактап бетерә алмый балны.

Ул көнне дә Саимә аңа булышырга дип керде. Назыйм әче бал белән сыйланып утыра иде. Анасы өстәлгә самавыр кертеп утыртты, тагын әче бал чыгарды һәм үзе, күз алларында әйберләрен җыеп, мунчага китеп барды.

Юри озак итеп юынды. Ул кайтканда алар һаман табын тирәсендә гөлдердәшеп утыралар, банка бушаган иде инде. Зал якта караваттан диванга мендәр күчкәнне күргәч, карчыкның сөенече эченә сыймады.

— Сиңа, малай, күптән өеңә кайтырга вакыт,— диде ул кырыс күренергә тырышып.— Син, Саимә, мунчага бар.

Алар чыгып киткәч кенә елмаеп куйды: чибәр килененең борынына чиертте бит.

* * *

Таңнар атты, кичләр була торды. Тормыш шулай үз көенә ага бирде. Назыйм, Наратлыга эшкә күчкәч, әнисенә ешрак сугыла башлады. Әни кеше аны әче балдан өзмәде, күңелен суындырмады.

Чираттагы шимбәдә ул тагын мунча якты. Вакытын белеп бетергән инде, Саимә дә килеп керде. Наратлыдан кайтышлый, бал авыз итәргә дип, Назыйм да сугылган иде.

— Мунчага барырга вакыт,— диде карчык берәүнең дә исемен атамый гына.

— Әйдә киттек, күрше,— диде Назыйм һәм Саимәнең йомшак җиренә сугып алды.

— Бәйләнмә әле, Назыйм,— дигән булды Саимә кашларын сикертеп. Үзе хуҗабикәдән күзләрен алмады.

Карчык, ишекне ябып, зур якка кереп китте.

Ул әйләнеп чыкканда кухняда Назыйм да, Саимә дә юк иде. Бик канәгать булып чәй эчәргә утырды. Сөтле чәен авызына китергән генә иде, өй ишеге киң ачылып китте. Анда килене Гөлфия басып тора иде. Аның җаны табанына төшеп китте.

— Назыйм кайда?— диде ул.

Кайнанасы өнсез калды. Ботын кайнар нәрсә пешерә башлагач кына дерелдәгән кулыннан чәе түгелгәнне аңлап, чынаягын өстәлгә куйды.

— Ул бүген монда кермәде.

— Алдашма,— диде килене.— Илһам сезгә кергәнен күреп калган.

Гөлфия, аның җавабын көтеп тормастан, чүәкләрен дә салмастан зал якны тикшереп чыкты, кием шкафына кадәр ачып карады. Кече яктан да тапмагач, җилләнеп чыгып китте.

Тораташ булып каткан биана, шапылдап ишек ябылгач, авыр итеп сулады: бәлки, кайтып китүедер. Һәм аның ни эшләвен белергә теләп, ишегалды ягы тәрәзәсенә барып ябышты. Оныгы Илһам да монда икән, ул мунчага төртеп күрсәтте. Карчык хәлсезләнеп тәрәзә янагына таянды.

Килен шунда ук мунча ишеген барып этте. Ишек ачылмагач, аягы белән типте, аннан ботаклы бүкәннәрне яру өчен көйләнгән тукмакны алып ишеккә бәрергә тотынды.

Ишек ачылып китте. Саимә чырылдый-чырылдый шәрә килеш лапас астына йөгерде. Килен аны куып маташмады, шөкер, имгәнү-мазар булмады, димәк.

Ишектә күлмәген чалбары эченә тыгарга да өлгермәгән килеш Назыйм күренде. Ул, кулларын бутап сөйли-сөйли ана каршы атлады, нидер аңлатмакчы, акланмакчы иде, ахрысы. Тик зәһәр килен аны тыңлап торамы соң: кош-корт эчәргә дип куйган шакшы су чиләген күтәреп алды да иренең башына китереп каплады. Назыйм, мәми авыз, суга төшкән тавык шикелле, ишегалды уртасында басып тора бирде. И-их, пешмәгән. Хатынын чәчүрмәсеннән эләктереп алып, күтәреп бәреп измәсен изсә, артыннан каравыллап йөрергә исенә төшмәс иде дә бит, булмады инде, булмады.

Малай чиләген башыннан алып куйды да, миңгерәгән сарык шикелле, ни эшләргә белми ишегалды уртасында басып тора бирде.

Килене чыгып киткәнне күргәч, ул, сандыгыннан малаеның туган көненә дип әзерләп куйган күлмәген алып, ишегалдына чыкты.

— Битеңне юу, өстеңне алмаштыр.

— Бу күлмәкне нишләтергә? — дип сорады Назыйм.

— Ташла, шунда калсын,— дип кулын селтәп җибәрде ана.— Үзем юармын.

Малае юынган арада ул сөйли, өйрәтә торды:

— Хәзер, беркая борылмыйча өеңә кайт. Тавышланма, кычкырса да дәшмә. Аерылам дия башласа, ялын, бүтән андый хәл кабатланмас, диң. Бу арада безгә килеп, эчеп йөрмә.

Озакламый Назыйм кире әйләнеп кайтты. Ул өйрәткәннәрне кабатлап торырга туры килмәгән: Гөлфия урам капканы ук биклэп куйган — кертмәгән иде.

* * *

Гөлфиянең аның өчен иң кыен чакта авылга китеп баруы Ленарны чыгырыннан чыгарды. Юк, хатыны югында нәфесен канәгатьләндерү өчен генә кирәк түгел иде. Ул аны үтәли күрә, элекке кебек яратуына ышана, шуңа авыр чакта янында булуын тели иде. Сөйләшергә, назлашырга гына түгел, киләчәк язмышлары турында да уртага салып киңәшергә кулай көнне ул китеп барды. Ленар моны һич башына сыйдыра алмады.

Киңәшмәдә дә Гөлфия һич исеннән чыкмады. Хәлимов, үз чыгышында, аны колхозны сәүдә оешмасына әйләндерә баруда, кибет ачарга җыенуда тәнкыйтьләп чыкты, барлык җитәкчеләр алдында кисәтүен белдерде.

Башка вакытларда булса, фикер алышуда сүз сорар, үзенең хаклыгын исбатларга тырышыр иде. Бу юлы аның сүзләре бер колагыннан керде, икенчесеннән чыкты. Шулай да дүрт сәгатькә сузылган бу киңәшмәдә инәләр өстендә утырган күк тойды үзен. Тәнәфестә башка колхоз җитәкчеләре чәнечтереп-төрттереп алганда да, усал җавабы белән авызларын капламады, бөтенләй дәшмәде, тәмәке генә көйрәтте.

Киңәшмә тәмамлануга, ашханәгә кереп тиз генә ашап чыкты да, авылга ашыкты: асфальттан тизлекне йөзгә кадәр җиткерде.

Авылда да үзенә урын тапмады. Буш йортка кайтып ни эшләсен. Идарәгә кереп чыкты, кыр станына тукталды. Кирпеч заводына барып чыкты, хәл белеште. Тик бер җирдә дә озак тормады, машинасы янына ашыкты. Балтасы суга төшкән шикелле кая барырга белми аптырады.

Кабинетына керде һәм ишекне эчке яктан бикләде. Өстәле артына узып сейфны ачты, кыштан бирле саклап торган кыйммәтле коньяк шешәсен кулына алды. Урам як тәрәзәгә күз салды. Идарә тирәсендә машина, кеше-мазар да юк иде. Графин янындагы стаканны алды, тулар-тулмас итеп коньяк салды. Бүген болай гына йоклый алмасын чамалый иде, сагышын исерткеч белән басарга булды.

Коньякны эчеп җибәрде, алдан әзерләп куйган шоколадны бер почмагыннан сындырып капты. Йотарга өлгермәде, телефон шалтырый башлады. Ул төребкәне кулына алды, әмма дәшмәде. Берәү белән дә сөйләшәсе килми иде аның.

— Алло, сез үзегездәме? Мине таныйсызмы?

Сафин айнып киткәндәй булды. Тавыш бик таныш иде.

— Син кайдан шалтыратасың?— дип сорады ул. Шалтыратучы, янында тыңлаучылар бар иде, ахры, аның кемлеген атамады, шуңа Гөлфия дә исемен телгә алмады.

— Наратлыдан, почтадан.

— Шунда тор, мин унбиш минуттан анда булам.

Кайтышлый алар юл буендагы «Үрдәк күле» аланына борылып керделәр. Караңгы төшкәнне шунда көтеп алдылар.

Менә җиргә эңгер җәелде. Әлегә кадәр ямь-яшел бизәкле тирә-юньнең төсе аерылмый башлады. Ак төстәге кыр, болын чәчәкләре генә, төнге факел шикелле, ялтырый иде.

Алар да кузгалдылар. Хәзер ике йортның да маллары җыелган, ышандырып калучылар киткән булырга тиеш.

Машинаны боруга, ут көлтәсе капка төбендәге эскәмиядә утырган сары сакаллы картның базык гәүдәсен яктыртты. Ул тиз генә урыныннан торды, кече капкадан эчкә кереп китте. «Волга» килеп җиткәндә капка ачык иде инде. Гөлфия, картның күзенә чалынмас өчен, Ленар ышыгына сыенды.

Карт барыбер рәиснең ялгыз түгеллеген күреп өлгергән иде, машина янына килеп тормады, бикләвеч кендекне тыкты һәм чыгып китте.

— Мин өйгә чыгам, Ленар.— Ул шулай диде, үзе аңа сыенган килеш кала бирде.— Зыятдин бабай күрде, оят.

— Ул сер саклый белә,— диде рәис.— Шулкадәр сагынып, көтеп алгач, сине җибәрде юк инде.— Ул аны үзенә таба тартты, кайнарланып ireннәреннән үбәргә кереште.— Хәзер сине кулымнан ычкындырсам, юләр булырмын.

— Безнең бу уенның азагы күңелсез бетәчәк, Ленар. Зинһар, җибәр.

— Бетәсе беткән инде,— диде Сафин ашыгып.— Моны уен гына санасаң, ялгышасың.— Ленар аны каты итеп кысты, хатынның кайсыдыр әгъзалары шытырдап куйды хәтта.— Бу безнең яшьлегебездә саклый алмый югалткан мәхәббәтебезне, үзебез югалткан йолдызларыбызны кабат табуыбыз.

— Әкият сөйләмә, Ленар,— диде пышылдап кына хатын. Гүя, аларны тыңлап торучы бар иде.— Фани дөньяга әйләнеп кайт. Без синең белән икебез дә гаилә әхлагын бозачак затлар гына.

— Дөрес түгел. Хәзер безгә язмышыбызны хәл итәргә кирәк.

— Безнең язмышлар хәл ителгән инде, Ленар, сукмакларыбыз аерым.— Ул, тартылып аның кочагыннан чыкты, тураеп утырды.

— Ничек хәл ителгән?— Дусты аңа сәер итеп карады.— Миңнегөл мине ташлап китте, син ирең белән аерылдың. Өйләнешәбез дә еллар буе күңелне тырнап килгән мәхәббәт газапларыннан арынып, калган гомерне тыныч, бәхетле үткәрәчәкбез.

— Барысы да син уйлаганча җиңел генә хәл ителсә икән,— дип куйды Гөлфия.

— Мин хәйран калам, син һаман да миңа ышанмыйсың. Солдаттан ялга кайткач та чыкмадың. Яратуыма ышанмадыңмы?

— Ышандым.

— Алайса нигә чыкмадың?
— Бер сәбәбен әйткән идем инде, иремә хыянәтне күз алдыма китерә алмый идем.
— Тагын?
— Анысыннан да бигрәк баскан эзеннән ут чыга торган егеткә хатын килеш ничек чыгыйм?
— Яшьли сөйгән ярыңа,— дип төзәтте Сафин.
— Гомер буе битәрләвеңнән курыктым.— Гөлфия хәзер моны яшереп тормады.
— Ләкин син барыбер минеке.— Ленар аны иреннәреннән суырып үпте.— Хәзер курыкмыйсыңмы?
— Хәзер,— Гөлфия уйланып алды,— без икебез дә тигез, гаиләләребезгә хыянәт иткән хатын һәм ирдер инде.
— Ничек алай? — Ир үзләренә бирелгән мондый рәхимсез бәя белән килешә алмады.— Ә безнең күңелләрдә еллар буе янган мәхәббәтне кая куясың? Мин синең бу нәтиҗәң белән килешә алмыйм.
— Килешсәң, килешмәсәң дә, бу шулай. Синең хатының бар, мин иремнән законлы аерылмаган.
— Миңнегөл — горур хатын. Барып чакырмасам, гафу үтенмәсәм, кайтмаячак. Ә мин берәүгә дә ялынмыйм. Сине, Такташчарак әйткәндә: «Гөнаһ фәлән диеп тормадым, шушы төндә күрше мужигының чибәр хатынын кереп урладым». Моның өчен Назыймның миңа үпкәләргә хакы юк.
— Мине, ярар, урладың да, ди. Ә дүрт баланы кая куясың? — диде хатын күзләрен мәгънәле уйнатып.— Аларны ятим, бәхетсез итеп, мәхәббәтеңнән тәм таба алырсың микән?
— Алары да уйланылган,— диде Ленар.— Миңнегөл балаларны миңа бирми. Аларга алимент түләрмен. Синең балаларыңа мин үзем әти булам: какмам, чит күрмәм.
— Әй, син минем гомерлек сагышым.— Гөлфия назлап, аның башыннан сыйпады, бармаклары белән чәчләрен аралады.— Кайчак син шулкадәр җитди, шулкадәр акыллы, кайчак — хыялый. Алары турында уйлама, бу санаулы кичләрең өчен генә дә ничек җавап биреп бетерерсең, белмим. Үзең беләсең ич: Хәким Нурмөхәммәтович болай да башыңа күсәк белән бирергә җай гына көтә иде — кулай мизгел чыкты. Күңелем сизә: аның алдында җавап тотасыларың алда әле. Мин ярар, кусалар, башка районга китәрмен — үкенечем калмый. Ә синең монда башкарасы эшләрең, исбатлыйсы нәрсәләрең күпме? Аларның әрәм булуы бар.
— Юкка курыкма,— дип каршы төште Ленар.— Безне беркем күрмәде. Бездән башка ике арабызда ниләр булганын исбатлый алмыйлар.
— Ул кадәре шулай да булсын.— Гөлфия гашыйкгы уйлаганнарның барыбер чынга ашмасын аңлый, аны да шуңа ышандырасы килә иде.— Без өйләнештек, ди. Әмма бу безгә, партиянең иң актив ике членына бик кыйммәткә төшәчәк. Хәлимов синең, минем мәхәббәт кичерешләрен тыңлап тормаячак, башкаларга сабак булсын өчен, безне КПССтан чыгартачак.
— Моның белән нәрсә әйтергә телисең? — дип сорады Ленар, аның фикеренең асылына төшенмичә.— Партия члены булгач, минем башка хатынны яратырга хакым юкмы? Сиңа гашыйк кешеңә кияүгә чыгарга ярамыймы?
— Теләсә ни булса да, мин партиядән башка яшәүне күз алдына китермим.
— Мин, Гөлфия, коммунизм төзүчеләрнең алгы сафында байтак атладым һәм бер хакыйкатьне аңладым. Безнең җитәкчеләр социаль гаделлек, намус турында трибунадан вәгазь укып төшәләр дә, залдан чыгуга, сөяркәләре янына ашыгалар: аракы эчәләр, азалар. Һәр колхоз председателенең, район җитәкчеләренең бер яисә берничә сөяркәсе бар.
— Синеке дә бар ич,— дип куйды хатын моңсу гына.

— Сөяркә генә санасам, мин сиңа кагылмас та идем.— Ленар аңа усал карап алды.— Ихлас күңелдән яратмасам, яшь чакта ук Гамир Җәвидәне алдаган күк итәр идем дә, бүтән әйләнеп карамас идем. Менә, яшермим, ирешә ала идем. Мин сине киләчәгем өчен сакладым. Бүген дә, теләгемне канәгатьләндерү өчен генә булса, ирсез хатын тапмас идемме?

Гөлфия тирән сулады. Ленар хаклы иде. Су буенда аның кочагында таңны каршылаган кичләрдә үз-үзен белештермәс, аның теләгенә каршы килә алмас мизгелләр булмады түгел, булды. Ул тыйнаклык күрсәтмәсә, нәфесен чикләмәсә, Гөлфия аңа каршы торырлык халәттә түгеллеген сизә иде. Соңрак, иренә каты ачуы чыкканда, күңелендә туган үкенүләрен исенә төшерде. Ул чакта Ленар тиешлесен эшләгән булса, хурлыгы булмаган булыр иде ичмасам! Ә болай?! Күпме нахак ишетеп, кем өчен намус саклаган булып чыкты. Шуның кадерен дә белмәде бит ул, уҗым бозавы.

Сафин, көтеп-көтеп тә берни ишетмәгәч, сүзен дәвам итте:

— Минем мәсьәлә бюро аркылы узачак та узачак, чөнки Хәлимов һәм аның авызына карап торучылар өчен бу — миннән арынуның иң кулай юлы. Ләкин шуны исеңдә тот: Миңнегөл аерылса да, әләкләшеп йөрмәячәк. Эш синнән генә тора, чөнки безне берәү дә тотмады.

— Мин үз теләгем белән синең кочагыңа кердем, сине сатарга вөҗданым кушмаячак. Бу хыянәт булыр иде. Андый юлга бассам, хыянәтче исемен күтәреп җирдә яшәмим мин, үземне-үзем юк итәм. Үзебезнең икърардан башка, безнең бу гөнаһларыбызны исбатлый алган очракта да, мин сине сатмаячакмын, барын үз өстемә алам: мине теләсә ни эшләтсеннәр, сиңа гына тимәсеннәр. Синең ишеләр җәмгыятьне алга үстерү өчен кирәк.

— Мин үзем өчен курыкмыйм. Чыгарсалар чыгарырлар, коммунист булып калам дип, гомер буе иркле тоткын хәлендә яшәү мөмкин түгел. Гомумән, ул мәсьәләгә битараф мин хәзер: чыгарсалар — көенмим, калдырсалар — сөенмим.

Ул тынып калды. Гөлфиянең бу минутта аның уйларын бүләргә җитәрлек кодрәте юк иде. Ул үзе дә тирән уйга чумып утыра бирде. Үзе өчен идеал санаган бердәнбер ир-ат бүген аңа, ниһаять, тәмам ачылып җитте шикелле. Ул Ленарны яхшы белә: максатына ирешү өчен барын эшләргә әзер, нык ихтыярлы, акыл белән, төптән уйлап эш йөртүче кеше. Ләкин ул аның карашларын аңлый, алар белән һич килешә алмый.

Кинәт кенә борылып, ул аны яңадан кочагына алды.

— Төкер, Гөлфия, барысына,— диде ул аны битеннән, маңгаеннан үбә-үбә.— Куйбышев яисә Ульяновск өлкәсенә күчеп китәрбез дә, үз белгечлекләребез буенча эшләрбез. Язмыш кабат икебезне аермасын.

Ул машина ишеген ачып җибәрде, чыкты һәм аны күтәреп алды.

— Чү, җибәр, Ленар! — Ирнең үбүеннән туктап торган мизгелләреннән файдаланып, хатын телгә килде.— Төшер, үзем керәм.

Сафин аны тыңламады, ишеккә таба атлады.

— Чү, танкеткаларымны салам,— дип карады.

Исәрләнгән ир аның бу үтенечен дә колагына элмәде. Гөлфия, аның кулында килеш, аякларын селкеде. Танкеткаларының берсе баскычта, икенчесе чоланда төшеп калды...

* * *

Гөлфия вакыт исәбен югалтып, алдагы күңелсез язмышын фаразларга тырышып, тагын күпме яткандыр — әйтә алмый. Аның уйларын якында гына туктаган машина тавышы бүлде. Йөрәге «жу» итеп китте, куркуыннан сикереп торды. Чаршау почмагын чак кына каерып сыңар күз белән урамга төбәлде. Миңнегөл яшел «Жигули»дан төшеп килә: кире кайткан!

— Ленар, тиз тор, хур булдык.— Ул ашыга-кабалана үз киемнәрен эзләргә кереште. Кызулык белән эчке күлмәген кире ягы белән киеп куйган булып чыкты. Алмаштырып тору кая — күлмәгенә ябышты.

— Ни булды?— диде хуҗа күзләрен ачып, хатынның утка кергәнен күреп.

— Алла хакы өчен тиз бул,— диде ул еларга җитешеп.— Күрмисеңмени?! Миннегөлләр кайтты.

Ул элеккечә үк саклык чаралары күреп урам якка кабат күз салды. Миңнегөл янында Ленарның әбисе, бабасы, балалар басып тора. Алар янына Зыятдин карт якынлашып килә.

— Уеннан уймак чыкты,— диде Гөлфия дер-дер калтырап.— Нишлибез хәзер?

— Курыкма,— диде Ленар гомер күрелмәгән тынычлык, сабырлык белән. Үзе җитез генә чалбар төймәләрен, каешын каптыра бирде.— Хәзер алар кергәләгәнче, тәрәзә аша төшәсең һәм арт яктан Чирмешән буена чыгасың. Аннан тынычлап өеңә кайтасың.

Гөлфия көрсенеп куйды. Курку белән ул үзе берни уйларга сәләтсез, кайтучыларга күренмичә, җәнҗалсыз котылу әмәлен башына китерә алмаган иде. Хәзер әзрәк җан иңде.

Ленар тәмам киенеп өлгергән иде, үрелеп тәрәзәне ачты.

— Тизрәк төшер мине.

Ир аны биленнән күтәреп алды, каты итеп суырып үпте. Гөлфия, башында ул кайгымы соң, аю кочагына эләккән күк сизсә дә, бу хакта телгә алып тормады.

— Мин Каенсарга китәм,— диде ул, Сафин авызын аның иреннәреннән алуга пышылдап кына.— Солтан озатсын әле.

— Идарәгә бар. Озатыр.

Аяклары җиргә тигәч, хатын иркен сулыш алды, урам якка күз ташлады. Андагы халык, шөкер, биредән күренми иде. Ул вакыт югалтып тормастан, Чирмешән ягына йөгерде.

Сафин тәрәзәне япты, бүлмә эчен күздән кичерде. Тәрәзә төбеннән Гөлфиянең сәгатен, идәннән күкрәкчәсен алды, барын кесәсенә шудырды һәм, каты сусаган булса да, кухняга сугылып тормастан, ишегалдына чыкты. Урамнан керә торган кече капканы кайсыдыр этә, бакча ягындагысын тагын берсе шакый. Югыйсә, «сандугачлар»ны урын өстендә үк эләктерәселәре булган икән.

Ул алдан «Волга»ны кабызды, аннан соң гына барып зур капканы ачты, машинасына кереп утырды, тизлеккә салды. Машина артка чигә бирде. Капка төбендә Миңнегөлнең агарган йөзе, анасының йодрыкланган куллары күренеп калды.

Юлга чыгып җитүгә, ул тизлекне алмаштырды. Машина бакча каршында торган «Жигули»га чак бәрелмичә, кызу тизлектә урам буйлап җилдерде.

...Гөлфия, бәрәңге бураздасы аша йөгереп узып, кура койма арасыннан үтте һәм Чирмешән буена килеп чыкты. Шунда гына ашыгып, артына карарга җөрьәт итте. Күзәтеп торучы күренми иде. Турыдан-туры куркыныч узды шикелле. Калганын уйлап, исәпләп торырга вакыты юк, аңлык башы да эшләми. Бер генә нәрсә ачык: хәзер аларның язмышы күбесенчә Миңнегөлгә бәйле. Бу хатын аларны бюрога куйдырта, башкача да эшли ала.

Ул Миңнегөлне күз алдына китерде. Үзе Назыймны Саимә белән тоткач,ниләр кичергәнен исенә төшерде. Һәм тәннәре чымырдап куйды. Хәзер аның күзенә ничек күренергә?

Монда озак басып торырга ярамый, кеше күрүе, әллә ни уйлавы бар. Кер чайкый торган басмага керергә, битен юып алырга булды.

Шунда кылт итеп исенә төште: танкеткалары Ленарларның ишек төбендә калды бит. Ярый ла егетенең аларны алырга башы җитсә?.. Танкеткалар кире каккысыз дәлил бит. Аның тәннәре өшеп китте.

Чирмешән суында битен, яралы аягын юып киптерде дә кайтырга чыкты. Бәхете,— ни иртә, ни төш чак түгел,— сукмакта каршы очраучы булмады. Ленарлар йорты ягына күз чите белән генә карады да тиз генә үз капкаларына кереп китте. Аны урамда күзәтеп торучы юк иде шикелле.

Капканы ябуга, баскыч төбендә яткан танкеткаларын күреп алды.

Алар урталай туралган иде.

* * *

Тикшерү үзенә йөкләнгән хатны Җәвидә дикъкать белән кабат-кабат укыды. Имзасыз хат авторы Сафинны тотнаксызлыкта, чит кеше гаиләсен таркатуда гаепләгән, партиядән чыгаруны таләп итеп төгәлләгән.

Җәвидә исә Ленар белән Гөлфиянең мәхәббәт мажаралары турында авылга кайткач ишетте. Телдә сүз гел алар хакында гына иде. Авылда шулай бит: гадәттән тыш бер вакыйга булса, икенчесе килеп чыкканчы сөйләнә.

Авылга таралган хәбәрнең гайбәт кенә түгеллеген әнисе сүзләреннән үк чамалады. Ул моңа гаҗәпләнмәде дә. Ленар колхозга килгәч, ике арадагы яшьлек хисләренең яңадан кабынуын сизә иде. Моның азагы шуның белән бетәсенә ышана килде һәм хаклы булып чыкты.

Райкомда шундый тәртип яшәп килә: инструктор үзе кураторлык иткән партоешмада гадәттән тыш вакыйгаларны белеп торырга, хәбәр итәргә тиеш. Ул чираттагы якшәмбедән килгәч, моны Гамирга житкермәде. Бу факт турында хәбәр башкалар авызыннан барыбер килеп житәсен, үзенә дә сүз булуы ихтималын белсә дә, дәшмәс булды — белмәгәнгә сабышырга ниятләде.

Моның сәбәпләре байтак иде. Үзе ихтирам иткән Ленарны сатарга җыенмый иде ул. Һәм коммунист буларак аның соңгы кыланышларын зур гаепкә санамады. Райкомда эшли башлагач, тирәсендәге ир-атларның чит хатыннар белән йөрүен; хатыннарның ир өстенә ир тотуын белде. Шулай булмаганны монда эшләтмиләр. Аларга яраган бу кагыйдә Ленарга ярамыймыни?! Бусы бер ягы гына: һәркемнең үз вөҗданына кагылышлысы. Ленар өчен бу очрак зур фаҗигагә әйләнүе бар: хәзер Хәлимов аның сөрлеккәнен генә көтеп йөри. Ул бу хакта аңа имешмимеш ясап белдерсә, төптән тикшерергә, ачыкларга кушачак. Болай, бәхете булса, бу хакта бәлки Хәлимовка килеп житмәве дә мөмкин, яисә соңга калып кына ирешүе дә ихтимал.

Шуларны уйлап, ул дәшми калырга булды. Тик аны коткара алмады: имзасыз хат бик тиз килгән. Хатны тикшерүне Хәлимов аңа йөкләде. Бу аның партоешмасы булган өчен генә түгел, аны ышанычлы кешесе санап. Аның Ленарга карата мөнәсәбәтләрен белмичә. Бу бер яктан уңай: ул Сафинга бу очрактан ерып чыгарга булышачак. Әмма, икенче яктан, бу аның үзенә авыр күсәк булып төшүе дә бик мөмкин. Ничек кенә булса да, Җәвидә үз фикереннән кайтмаячак.

Җәвидә алдан Ленарның үзе белән киңәшергә булды. Тик рәис эш белән күрше өлкәгә чыгып киткән иде. Сул күз төбе каралып чыккан Миңнегөлне очраткач, Җәвидә гаҗәпләнеп:

— Нәрсә булды, Миңнегөл Саматовна? Күзегезне нишләттегез? — диде.

— Утын ватканда пүлән тиде.

— Утын пүләнеме, башкасымы? — диде Җәвидә.— Бу хатта, мәсәлән, бөтенләй башкача язылган. Ул хатны чыгарып бирде.

Миңнегөл хатны кабат-кабат укыды. Үзен тыныч тотарга, сиздермәскә тырышса да, хат тоткан кулы калтырый иде. Яңаклары алсуланып чыкты, ирен кырыендагы миңе төсенә керде.

— Йә, шуннан соң ни диярсез? — Җәвидә дәшми тору артыкка сузылгач башларга булды.

— Ни диим? — Ул иреннәрен бөреп алды. — Мин белмим, күрмәдем. Үзләреннән сорагыз.

— Белмәгәч, нигә соң мендәрләрегезне җилгә очырдыгыз?

Миңнегөлнең күзләре кысылды, Җәвидәгә усал карады.

— Иске мендәрләр иде алар, тавык йоны катыш, — диде. — Казлар асрыйм, хәзер мамык та җитәрлек.

Җәвидә Миңнегөлнең ирен бирмәсен беренче сүзләреннән үк чамалады, әмма аны сынавын дәвам иттерде. Әңгәмәдәшенең үзен ышанычсыз тотуын, каушавын сизеп тора иде. Сорау алу бәлки тагын бүтән тикшерүче тарафыннан да кабатлануы мөмкин бит. Хатынны шуңа әзерләп куясы итте.

Миңнегөлнең яңаклары тагын да кызара төште. Әмма ул, курку хисеп җиңеп, элеккене кабатлады.

— Юк сүз, күрмәдем, белмим. Ленарга үчлеләр бар, шулар гаиләсен дә болгатмакчы булалар.

Хәзер аннан шуннан артыгын алып булмаслыгы ачык аңлашылды. Ул Миңнегөлдән, сөйләгәннәреннән чыгып, аңлатма яздырып алды.

Гөлфия дә алдан баш тартты. Казанда «Таң» кунакханәсеннән бергә чыгып барганда аларны күрүче шаһит барлыгын, бюрода аның да катнашасын әйткәч, куркуга төште. Гаебен танымаса да, шөбһәләнеп сорады.

— Бюрода безне нишләтергә мөмкиннәр инде, Җәвидә Хәлиулловна? — диде.

— Анда берәүне дә башыннан сыйпамыйлар. — Аның Гөлфиянең каушап калуына ачуы чыкты. Бюрога барып җитсә, бөтенләй мәлҗеп төшүе бар. Ул чагында абынуы, Ленарны бөтенләй батыруы мөмкин. Аңа шул хакта каты гына чәпчеп алмакчы иде дә, тыелып калды? — Шулай, ахирәт, — диде килешүчән тонда. — Эш бюрога барып җитсә...

— Җәвидә, син райкомда эшлисең, мондый очракларны тикшерүгә катнашканың бардыр.

Җәвидә иреннәрен бөрде:

— Минем андый персональ эшләрне тикшергәндә катнашканым юк. Юләргә акыл бирсәң, качарга да юл тапмассың.

— Ленарны болай да өнәмиләр, бу аноним хат әче торма өстенә тоз инде.

— Аны кем өнәми? — Җәвидә моны һични белмәгәндәй һәм дорфа итеп сорады. — Колхозы алдынгы, эше гөрләп бара.

— Анысы шулай, әмма сөрлеккәнен көтеп торучылар да юк түгел.

— Әйе, — диде, ниһаять, Җәвидә. Соңгы әйткәннәреннән соң Гөлфия аны сата алмый инде, ычкындырса, үзе дә буталачак. Ул да ачылырга булды. — Бу очракта синең сүзләрең икегез язмышын да хәл итәчәк.

— Шулай булгач, мин ничек эш итәргә тиеш?

— Миңа аңлатма язып бирәсең, — диде Җәвидә боеру тонында. — Шуннан соң карарбыз.

Җәвидә Ленарга да үзенә билгеле булганнарны сөйләде.

— Син аларны исбатла, — диде Сафин, исе китмәгән кыяфәттә.

— Колагыңнан ук батырырга була иде. — Ул бүгенге очрашулары, Гөлфиянең үз-үзен тотышы шик тудыруы турында да искәртте.

Райком секретаре Хәлимов Җәвидәнең белешмәсе, шаһитларның аңлатмалары белән Гамир Харисов барында танышты. Җәвидә аның канәгать түгеллеген чыраеннан ук чамалады: укыган саен караңгылана барды.

Беренче дәшми генә документларны райкомның оештыру бүлеге мөдире Харисовка таба шудырды. Анысы тиз генә аларга күз йөгертеп чыкты.

— Син аларны точно үзең күрдең инде? — Харисов кәгазьләрдән башын күтәрүгә аңа карады. — Ялгышмадыңмы? Бутамадыңмы?

— Кемне кемне тик аларны гына таныйм инде,— диде Харисов хәтере калып.

— Алар сине күрмәдеме?

— Мин баскыч яныннан читтәрәк танышым белән сөйләшеп тора идем,— диде оештыру бүлеге мөдире.— Алар «Таң»нан чыгуга икенче якка борылдылар, трамвай тукталышына таба киттеләр.

— Туктатырга, сөйләшеп алырга башыңа килмәде инде,— диде Хәлимов, канәгатьсезлек белән.

— Бюрода мин аларның күзләренә карап әйтәчәкмен,— дип акланды Харисов.—Ниләр кигәннәрен, вакытын әйтеп күрсәтәм.

— Сафинны алай артыннан карап калып кына тота алмыйсың. Гомумән, Сез икегез дә бу эштә прошляпили, барыгыз!

Алар дәшми генә урыннарыннан тордылар. Җәвидә мондый бәяне ишетәсен алдан ук чамалаган иде.

* * *

— Син теге хатның очына чыга алмадың тәки?

Харисов ишеккә якынлашып килгән җиреннән туктальш калды һәм кире борылды.

— Нәрсә хакында әйтәсез ул, Хәким Нурович?— Харисов райком секретаре Хәлимовны аңламый калды.— Кайсы хатны?

— Классташың Сафинга кагылышлысын каплап калдырмакчы булдың инде.— Беренче секретарь аны үчекләп елмайды. Парторгтан китәргә аның аркасында мәҗбүр булганга, Харисов Сафинны яратмый, дошман күрә һәм моны Хәлимов белә иде.— Дустыңны яклыйсың инде.

Харисов аның төрттереп сөйләгәнен аңлаган иде, шаяруга борып тормады, турысын әйтеп салды.

— Әйе, аның белән уңышсыз килеп чыкты, Хәким Нурович. Минемчә, бу эшне Җәвидәгә тапшыру начар гына булды шикелле.

— Нигә шулай дисең?— Хәлимов аңа сынап карап торды.— Җәвидә безнең кеше ул.

— Сезгә карата аның карашын әйтә алмыйм, Хәким Нурович.— Харисов ашыкмыйча, һәр сүзен үлчәп, басым ясап сөйләде:— Әмма Сафин белән дуслар алар. Мәктәптә Җәвидә Ленарга гашыйк та булган иде.

Харисов бу мәсьәләне Җәвидә тикшерүгә риза түгел иде. Белгәч үк бу хакта Хәлимовка кереп аңлатырга уйлады, тик аның бер әйткән сүзеннән, ялгыш булса да, кире кайтмавын белгәнгә, батырчылык итмәде: сүгеп кенә чыгаруы бар. Хәзер кулай чакта, шиген сак кына аңа ирештерде.

— Син авылга кайтып йөрисең бит, андагылардан бу тарихны үзең ачыклап кил әле.

— Минемчә, хәзер соң инде,— диде Харисов.— Алдан барасы калган.

— Ничего, соң түгел, җае килеп чыгар.

Әңгәмә тәмамланса да, бүлек мөдире борылып чыгып китмәде. Секретарьның кәефле чагы, күңелендә күптән йөргән тагын бер фикерне аның күңеленә салып куясы итте.

— Минемчә, бу очракта Сафинга икенче яктан килергә кирәк, ярдәмче хуҗалыкларын тикшерергә. Алар закон, инструкцияләргә каршы килә ич. Кышын теплицадан кыярын райпога тапшырмыйча, Куйбышевтагы бер заводка саткан, финанс тәртибен бозган!

Хәлимов аның сөйләгәнен азаккача тыңлады, әмма кашларын җыерып куйды. Гамир шунда ук аңлады — ошатмады. Шулай булып чыкты да.

— Мелочь бу.— Секретарь уйланып торды.— Сафинга тотынсаң, шундый итеп эләктерергә кирәк — тын да ала алмасын. Югыйсә, синеңчә

генə калдыру кызык түгел, аны тизлəнерлек итəргə кирəк.— Ул туктады, мөдир моны ничек кабул иткəнен күзəтеп торды. Харисовның ул əйткəнгə кул куеп торучы икəнен белə иде, əңгəмəне кискен тонга күчеп очлады: — Син тыкшынырга яратасың, тик миңа төрле кирəкмəс фикерлəр белəн кермə. Бар, эшеңне эшлə.

* * *

Хəлимов, ахыр чиктə, аның идеясен кабул итмəсə дə, хəтерен калдырырлык итеп очласа да, боекмады Гамир.

Райкомда ул берничə ел эшли инде. Каенсарга баргач, эше һич җайлана алмады аның. Колхозда хəл начарая барганын күреп, чыгарып төшергəнче, югары партия мəктəбенə китте. Аннан кайткач, пропаганда бүлегенə билгелəделəр. Берничə ай элек, аны тəмам сынагач, Хəлимов төп бүлеккə күчерде. Моны ул үзенə зур ышаныч, мəртəбə итеп кабул итте. Мөдир генə булса да, бюро əгъзасы, тəртип буенча секретарьлардан бер баскыч түбəн саналса да, Хəлимов төп мəсьəлəлəрдə аның белəн киңəшə. Бүген дə, шелтəлəп алса да, Сафин хакында аның белəн фикерлəшүе иде. Ул Хəлимовка үзе телəгəн оеткыны салды. Бу килəчəктə дə дəвам итəчəк. Дөнья бит ул куласа, əйлəнə дə бер баса. Сафинны да басачак. Тагын җае чыгасына ул бүгеннəн үк ышана.

Сафин белəн Сəйфетдинова арасындагы мəхəббəт уены тарихының күп кенə яңа детальлəре ачыкланды, Җəвидəнең ике йөзле пəке икəнлеге тəгаенлəнде.

Лəкин əлегə яңа сигнал буенча кабат тикшерү үткəрүдəн тоткарланып торырга булдылар. Кабат тикшерү уздыру, өстəмə мəгълүматларны расласа да, төп фактны исбатларга ышаныч юк, чөнки «геройлар» мондый очрашу, аңлашуга алдан əзер инде. Бу Җəвидəгə дə үзенə ышанмауларын сиздерəчəк, моны эшлəргə иртəрəк əле, вакытыннан алда аның турыдан-туры Сафин ягына чыгуы вакыйгаларны катлауландырып җибəрергə мөмкин, чөнки ул күп нəрсəне белə.

Райком, бу вакыйгалардан соң, ниндидер чаралар күрергə тиеш иде. Урак башланган дəвердə Сафинны алу кулай түгел. Анысы бер хəл, җиде елдан артык канына күп тоз салган Сафинны болай гына чыгарып җибəрү дə күздə тотылмый иде.

Бу сигналны тикшерми торуның тагын бер сəбəбе бар. Хəлимов, ниһаять, Гөлфия Сəйфетдинованы аппаратка алырга күрсəтмə бирде. Аны бирегə күчерəсе булгач, керлəрендə казыну урынсыз.

Харисов, бу вакыйгалардан соң, Гөлфияне райкомга алу килешмəвен беренчегə əйтеп караган иде, сүзе үтмəгəч, ашыгыч рəвештə аны чакыртып китерде.

— Мин Каенсарга укытырга китəм,— диде Гөлфия, ни өчен чакыруларын белешкəч.

— Юк, сиңа Каенсарга түгел, райкомда инструктор булып эшлəргə туры килер.

— Ничек инде алай? — Сəйфетдинова элекке сабакташына сəерсенеп карады, аннан телəр-телəмəс елмайган итенде.— Үзем белми дə калганмын, минем кая күчəсемне хəл итеп тə куйганнар.

— Шулай, Гөлфия.— Зур эш башкарган шикелле Гамир кулларын уып куйды.— Авыл өеннəн, урам сазыннан арынып, бар уңайлыклары булган фатирга күчəчəксез. Моның өчен миңа бер рəхмəт əйтерсез əле. Мондый бəхет сирəклəргə тəти. Сезне монда күчерү өчен беренче алдында күп тырышырга, җавап тотарга туры килде.

Ул бу мəсьəлəгə үзенең дə катнашы барлыгын сиздереп куясы итте.

— Мин авылга күнеккəн, авылны яратам.

— Шəһəргə килеп яши башласаң, үземнəн белəм, авыл тиз онытыла ул.

— Аны онытмас өчен авылда гына яшим инде.

— Син нәрсә, Гөлфия?! — Мөдир әлегә кадәр укытучыны әдәп йөзеннән генә тарткалаша дип санаган иде, соңгы сүзен ишеткәч, җитдигә һәм «син»гә күчеп әйтте.— Бу мәсьәлә хуҗаның үзе тарафыннан хәл ителгән.

— Ул кадәренә ышанам.— Сәйфетдинова да бу үзгәрешне игътибарсыз калдырмады, аңа иярде.— Тик бер кечкенә мәсьәләне онытып җибәргәнсез: минем фикер, теләкне исәпкә алмагансыз.

— Хәким Нуровичны үзең беләсең, Гөлфия. Аның алдында синең, минем фикер була алмый, ул кушканча гына.

— Бу таләп миңа кагылмый, Гамир Садыйкович.— Хатын үзен иркен тотты, киреләнә бирде.— Мин бит дәрәҗәгә омтылмыйм. Туган авылыма кайтып, үзем теләгән хезмәтемне дәвам итәм.

— Вакытны гына сузасың, Гөлфия.— Гамир бу сатулашудан туеп килә иде, кистереп куйды.— Мәсьәлә хәл ителгән, бернинди үзгәреш була алмый. Кереп «әйе» генә диясе.

— Сәләтемә, теләгемә туры килмәгән эшкә алына алмыйм, бары шул.

— Кемнең нәрсәгә сәләтле икәнен ачыклауны безгә калдырыгыз инде, иптәш Сәйфетдинова.— Мөдир үзенең өстенлеген сиздереп куясы итте.

— Балаларны яратам.— Ул да яңа дәлил китерергә мәҗбүр булды.

— Партия сезгә җаваплырак эш — коммунистларны тәрбияләүне йөкли,— диде Харисов үз-үзенә нык ышанган төстә. Аннары сейфыннан шакмаклы дәфтәр битенә язылган хат алды да Гөлфиягә тоттырды.— Сафинны сайлатканнан соң күп сулар акты инде.

— Мин Каенсарга балаларны да кайтарырга сөйләштем. Анда пропагандист итеп билгеләргә булдылар. Бөтенесе хәл ителгән, иремә дә эш бирәләр. Минем әмер генә кереп аласы калды.

Бүлмә хуҗасы телефон алып номер җыйды һәм роно мөдире белән сөйләшеп алды, аннан төребкәне Гөлфиягә сузды. Роно мөдире гафу үтенде, Каенсарга яңа килгән укытучыны эшкә җибәрүләрен белдерде. Башка җиргә дә күчерә алмавын искәртте.

Аларның сөйләшүен тыңлап торган бүлмә хуҗасы тантана итүен яшереп тә маташмады.

— Хәзер ни диярсең? Сиңа районда гына түгел, республикада да эш бирмәячәкләр. Читкә китәсең икән, партучеттан төшермибез, кире әйләнеп кайтачаксың.

— Мине яраткан эшемнән аерып бирегә китерү кем һәм ни өчен кирәк? — дип сорады ул еларга җитешеп.

Сәйфетдинова җиңелгән иде инде, кемгә, ни өчен кирәген Харисов үзе дә чамалап кына белә, аңлатырга исәбендә дә юк иде.

— Анысы икенче мәсьәлә, диде ул.— Син — партия номенклатурасындагы кадр. Партия кая кушса, шунда эшләргә тиешсең.

— Мин кайтып уйлап, ирем белән киңәшеп килим әле.

— Юк, юк! — Гамир бармагын селкеп алды.— Назыйм Наратлыда эшли, каршы килмәячәк. Хәзер Хәким Нуровичка керәбез.

Ул телефон аша беренче секретарь белән сөйләште.

Алар кергәндә Хәлимов китәргә җыенган иде, ишек төбендә каршылады.

— Ә-ә, Гөлфия сеңел икән! Исәнмесез! — Ул аның белән коры гына күреште һәм дәвам итте: — Без сине Камышлыдан күчерү белән бераз соңгарак калдык, неудачнорак килеп чыкты. Но, ярар, соң булса да уң булсын. Әйдә, иртәгәдән эшкә чыгасың. Калганын соңыннан сөйләшербез.

Гөлфия аның тарафыннан үзенә шулкадәр салкынлыкны көтмәгән иде. Әдәп өчен генә булса да, хәлен белешер, тәбрикләр дип уйлаган иде. Алдан әле мәктәптә калырга сорамакчы да иде, әмма, Ленарны бәлагә тартмас өчен, баш ияргә булды.

Хәлимов чыгарга борылды. Гөлфия, гарьләнүдән, елап җибәрмәс өчен иренен тешләде, тамагына килеп тулган төерне авырлык белән йотып җибәрде.

* * *

Хәлимов «Таң» колхозына барырга булды бүген. Уракка төшкәннән бирле бу колхозда булганы юк иде аның. Баруның хаҗәте дә шул кадәр генә, Сафин беркемнең күзәтүеннән башка да үз эшен алып бара белә. Райкомның колхоздагы вәкиле итеп тә, нәкъ шуның өчен, рәис белән килештерә торган Низамованы гына билгеләде. Ул уракның нормаль барышы турында хәбәр итеп тора. Сводкада да хуҗалык башкалардан алда.

Кыр эшләре, башка тармаклар өчен дә күңеле тыныч. Әмма рәиснең кирелеге, үзенчә эшләве аның җен ачуларын чыгара. Тыюга карамастан, Сафин колбаса эшләү цехына җиһазлар сатып алган. Теге чакта кыярын да Куйбышевка озаткан булып чыкты. Соңгысын кемдер Казанга шикаять язгач кына белде ул. Партиянең өлкә комитеты секретаре алар белән киңәшмәдә шуны күтәреп чыкты: Наратлыда үзләре үстергән кыярны да читкә саталар икән. Ә районда кышын, гомумән, яшелчә сатылмый. Ул Хәлимовтан моның сәбәбен аңлатуны таләп итте. Хәлимов бу хакта хәбәрдар түгеллеген белдереп котылмакчы иде, ул аны бүлдерде, райондагы хәлләр белән таныш түгеллектә гаепләде. Гел мактауга гына күнеккән Хәлимов өчен республика, район җитәкчеләре алдында моны тыңлавы авыр да, хурлык та иде.

Кайткач Сафиннан үчен кайтарды, билгеле. Үткән киңәшмәдә, үзен дә трибуна артына чыгарып, арт сабагын укытты. Аңа учет кенәгәсенә язып, каты шелтә чәпәделәр. Әмма ул, кире беткән татар, үз фикерен яклап чыкты, моның сәбәпләрен дә аңлатты. Моның зарарлы ягы да зур: башка рәисләр тыңлап, ишетеп-күреп тора. Шуңа Сафинны бүләргә, анасын кушып сүгәргә туры килде. Шуннан соң ул ниләр эшләп ята икән, күңеле тартмаса да, үз күзе белән күреп кайтырга булды.

Сафинны кисәтеп куймаган иде, ялгызы гына колхоз җәйләвен, басуларны карап йөрде. Һәр җирдә тәртип күреп уйлап куйды: хезмәтне оештыра белә үзе.

Алдан ук ерак бригадаларны урап чыкты, вак-төяк кимчелекләрне дә хәтеренә сала барды: чираттагы киңәшмәдә Сафинны камчылап алырга боларның кирәге чыгар.

Китәр алдыннан юл буенда турыдан бодай урдыручы комбайннар янына туктады. Анда Нургаяз Мәүлетовның звеносы эшли булып чыкты. «Волга»ны күргәч, Мәүлетов, штурвалны ярдәмчесенә тапшырып, янына төште. Алар электән танышлар иде инде.

— Ай-яй, Нургаяз! — Хәлимов ни әйтергә сүз таба алмый торды. — Мондый кыек эшкә юл куярсың дип уйламаган идем. Колхозның партком члены, атаклы механизаторы шундый көндә турыдан-туры сукты-рып ятсын әле. Бу бит технологияне тупас бозуга керә. Сафин моңа ничек юл куя?

— Хикмәт анда түгел бит, Хәким Нурмөхәммәтович. — Мәүлетовнең беренче сүзләрен ис китмәгән кыяфәттә кабул итүе аны гаҗәпләндерде. — Кайсы ысул файдалыны ындыр табагы күрсәтер. Барометр явым төшемне искәртә, без теземгә салгач кына яңгырлар китсә?!

Ул арада басу кырыена Сафинның кара «Волга»сы да килеп туктады.

— Син... мать, үзең генә түгел, колхозчыларыңны да райком секретарена каршы сөйләргә өйрәтеп куйгансың, — дип каршылады аны Хәлимов.

— Кызганыч ки, ул хакта аны өйрәтеп торырга вакыт тимәде, Хәким Нурович. — Сафин беренченең ачуы тулышканын белсә дә, үзен

тыныч тотты.— Һәм мин, гомумән, өйрәтү, боеру гадәтен ташларга исәплим.

— Ә ничек эшләргә исәп?—Бу сорауны биреп вакланып торасы түгел иде дә, ярсуы җиткән чак, үзен тыеп кала алмады, теленнән ычкынды.

— Уйлап карагыз әле, Хәким Нурович, бу җиргә кем хуҗа?— Сафин туп-туры аңа карады.

— Бу синең җирләр,— диде Хәлимов рәиснең соравының асылын аңламастан.

— Сез дә, мин дә түгел,— диде Сафин баягыча сабыр, әмма катгый итеп.— Кем игә — шул хуҗа. Бездә бу бригадада хәзер нәкъ шулай — менә ул хуҗа. Комачауламыйк аңа, чыгыйк моннан.

Ул Нургаязга төртеп күрсәтте.

Хәлимов моның кадәрен миендә эшкәртә алмый иде. Аны басудан куганны күргәне юк иде бу гомердә. Әмма монда бу хакта сөйләшү, бәхәсләшү файдасыз, Сафин аның боерыгына буйсынмаячагын теленнән әйтте. Ул кул селтәде дә машиналар торган җиргә, юл кырыена таба атлады. Сафин да аңа иярде.

— Без телибезме-юкмы, җиргә мөнәсәбәтне шулай итеп үзгәртергә, игенчене аның чын хуҗасы итәргә кирәк. Шунсыз җирдән теләгәнчә уңыш ала алмаячакбыз.— Сафин атлаган уңайга сөйли бирде.— Колхозда җир иясез, димәк, хуҗасыз. Хезмәт нәтиҗәсе белән кызыксынмый, түләү тигезләү системасы нигезендә үткәрелә, көнлекче буларак хезмәт хакы ала. Нургаяз звеносы быел, арендада булгач, җирне үз кыры санап, бернинди күрсәтмәсез җанын-тәнен куеп эшләде. Башка бригадалардан ун центнерга артык уңыш алып килә. Шуңа күрә, һавалар бозылып киткәнче соңгы участогыннан да бодайны җыеп калырга ашыга.

Хәлимов, гүя, ишетми, аны тыңламый да иде, нәфрәте кайнады.

— Син нәрсә телисең соң ахыр чиктә?—диде ул ачу белән. Алар райком «Волга»сы янына килеп җиткәннәр иде инде.— Үзеңне Үзәк Комитет, обком өчен уйлаучы итеп санамакчы буласыңмы? Анда синең кадәр генә башлылар юк саныйсыңмы? Тик кара аны, сакалыңны учлап калма. Иртәгә иртән бюрога киләсең, персональ эшеңне шунда карарбыз.

— Мине анысы куркытмый, теләсә кайчан әзер,— диде Сафин.— Карый-карый армаган булгасыз, тагын да карарсыз.

Хәлимов «Таң»нан соң «Коммунизм юлы»на, дөресе, умарталыгына керергә, шунда ял итеп алырга исәпләгән иде, әмма планын үзгәртте. Сафин белән ачыктан-ачык бәрелешү бер хәл, бөкрене кабер генә төзәтә, аның күңелен икенче нәрсә борчыды. Сафин райком күрсәтмәсен бозып, үзе теләгәнчә эшләп ятканда Низамова аны күргән, белгән, аңа белгертмәгән. Димәк, Гамир хак булган, Сафин эшен теге вакытта аңа тапшырып та ул хата эшләгән. Анысы бер хәл, Сафинны иртәгә бюрода тикшерәчәкләр, партиядән чыгарачаклар, бусы ачык. Әмма икенче нәрсә аннан да куркынычрагы — хыянәт. Низамова аның яклы булып, Сафинны яклап килгән. Бу бит ашаган табагыңа төкерү дигән сүз. Ул җитәкләгән аппаратта Сафин үз кешесен тоткан. Алар әле аның турында кирәкле-кирәксез сүз сөйләгәннәрдер, эшчәнлегенә үзләренчә бәя биргәннәрдер. Сафин аны ничек үз ягына аударган? Гыйшык-мишык уйнап, мөгаен.

Хәлимов Сәйфетдинованы да аппаратка алды. Моның ул үзе генә белә торган сәбәпләре, сере бар иде. Гөлфия — Сафинның ышанычлы дусты, тагын бер әзер шпионы. Ничек элегрәк моны башына китермәде соң?!.

Секретарь нәтиҗә чыгарып куйды: аларны мөһим бер нәрсәгә дә катнаштырмаска. Низамовасын, берәр сәбәп табып, тизрәк ычкындыры-

рга. Никадәр тиз, шулкадәр яхшы. Куып чыгарырга ярамый, әлеге дә баягы, шик-шөбһә уятмаслык итеп кенә озатырга. Үзенең үтенече буенча. Югыйсә, ул бөдрә баш күп нәрсәне белә, аларны дөньяга чыгаруы бар.

Хәлимов райкомга эш сәгате тәмамланыр алдыннан кайтып керде. Кабинетына узуга Харисовны чакыртып алды, кече залга хәзер үк аппаратны җыярга боерды.

Юри көттереп, унбиш минутлар узгач кына кабинетыннан туры кече залга үтте, президиум өстәле артына керде. Үзара ярым пышылдап кына сөйләшеп утырган аппаратчылар шып булдылар.

Хәлимов алдан Харисовны бастырды, авыл партия оешмалары урак чорында ни эшләве турында хәбәр итәргә боерды. Харисов сорауны аңламыйча ык-мык килде, аннан соң гына районда урак барышына бәя биреп сөйләп китә алды. Тик озак тыңлап тормады беренче, «Таң»да парткомның эше хакында сораулар бирде. Харисов анда эш ипле баруын, парткомның тиешле югарылыкта булуын белдерде.

— Ә син анданиләр эшләгәнен беләсеңме соң? — дип кискен сорау белән бүлдерде аны Хәлимов. Бүлек мөдире дәшмәде. Хәзер ни әйтсә дә, беренче каршы төшәсен чамалап өлгерде инде.

Аны, бастырып куйган килеш, шактый сүкте дә, урынына утыртты. Чиратта колхоз партоешмасына кураторлык иткән Низамова иде. Җәвидә трибунага чыкты, дәшмәде. Мондый чакта үзен ничек тотарга кирәген үзләштергән иде инде ул. Тик Хәлимов аңа болай гына котылырга ирек куймады.

— Әйт әле, Җәвидә, Сафин ни өчен үзендә секретарь итеп Эльвира исемле кызны тота?

Сорауның тузга язмаган, инструктор аңа җавап бирә алмаганын алдан белә ул. Ачуланырга булса, һәрчак шундый бер сорау бирә. Аның каршындагы кеше аптырап кала, билгеле.

— Әйтә алмыйм,— диде Низамова секретарьның үзеннән җавап көткәнен күреп.

— Син нәрсәне генә беләсең соң? — дип китереп куйды Хәлимов бөтен залны яңгыратып.— Синең коммунистлар кеше хатыннары белән типтерәләр, аларны тәрәзә аркылы үз хатыныннан качыралар. Синең коммунистлар райком күрсәтмәсенә буйсынмыйча игеннәрне турыдан суктыралар. Син боларның берсен дә белмисең, әллә белеп яшерәсеңме?

Хәлимов залга күз салды, Сәйфетдинованы эзләп тапты, аның килеш-кыяфәтенә игътибар итте. Гөлфия чөгендер төсле кызарынган, башын аска игән. Менә шулай, үзенең кемлеген белеп торсын, башын күтәреп башкаларга карый алмасын. Ул чагында, бәлки, аның ягына күчәр.

Секретарь карашын яңадан Җәвидәгә күчерде. Кызарынган-бүртенгәнгә тавыш-тынсыз бермәл карап торды. Аның бу сүзләреннән Җәвидә елар кебек тоелган иде. Әмма ул еларга җыенмый, кысык күзләре белән аңа ачулы карап тора. Бу аны тәмам чыгырыннан чыгарды. Кызып китеп сәгатькә якын теленә ни килгән белән сүкте, әнисен, әбисен дә калдырмады. Ахырдан, тамагы сүз әвәли алмаслык дәрәҗәдә кипкәч, кергән ишектән кабинетына чыгып китте.

Залда калганнар, таралырга димәгәч, ничек утырган булсалар, шул хәлдә калдылар. Җәвидә дә, такта янында бастырып калдырган бала сыман, кымшанмый тора бирде.

Үрә катып басып торудан арган Җәвидә, биш-ун минут үткәч, тәрәзә ягыннан шыбырдаган тавыш ишетеп башын шул якка борды һәм авызын ачып янә катып калды. Хәлимов «Волга»сына утырып маташа иде.

Тышта ниндидер котелмәгән нәрсә барлыгын сизенеп, тәрәзәгә якын утырган Гамир да торып карады, Хәлимовның китеп барганын күрде.

— Өйләрегезгә кайтырга мөмкин, иптәшләр,— дип белдерде ул.

Залдагылар берьюлы диярлек тирән сулап, мышнап куйдылар.

* * *

Гөлфия кабинетына кергәч кенә әзрәк аңын җыйды. Хәлимов планерка, киңәшмә саен бер-ике хезмәткәрен юк сылтаудан бар ясап сүккәнен белеп өлгергән иде инде. Әмма бүгенге кебегенә, хатын-кызны анасы белән сүккәнгә хәйран калды. Әлегә кадәр, монда яңа кеше буларак, аңа кагылганы булмады. Әмма бүген аны да шундый итеп төпкә утыртты ки, киләчәктә үзенә дә рәхим-шәфкать көтәргә урын булмавын ул шунда ук аңлады.

Ул каршы кабинеттан Гамир киткәнне көтеп өстәл тирәсендә казынды. Аның ишек япканын ишеткәч тә чыгарга ашыкмады. Мөдир ике катны да тикшереп чыкмыйча китми әле. Вакытны сузар өчен көзгесен чыгарды. Төсе качкан, кыяфәте суга төшкән тавыкныкы шикелле: киңәшмә аның котын алды бит бүген.

Җәвидә,— нәкъ ул уйлаганча,— китмәгән, тавыш-тынсыз гына яшь коя иде.

— Йә, ярар, тынычлан, Җәвидә,— диде ул аны юатырга тырышып.

— Бу йортта шулай инде,— диде Җәвидә күз яшьләрен кульяулыгы белән сөртә-сөртә.— Торма ачуын тоздан алалар.

Гөлфиянең тәненә каз бөртекләре бәреп чыкты. Хәким Нурович Җәвидәне ике гаебе: Сафин белән аның арасында булган мәхәббәт уены һәм колхозда бодайны турыдан урдыруга юл куйдырган өчен сүкте. Төптән уйлап карасаң, икесендә дә аның гаебе юк. Җәвидә шуларга төрттерде. Тик кайсысын — мәхәббәт тарихынмы, Сафинның үз белдеге белән эшләвен күздә тоттымы, әллә икесен берьюлымы? Ничек кенә булмасын, Җәвидәгә бүген алар өчен эләкте. Тик, инде эш узган, моңа кайтып торудан файда юк, дәшми калуны хуп күрде.

— Гамир сезнең тарихны ачмакчы булып җан талашты, булдыра алмады. Шуның өчен Хәлимовка эләкләп канымны суыра.

Бу минутта Гөлфия Ленар күптән әйткәнне уйлый иде: Сафин гына түгел, үзе дә тоткын. Бүген моны ул, ниһаять, ачык аңлады.

Ул үсмер чакта караган бер фильмне исенә төшерде. Сунарчылар бүреләрне төрле яклап кысрыклап урманга куып кертteләр һәм һәрьяклап кызыл флаглар кадап чыктылар. бүре, усал ерткыч булса да, кызыл флаг кадалган җирдән чыгарга курка, икенче якка ташлана, әмма тагын шуңа юлыга. Сунарчылар аларның тозакта икәнен беләләр, ауларга ашыкмыйлар. Ул үзен дә бүген шундый тозакка эләккән шикелле хис итте. Аны да, куып китергән бүре кебек, монда мәҗбүри күчерделәр. Ул да моннан үз теләге белән ычкына алмый. Шулай булгач, тоткын булмый кем булсын соң?!

* * *

Гөлфия вакытны киңәшмәдән киңәшмәгә кадәр санап яшәде. Һәр планеркада үзен бастыруын, Җәвидәчә җәзалавын көтте. Әмма теге киңәшмәдән соң тотынган яңгырлар беренченең кәефен ник бозды, сүз гел урып-җыюны төгәлләү турында гына барды.

Райкомда тагын бер тәртип урнашкан — инструкторлар чиратлашып эштән соң һәм иртән иртүк кизү торалар. Андый вакытта аларның төп эше беренче секретарьның техник сәркатибе вазифасын үтәүдән гыйбарәт. Беренче эштә булса, теге яки бу җитәкчене эзләтә. Дежурный аны җиде кат җир астыннан да табарга, тоташтырырга, кирәк икән, чакыртып китерергә тиеш. Ул кабинетында юкта инструкторлар, гадәттә, белемнәрен күтәрер өчен берәр әсәр укып утыралар.

Гөлфияне бүген чираттан тыш кизү торырга куйдылар. Төшке ашка кайткач, ул маршал Жуковның мемуар китабын үзе белән эшкә алды. Өйдә балалар белән булышканга, укырга вакыты аз кала иде. Хәлимов

колхозга чыгып китте, аннан кайткач райкомга кереп тормас, мөгаен. Күп вакыт ул шулай итә.

Ул йотлыгып укый башлады. Тик озак укырга туры килмәде, сәркатип бүлмәсенә Харисов килеп керде.

— Хәким Нурович юкмы? — дип сорады ул.

— Колхозда,— диде Гөлфия бер сүз белән генә.

— Кайсында?

— Белмим.— Гөлфия монда артык сүз ычкындырырга ярамавын белә инде: белмимнең башы авыртмый.

Харисов бүтән сүз әйтмәстән кабинетына кереп китте.

Ул яңадан маршал китабын кулына алды, кәгазь кыстырган битен ачты. Полководецның яшьлеге белән бәйле вакыйгалар эченә кереп чумды.

— У-һу, кемне күрәм,— дигән тавышка сискәнеп башын күтәрде. Каршында өлкә комитетының бүлек мөдире урынбасары Нәбиев басып тора иде. Ул, китап белән мавыгып, аның кергәнен сизми калган булып чыкты.— Сез дә мондамыни, Гөлфия?

Нәбиев районга килгәндә «Таң» колхозына кагылмый калмый. Алар шунда танышып калганнар иде.

— Әйе, күчерделәр.

— Дөрес эшләгәннәр,— диде Нәбиев.— КПСС райкомында сезнең ише партиягә ихлас бирелгән коммунистлар эшләргә тиеш тә.

Гөлфия дәшмәде.

— Син Сафинны яхшы беләсең инде,— дип янә башлады Нәбиев, бүтән сүз ишетмәгәч.— Җиде елда шулкадәр эшләгән — искиткеч. Турысын әйткәндә, Гәрәев егерме елда да аның кадәр булдыра алмаган әле. Мин ул килгәч үк сездә булган идем, хәзер авылыгызны танып та булмый. Менә кемгә герой бирергә кирәк.

— Бу бик гадел булыр иде, Шәүкәт Нәбиевич,— дип беренче тапкыр үз фикерен белдерде Сәйфетдинова.

— Барысы җирле җитәкчелеккә бәйләнгән,— дип куйды Нәбиев.— Аның Хәлимов белән боткасы пешмиме әллә?

— Мин монда яңа кеше бит әле.— Гөлфия өлкә комитеты вәкиленә хакыйкатьне ачарга җөрьәт итмәде. Харисовка сүзе барып җитсә, җавап биреп бетерә алмассың.— Күп нәрсәне белмим.

— Шулай.— Бу Нәбиевның аның белән килешүе идеме, әллә үз алдына гына моны әйтә куйдымы — Гөлфия аңламады. Әзрәк тынып торгач сорады.— Хәким Нурович кайтасын хәбәр итмәдеме?

— Бәлки, ул бүген монда кереп тормаска булгандыр,— дип үз фаразын белдерде Гөлфия.

— Юк, без аның белән алтыда очрашырга килешкән идек,— диде Нәбиев.— Эш бар иде.

* * *

Сәгать алты тулып килгәндә коридорда тамак кырган тавыш ишетелде. Гөлфия аны таныды, китабын тиз генә ябып, өстәл тартмасына шудырды.

— Йә, ничек, дежурлык итәбезме, Гөлфия? — Хәлимов, кабинеты янында тукталып, аңа таба борылды. Яңаклары алсуланган: әзрәк кәефләнеп кайтканга охшый.

— Әйе, Хәким Нурович.— Гөлфия урыныннан күтәрелде.

Хәлимов бүтәнне сорамастан, кабинетына узды. Берничә минуттан телефон аппаратында кызыл ут кабынды. Ул аны үзенә чакырды.

— Мине сораучы булмадымы?

— Нәбиев колхоздан кайткач сорады.

— Яхшы,— дип куйды секретарь.

Гөлфия Хәлимовны күзәтте. Кәефе әйбәт күренә аның, күзләре елмая. Мондый чакта фатир хакында сөйләшеп калсаң уңай, билгеле. Аның мондый көннәре сирәк була. Вакыты да бик кулай: авыл хуҗалыгы идарәсенең шәһәр үзәгендәге йортын файдалануга бирәләр. Харисов шуңа исемлек төзегән очраклы рәвештә өстәленнән күреп чыкты. Хәлимов вәгъдә иткән булса да, яшертен исемлектә аның фамилиясе юк иде. Җәвидәгә ялгыз башына да ике бүлмәне язып куйганнар.

Ятып калганчы атып кал: ул сорарга җөрьәт итте.

— Хәким Нурович, РАПО йортын тапшыралар, имеш. Аннан безгә дә квартира булмасмы икән?—диде белмәгән булып.— Бер бүлмәдә кысан, балаларга дәрес әзерләргә дә урын юк.

— Так!—Хәлимов уйланып торды һәм юләр шикелле үзалдына көлеп алды.— Фатир дисең инде. Әле бусын да юмадык бит.

Гөлфия бер мәлгә аптырап торды, әмма беренченең карашы мәрхәмәтле иде, үзен кулга алды.

— Икесен бергә юарбыз, Хәким Нурович.— Ул шаяртуны кабул итүен сиздереп ирен чите белән генә елмайды.— Бусында кунаклар утыртырлык урын да юк. Коллективны тулай торакның бер бүлмәсенә ничек сыйдырмак кирәк.

— Күңелең иркен булса, кунак кая да сыя ул.— Хәлимов һаман ягымлылык саклады.— Аннары мин коллектив белән бергә кунакка йөрмим.

— Алай булганда бик җиңел,— диде сөенеп Гөлфия.— Иртәгә Назыймның ял көне, кичке чәйгә рәхим итегез.

— Иртәгә мин бушамыйм әле.— Хәлимов нидер исенә төшергәндәй тиз генә өстәл тартмасына тыгылды, ачкычлар бәйләме чыгарды.— Картың, балаларың өйдә юк кичне бер чакырырсың әле. Һәм икенче көнне менә шул ачкычларны кереп алырсың. Бүген безнең белән куна барып кайтсаң, алар иртәгә үк керер.

Гөлфиянең оялудан йөзе кызыша башлады, кул-аягын калтырау алды, теле тотлыкты. Моның кадәр оятсызлыкны аның авызыннан ишетүне һич тә башына сыйдыра алмый иде ул.

— Бусы сиңа уйланыр өчен,— диде Хәлимов көтеп-көтеп тә җавап ишетмәгәч.— Хәзер, сеңел, бер нәрсә дә бушлай гына эшләнми—заманасы шул.— Тагын әзрәк туктап аңа карап торды да боерды:—Ә хәзер миңа Низамованы тиз генә чакырып китер.

Сәйфетдинова аның кабинетыннан ничек чыкканын, Җәвидә номерын ничек җыйганын да хәтерләмәде: барын инстинкт буенча эшләде.

— Әй аллам,— диде Җәвидә чакыруны ишеткәч. Төребкәдә аның мыш-мыш килеп сулаганы ишетелде.— Гөлфия, әйт әле, зинһар, ул өйдә юк, тапмадым диң. Мин бүтән аппарат янына килмим, трубканы алмыйм.

— Соң ничек була инде бу?—Гөлфия аны аңласа да, әйтергә сүз таба алмады, аптырап калды. Миендә бер генә фикер иде: Хәлимовның боерыгы үтәлергә тиеш.

— Син минем хәлне аңла, Гөлфия. Миңа теге кунакка килүче белән умарталыкка барырга дигәннәр иде. Әмма бүген ир-ат заты кабул итә торган көнем түгел. Аңлыйсыңмы, хатын-кызның андый вакыты да була бит. Зинһар, өйдә юк, дия күр. Калганын иртәгә аңлатырмын, җавабын үзем бирермен.

— Бу ничек була инде, Җәвидә?—Хезмәттәшен яшереп калу турында уй аның күңеленә дә кереп карамады.

— Йә, ходай,— дип куйды Низамова.— Инде ул мәсьәләдә дә безгә ирек калмаган икән.— Аның тавышы ачулы, нәфрәте ерактан ук сизелеп тора иде.— Бар, кереп әйт: мин өйдә, юл уңаеннан ала чыксыннар.

Гөлфия җиңел сулап куйды.

* * *

Жәйге яңгырлар көзгә килеп тоташты. Көннәр гел сүрән, болытлы торды, ара-тирә иләктән чыккан шикелле вак яңгыр сибәләргә кереште. Ул бер тотынгач тәүлекләр буена сузылды.

Хәлимовның да чырае гел шул болытлы көн шикелле, кул астына эләккән бер хезмәткәрен утлы табага бастыра килде.

Бер көнне Гөлфия уйланып утырды да китапханәгә төшеп китте. Белешмә-җавап язу өчен атеистик темага брошюралар алмакчы иде.

— Надежда Ивановна, сез мондамы? — дип сорады ул уку залында кеше күрмәгәч. Җавап бирүче дә, китаплар саклана торган эчке бүлемнән чыгучы да булмады. Китапханәче буфетка чәй эчәргә кергән, күрәсең: югыйсә, ачык калдырмас иде. Ул аны көтәргә булды.

Ул арада уку залына Җәвидә килеп керде һәм пышылдап:

— Ни эшлисең әле? — дип сорады.

— Белешмә дип канны эчә бит.— Гөлфия хәзер, үзләре өстеннән кергән хатны тикшерү вакытында аңлап калгач, Җәвидәгә тулысынча ышана, үзләренең хәле турында иркенләп фикер уртаклаша иде.— Җавап язу өчен материаллар алырга төштем...

Җәвидә эчке бүлем ягына төртеп күрсәтте һәм күрсәткеч бармагын авызына куйды: теленне тый, янәсе.

— Монда кеше юк, курыкма.— Аннан икенче темага күчеп сорады.— Хәлимов диндар бабайлар хаты өчен дә Ленарга ябырылды: аны нишләтергә мөмкин?

— Ленар артында түгел, алдында сүккәндә дә исе китми әле. Кирәген кыска гына, кырт итеп әйтеп авызын каплый да трибунадан төшеп китә.

Алар беравык тын тордылар.

— Ленар колхозга председатель итеп сайлангач ук: «Мин — иректе тоткын», дигән иде. Хәзер тәмам аңладым: чынлап та, без барыбыз да иректе тоткыннар икән бит.

— Ленар белми әйтми инде, чынлап та шулай,— дип аның белән килеште Җәвидә.— Мин монда шуны белми килеп каптым, ә син, юләр, белә торып килгәнсең. Хәзер моннан яхшылык белән башны алып чыгып булырмы — белмим.

Шулчак ишек ачылып китте, Надежда Ивановна килеп керде.

— Гамир, син мондамы? — дип сорады ул русчалап.

Тавыш ишетелмәде. Китапханәче эчке якка үтте. Котлары алынган инструкторлар, йомышларын да онытып, залдан чыгып киттеләр.

— Бүген киңәшмәдән соң Надя янына китапханәгә кергән идем. Ул буфетка чыгып китте,— дип ашыгып сөйли башлады Харисов.— Мин шүрлекләр ягына кереп, китаплар караштыра башладым. Шулчак китапханәгә Җәвидә белән Гөлфия килеп керделәр һәм серләшә башладылар.

— Шуннан ни? — дип сорады секретарь.

Харисов китапханәдә инструкторларның икесе арасында булган сөйләшүләрне сүзгә сүз җиткерде.

— Нинди «иректе тоткын» ул? Кем тоткын? — Кабаланып сөйләгән мөдирнең төп фикерен тотып өлгерми калды секретарь.— Аңлатып сөйлә!

— КПСС райкомы бюросы карары нигезендә эшкә җибәрелгән, билгеләнгән коммунистлар барысы да тоткын булып чыгалар. Бу — зур политик хата.

— Бу хата гына түгел.— Ниһаять, Хәлимов җепнең очын тотып алды.— Хатаны кеше үзе аңламый эшли. Ә бу, болар — аңлы рәвештә партия курсына каршы чыгучылар. Сталинны сүгәләр, әмма ул партияне әнә шундый корткычлардан чистарткан һәм бик дөрес эшләгән.

— Гөлфия бер хәл, ул Ленарны яшьтән яратты, гомер буе аның йогынтысыннан чыга алмады, сөяркәсе булырга да риза.— Хәлимов туктаган арада Гамир бу мәсьәләгә үз карашын белдереп калырга ашыкты.— Турылыклы күренгән Җәвидәнең дә алар кубызына биюче булуы аңлашылмый.

— Гаҗәп,— дип куйды Хәлимов һәм мөдиргә туры карап сорады.— Син арттырмыйсыңмы? Бутамыйсыңмы?

— Что сез, Хәким Нурович.— Харисов тиз генә кесәсеннән блокнот тартып чыгарды.— Бу хакта сөйләшә башлагач онытканчы язып ук куйдым.— Ул тиешле битен ачып блокнотны секретарь алдына салды.

— Котелогың эшли икән, молодец.— Хәлимов блокнотны бер читкә алып куйды: укырга өлгерер, хәзер тәэсирләре белән уртаклашты.— Аппаратта агулы еланнар үрчетеп ятабыз икән ич, менә бәла нәрсәдә.

— Минемчә, КГБдан кеше чакыртырга кирәк.— Гамир форсатны тулы файдаланып калырга тырышты.— Ни эшләтергә кирәген алар үзләре белер.

— Юләр,— диде Хәлимов авызын турсайтып.— Бөтен Союзга даны таратыргамы? Синең, минем баштан сыйпарлар дисеңме әллә?

Харисов авызына су капкандай тынып калды. Хәлимов ашыкмый гына урыныннан торды, өстәл артыннан чыкты, кабинеты буйлап йөреп килде. Бүлек мөдире, хәзер үзенә ябырылудан шүрләп, еш-еш сулады.

— Бу хакта кемнәргә сөйләдең?— Ул аңа карчыга күзләре белән ашардай булып карады.— Тик турысын әйт, югыйсә үзеңә начар булыр.

— Беркемгә дә, Хәким Нурович,— диде мөдир аптырап.

— Беренчедән, Сафин белән Гөлфиянең мәхәббәт тарихын яңабаштан тикшерергә кирәк,— диде Хәлимов, байтак уйланып утырганнан соң.— Амораль тәртибен исбатлый алсак, аны шундук партиядән чыгарырга мөмкин. Икенчедән, РАПО начальнигына команда бирергә кирәк, ревизорлар җибәреп, Сафинның барлык подсобный цехларын җентекләп тикшерсен.— Ул мөдиргә карады, сораулы карашын күреп өсти куйды.— Да, да, аңлыйм, моны мин үзем кушармын.— Ул урыныннан торды.— Тагын... Пока син минем күрсәтмәдән тыш бернинди адым да ясамыйсың. Үзең бүген монда бул.

— Тегеләрне бүген аерасы иде. Гөлфиянең башына тай типмәгән, сизсә, шикләнсә...

— Әйе, анысы безнең өчен каты чикләвек булачак, ул Җәвидә генә түгел инде, Сафинның турылыклы ялчысы.— Хәлимов тәрәзә янына китте, урамга карап тора башлады. Харисов аның бу минутта үзе куйган проблемалар хакында уйлавына шикләнмәде. Дөрес күрәзәлек иткән булып чыкты. Хәлимов борылды һәм болай дип карар кылуын белдерде.— Гөлфияне болай гына алдырып булмый, мин алдан Җәвидәсен чакырып барын сөйләтәм. Ул сүзләрен таныгач, тегесе беркая бара алмый. Димәк, бүгенгә Сәйфетдиновасын моннан озатырга кирәк.

Харисов Сәйфетдинованы колхозга озатып җибәрүен шалтыратып әйтүгә, Хәлимов Низамованы үзенә чакыртып алды.

— Йә, хәлләр ничек, Җәвидә?— Ул махсус рәвештә бюролар үткәрә торган өстәл башына күчеп утырган иде, аңа яныннан урын күрсәтте. Җәвидә берәр эш кушадыр дип блокнотын, авторучкасын кулына алды. Хәлимов бүтән сүз дәшмәде, аны шактый күзәтеп утырды, кулы белән яшь хатынныкын угалады. Җәвидә кулларын яшермәде, оялган булып башын читкә борды.— Ниләр белән шөгыльләнәсең әле?

Җәвидә санап күрсәтте.

Хәлимов тагын берничә мөһим булмаган сорау бирде, ирләр арасында йөргән бер мәзәкне сөйләп алды: рәхәтләнеп көлештеләр.

Җәвидә көлгән арада Хәлимов аның йөзенә туры карап тора башлады. Аның йөзе җитдиләнүен күреп, ул көлүен бүлде.

— Сезнең кайсыгыз ирекле тоткын әле?— Хәлимов сорауны кинәт һәм кабыргасы белән китереп куйды.— Синме? Гөлфияме? Әллә?!..— Юри әйтеп бетермәде.

Җәвидә бер мизгел эчендә кызарып чыкты. Моны күргәч, Хәлимов эчтән тантана итә башлады: ул — үз кеше, хәзер барын ачып салачак.

Җәвидә, йөз кызыллыгын яшерә алмаса да, үзен тиз кулга алды.

— Мин аңламадым,— диде ул аптыраган кыяфәттә.— Нинди ирекле тоткын ул, Хәким Нурович?

Хәлимовның йөзе каралып чыкты. Ул да Җәвидәне аңлады, үзенең хата җибәрүен дә сизде: урап тикшерәсе калган. Ләкин хәзер тукталып калу мөмкин түгел, сүзнең азагына чыгасы, кемнең кемлеген тәмам ачыклыйсы бар.

— Йәле, эшлисең, яшисең килсә, турысын сөйләп бир: китапханәнең уку залында кайсыгыз ни сөйләде? Тик турысын гына.

— Әйе,— диде Җәвидә үз-үзенә ышанган хәлдә.— Без аның белән уку залында очраштык. Ләкин безнең арада андый сүз булмады.

— Булганын син аның миннән сора,— диде Хәлимов сүзләрен алтын тешләре арасыннан сөзеп чыгарып, күзләрен кысып.— Яшереп тору үзеңә файдасыз: миңа ул билгеле. Миңа просто кемнең кемлеген ачыклау гына кирәк.

— Безнең арада андый сүз булмады,— дип кабатлады Низамова, аның йөзенә туры карап.

— Син нәрсә?— дип тешләрен шакырдатты Хәлимов.— Мин үземнән уйлап чыгармыйм бит моны.

— Бу әләкче эше, безнең күралмаучы кеше эше генә.

— Моны ахирәтең үзе кереп сөйләде.

— Кем сөйләсә дә, ялган, яла гына. Ул сезнең алда ышаныч казанырга тырышкан хыянәтче эше генә.

Хәлимов байтак кына Җәвидәгә карап торды.

— Ах, син әле шулаймы,— диде ул нәфрәт белән.— Ашаган табагыңа төкерәсеңме, өстерәлчек.

— Теләсә ни әйтегез, әмма юкны бар дия алмыйм мин.

— Мин сине тараканны изгән шикелле сытачакмын, шлюха. Гаебеңне танысаң, үзеңә җиңелрәк булыр.

— Мин булмаганны булды дия алмыйм, Хәким Нурович,— диде Җәвидә күзләрен дә йоммыйча аңа караган хәлдә.

— Аңлашылды, синең белән потом разберемся,— диде Хәлимов ачуына буылып.— Тик кисәтеп куям: бу сөйләшү пока үзара гына. Моның белән КГБдан тиешле кешеләр шөгыльләнер. Алар телеңне ачтыру юлын табар. Гаебеңне танып, безгә булышсаң гына, башыңны исән-имин алып чыгарсың. Яхшылык белән котыласың килсә, бу сөйләшү турында оныт. Беркем дә белергә тиеш түгел. Компаньоннарың да.

* * *

Гөлфия сигез тулганда шалтыратты.

— Хәким Нурович, исәнмесез. Бу мин — Сәйфетдинова әле. Гамир Садыйкович өегезгә шалтыратырга кушты.— Борчуым өчен гафу итегез.

— Зарар юк,— дип аны тынычландырды Хәлимов.— Кичә обкомнан идеология секретаре үзе шалтыратты. Бездән Камышлы картлары хатына аңлатма сорый. Алар инде Мәскәүгә үк язганнар диме. Җавап иртәгә аларга барып җитәргә тиеш.

— Ул әле язылып та бетмәгән, Хәким Нурович, иртәгә ничек тә барып өлгерми, почта аша берничә көн бара,— диде Сәйфетдинова.

— Баручы аша озатырбыз,— диде Хәлимов.— Кирәк икән, үзеңне үк машина белән илтеп кайтырга җибәрербез. Эш аңа тералмәс. Менә

чирләп киттем әле, йөрәк дулый, кан басымы әллә күпмегә күтәрелгән. Әйдә болай итик. Син ул белешмәнең язган кадәрен ал да безгә кил. Җавапны киңәшеп әзерләрбез. Ул арада Гөлчирә апаң юкә баллы чәй әзерли торыр.

— Мин хәзер барып җитәм, Хәким Нурович.

Аңа озак көтәргә туры килмәде, ишектә кыңгырау чыңлады. Хәлимов диванга җәйгән урыныннан кузгалмады, ята бирде.

— Керергә ярыймы?

— Гөлфия, синме? Кер әйдә, монда уз.

— Исәнмесез, Хәким Нурович.— Гөлфия зал якка үтте.— Нәрсә, шулай каты чирләдегезмени? Мин аяк өстеннән үткәрә торган авыру гына дип торам тагын.

— Йөрәк нык чәнчә, Гөлфия. Башка чыдарга юк. Илле яшь үзен сиздерә шул.

— Сезгә берәр төрле ярдәм кирәкмиме соң, Хәким Нурович? Чәй кайнатырга түгелме?— Гөлфия аның хәле турында чынлап кайгыртырга керешге.— Гөлчирә апа да өйдә юкмы әллә?

— Дарулар алырга дип чыгып китте. Хәзер кайтып җитәр. Син миңа карап торма инде, Гөлфия. Утыр да җавапны язып бетер. Беләсеңме, нәрсәгә басым ясa. Зыятдин картка. Партиядән куылган, шуңа Совет властена, партиягә үч итеп башкаларны котырта, дип. Әнә өстәл, шунда утыр. Аннан бергә укып чыгарбыз. Аңа кадәр минем хәл дә уңайлана төшәр, бәлки.

Ул карап ятты, Гөлфия хатны, үз җавабын укып чыкты, нидер сызды, нидер өстәде.

— Нәрсә, бетмиме әле, Гөлфия?

— Хәзер, йомгаклыйсы гына калды инде.

— Ярар,— диде Хәлимов үз алдына сөйләгәндәй.— Мин Гөлчирә апаңны карап керим, валидол эчеп килим.

Күрде, Хәлимов торгач сагаеп, шикләнә калган Гөлфия тынычланды, янә авторучкасын кулына алды. Ул ишегалдына чыкты, урамга күз салды. Кергәндә акрын гына ишекнең бикләвечен борды һәм ачкычны кесәсенә салды. Аптечкадан берничә таблетка порошок алды, бергә кушып су белән йотып җибәрде, залга әйләнеп кергәч, Гөлфия шикләнмәсен өчен, читкәрәк утырды һәм җавапны кулына алды.

— Шулай яраса инде,— дип куйды Гөлфия.

— Тиз эшлисең дә соң үзең. Акыл да бар үзеңдә. Күптән райкомга аласым калган. Нинди сәләтле партия работнигын күрми торганбыз, бериш инструкторның өчесенә торасың бит син. Менә дигән идеология секретаре. Сәнгатов җаен партия мәктәбенә китәргә җыена, әйткән иде диярсең, аның креслосы — синеке.

Ул әлегә кадәр аның авызыннан бер җылы сүз дә ишетмәгән Гөлфиянең күңеле эреп киткәнен йөзеннән үк күрде һәм үзе өчен кулай мизгел җиткәнне аңлады.— Тик аңа кадәр бер нәрсәне генә ачыклап узасы бар. Ул урындыгыннан торды, өстәл янына килде, әңгәмәдәшеннән күзен алмыйча гына җавапны өстәлгә куйды.— Бер кечкенә нәрсәне генә.— Әйт әле, Гөлфия, сезнең кайсыгыз ирекле тоткын?

Гөлфия, инәләр өстенә утыргандай, ялт сикереп торды. Ул өстәл белән Хәлимов арасында калды: аралары бик якын, секретарьның юан корсагы аңа тиям-тиям диеп тора иде.

Хәлимов күзләрен аннан секундка да алмады. Инструкторның көтелмәгән бу удардан миңгерәүләнеп калганын ул чамалый иде. Хәзер аңа айнырга, аң алырга бирмәскә кирәк. Шуңа кадәр өлгерсә, максатына ирешәчәк.

— Юк инде, йөзеңне яшермә, әйт: кем ирекле тоткын?— Ул аңа таба бер адым ясады, корсагы белән төртте. Гөлфия, ишек ягын Хәлимов каплап торганга читкәрәк тайпылды, артка таба чигенде.

— Йә, нигә дәшмисең? — Ул тагын бер адымга алга күчте, корсагы белән янә этте. Көтелмәгән бу сүзләрдән коты алынган хатын тагын арткарак чигәргә мәҗбүр булды.— Кабатлап сорыйм: кем иректе тоткын? Синме, Җәвидәме? Ленармы?

Ул тагын аягын алга күчерде, тау чаклы корсагы белән аны этте. Хатынга чигенер урын калмаган, аяклары диванга терәлгән иде инде, ул икенче аягын да күчерүгә, тигезлеген югалтып, диванга авып төште.

Хәлимов төгәл исәпләгән булып чыкты, барысы да планлаштырганча килеп чыкты.

Ул, хатын кузгала башлаганчы, аның өстенә ауды. Диван каты шыгырдап куйды. Гөлфиянең «ай-яй» диеп ыңгырашканы ишетелде.

* * *

— Торыгыз инде, Хәким Нурович, авыр бит.— Тораташ булып яткан Гөлфиянең, ниһаять, теле ачылды.

«Әһә, хәзер инде монының сөйләрлеге бар». Хәлимовның күңеленә беренче булып шул уй килде. Алдан ул хатын кычкырып, талпынып карар дип көткән иде, әмма ул карусыз буйсынды. Кыргый хатынның физик яктан шулай ансат кулга төшерде ул. Психологик җиңү өчен дә ачкыч шул булырга тиеш. Минутын да кулдан ычкындырырга ярамый.

— Син тәки минем сорауга җавап бирмәдең бит әле, сылукаем.— Ул кеткелдәп көлде, аның иреннәреннән үбеп алды, хатын көчәнеп башын янгарак борды. Теләмәде, димәк. Ул башкача эш итәргә булды, аның муены астындагы кулын тартып алды.

— Ай-ай-ай,— дип ыңгырашты хатын. Белә: аның центнер да утыз килолы гәүдәсен күтәреп яту җиңел түгел.— Гөлчирә апа кайтыр.

— Казанда ул, курыкма,— диде Хәлимов, исе китмәгән булып.— Тыныч бул.— Ул хатынның акыл җыя баруын аңлый, ашыгырга кирәк. Югыйсә, икенче яктан да сындыра алмаса, эш катлауланып китү ихтимал. Ленарга хәбәр итсә, судка кадәр китүе бар. Ул бар куәте белән хатынга сыланды һәм күкрәген аныкы өстендә йөртә башлады.

— Ай-ай-ай, әнием,— дип чәрелдәвек тавыш белән кычкырып җибәрде хатын.— Имиләремне изәсең бит.

Ул беренче тапкыр хатын-кызның кайчан сингә күчкәнен белә иде. Тик монысы өчен бүген мөһим түгел. Аның ялваруын ишетмәде, алдагыча хәрәкәтләнә бирде.

— Йә, әйт инде, былбылым, кем соң ул иректе тоткын? — Ул моны юри пышылдап кына әйтте.— Онытгыңмы әллә? Мин белүен беләм, китапханәдән чыгуга, Җәвидә кереп сөйләп чыкты чыгуын, әмма синең авыздан да ишетәсе килә.— Ул авызын аның авызына куйды, тагын тончыктырып карарга җыенды.

— Ленар,— диде Гөлфия.

— Тагын кем?

— Мин, Җәвидә.

— Кайда, кайчан әйттегез инде? — Ул бар көче белән хатынга сыланды.

— Кичә... Райкомның уку залында... Мин... Җәвидәгә.— Ул өзек-өзек кенә әйтә алды, чөнки шулай гына тын ала иде. Хәлимов, кузгалган булып, тагын аның күкрәге өстендә үзенекен йөртте.

— Әнием, ү-ләм! — дип кычкырып җибәрде Гөлфия.

— Үлмисең, матурым, үлмисең.— Ленарның минем хактаниләр сөйләгәнен ачып бирсәң, җәннәттә генә яшәтәм мин сине, былбылым.— һәм ир кеше бар авырлыгы белән тагын аңа сыланды.

— Сөй-лим,— диде Гөлфия тын алганда.— Тик, зинһар, измәгез генә. Сытасың бит.

— Барысын да,— диде Хәлимов, аңа тын алырга ирек биреп.

— Белгә-нем-не...— диде Гөлфия.

— Вот, молодец,— диде Хәлимов.— Мин сине гел намуслы хатын санап йөрдем һәм ялгышмаганмын.

Гөлфия еш-еш тын алып хәрәкәтсез ята бирде.

— Йә, хәзер сөйлә,— диде ул хатынның тын алуы нормальләшә баруын күреп.— Ленар предлыкка сайлаткач ук үзен ирекле тоткын дип санадымы?

— Әйе.

— Башың эшли кебек үзе,— дип нәтиҗә ясады Хәлимов.— Йә, ярар, хәзергә җитеп торыр. Иркенрәк итеп башка вакытта, башка урында сөйләшербез әле...

Хәлимов яныннан чыккач, үз язмышы турында уйламады да Җәвидә: беткән баш беткән. Аны бер генә уй биләде: Гөлфияне кисәтергә, Ленар белән киңәшергә. Үзләрен хәзер берни коткара алмаса да, бәлки, куып чыгару белән чикләнерләр. Райкомнан статья белән кумыйлар, бәлки үзләрен гариза язарга кушырлар. Алардан бушану белән Ленарга ябырылачаклар. Аңа саклык чаралары күрергә кирәк: шул хакта сәгате, минуты белән хәбәр итү зарури. Башкаларын уйларга аның башыирешми, Җәвидә миңгерәгән шикелле иде.

Бөтен кабинетларны да тикшереп чыкты, бәдрәфкә кадәр сугылды: Гөлфия беркайда да юк иде. Түзмәде, сәркатип кыздан беренче янында кем булуын белеште: хәзер аны газаплыймы әллә тиран.

Гөлфиянең анда булмавын белгәч, бер иркен тын алды: шөкер! Көн тәмамланып килә, иртәгә кадәр ул аны өенә барып та кисәтә алыр.

Җәвидә телефоннан шалтыратырга курыкты: тыңларга кушкан булулары бар. Шулай да ансыз чара юк, исемен әйтми генә Ленарга, ул булмагач, Эльвирага шалтыратты. Иртән Казанга киткән, бүген үк кайтасы икән.

Ашыгып фатирына сугылды, авыл хатыннары кебек алдан яулык бәйләп җибәрде: танымасыннар.

Ул ашыга-ашыга Гөлфияләр яши торган нефтьчеләр тулай торагына килеп керде. Үзе өйдә булмаса, иренә яисә балаларына әйтеп калдырырга исәп тотты.

Гөлфияләр бүлмәсе кыңгыравына кабат-кабат басты, эчтән тавыш ишетелмәде.

Вакыт әрәм итеп торасы юк, Камышлыга барырга кирәк. Сафин кайтам дип киткән ич. Автовокзалга кермәскә булды, авылга машиналар йөреп тора, очрар әле.

Озак көтәргә туры килмәде, машина килеп чыкты.

Җәвидә аның милициянең «кара козгын»ы икәнен таныды. Күңеленә шөбһә керде: аны эзләп чыкканнармы әллә?

Тукталышта машина көткән аның ише ике мосафир егет тә йөгереп килеп җитте.

— Сезне түгел,— диде кабина ишеген ачучы.— Җәвидә, килегез!

Җәвидә килеп кергәндә Ленар, алдына калын папка куеп, машинкада басылган текстны укып утыра иде.

— О-һо! — Җәвидәне күргәч йөзе яктырып китте.— Уз. Утыр. «Шампанское»ны эчешергә иптәш булды.

— Эчкән-эчкән, аның белән генә авыз пычратып торасы түгел инде.— Эчен кайгы кимерсә дә, берьюлы чишелеп булмый бит. Рәиснең авызы колагына җиткән бу минутта бигрәк тә.— Булса — «Коньяк», һич югы «ак» булсын.

— Анысын да табарга була.— Сафин кулларын уып алды һәм сораганны да көтмичә сөйләп китте: — Нәбиев кемгәдер киңәш иткән, ахрысы, Казаннан шалтыратып ярдәмче хуҗалыкларыбыз турында мәкалә язуымны үтенгәннәр иде. Яза башлагач, ул бик күләмле килеп чыкты.

Фәнни яктан бәяләү өчен редакция аны институтка биргән. Ул элекке остазым Шәрәповка килеп эләккән. Галим укып чыккач, аны кинәйтергә, тулыландырырга тәкъдим итте. Әзерләп илттем. Аны диссертация итеп кафедрада якларга киңәш иттеләр, фәнни җитәкчеләр билгеләделәр. «Бик үтемле тема, бәхәссез узачак, үзеңне бүгеннән экономика фәннәре кандидаты итеп сана»,— дип җибәрделәр. Диссертацияне яклау вакытын гына билгелисе калды, ул якын араларда хәл ителергә тиеш.

— Котлыйм сезне, Ленар Салихович.— Җәвидә эчке каршылыкларын басып елмайгандай итте.— Сез максатчан кеше, булдыргансыз.

— Шәрәпов Нәбиевкә шалтыратты.— Сафин бүген, Җәвидәне беренче тапкыр күрә, эчтән-тыштан балкый иде.— Аны фәнни китап итеп чыгарырга тәкъдим итте, кыйммәтен аңлатты. Шәүкәт Сабирович бастырып чыгару мәшәкатьләрен юллауны үз өстенә алды.

Җәвидә боларны эчке курку белән кабул итте. Хәзер, райкомдагы бүгенге хәлләрдән соң, Сафинның бу тырышулары юкка чыгуы бар, моны ул анык сизә. Алар, ике кортлы тел, аңа нинди киртә куюларын хәзер, Сафин сөйләгәннән соң гына, аңлады.

— Сез мәктәптә укыганда, белүемчә, яңа сортлар белән мавыга идегез бит.— Күңелендә бөтенләй башка уйлар булса да, сүзләренең ат аягын дагалаганда бака ботын кыстырган шикелле килеп чыгуын чамаласа да, Җәвидә шул хакта гәп кузгатты. Ул Сафинны хыялый дөньядан тизрәк арындырырга, бүгенге чынбарлыкка кайтарырга ашыкты.

— Монда, колхозда сорт сынау белән шөгыльләнү мөмкин түгел, шунлыктан, шартларга яраклашып, икенче проблема өстендә эшләргә туры килә.— Сафин хәвефне сизми, элеккечә күтәренке рухта кала бирде.— Йә, ничек, юабызмы? Мин хәзер Миңнегөлгә шалтыратам — әзерләнеп торсын.

Җәвидә сискәнеп куйды.

— Юк, бүген түгел, Ленар Салихович.

— Нишләп алай?

— Кәефем юк.

— Нәрсә булды? Авырдыңмы әллә?

— Авырсам, больницага барган булыр идем.

— Әйт, нәрсә булды? — Сафинның кәефе тиз сүрелде.

— Эштә җитди күңелсезлек килеп чыкты.

— Ачуландымы?

— Ул гына булса икән.

— Кызлар шикелле кыланма, ачык әйт: ни булды?

Ул вакыт җиткән санады.

— Эшләр харап, Ленар Салихович.— Артык сузар хәләттә түгел иде ул, берьюлы ачып саласы итте.— «ЧП» килеп чыкты — без яндык. Шуның өчен ашыгыч рәвештә синең янга киңәшкә килдем: нишләргә?

— Кемнәр ул «без»? — дип сорады Сафин.

— Син, мин, Гөлфия.

— Аңлатып бир. Ленар Җәвидәнең бер сүз белән аңлата алмавына, сузуына ачуы чыкты.— Табышмак ясама.

Җәвидә ашыга-кабалана бүген булган хәлләрне кабатлап чыкты. Азактан үзеннән өстәде:

— Син, дөрестән дә, безнең барыбызның ирекле тоткын булуын бик тиз аңлаган булгансың икән.

— Нәрсә, шул хакыйкатьне аңлар дәрәҗәгә үсеп җиттеңме? — дип сорады Сафин, усал елмаеп.

— Анысы бер хәл, болар барысы да Хәким Нуровичка билгеле инде,— диде эчтән сыкрап Җәвидә.— Мине чакыртып сорау алды, янады.

— Авызыңны ачып теләсә кайда кирәк-кирәксезне сөйләп йөргәч, шулай буласы билгеле инде.— Ул иреннәрен турсайтып аны сынап утырды һәм өстәде: — Акылыңа килеп сөйләп тә бирдең инде?

Җәвидәнең җылыйсы килеп китте. Аңа серен, хакыйкатьне сөйли, ул, тапкан вакыт, үчекли. Әмма аның үпкәләргә урыны, вакыты да юк инде.

— Сөйләсәм, Сезнең каршыга килә алыр идемме?

— Шулай,— дип аның белән килеште Ленар.— Тик аңа кем әләкләп өлгергән соң? Икегезнең берегез.

— Алай була алмый,— диде Җәвидә аптырап.— Гөлфия үзе башлады. Аның хәле мине сынаудан узган чак, үзең дә беләсең. Безне тыңлап торучы булган.

— Бәлки, Надя тышкы яктан тыңлап торгандыр. Ул бит татарча яхшы белә.

— Мөмкин түгел, без аннан еракта идек.

— Алайса эчке яктан Гамир үзе тыңлап торган,— дип нәтиҗә ясады Сафин.— Надя аннан башка берәүгә дә китапханәне калдырып чыкмый. Гамир кергәч, ул үз йомышлары белән чыгып киткән.

Җәвидә авыр сулады: Сафин әйткәне чынга якын сыман иде.

— Бу ничек булып бетәр инде, Ленар Салихович?

— Турысын сөйләп бирсәгез, бәлки гафу итәр. Әмма сезне ул бүтән янында калдырмаячак инде.

— Ә син?

— Иң кискен вакытта гына аяк тышавы булдыгыз,— дип куйды һәм тешен кысып, йодрыгын өстәлгә төеп торды.— Кирәк бит!

Җәвидә аның хәлен аңлый, чыны шулай: эшеннән дә алырлар, партиядән дә чыгарырлар. Ул чагында диссертациясен үткәрмәячәкләре билгеле инде.

— Сез ни әйтсәгез дә хаклы, Ленар Салихович. Үзебез өчен кайгырмыйм, түзелештә буяучы булып та эшләрмен. Сиңа хәзер ничек ярдәм итәргә? Мин, теләсә ни эшләтсә дә, төрмәгә яптырса да, бүген әйткәннәрне генә кабатлыйм. Гөлфиянең дә Сезне сатмасына ышанам.

— Ләкин ул хәзер Сезгә ышаныр дисеңме?

— Ышанмасын, эштән чыгарсын, әмма сиңа кагылмасын. Ул бит Сез кайчандыр әйткәнне бу очракта раслый алмый.

— Монда суд законнары роль уйнамый,— диде уйланып Сафин.— Ә бу очрак аңа ачыктан-ачык көрәшергә сылтау бирәчәк.

— Син әйтмәдең бит әле.— Җәвидә үзе дә сизмәстән тагын «син»гә күчте.— Без ни эшләргә тиеш?

— Җибәрсә, гариза язып китегез. Бу хәлдән соң сез анда эшли алмаячаксыз инде.

— Ә син?—дип ашыгып сорады Җәвидә. Аны нәкъ шул борчый иде.

— Мин аның каршына барып гафу үтенмим инде, ул барыбер кичермәс тә иде. Андый түбәнчелеккә төшә алмыйм. Бүген ничә еллар буе куйган хезмәтемнең нәтиҗәләрен көткәндә генә китә дә алмыйм.

— Моны ничек диеп аңларга?—Җәвидәне курку хисе биләп алды. Алар китсә, Сафинны ялгызын гына ул изеп ташлаячак бит.

— Ул чагында, теләсә ни белән бетсә дә, мин үтенеп, ялынып райкомнан китмим,—диде Җәвидә катгый фикергә килеп.

— Ирләр сугышканда хатыннар да катнашса, беләсеңме, ни була?— диде Сафин каршы төшеп.— Комачаулый, үзенә дә эләгә.

— Ул мине имгәткәндә мин карап торырмынмы?!—Җәвидә кинәт кабынып китте, кечкенә кулын ирләрчә йодрыклап селкеп алды.— Мин белгәннәр аны муеныннан гына түгел, түбәсе күмелгәнче батырырга җитә. Герой исемен хезмәте өчен алдымы әллә? Казанга бүләк ташып кына. Кемнәргә икәнен дә беләм.

— Ярар, монда батырайма, гайрәтеңне сакла.— Сафин ирен читләре белән елмаеп куйды.— Гайрәт бар икән үзеңдә.

— Мин күрсәтәм әле аңа.

— Булды, тынычлан.— Сафин яңадан җитдиләнде.— Бу шулай бетәсен мин алдан ук чамалый, шуңа әзер идем. Хак сүзне ана барыбер әйтәсе идем. Сезнең сүзләр вакыйгаларны бары тизләтте генә.

— Синең хаклык өчен азаккача көрәшүеңә мин күптән ышана килдем. Син нык холыклы, тик Гөлфияне ничек кисәтергә?

Сафин ул әйткән номер буенча Наратлыга шалтыратты. Җавап бирүче булмады.— Бәлки ул Каенсарга китеп баргандыр?—диде Җәвидә.

— Анда булса хәзер табабыз, чакыртабыз аны,— диде Сафин. Анда сеңлесе Әнисә почта бүлегендә эшли иде, шуларга шалтыратты. Әнисә үзләреннән ике йорт аша гына яшәгән Гөлфиянең әниләренә барып килде. Ул анда кайтмаган иде.

* * *

Бүгенге хурлыкны Гөлфия һич күтәрә алмый. Ире алдында тагын гаепле. Ленар белән булган чактагыча моны ул аңа сөйләп тә бирә алмый. Әгәр шул килеш больницага барса, сөйләп бирсә? Милиция аркылы эш йөртергә кушачаклар. Врачлары да Хәлимовтан тетрәп тора: аның файдасына берни эшләмәячәкләр. Аны, гайбәтен сатып, районнан ук куачаклар. Хәлимов хакыйкатьне күзенә карап әйткән берәүне дә районда калдырмый, куа алмаса, барыбер китәргә мәҗбүр итә.

Ул хурлыгына түзәр, башка чарасы юк. Бәлки Назыйм да ишетмәс—узар. Әмма Ленар алдында кичерә алмаслык гаепле: еллар буе фикердәше булып серен алды, алды да сатты. Хәер, ул да, Җәвидә дә сатты. Җәвидә моны авыр кичермидәдер, әмма ул үзен моның өчен мәңге гафу итә алмаячак.

Гөлфия Хәлимовны күз алдына китерде һәм укшый башлады. Авызының сасысы һаман да үпкәләрендә саклана кебек. Тик монда, урамда коса алмый, узган-барган аны исерек санавы бар. Ул авызын тотты, иреннәрен тешләде, уртына тулган шакшы сыекчаны, үзен көчләп, йотып җибәрде.

Тулай торакка кергәндә бер генә нәрсәне теләде: танышлары очрамаса иде.

Ул ашыгып үз бүлмәләренә кереп китте һәм ишекне эчтән бикләп куйды. Хәзер аңа юлда уйлаганнарын гамәлгә ашырырга берәү дә комачауламаячак.

Иң элек ул шифоньер янына килеп яңа эчке киемнәрен сайлап алды һәм ашыга-кабалана киенде. Күлмәгенең дә бәйрәмгә кия торганын сайлады. Хәзер аларны саклап торуның кирәге калмады. Иләндә яткан киемнәрен җыеп ваннага, башка керләр астына яшереп куйды.

Ванна бүлмәсеннән чыкканда ишек төбендәге өчъяклы көзгегә күз салды. Чәчләре тузгыган, йөзе таушалган, муеннарында кара таплар: шакшының үпкән эзләре. Аларны тәртипкә китерергә кирәк.

Күп уйлап тормастан, массаж тарагы белән чәчен тарарга кереште. Чәбәләнеп беткән чәчләрне көчкә тәртипкә китерде. Аннан ашыгып битен, муеннарын юды. Монысы мәшәкатьле булмады, мул итеп пудра сылады да, кулы белән ышкып тигезләде. Җинаять эзләре калмады, йөзе, тәне дә ап-ак булып китте. И-их! Күңел җәрәхәтләрен дә шулай тиз генә юып алып булса икән?! Кызганыч, булмый шул. Хөрмәт, юк-юк, алай гына түгел, бүгенгәчә мәхәббәт саклаган кешеңә хыянәтне мәңге юып аласы юк. Ленар теләсә ни эшләсен, Гөлфия үз-үзен барыбер кичерәчәк түгел. Димәк, бер генә юл кала. Юлда кайтканда уйлаган ниятен гамәлгә ашырасы.

Гөлфия алгы якка чыкты, үзенә кирәкле шешәне сайлап алды. Кулы белән бөкесен тартып карады, булдыра алмады, тешләре белән кысып суырып чыгарды. Андагы сыекчаны стаканга агызды. Стакан тула язды. Аны кулына алды һәм, ни эшләгәнен үзе дә аңламастан, яңадан көзге янына килде.

Көзгедән ап-ак йөзле чибәр, мөлаем хатын карап тора иде. Гөлфия үзенең шул сурәтенә күпмедер мизгел тын гына төбәлеп торды. Күзләреннән, ихтыярсыз, яшь тамчылары тәгәри башлады. Ул аларны туктату өчен күзләрен кысып, йомып карады, алар тыелгысыз тәгәри, күз алдын томалый бирде, көзгедәге сурәте томан артында кала барды. Шулай да аерыла алмый карап торуын дәвам итте, күңелендә инде ничәнче кабат бер үк фикерләр әйләнде.

Юк, бернәрсәгә дә үкенми инде хәзер. Фани дөньяда ни рәхәт, ни шатлык күрде? Ленарны өзелеп яраткан иде, әнисе әйтмешли, тәкъдирдә язылмаган булган икән, гомерлек үкенеч кенә калды. Шул үк тәкъдир аны Назыйм белән кушылдырды — ни күрде? Аның теләгән үтәп, керләрен юып, аш әзерләп айлар, еллар узды. Рухи уртаклык кая, араларында әчке якынлык та булмады: иренең җаны, тәне дә салкын иде аңа. Башын бер бәйләгәч, балалар тугач, бәхетен барыбер табар өмете калмагач, яши бирде.

Стаканын авызына якын китерде: хәзер, хәзер. Тагын бер мизгел генә көтә дә, балаларын гына күз алдына китерә дә... Ярый әле, алар өйдә юк, кышкы каникулга чыгуга, аларны авылга, әнисенә илткән иде. Алар янында булса... Алар, Назыймга ышаныч юк, әнисе янында торып калырлар. Хәзер ни әйтсәң дә, зурлар, кулдагылар түгел инде. Кызганыч та бит, ләкин ни эшләмәк кирәк. Әнисе, тормышның әче-төчесен татыган булса да, нык әле, бирешмәс, балалар хакына үзен кулга алыр... Аны аңлар һәм кичерер.

Кинәт күкеле сәгать — әниләренең туй бүләге кычкыра башлады: бер тапкыр, ике, өч. Назыйм кайтырга сәгатьтән артык кына вакыт калды: бүтән сузарга ярамый. Ул янә стаканын авызына китерде. Борынына тәмсез ис бәреп керде...

* * *

Ишектә озын-озын кыңгырау чыңлый башлады. Ул стаканын көзге алдына куйды һәм ишек ягына борылды.

— Кем? — дип сорады.

Шуннан соң гына аңлап алды, дәшмәскә иде бит аңа. Шалтыратучы борылып киткән булыр иде. Планнары бүленде. Хәзер соң инде, өйдә икәнен белгерткәч, ачмыйча булмый.

— Гөлфия, кая югалдың син бүген? Ач әле тизрәк.— Шалтыратучы Җәвидә иде.

Гөлфия дәшми-тынмый гына ачкычны борды һәм керүчегә юл бирер өчен арткарак чикте.

— Кая югалдың син бүген? — Керешкә Җәвидә соравын кабатлады.— Бүген өченче кабат киләм инде. Ни эштә, ни өеңдә юк. Берәр нәрсә булдымы әллә?

— Кичә Калинин колхозына барган идем бит. Анда парторг алмашынды.— Ул нәкъ Хәлимов өйрәтеп җибәргәнче сөйләде.— Бүген ике арасында партия документларын, эш алмашу булды. Шуңа тоткарланырга туры килде. Яңа кайтып кердем.

— Мин әллә ниләр уйлап бетердем.— Җәвидә кыстаганны да көтмичә, җылы итекләрен салды, бүлмәгә узды. Гөлфия аңа ияререгә мәҗбүр булды.

— Сине Хәлимов чакырмадымы? — Аңа сынап карап торгач, Җәвидә янә башлады.— Берәр нәрсә сорамадымы?

— Юк,— диде Гөлфия.— Ул авырый бит.

— Кайдан беләсең? — дип сорады ашыгып Җәвидә. Шунда ук күңеленә шик керде.— Кичә күркә кебек кабарып көн азагынача утырды, бер чите дә китек түгел иде әле.

— Мин кеше әйткәнне әйтәм.— Гөлфия хатасын сизеп, аны тиз-тиз төзәтте.

— Кем әйтте? — Җәвидә өчен бу бик мөһим иде: күрмәгән, әмма белә. Кайдан?

— Гамир иртәнге якта колхозга шалтыратты. Ул әйтте. Парторглар арасында алыш-биреш ясатып кайтырга да кушты.

— Шөкер,— диде Җәвидә. Ул бушанып калды, якындагы урындыкка утырды.— Югыйсә, котым очкан иде.

— Нәрсә булган тагын? — Гөлфия аның ни өчен курыкканын белә иде, әмма моны сизмәгәнгә сабышты.— Тагын бер-бер «ЧП» булганмы әллә?

— Кичә синең, минем белән булганы да бик житкән.

— Анысы «ЧП»га керми бит,— диде Гөлфия.— Беркем берни белмәде.

— Белмәде,— диде Җәвидә иреннәрен бөреп, аны үчекләгән кыяфәттә.— Хәлимовның яллы эте анда булган шул.

— Кит аннан! — Гөлфия гаҗәпләнгән булды.— Кем булган?

Гөлфиянең соңгы вакытларда якынаеп, дуслашып киткән Җәвидәне күрәсе дә килми иде бүген. Бу хәлгә аны ул төшерде бит. Аңа ышанып сүз кузгатмаса, бүген күргән хурлык, түбәнчелеккә төшәр идеме ул? Икейөзле! Хыянәтче! Аның серен алды да, Хәлимовка менеп әләкләде. Хәзер үзен акламакчы: янәсе, тыңлап торганнар. Үзен аклау өчен башкага сылтый. Әмма Хәлимов аның барын ачып биргәнен әйтте бит инде.

— Кем? — Үзе өчен әһәмияте калмаса да, Гөлфия моны сорарга тиеш иде. Бәлки, чынлап та, Гамир анда булгандыр. Ул алар турында кереп әләкләгәч, Җәвидә дә чишелгәндер.

— Бу хакта мин дә баш ваткан идем, тапмадым. Ленар бик ансат чиште: безне Гамир тыңлап торган.

Бу Гөлфия көздә тотмаган яңалык иде.

— Ленар моны кайдан белә? — дип сорарга мәҗбүр булды ул.

— Менә сиңа! — Җәвидә ике кулы белән ботына чабып куйды.— Бездән бигрәк аңа кагылгач, ничек белмәсен инде.

— Син әйттең, димәк,— диде Гөлфия.— Кайчан, ничек күреп өлгердең әле?

— Итәгеңә ут капкач ничек кенә өлгерәсең әле,— диде Җәвидә.— Кичә ничек кабаланганны белсәң иде син.

Гөлфия уйлана калды. Ничек була соң әле бу? Ул баштан Хәлимовка барып сөйләп биргән, аннан Ленаргамы? Бу аның башына сыймый иде.

— Безнең сүзләр, бәлки, беренчегә барып та җитмәгәндер әле?! — Мәсьәләгә ачыклык кертү өчен ул юри бу сорауны бирде.— Юкка гына кабаланасыңдыр.

— Аны син миннән сора,— диде Җәвидә кызуланып күкрәгенә сугып алды.— Кичә төш узуга мине чакыртып алды, әйткәннәребезне сүзгә сүз кабатлап күрсәтте.

— Ә син нәрсә дидең? — Гөлфия бу сорауны юри бирде: ни дияр? Алдан аларны сатканын танырмы, юкмы?

— Нәрсә диим? — Җәвидә кинәт урыныннан торып басты, ашыгып сөйли башлады.— Сөйләдек дияргә минем башыма тай типмәгән бит. Юк, андый сүз булмады, дидем. Ул җикерергә, янарга тотынды: КГБдан чекистлар китертәм дип тә куркытмакчы булып карады. Котым ботыма төште, әмма барыбер әйтмәдем.

Нәкъ ул уйлаганча килеп чыкты: Җәвидә тырышып-тырышып җинаятенең очын яшереп маташа.

— Син бая безнең өстән Гамир әләкләгән дидең. Моны нәрсәгә нигезләнеп әйтәсең?

Җәвидәнең үз гаебен өстенә алырга исәбе юклыгы аңлашылды. Инде иң алдан улмы, Гамирмы кереп әләкләгәнен генә ачыклыйсы калды.

— Надя китапханәне беркайчан буш калдырмый, буфетка кергәндә дә безнең ишене чыгарып бикләп калдыра. Болар сиңа билгеле бит.

Бу кадәресе ул әйтеп тормаса да мәгълүм. Гөлфия башкасы хакында уйлады. Җәвидә Ленар турында сөйләгәнне Хәлимовка җиткергәч, ни күзе белән аның үзе каршына бара алган? Бу кадәресе акылга сыймый торган эш.

Ленарны кисәтеп кую аның хәлен күпкә катлауландыра. Ул Хәлимовка бар дөресен сөйләгәч, аннан бер нәрсәне ялынып сорады: Сафинга үз теләге белән районнан китәргә мөмкинлек бирсен. Хәлимов ризалык бирде. Алар планы буенча моны көтмәгәндә эшләү күздә тотылды: беренче секретарь кинәт кенә чакыртып ала, бу фактларны китерә. Болар Сафинны эштән бушатуны сорап гариза язарга мәҗбүр итәргә тиеш. Алдан бу хәлләр турында белгәч, Ленар өчен көтелмәгән удар булмый инде. Бу очракта Сафин әзерләнеп куйган инде, тагын мөгез чыгаруы мөмкин. Болай булгач гауга ничек бетәсен Гөлфия күз алдына да китерә алмый.

Гөлфия шул хакта уйлап, соравының очына чыга алмый басып тора бирде.

— Мин аның кабинетыннан чыгуга сине эзләдем. Тапмагач Камышлыга, Ленар янына киттем. Аның белән бергә дә сине эзләдек. Без генә түгел, бүтәннәр дә эзләде.

— Кемнәр? — дип сорарга мәҗбүр булды Гөлфия.

— Дөресен генә әйт әле, Гөлфия: кичә, бүген бу мәсьәлә буенча ул сине чакырмадымы әле? — Җәвидә аның соравына җавап биреп тормады, башкасы мөһим иде.

— Чакыртырга тиеш идеме? — Сорауга каршы сорау куйды Гөлфия.— Чакырса ни? Беренче секретарь кеше урам хатыннары шикелле сүз куып йөрмәс инде.

— Ул моны болай гына калдырыр дисеңме? — Җәвидә иреннәрен турсайтты. Хезмәттәшенең кичәге сүзләргә әһәмият бирмәве аны борчуга салды.— Мин аның сиңа нинди мәкерле планнар корганын белмим, әмма бер нәрсә ачык. Миннән безнең сүзләрне ала алмагач, бар авырлык сиңа төшәчәк.

— Артыннан сөйләгән сүз өчен шулай үч куып йөрмәс инде,— дигән булды Гөлфия кабат. Ул һаман Хәлимов белән хурлыклы килешүенә ышана иде. Максатына ирешкәч, Ленардан арынгач, артыгы белән җиткән. Җәвидәне дә, эш эзләргә үзенә калдырып, чыгарып җибәрергә риза булды инде.

— Ахмак,— диде Җәвидә кашын-күзен җимереп.— Син аны белмисен әле, күрмәгәннәреңне күрсәтер. Ул бит ерткыч, тиран.

— Нәрсә эшләр? — диде Гөлфия, кызыксыну күрсәткән булып.— Кычкырыр, җикерер.— Җәвидә шикләнмәсен өчен ул Хәлимов өйрәткәнчә кәмит уйный бирде.— Аңа без күнеккән инде.

— Безнең хакта сүз булуы да мөмкин түгел, без икебез дә яндык, артыбызга тибеп озатачак.

— Шуннан артыгын ни эшли ала? — диде Гөлфия.— Мин дүшәмбедән үк аңа гариза язып керәм: китәм.

— Әйе, аңа безнең ишеләр кирәкми.— Җәвидә аның белән килешүен белдерде.— Без ярар, ә Ленар? Безнең сүз аркасында ул да яначак бит. Ул теге сүзләрен безгә ышанып сөйләгән иде. Без аны саткан булып чыгабыз.

— Син нәрсә тәкъдим итәсең?

— Ул, савыгып эшкә чыгуга, сине чакыртачак. Миннән алган шикелле допрос алачак. Сине куркытыр, янар, КГБдан чекистлар китертәм, дияр. Андый эшкә ул сәләтле, әллә ни уйлап чыгарыр. Безнең сүзебез бер генә булсын: әйтмәдек, андый сүз булмады. Гамир ялагайланып уйлап чыгарган дияргә кирәк. Теләсә кем — милиция, чекистлар алдында да.

— Ул ышаныр дисеңме?

— Ышанмый, беләм. Ул беркемгә дә ышанмый. Әмма без моның белән Ленарның хәлен күпмедер дәрәҗәдә җиңеләйтә алабыз. Бәлки, ул яхшылык белән котыла алыр.

Гөлфия дәшмәде. Шул арада күкеле сәгать тагын телгә килде, бер мәртәбә кычкырды.

— Озакламый Назыйм кайта, минем чәем дә куелмаган,— диде Гөлфия һәм кухня якка чыкты. Бәлки Җәвидә шуннан соң китәр.

— Бүген сине саклый-саклый туалетка да кермәдем, ант әгәр,— диде Җәвидә һәм ваннасы, туалеты уртак булган бүлмәгә кереп китте.

Гөлфия Җәвидәнең китәргә ашыкмавын чамалады. Чынлап та, чәй куярга кирәк, ансыз озатып булмый. Назыйм да аракыга ябышмаса, кайтыр вакыт якынлаша.

Гөлфия чәй әзерләргә диеп кранны ачты, газны кабызды. Су алырга дип чәйнеген тотып килсә, кранда су юк булып чыкты.

— Мин колонкага суга барып киләм,— диде ул һәм чиләк тотып чыгып китте.

Җәвидә ванна бүлмәсеннән чыгышлый көзге алдына туктады, кыяфәтенә күз салды. Борынына нindидер сасы ис бәрелде. Нинди ис бу? Мәчеләре булып, пычраткanмы әллә? Борынын тартып-тартып иснәде, якын тирәдә күз йөгертә башлады. Шулчак көзге тартмасы өстендәге стаканны күреп алды. Нәрсә бу? Кулына алып иснәп карады. Исе җирәндергеч сасы.

Ул стаканны урынына куйды, көзге янындагы шешәне күтәреп этикеткасын карады. Уксус катнашмасы.

— Бәтәч,— дип куйды Җәвидә үз алдына. Мие аша яшен тизлеге белән уй йөгереп узды. Куркуыннан чак шешәсен төшереп җибәрмәде.— Димәк...

Беренче мизгелләрдә ул уксусны түгәргә уйлаган иде, аннан бу фикереннән кире кайтты. Юк, аның үзенә сизүен белдерергә ярамый, бар да искечә калсын.

Коридорда аяк тавышлары ишетелде. Ул тиз генә зал якка үтте, урындыкка утырды. Ишектә Гөлфия күренде.

— Дускай, ни булса да безгә икебезгә дә гариза язып китәргә кирәк.— Аның артыннан кухняга кергәч, ул шул хакта сүз башлады.— Шуннан да яхшысы юк.

— Җибәрер микән соң?— дип шик белдерде Гөлфия.

— Эшлим дисәң дә тотмаячак ул,— диде Җәвидә ышанычлы итеп.

— Бая киресенчә дигән идең,— дип куйды Гөлфия буйсынучан тонда.— Синең кайсы киңәшеңне тотарга соң?

— Анда барын да уйлап җиткермәгәнмен,— диде Җәвидә.

* * *

Җәвидә үзләренең хәле тагын да катлауланганын серкәле стаканны тотуга аңлады: Гөлфия «чишелгән». Хәзер, ике ут арасында калганын аңлагач, агу эчеп котылырга исәпләгән.

Гөлфиянең хыянәтче булганына ышанасы да килми. Ләкин бу булган, моны аның бүгенге тотышыннан ук чамаларга мөмкин. Ул Хәлимовтан куркып калган, димәк. Хәер, белмәссең, Хәлимов барына әзер. Бәлки ул аны «сатып алгандыр». Ул да бит бер төн сорап аның белән башын бәйләде. Аннан котылырга әмәл тапмады, вакытында араларны кырт кисәргә тәвәккәллеге җитмәде: иреннән колак какты. Ул ярар, кешегә зыян итмәде. Гөлфия бит аны, Ленарны да нинди кыен хәлгә куя: хәзер аларга карата Хәлимовның хөкем карары чыгарылгандыр инде.

Билгеле, Гөлфия Хәлимовка уку залында булганнарны гына танымагандыр. Андагы сүзләр, ул таныса-танымаса да, Хәлимовка мәгълүм. Аның өчен генә серкә эчәргә әзер тормас иде. Ленар аңа сөйләгәннәрнең барын җиткергән булса? Бу галимнәрчә әйтсәң, алар өчен катастрофа дигән сүз. Гөлфия шуларны соңыннан аңлаган һәм котылмакчы күрәсең. Ул да, үзләре дә кызганыч. Ленар мең кат хаклы: үзләре теләгән темага

фикерләрен әйтергә дә хокуклары булмагач, кем соң алар? Билгеле инде, иректе тоткыннар!

Уйлары үз язмышына әйләнеп кайтты. Хәл шундый кискен борылыш алгач, Җәвидә ни эшләргә тиеш? Хәлимов, ул таныса, аны Гамир, Гөлфия белән дә очраштырачак, сорау алачак. Алар әйтеп торганда аңа ансат булмаячак. Ләкин ул бер нәрсәне белә: аны да сындырса, Хәлимов бар көч белән Сафинга ябырылачак. Юк, теләсә ни булса да, алдагы сүзләреннән читкә тайпылырга ярамый аңа. Шул чагында гына, файда итә алмаса да, Ленарга тагын да зыян китермәскә мөмкин.

Ленар ни эшләргә тиеш? Әмма аңа бу шартларда саклык чаралары күрергә кирәк. Боларына аның башы ирешми. Үзе әмәлен тапса гына. Әмма аны Гөлфиянең хыянәте хакында кисәтеп кую кирәк.

Бәхеткә рәис бу юлы да идарәдә туры килде.

— Бүгенгә свидание билгеләмәгән идек шикелле,— дип усал көлемсерәде Сафин, аны күргәч.

— Шаярта торган чакмы соң,— диде Җәвидә эчтән сызып.— Хәл тагын да катлауланды бит.

— Беләм,— диде рәис төксе генә.— Күптән түгел генә минем янда Камил булып китте.

— Мин аңладым. Камилнең бу тарихка нинди катнашы бар?— дип соравын кабатлады Җәвидә.

Сафин күпмедер тәтен суыра бирде, дәшмәде. Җәвидәгә билгесезлек газап иде, әмма тагын кабатларга батырчылык итмәде: халәтен ул күреп тора ич.

Ниһаять, Сафин ачыклап бирде.

— Бүген Камил Казаннан кайтышлый Хәлимовлар яныннан узып бара икән. Гөлфия Хәлимовлар йортыннан килеп чыккан.

— Ә-ә-ә!—дип сузды Җәвидә һәм авызын ачкан килеш бермәл дәшә алмый торды—Чынлапмы?

— Камил юри сөйли торган малай түгел.— Сафин сул кулы белән иягенә таянды.— Соңга калып булса да, акылга утырды. Эчми дә.

— Бәлки аңа охшаган кеше генә булгандыр?—Җәвидә ис китүдән һаман айнымаган иде әле. Фикер йомгагының очы тәмам чуалды. Әлегә кадәр ул Гөлфияне куркытып сөйләгәндер дип уйлады. Яки «Җәвидә сөйләде инде», дип алдап серен ачкандыр нәтиҗәсен чыгарган иде. Хәлимовның өенә бару бөтенләй башка хәл. Димәк, ул моны ирекле эшләгән. Аларның бу бәйләнешләре бәлки алдан ук килә, ул шпион кебек аңа электән үк сөйләп килгәндер. Ул чагында ни өчен Хәлимов аларга бәйләнмәгән: күбрәк серләрен алу өченме? Шулайдыр, мөгаен. Икенче ягы да бар: тиктомалдан кузгатса, Гөлфиянең хыянәтче икәнлеге ачыклана бит, җаен көткән. Китапханәдә сөйләшү кулай сәбәп булып чыккандыр. Гөлфия үзе сүз башлады: бу чынга якын. Аны һәм Ленарны батыру, үзе акланып калу өчен иң җайлы вариант.

Алай дисәң, соңгы планеркаларда Хәлимов Гөлфиянең канын күпме суырды. Киңәшмәдән чыккан саен яшеренеп күпме кайнар яшен түкте. Юк, боларын ул Җәвидәгә күрсәтү өчен генә агызмагандыр.

— Охшаш кына түгел, үзе булган,— диде авыр сулап.— Камил аны туктаткан, янәшә сөйләшеп барганнар. Әйтүенчә, чырае качкан булган, йөзен гел яшерергә тырышкан.

— Миңа тагын бер нәрсә аңлашылмый,— диде Җәвидә.— Камил моны кайта-кайта ук кереп сөйләгән. Ул бит кичәге хәлләрне белми. Сине көнләштерер өченме?

— Син аның Хәлимовка нинди үчле икәнен белмисеңмени?!

Җәвидә тын калып шактый утырды. Бәлки охшаш кеше генә булгандыр дигән соңгы өмет чаткысы да сүнде.

— Ә син Гөлфиянең аңа сөйләгәнен кайдан белдең?—Тәмәкесен соңгы кабат суырып көл савытында сүндергәч, игътибарны аңа күчерде.

— Мин аны бүген төш узганчы эзләдем, эштә булмады. Квартирасына да өч тапкыр бардым. Соңгысында гына кайткан иде. Димәк, ул аңа кадәр Камил күргән йортта булган.
— Анысын син хәзер генә белдең,— диде Сафин.— Ә чишелгәнен нәрсәдән чыгып әйтәсең?
— Ул уксус эчәргә әзерләнгән булган.— Ул бүленеп торды һәм очлады.— Ярый әле барып кердем.
— Шул гына җитмәгән иде,— диде Сафин иреннәрен турсайтып.— Алдан саткан, аннары котылмакчы булган.
— Ленар Салихович,— диде җәһәт кенә Җәвидә.— Буласы булган. Сез дә аны кысмагыз инде. Сез берәр усал сүз әйтсәгез дә, фаҗига котылгысыз.
— Син нәрсә? — Сафин аңа шундый усал итеп карап куйды, Җәвидә куркып китте.— Мине хатын-кыз белән сүз куып, сугышып йөрер дип уйлыйсыңмы? Вөҗданы хөкемдар аңа.
— Ул үзе дә моны авыр кичерә,— дип баягы фикерен дәвам итте Җәвидә.— Дөнья белән хушлашырга аңа бер авыр сүз җитә.
— Хәзер, бөтен козырь карталар Хәлимов кулында.— Сафин өстәл артыннан чыкты, аның янына туктады.— Хәер, бу тозактан ычкыну өчен, минемчә, бер юл гына кала: аннан гафу үтенергә.
— Ничек? — Җәвидәнең күзләре зур булып ачылды.— Бар гаепне синең өстеңә генә аударып калдырыргамы?
— Син шуны аңла, Җәвидә,— диде Сафин аның каршына тукталып.— Миңа син алай да, болай да ярдәм итә алмыйсың. Шулай булгач, кичә әйткәнне генә кабатларга кала: бу уеннан чык.
— Сине ялгыз калдырыргамы? Аның кулында аппарат. Ирләрчә синә кара-каршы үзе генә чыкмый бит ул, шул аппараты белән бергә ябырыла. Андый һөҗүмгә берәү дә чыдамый.
— Ә минем чигенер урыным юк һәм моны теләмим дә. Аның каршына тезләнмим. Димәк, бер генә юл кала: көрәшергә!
— Ни булса да, хәзер мин синең белән Ленар Салихович.— Ул кинәт исенә төшереп, сумкасын ачты һәм аңа бер дәфтәр алып бирде.— Монда Хәлимовның бар этлекләре язылган. Ул Хәлимов кулына эләксә...

* * *

Дүшәмбе көнне иртән Гөлфия эшкә гадәттәгедән күпкә иртәрәк килде. Җитәкчеләрне кабул итә башлаганчы беренче секретарь белән сөйләшеп калырга иде исәбе. Хәер, сөйләшәсе калмаган, эштән китү турындагы гаризасына имза, ягъни рөхсәт тамгасы салдырасы гына. Назыймга бу хакта сиздермәде әле, гаризасын эшкә килгәч, тәрәзәдән Хәлимовны күзәтә-күзәтә язды.
Хәлимов гаризаны шактый озак укыды, аннан күзлеген салып аңа карап торды.
— Парткабинет мөдире Хәйдәровның тагын бер айдан пенсиягә китәсен беләсең бит,— диде ул һәм күзлеген, ниһаять, өстәлгә куйды, гадәт буенча бармак буыннарын шартлатып чыкты.— Син аның эшен кабул итәргә әзерлән.
— Мин монда бүтән бер көн дә эшләмәячәкмен.— Гөлфия тулган, сытылырга торган җимеш шикелле иде.— Калу турында сүз дә булуы мөмкин түгел.
Хәлимов башын күтәреп аңа янә сынап карады.
— Утыр,— диде ул салмак, әмма боеру тонында. Гөлфиянең боерыкны үтәвен күзәтеп торды.— Так,— ул тагын уйланып алды һәм бүтән сүз әйтмәстән, өстәл тартмасын ачты, ачкыч бәйләме чыгарды, аның алдына куйды. Гөлфия аларны таныды: теге вакытта фатир сораганда аларны күрсәткән иде бит. РАПО өчен махсус төзелгән йортның өч бүлмәле

фатиры ачкычы иде алар. Аны булгәндә үзләренә ике бүлмәлесе дә эләкмәгәч, ничә көн елап беткән иде. Хәзер төшенә дә кермәгән фатир ачкычларын күргәч, тәненә каз бөрчекләре бәреп чыкты, җилкәләрен җыерып куйды: ачкычның ни бәрабәренә икәнен белеп тора. Шуңа күрә ачкычларга таба әйләнеп тә карамады.

— Алай бик настаивать итсәң, тотмабыз, билгеле.— Халимов үзен тыныч тотып сөйләде.— Әмма бүген, хәзергә син миңа кирәк әле.— Гөлфиянең еларга җитешеп челт-челт күзләрен йомгалавын күреп ашыгып өстәде.— Курыкма, сиңа берәү дә бер сүз әйтмәс, кагылмас та.

— Мин монда бүтән эшли алмыйм,— дип кычкырып елап җибәрде Гөлфия.

— Тынычлан, Гөлфия.— Хәлимов тәмам йомшап төшеп аны үгетләргә кереште.— Квартираң булды. Эшкә теләгән җиреңә китәрсең. Әмма бер нәрсәне аңла: бу гауганың очына чыкмыйча мин сине барыбер җибәрмим.

— Сез бит Сафинга тимәскә вәгъдә бирдегез,— диде Гөлфия яшь аралаш.— Тимәгез аңа, зинһар.

— Тимим мин аңа,— Хәлимов үзенә болай хәтеренә төшерүне кабул итәргә күнекмәгән, ачуы чыкты.— Бөтенесе синең белән килешкәнчә кала.— Ул соңгы сүзләренә аерым басым ясады.— Әмма аның минем районда эзе булмаска тиеш.

— Минем белүемчә, аның каты шелтәсе бар, андый җәза бирелгән коммунистларны, гадәттә, җибәрмиләр. Башка җирдә дә алмыйлар.

— Яхшылык белән китәр. Чип-чиста. Шелтәсен алып җибәрәм. Бары китеп кенә олаксын. Ничек әйтәләр әле: дүрт ягы кыйбла!

— Минем белүемчә, ул ярдәмче хуҗалыклар белән тәҗрибәсен төгәлләү алдында. Шуның буенча диссертациясен дә яза иде.— Гөлфия аның турында сөйли башлагач, кызып онытылып китте, ике көн элек булганнарның авыр тәэсирләре, кыска вакытка гына булса да, исеннән чыкты.— Аңа күпмедер вакыт кирәк булуы ихтимал.

Хәлимов аның сулыш алуын, үзен иркенрәк тота башлавын шунда ук чамалады һәм бармагын аңа таба селкеп торды.

— Миңа андый ученый кирәкми, минем сүзне тайпылышсыз үтәүчеләр генә кирәк.

Хәлимовның соңгы сүзләре Гөлфияне реаль чынбарлыкка әйләндереп кайтарды, тирән тын алды.

Хәлимов аның белән хәзер шикләнмичә сөйләшә башлады. Хатынның психологик шоктан чыкканын чамалап өлгергән иде инде.

— Бер ташлама ясасаң, икенчесен дә сорыйсыз. Әмма бу мәсьәләдә мин бүтән бер адым да чигенмим. Китеп олаксын! Син аңа шуны минем шәхескә кагылмый гына аңлатырга, миңа гариза кертүенә ирешергә тиеш.

Гөлфияне каты курку биләп алды. Авызын ачты, тик сүзе генә чыкмады.

— Мин моны булдыра алмыйм,— дип танырга мәҗбүр булды ул.

Хәлимов әңгәмәдәшенең һәр хәрәкәтен күзәтә, халәтен аңлап тора иде, тагын тавышын түбәнәйтте.

— Булмый икән булмый, алдан әйтүең яхшы. Аның белән сөйләшер кеше табылыр.

Хәлимов, тынычлану өченме, кабинеты буйлап йөреп килде.

— Синең өйдә бөтенесе нормальме?— Ул аның карашына тукталды, әмма инструкторының башын аска июен күреп арырак үтеп китте. Аны тынычландыру өчен, җавабын да көтмәстән өстәде: — Бөтенесе без синең белән килешкәнчә эшләнәчәк. Ә теге бәдрә баш ахирәтеңнең минем райкомда бүгеннән эзе калмаячак. Ашаган табагына төкерүче ул.

Гөлфиянең мие аша, яшен тизлеге белән куышып, сораулар узды. Ул аңа дөресен сөйләгәч ничек әле табагына төкергән? Җәвидә табакка төкерүче, ә ул, Гөлфия кем? Шундый ук кеше түгелме? Ни өчен ул

Җәвидәне куа да аны калдыра? Монда ул аңлый алмаган нәрсәдер бар? Нәрсә ул?

Уйлана торгач, ул бер фикергә тукталды һәм тәне суынып китте: димәк, Җәвидә әйтмәгән! Менә ни өчен Хәлимов аны куа. Ул үзе генә аңа бар белгәнен сөйләп биргән икән...

— Сиңа ни булды? — Хәлимов аның халәтен чамалый иде, билгеле. — Йөрәк даруы кирәкме? Чәй бирергәме әллә? — Әйткәнен дә көтмәстән, ул графиннан чынаякка чәй агызды, аңа сузды.

Гөлфия чынаякны сузылып алды, чынлап та авызы кипкән иде. Аны авызына китергәндә чәй чайпалып түгелде. Эчә башлагач, җамаяк кырые тешләрен тиеп шыкылдады.

— Бәлки «скорый» чакыртыргадыр? — диде Хәлимов, аның хәленә керешеп.

— Кирәкми. — Чәйдән бушаган җамаягын өстәл кырыена куеп әзрәк сулыш алгач кына сөйләрлек хәлгә килде Гөлфия. — Мине бүтән бернигә дә катнаштырмагыз, зинһар, — диде калтыравык тавыш белән. — Хәзер үк җибәрмәсәгез, ял бирегез.

— Анысы бүгеннән була, ал гына. Күченү, урнашу өчен болай да отпуск кирәк сиңа.

Гөлфия бүтән сүз әйтмәде, чыгарга борылды.

Ул чыгуга, беренче кабинетына Гамир кереп китте. Гадәттәге планерка вакыты җиткәнлектән, Гөлфия туры кече залга үтте. Аның артыннан диярлек Гамир Харисов белән Хәлимов та керде.

— Борынгылар ничек әйткән әле: үксез бозау асрасаң авызың-борының май итәр, үксез бала асрасаң, авызың-борының кан итәр. — Хәлимов планерканы шул кереш сүз белән ачты. Гомеренә булмаган хәл, саф татарча башлады. Гөлфия, куркудан, башын аска иде.

— Безнең арада да андыйлар бар икән. — Ул русчага күчеп дәвам итте. — Кайберәүләрне урамнан тотып кергән шикелле, хәзерлексез килеш эшкә аласың, өйрәтәсең, укытасың, ул сиңа аш урынына таш ата.

Райкомда үткән атна азагында булган хәлне күпчелек белми иде, залдан гаепләне эзли башладылар, як-якларына карандылар. Барысы Гөлфиягә тукталды. Ул йөзен яшерер урын тапмады.

— Сез алай читләтеп сөйләп маташмагыз инде. — Җәвидә ялт урыныннан сикереп торды, чатлатып татарча тезеп китте: — Сүз минем хакта бара икән, битегездә шәм янмаса, фамилиямне әйтегез. Эшне белмәвемне яшермим, үз кирәгегезгә чакырдыгыз. Бу йортта эшне белүчеләр кирәкми дә: йә тәлинкә тотучылар, йә башкача яраучылар гына кирәк. Мин дә шундыйларның берсе буларак килеп эләктем. Мондагы тәртипләр белән килешә алмасам да, вакыты җиткәнче дәшми яшәдем. Инде көне җитте — мин китәм. Әмма хаклыкны йөзегезгә әйтеп китәм. Әйе, бу ашаган табакка төкерүдер. Ләкин сез хакыйкать өчен көрәшүчеләрнең намусына төкергәндә, аларны таптаганда бу адымым өчен мин нигә газапланырга тиеш әле?!

Ул пауза ясап тын алды, фикерләрен туплады булса кирәк.

— Әйе, мин китәм. — Ул карашын залдыгы хезмәттәшләренә күчереп, ашыгып ялгап китте. Үзенә күп сөйләргә ирек бирмәячәкләрен чамалый иде, авызыннан ташкындай сүз аттырды: — Тормышның ачы хакыйкатен аңлап китәм. Халык өмет белән караган бу йортта намуслы, әдәпле кешегә урын, гаделлек тә юк. Монда — зиначылар, эчкечеләр, ялагайлар штабы. Шундый булмаган кешеләргә районда эшләргә, яшәргә дә ирек бирмиләр. Мин шуны аңлап, йөзегезгә бәреп, намусымны акландырып китәм бу йорттан.

Кече залда чебен очкан тавыш та ишетелерлек иде. Берәү дә тын алганын сиздерергә дә җөрьәт итмәде. Татар хезмәткәрләр, котлары алынып, аның һәр сүзен йотып калырга тырышты. Урыслары, мәгънәсен аңламаса да, сүзнең бик зурдан купканын райком эчендә моңарчы күрелмәгән җәнҗал барганын яхшы чамаладылар, күзләрен зур ачып инструк-

тор чыгышының эчтәлегән аңларга тырыштылар. Тик аларга кая, татарларга да ул ни әйтергә теләгәнне отып өлгерүе кыен, Җәвидә пулемет кебек сиптерде.

Хәлимов, Җәвидәнең беренче сүзләрен ишетүгә бермәлгә югалып калды. Байтак еллар аны үзенең кәнизәге итеп кенә күргән, курчак итеп кенә йөрткән хатында мондый кискенлек, тәвәккәллек, гайрәт, нәфрәт барын күз алдына да китермәгән иде. Бу тойгыларыннан арынгач кына аның ни сөйләвен аңларга тырыша башлады. Мәгънәсе миенә барып җиткәч, бурлаттай кызарып чыкты.

— Молчать,... мать.— Ул бар куәте белән өстәлгә китереп сукты, урыныннан сикереп торды.— Партия — чорыбызның акылы, намусы һәм вөҗданы. Син — аңа кереп оялаган корткыч көсе.

— Ә сез партбилет артына яшеренеп ятучы әчкече, ришвәтче һәм намус төшенчәсен югалткан эгоист, кешеләрне канын эчүче деспот. Үзегез әйтмешли, тупица.

— Вон моннан! — дип бар тавышына җикеренде Хәлимов.— Харисов, нәрсә авызыңны ачып утырасың. Чыгар аны. Акылын җуйган юләр ич ул.

Харисов эһ иткәнче Җәвидә янына килеп җитте, шунда ук җиңенә ябышты.

— Син бик күп акыллы, намуслы кешеләрне таптадың, чөнки алар синең колың, тоткының булырга теләмәделәр,— дип кычкырды Җәвидә.— Ләкин алар өчен җавап бирергә туры килер, суд залында булмаса, намус хөкеме алдында. Хакыйкать барыбер өстен чыгар.

— Нәрсә басып каттың, Харисов,— дип җикерде Хәлимов.— Чыгарыгыз аны залдан. Фәхриев, Жемков булышыгыз аңа. Булышырга милиция чакыртыргамы әллә?!

Фамилияләре аталган инструкторлар шул минутта Низамова янына йөгереп килеп җиттеләр, аның икенче җиңенә ябыштылар.

— Кагылмагыз миңа,— дип чәреләдәвек тавыш белән кычкырып җибәрде Җәвидә.— Мин үзем чыгам.— Ул гайрәтләнеп ирләрдән кулларын тартып алды, кулларындагы редикюлен ачып дүрткә бөкләнгән кәгазьне алды, җәйде һәм Халимовка таба очырды.— Менә гаризам, үз теләгем белән китәм. Әмма исендә тот, иптәш Хәлимов, миңа һәм Ленарга бирәр зыян килсә, унбиш еллык җинаятьләреңнең барысы да дөньяга чыгачак.

Ул үзе залны ташлап чыгып китте. Хәлимов күпмедер авыр-авыр сулыш алды һәм таралырга боерды. Аппаратчылар тавыш-тынсыз гына залны бушатты, беркем дә авыз ачып сүз әйтергә батырчылык итмәде.

Гөлфия дә башкаларга карарга куркып, башын аска иеп, ашыгып кабинетына керде. Шул арада Надя килеп җитте.

— Сөенечкә нәрсә бирәсең? — диде ул татарчалап. Йөзендә шатлыклы нурлар балкып тора иде. Ул бит планеркада катнашмый шул.

Гөлфия аңа берни аңламый карап торды, әмма сөенергә ашыкмады, хәтта ни хакында сүз баруы белән дә кызыксынмады.

— Хәким Нуровичта ачкычларыңны онытып калдыргансың.— Түзмәде, учын җәеп аларны күрсәтте. Үзе аны күзәтүен дәвам итте. Ул моны ничек кабул итәр, шатлыгыннан ни эшләр? Көтте-көтте дә Гөлфиянең чырае ачылмавын күргәч, үз фикерен белдереп куюны кирәк санады.— Безгә беренче каттан биргән иде, икенчесен сиңа саклаган булган икән. Ну, хәзер күршеләр булабыз инде. Күченгәч сөйләшербез. Пока.

Гаризасының почмагына беренченең рөхсәт салуын көтеп үз кабинеты белән кабул итү бүлмәсе арасында әллә ничә тапкыр әйләнде: беренчегә бюро әгъзалары җыелган иде. Алар чыгуга, сәркатип кыз аңа аның гаризасын да чыгарып бирде.

Виза салдырган гаризасын тотып бухгалтерга төшеп барганда, уйламаган-көтмәгән җирдән, Назыймга тап булды. Ул ашыгыч рәвештә аның янына якынлашып килә иде.

— Нәрсә бар? — дип шөбһәләнеп сорады ул.— Балалар берәр зыян эшләгәнме әллә?

— Әйдә, тиз! — Ул аның соравын, гүя, ишетмәде дә.— Безгә фатир биргәннәр икән бит. Горсовет председателе сине эзләтә. Ордер язылган, синең подпись кына кирәк.

— Син нәрсә? — Гөлфия бухгалтер бүлмәсенә кергәч, ире дә аңа ияреде.— Мондагы эшләрең калып торсын, аннан соң да өлгерер. Горсоветта сине көтәләр.

— Мин хәзер.— Бухгалтерга гаризасын тапшырып чыккач, ул ирен туктатты.— Шунда гына көт. Мин кабинетымны гына бикләп калдырам.

Ул җәһәт атлап баскычлар буенча өскә күтәрелә башлады. Үзе уйлана бирде: ул хәзер ни эшләргә тиеш? Намусын таптаган өчен бирелгән бүләкне ничек алырга кирәк — бу үзе вөҗдансызлык ич. Әмма... Хәзер инде буласы булган, ул бернине үзгәртә, кире кайтара алмый. Ә яшәргә кирәк. Үзе хакында булмаса, балалары хакына. Агу эчеп, аларны ятим итеп кемгә файда? Дошманнары гына сөенәчәк. Ә квартира белән нишләргә соң? Хәзер ире, балалары белгәч, баш тартса, алар белән дә аңламаучылык килеп чыга. Дөресен ул аларга сөйли алмый. Сөйләсә ни? Аңа бит болай да квартира тиешле. Бусыннан баш тартса, икенчесен сорарга тиеш. Шулай булгач, теләмәсә дә, ул квартираны алырга тиеш булып чыга.

Шул фикеренә тукталгач, ул ашыгып кабинет ишеген ачты, өстәл өстендә Надежда Ивановна куйган җирдә калган ачкычларны алып чыкты.

Фатир бүгеннән керергә әзерләнгән: кухня, ваннага кафель ябыштырылган. Бүлмәләрдә паркет идәннәр, чит ил обое белән бизәлгән. Кухняга керә торган аралыкта стенага да кием шкафы ясап урнаштырылган, анысының да такталары полировкалы. Моны күргәч, ире, балаларының шатлыгы эчләренә сыймады. Назыйм шунда ук машина алырга китте. Шофер һәм ике хезмәттәше белән тулай торактагы юклы-барлы әйберләрен бер-ике сәгать эчендә күчереп тә куйдылар.

Күченү, әйберләрне урнаштыру, җыю-юу мәшәкатьләре белән көн, кич узганы да сизелмәде. Назыйм әйбер бушатканда йөкчеләр белән бергә шактый сыйланып алган иде, алар киткәч арлы-бирле буталгалады да ятып йоклады. Унбер тулгач, балаларны көйләп диярлек яткырды да, үзе дә йокларга әзерләнә башлады. Шулчак, машина тавышы ишетелеп, ишегалдына күз салды. Милициянең тоткыннар йөртә торган «кара козгын»ын күргәч, тәне эсселе-суыклы булып китте. Яхшы ният белән килмәгән бу машина: кем артыннан? Әллә аны алыргамы? Куркуыннан коты ботына төште.

Тәрәзә янагына сөялеп көтә башлады. Машинадан милиция киемнәре кигән берничә кеше төште. Аларга ак халатлы тагын берәү кушылды.

Милиционерлар алар подъездына кереп киттеләр. Гөлфиянең шиге тагын да көчәйде, тын алырга да куркып басып торды, кыңгырау тавышын көтте.

Азрак вакыт узгач, хәл алып, ишек төбенә барды, «күзчек»тән карады. Аларга каршы ишек төбенә җыелганнар иде тегеләр. Анда Җәвидә яши иде. Аны ачтырып керделәр.

Ачык калган ишектән ишетелеп торды: эчтә ыгы-зыгы, тавыш башланды. Җәвидәнең чәрелдәп кычкырганы яңгырады. Тегеләр этә-төртә аны коридорга алып чыктылар, сөйрәп диярлек түбәнгә алып төшеп киттеләр. Тышка чыккач (Гөлфия ул арада кабат кухня тәрәзәсенә барып капланган иде), аны тупас рәвештә бәргәли башладылар. Машина ишеге төбендә соңгы тарткалаш булып алды: бәреп ектылар да кул-аягыннан эләктереп бүрәнә шикелле эчкә аттылар. Артыннан үзләре дә шунда кереп тулдылар. Машина шунда ук кузгалып та китте.

Гөлфияне курку тәмам биләп алды: икенче юлы аны алырга килмәсләрме? Бу бит мөмкин хәл. Йә, ходаем, тагын ниләр күрәселәре бар икән?!

* * *

Харисов рәсми һәм салкын каршылады, күрешкәндә дә йөзен читкә борды.

Сафин да үзен җитди тотты, күңел өчен генә күреште һәм кыстаганны көтмичә, килүчеләр урындыгына утырды. Нигә чакыруларын ачык белмәсә дә, сүз кай тирәдә барырга мөмкин булуын чамалый иде.

— Кемгәдер ошарга тырышу принципта яхшы нәрсә үзе. Ләкин этиканы да онытырга ярамый,— дип чәнечтереп башлады Сафин.

Харисов үзен тотышы белән Хәлимовка охшарга тырыша иде. Билгеле, рәиснең шул хакта бакчасына таш атуын сизде, ләкин бәхәскә кереп тормады. Бәхәстә Сафинны җиңә алмасын алдан ук белә иде ул.

— Этикалар турында гәп куертып торырга вакыт юк.— Ул да үзенең урынына кереп утырды.— Миңа Сезнең белән сөйләшү йөкләнде.

— Кем исеменнән эш йөртәсез дип кабул итәргә инде моны?

Харисов аның соңгы сорауны юри биргәнен аңлады. Сафин аның рәсми вазифасы буенча үзеннән өстен булуын да, кем исеменнән эш йөртүен дә белә. Аны өнәмәгәнгә юри гәп куерта. Башкалар белән эш иткәндә булса, тавышын күтәреп, янап та куркытыр иде, әмма бүгенге әңгәмәдәше аны бик яхшы белә. Ул аны Хәлимовка да алып керә алмый, мәсьәлә аның кабинетында хәл ителергә тиеш. Шуңа ул Сафинның чираттагы чәнечкеле сүзләрен дә кабул итәргә, тамак төбендәге төерен йотып җибәрергә тиеш булды. Әңгәмәне дәвам итәргә кирәк бит әле.

— КПССның Наратлы райкомы исеменнән дип кабул итә аласыз. Сез бер заман, хәтерем ялгышмаса, фәнни эш белән шөгыльләнергә бик омтылган идегез шикелле. Шул чактагы ниятләрегездән кире кайтмагансыз дип уйларга кирәк. Сез бит егет чактан ук бик үҗәт идегез.

— Кайгыртучанлыгыгыз, игътибарыгыз өчен рәхмәт.— Сафин юри елмайгандай итте.— Сигез елга якын председатель булып эшләп мондый игътибарга лаек булганым юк иде әле. Кемнең ни белән мавыгуына кадәр кызыксынгач, шәп инде ул.

Харисов бу юлы да төрттерүләрне колагына элми үткәреп җибәрергә мәҗбүр булды.

— Теләгегез бар икән, китә аласыз,— диде әңгәмәдәше хисләргә бирелеп тормыйча, рәсми генә.

— Мавыктыргыч идея бу,— диде Сафин уйланган булып һәм кәнәфиендә тураеп утырды.— Кызганыч, сигез ел буена ул кызыл постау астында әрәм яткан. Хәзер соң инде. Башка вариантларга күчик булмаса.

— Анысы бик ансат.— Ул ни әйтәсен рәис алдан белеп торгач, уен уйнауның кирәге калмады Харисовка, ачыктан-ачыкка күчте.— Теләгән җиреңә китәсең. Эшсез калырмын дип курыкма. Документларың чиста булгач, теләсә кайда Сезне биш куллап алырлар. КамАЗ яны авыл зонасында колачлап эшләргә була. Сиңа, эшлекле җитәкче буларак, әйбәт рекомендация тәэмин ителгән сана.

Рәис уйланып утырган мизгелләрне ул үз файдасына мәсьәлә хәл ителгән санап торды. Кире кагар булса, Сафин шунда ук өздереп салырга тиеш иде. Ул исәпли, димәк...

— Бу табышмакта бер генә нәрсәне ачыклыйсы бар,— диде Сафин кинәт елмаеп.— Наратлының барлык хуҗалары кайчан КамАЗ патриотларына әйләнеп беткән соң әле?

Харисов кызарып чыкты. Бу юлы, элеккеләре кебек, аның төрттерүен аңламаганга сабышып кына үткәреп җибәрү мөмкин түгел инде.

— Мин кушканны тапшыручы,— диде ул ахыр чиктә үзен аклау өчен.

— Тапшыручы икән тапшыр: мин куркып качмыйм, сөрелеп тә китмим. Принципта китәргә әзер, ләкин моның өчен кайбер шартларны үтәү зарури.

Харисовның ачуы чыкты: кыл-күпер өстендә тора, алай да шартлар куеп маташа. Ләкин, боларны Хәлимовка җиткерәсе, анысы шуннан чыгып хәрәкәт итәсе булгач, аларны тыңларга тиеш иде.

— Тыңлап карыйк,— диярга мәҗбүр булды ул.

— Иң беренчесе — Җәвидәне кайтару.

— Акылыннан язган тотнаксыз хатын өчен сүз көрәштерәсеңме?— Харисов исе киткәндәй кыланды.— Мин берәр җитди шартың бар дип уйлаган идем.

— Юләр сатма, классташ.— Ул юри аның кемлеген искә төшерде.— Фактларга, вакыйгаларга карата һәркемнең үз карашы, позициясе булырга тиеш.

— Минем позициям һәрвакыт ачык,— диде Харисов, тоткарлыксыз рәвештә.— Бу мәсьәләгә карата да. Ул КПСС райкомы, аның бюросыныкы белән тәңгәл килә.

— Алайса әйт әле: Низамова, нормаль эшләп йөргән кеше турында «акылыннан язган» дигән уйдырмага ышанасыңмы син?

— Аның язмышы мине кызыксындырмый.— Харисов бу киеренке әңгәмәдән арыну җаен гына кайгыртты.— Акыллымы, юләрме — моны ачыклау махсус белгечләр эше.

— Алайса икенче сорауга җавап бир: төн уртасында ишеген ачтырып кереп, кулына богау салып китү кем эше? Аны бит урамда саташып йөргәндә алдырмадыгыз, йокларга яткан җиреннән алып җибәрттегез. Бусы кем эше?

— Аны кайчан, ничек озатканнарын белмим һәм белергә дә теләмим, бу минем вазифама керми.

— Сезнең вазифага нәрсә генә керә соң, попугай шикелле әйткәнне кабатлау гынамы?

Харисов тирләгән яңакларын сөртте, кульяулык чите белән авыз тирәләрен ышкыды.

— Райкомны психик авырулар язмышы кызыксындырмый,— диде ул.— Аның өчен махсус учреждение бар.

Сафин да кергәннән бирле кадаклар өстендә утыра иде.

— Аларны озаттыру гына кызыксындырамы?— дип янә чәнчеде.

Харисов, билгеле инде, моңа җавап бирә алмады.

— Сезнең бүтән сорауларыгыз юкмы?— Ул барыбер аны азаккача тыңларга тиеш иде бит.

— Низамованы кайтарыгыз әле, аннан миңа кагылышлыларына күчәрбез.

— Син үзеңне ул кадәр кемгә куясың?— Харисов түзмәде, сабыр, шул ук вакытта ачулы тавыш белән сорарга мәҗбүр булды.— Артык борын чөяргә ярамый, гайрәтеңне тиз бастырырлар.

— Әмма тез чүктерә һәм синең шикелле попугай ясый алмаслар.

Харисовның яңаклары тартышып-тартышып алды, әмма ул түзде, гәпне тагын да куертмады.

Алар шуның белән дипломатик сөйләшүләрне очладылар.

Шул көнне кич Ленар Гамирның өенә шалтыратты, Гөлфияне телефонга чакыруын үтенде. Моны ул, әлбәттә, бу йортта яшәүче башка кешеләр аркылы да эшли алган булыр иде, әмма саклык, рәсмилек йөзеннән эшләде. Ике арадагы сөйләшүгә Гамир шаһит булачак.

Гамир аның гозерен бик теләп үтәде, бу сөйләшү Хәлимов өчен мөһим хәбәр булачак иде.

— Гөлфия Шакировна, Җәвидәне коткаруда ярдәм итәргә Сез ризамы?— дип такт һәм рәсмилек саклап мөрәҗәгать итте ул.

— Зинһар, ул мәсьәләгә мине катнаштырмагыз,— диде Гөлфия, калтыраган тавыш белән.

Сафинның җен ачулары чыкты, аның элекке дусты, иптәшеннән бик тиз йөз чөерүен битенә бәрәсе килде дә тыелып калды.

— Аңлашылды,— диде ул тыныч тавыш белән һәм сүзе беткәнен сиздерү өчен генә өстәде.— Минем бүтән үтенечем юк.

* * *

Ай буе колхозның финанс эшчәнлеген тикшергән ревизорлар киткәч, Сафин бюро утырышына чакырачакларын белә иде. Алар ревизорлардан күп нәрсә көтәләр иде. Сафин акт нәтиҗәләре белән танышты: куркырлык нәрсә күрмәде. Ярдәмче хуҗалыклар төзүне колхоз уставына туры килми дип кертмәкче булган иделәр, үзләрендә аны гомуми җыелыш карары белән законлаштырганлыкларын документлар нигезендә раслады: уставка өстәмәне берничә ел элек үк керткәннәр иде. Ревизорларга төзәтмә кертергә туры килде.

Ленар авылда үзен коммунистлар, колхозчылар яклаячагына ышанды. Аларның кәнәфи өчен куркасылары юк, хаклыкны аңларлар, якларлар. Шуңа үзен кулга алды, соңгы бәрелешкә курыкмый әзерләнде. Гомуми җыелыш исеменнән Җәвидәне психик шифаханәдән чыгаруны сорап мөрәҗәгать иткән карар проектын да әзерләп куйды.

Алдагы көнне парторг Хәбировка шалтыратып искәрттеләр: иртәгә колхозга Хәлимов килә, партҗыелыш булачак. Сәгать тугызга билгеләнгән иде җыелыш.

Хәлимов барлык бюро әгъзаларын җыеп килгән иде. Бюроның күчмә утырышы «Таң» колхозы коммунистлары катнашында узды.

— Без бүгенге утырышта «Таң» колхозы председателе коммунист Сафинның персональ эшен тикшерәбез,— дип бер керешсез башлады Хәлимов.— Аны беләсез: партия дисциплинасына буйсынмый, КПСС уставын, колхоз уставын тупас боза, райком күрсәтмәләрен үтәми, җитәкчеләрен санга сукмый. Бу хакта ул кабат-кабат кисәтелде, күп тапкырлар партия җәзасына тартылды.

Ул тавышын күтәрә барды, Сафинның җиде елдан артык эшчәнлеге дәвамында җибәргән хаталарын санады, законсыз рәвештә ярдәмче хуҗалыклар оештыруы һәм башкалар турында сөйләде. Аннан шәхси үпкәләре беләнябырылды, аны сүгәргә тотынды. Болары Сафин өчен яңалык түгел, күнегеп беткән, бернинди конкрет гаепләрлек сүз ычкындырмады әле.

Хәлимов сәгатькә якын аны шулай сүкте, җикеренде: тамагы кипте. Ул графиннан су салып эчәргә туктаган арада, Сафин түзмәде.

— Болар бары буш сүзләр, бәйләнгәнсез икән, конкрет дәлилләр турында сүз алып барырга кирәк,— диде.

— Буш түгел, иптәш Сафин, конкрет фактлары да бар.— Ул гайрәт белән стаканын шап иттереп өстәлгә куйды һәм дәвам итте:— Җәен, мәсәлән, синең өстән райкомга аноним хат керде. Кеше семьясын бозуың, хатын-кызны аздыруың хакында язылган иде. Син моны тикшерү барышында кире кактың. Партияне, аның бюросын алдаган булып чыктың.

— Фамилиясен атап конкрет сөйләгез,— дип бүлдерде аны Сафин.— Мин үземә яла ягарга юл куймыйм. Бу мәсьәләне тикшергәндә шаһитләр, ул хатын үзе дә кирәк. Болай гына тикшерү, закон, әхлак нормаларына да туры килми.

— Гыйшык мажараларыңны оныттыңмы әллә? Хәтерең бик сай икән. Ярар, без сиңа кайберсен искә төшерергә булышырбыз.— Ул гайрәтле ат сыман башын чайкап җибәрде, чәчләрен сыпырып алды.— Казанда «Таң»да сөяркәң белән типтерүеңне, хатының югында өеңә алып

кайтканыңны, хатының кайтып торканын, башкаларын да оныттыңмы әллә? — Хәлимов боларны тантана белән сөйләде.— Үзең оныттсаң, шаһитлар монда.

— Алар түгел, ул хатын үзе юк әле монда, аны чакыртырга кирәк.— Сафин Гөлфия булмагач, үзен иркен тотты. Килүеннән дә курыкмады. Аның алдында ул әллә ниләр сөйли алмый: сораулар бирергә, каршы дәлилләр китерергә, ахыр чиктә намусына чакырырга мөмкин. Шуңа ул моңа янә басым ясады.— Ансыз болар бары сүз боткасы гына.

— Ботка гына түгел, Сафин,— диде Хәлимов канәгать бер хис белән.— Бу юлы каты килеп каптың, ансат кына ычкына алмассың.

— Мин аның үзен бюрога китерүне таләп итәм.— Беренче секретарьның Гөлфияне читтә калдырырга планлаштырып килгәнен аңлагач, ул таләбен кабатларга мәҗбүр булды.— Персональ эшне аңа турыдан-туры кагылышлы булган кешедән башка карамыйлар. Бу устав таләпләренә туры килми.

— Ул авырый,— диде Хәлимов тыныч кына.— Чакырып торуның хаҗәте дә юк. Менә монда ул ни әйтергә теләгәнен барын язып бирде. Анда синең биографияңнең иң кызыклы моментлары бары язылган. Гыйшык маҗараң, район җитәкчеләре турында арттан сөйләп йөргәннәрең, КПСС сафларында торуыңны тоткын итеп санавың да...

Сафин нервланып иреннәрен чәйнәргә кереште. Үзе монда булса, азагын уйлап тормастан, күңелендәгеләрен Гөлфиягә, биредә утыручылар алдында, тезеп күрсәткән булыр иде, тик ул юк. Хәлимов боларны алдан күргән, саклану юлын сайлаган. Бу — Сафин өчен көтелмәгән һәм каты удар иде.

Ул оттырганын аңлады, әмма егылганчы сугышырга кирәген дә истән чыгармады. Батканда үзе белән Хәлимовны да аска тартырга булды.

— Үзе килмәгән икән — күрсәтмәләрен игълан итегез,— дип таләбен куйды.— Ул сез диктовать итеп яздырган текст кына. Монда утырган барлык коммунистлар чын хакыйкатьне белергә тиеш. Минем язмышны алар хәл итә, тикшерү һәрьяклап һәм тулы булырга тиеш.

— Интим мөнәсәбәтләргә кагылышлы ул аңлатманы монда уку мөмкин түгел, кызыксынучылар райкомга килеп укыр. Ә бюро членнары таныш инде.

— Син аны алдап өеңә чакырганны да, шуннан соң ул күрсәтмәләр биргәнне, кайтып агу эчәргә әзерләнүен дә беләләрме?

Хәлимов каралып чыкты, аңа нәфрәтләнеп карады.

— Сүз минем турыда бармый, синең оятсыз тәртибең турында бара,— диде.

— Синекенә дә чират җитер,— диде Сафин.

— Ленар энекәш, инструкцияләрне бозып, ярдәмче хуҗалыклар төзеп күпме сүз, шелтә алдың. Райком күрсәтмәсеннән чыкмыйча гына эшләсәң, мактаулы председатель булыр идең.— Гәрәев түзмәде, бәхәскә кушылды. Хәлимов өчен четерекле темадан сүзне читкә тизрәк алып китүне мөһим санады.

— Әйе, инструкцияләрне бозмыйча да яшәп булыр иде. Әмма мин беренче секретарь авызына гына карап тора алмадым, ярдәмче хуҗалыклар оештырып, колхозның дүрт миллион бурычын түләдем, ун миллион сумнан артыклык объектлар кордым. Ярдәмче хуҗалыкларның реаль нәтиҗәсе шул, шуның өчен унлап шелтә алдым. Ә сез колхозны ун миллион бурычка чумырган өчен Алтын Йолдыз тактыгыз. Бездәге хакыйкать шуннан гыйбарәт.

Гәрәев кызарып чыкты.

— Син, ... мать, персональ эшеңне тикшергәндә дә бюро членнарын хурлыйсыңмы әле.— Хәлимов чыгырыннан чыкты, культура йорты залын яңгыратты, өстәлгә китереп сукты.— Минем тәкъдим мондый: амораль тәртибе, чит кеше гаиләсен бозуы, район җиткәкчелеге турында гайбәт таратканы, үзен партия Үзәк Комитеты хуплаган курска каршы

куйган өчен коммунист Сафинны КПСС сафларыннан чыгарырга. Кем яклый, кул күтәрүегезне үтенәм. Бюро членнары, әлбәттә.

Бюро әгъзалары барысы да кул күтәрде.

— Хәзер, Зәбиров, синең чират.— Ул колхозның партком секретарена мөрәҗәгать итте.— Бюро карарын үз коммунистларың тавышына куйдыр. Чык бире.

— Мин бу карар белән килешә алмыйм, Хәким Нурович,— диде Зәбиров өстәл янына килгәч.— Гадел түгел ул.

— Ах, әле син шулаймы?! Сафин җырын җырлыйсыңмы? — Бюрога мондый тәкъдим: Сафинның партиягә каршы курсын яклаган өчен Зәбировны партком секретарьлыгыннан алырга, соңгы кисәтү белән каты шелтә белдерергә. Кем шул тәкъдимне яклый?

Бюро әгъзалары бу юлы да бердәм булды.

— Мин дә каршы, мине дә чыгарыгыз.— дип торып басты Нургаяз.

— Гаянов! — Хәлимов залда утырган өч милиционер ягына карады.— Алыгыз моннан, исерек ул.

Милиционерлар сикереп торып аның янына килеп җиттеләр, ике кулына ябыштылар.

— Бәйләнмәгез миңа, мин исерек түгел,— дип кычкырды Мәүлетов.

— Гаянов! Бюроны өзгән өчен дип протокол төзегез, биш ел утырып кайткач аңлар ул.

— Мин исерек түгел, мин бюро утырышын өзмәдем,— диде йомшап төшкән Нургаяз.— Фикеремне ачыктан әйттем. Без шулай турыдан сөйләргә күнеккән. Сафин безне шуңа өйрәтте.

— Әйдә, чык, айныклыгыңны тикшерәбез дә җибәрәбез,— диде Гаянов.

Нургаяз бу юлы карышмады.

— Тагын кем каршы?

— Мин,— дип торып басты Миңнегөл.— Мине дә аласызмы төрмәгә? Балаларым белән.

— Син исәпкә кермисең, утыр урыныңа тик кенә,— диде Хәлимов.— Муж да жена — одна сатана.

— Хәким Нурович! — Харисов утырган килеш кенә сүзгә кушылды.— Безгә алдан партком секретарен сайлап куярга кирәк. Җыелышны ул алып барсын.

— Запас вариант буенча кем әле монда безнең?

— Профком Сираев, аның замы.

— Тавышка куям: кем Сираевны партком секретаре итеп сайларга дигән тәкъдим яклый?

Каршылар булмады.

Аннары баш бухгалтер Рабига апа Сафинның финанс тәртибен бозулары турында тезеп китте.

Бүтән чыгыш ясарга теләүче табылмагач, Сираев Сафинны партиядән чыгару мәсьәләләрен тавышка куйдырды. Бу карарны яклап биш-алты кеше генә кул күтәрде, күпчелек тоткарланды. Сафинны ачыктан-ачык Зәбиров, Нурия апа гына яклады.

— Ә сез, иптәш Бакирова, ни өчен партия курсына каршы? — дип Хәлимов аңа ябышты.— Орден бирдергән өчен рәхмәтегез шулмы?

Укытучы каушап калмады.

— Ленарны мин малай чагыннан беләм, класс җитәкчесе идем. Аның ише туры сүзле, гадел укучы класста юк иде. Ул бүген дә шундый. Дүрт аякка да сөрлеккән колхозны ничек күтәрде, моны сез дә, коммунистлар да күреп тора. Шундый коммунистны партиядән чыгару КПСС абруен да төшерәчәк, аңа ышанычны какшатачак. Аның ялгышлары бар, моның өчен шелтә бирергә кирәк. Бу юлы Сез, Хәким Нурович, үзегез белән сүзгә килешкән өчен аннан үч аласыз. Ләкин...

— Ах-х, вон как! — Хәлимов өлкән педагогның тел төбен аңлап алгач, аңа чыгышын төгәлләргә ирек бирмәде.— Сез партийный преступникны яклыйсызмы әле?! Без сине аның белән бергә партиядән чыгара-

быз. Бюро членнары, каршылар юкмы? — Ул тарафдарларына күз йөгертеп узды. Кул күтәрергә, фикерен белдерергә теләүче табылмады.— Менә шулай, иптәш Бакирова, партбилетыгызны өстәлгә куегыз.

— Мин аны алып килмәгән идем.

— Бар, кайтып алып килегез. Син, Харисов, роно мөдиренә хәбәр бир, аны мәктәптән шуытсыннар!

— Ул пенсиядә инде, Хәким Нурович,— диде Гамир Садыйкович.

— Бик әйбәт, мәктәпкә якын китермәскә.

Бакированы залдан озаткач, беренче секретарь яңадан, инде башкаларга ябырылды.

— Да, без белми торганбыз, Сафин монда партиягә каршы курс үткәреп кенә ятмаган, коммунистларны да шуңа котырткан. Яле, бас, Саимә. Аңлатып бир, ни өчен кул күтәрмәдең? Райком члены, депутат булып тору туйдырдымы? Без моны исәпкә алырбыз.

— Мин күпләр күтәрмәгәнгә генә,— дип акланды савучы.

Аннан соң ул үзе танып белгән тагын берничә коммунистны бастырып ризалыкларын алды.

— Демократик централизм югары оешмалар карарының түбәнгеләр өчен мәҗбүрилеген күздә тота.— Аның кычкыра-кычкыра тавышы карлыккан иде, чыгышын бүлеп, тагын чәй эчеп җибәрде, хәл алды.— Кем уставның бу таләбенә буйсынмый, бюрода персональ эшләрен караячакбыз. Бакированыкы кебек. Тагын кайберәүләр моннан партбилетсыз кайтып китүе ихтимал. Сираев, син, әйдә, тавышка куйдыр. Син, Харисов, каршыларны исәпкә ал.

Яңгыр яуганда бала, таш яуганда баш жәл, диләр. Бу юлы тавыш бирүчеләрнең яртысыннан артыгы Сафинны КПССтан чыгаруга ризалыгын бирде.

Максатларына ирешкәч, каршыларның тәртибен тикшереп тормадылар.

Гомуми җыелышка колхозчыларны гына керттеләр. Анда дистәдән артык милиционер катнашты.

Райком җитәкчесе Сафинны сүкте дә сүкте, күп төрле гаепләр ташлады, шулар өчен партиядән чыгарылуын хәбәр итте. Шулай да аны эшеннән алуны унбишләп кенә кеше яклады.

Хәлимов Харисовны янына чакырды, нидер хакында киңәште. Тегесе начальник урынына калган Гаянов колагына чышын-пышын сөйләде, янына җыелган милиционерларга төртеп-төртеп күрсәтмәләр бирде. Тегеләре халык йөри торган аралыктан һәр рәт кырыена килеп бастылар.

— Сафин эшеннән үзен партиягә каршы куйган өчен чыгарылды. Аны яклау партиягә каршы килү дигән сүз,— дип китереп куйды район башлыгы.— Партия курсына кем каршы? Сез, иптәш милиционерлар, саный барыгыз.

Берәү дә кул күтәрмәде.

— Димәк, партия линиясенә каршылар юк. Сафин бертавыштан эшеннән азат ителде дигән сүз,— дип белдерде Сираев, үзеннән югарылар белән киңәшеп алгач.

* * *

Ләенар берничә көн буе уйлап, озын хат язды. Үзе, эшчәнлеге нәтиҗәләре, бүгенгечә эшләү мөмкин түгеллеге, Хәлимовның башбаштаклары турында да язды. Җәвиданең нигезсез психик авырулар шифаханәсенә ябылуын, аны чыгаруны таләп итүен дә калдырмады. Эльвира аны яшертен генә өч данәдә басып бирде.

Беренче нөсхәсен КПСС өлкә комитетына юллады. Ун көнләп вакыт узгач аны идарәгә чакырттылар.

Харисов аны хаты буенча Казанга чакыруларын хәбәр итте, Нәбиевка керергә икәнен әйтте.

— Шундый акыллы, талантлы кеше ул дәрәҗәгә төшсен әле.— Нәбиев аңа карамый гына үз уйларын ачып салды.— Синең урында берәү булса Алтын Йолдызлы председатель, йә райком секретаре булыр иде.— Ул туктады, йөзен аңа борды һәм кулын селтәде.— Хәер, болары турында сөйләнүнең кирәге юк,— диде Нәбиев.— Бүгенге реаль тормышка кайтыйк. Чебен дулап тәрәзә вата алмаганны гына аңларлык акылың калдымы әле синең?

— Бу нәрсә, тәрбия чарасымы? — дип сорарга мәҗбүр булды Сафин.

— Кызганыч, син киңәшкә колак сала белмисең, ул хакта сүз алып бару файдасыз. Мин сине башка өчен чакырдым. Дөресе, сине партkомиссия чакыртты. Курсташ буларак, шуңа кадәр сөйләшергә булдым. Минем киңәш шул: «Гөлфия үзе чакырды», дип сөйлә. Бу аның аңлатмасында да бар — почтадан дөрестән дә сиңа шалтыраткан бит.

— Ул мәсьәләдә гаепне хатын-кыз өстенә аударырга, чыны шулай булганда да, ирлек горурлыгым кушмый минем.

— Ул бер дә хатын-кыз горурлыгын санап тормаган бит,— дип ашыгып әйтеп салды Нәбиев.— Бу — синең төп гаеп.

— Анда аннан катырак статьялар да бар,— дип куйды Сафин.

— Аларны кызулык белән яздым диярсең, тәүбә итәрсең: хатынны кире алырсың, ул чагында, хезмәтләреңне искә алып, бәлки партиядә калдырырлар, хотя бы кандидат итеп. Шул кадәренә булышырга өстемә алам. Студент чактагы игелекләрең хакына.

— Мин үз язмышым өчен кайгырмыйм, эшләрмен дә ашармын. Аның өчен генә булса, бу хатны язып та тормаган булыр идем. Миңа хакыйкать кирәк. Ә хакыйкать шунда ки, без сазлыкка кереп барабыз. Миңа партияне, аның югары җитәкчелеген дә эш, авылга җитәкчелек формаларын үзгәртү зарурилыгына ышандырырга кирәк. Минем «Таң»да үткәргән эзләнүләрем, аларның нәтиҗәләре юнәлешне сайлау өчен нигез була ала.

— Хакыйкать, яңа методлар, имеш,— диде Нәбиев аңа ачулы караш ташлап.— Синең хәлдә аны эзләмиләр. Кимчелекләрне эзләгәнче, гафу үтенеп апелляция яз.

— Мин язган һәр сүземне фактлар, эш күрсәткечләре белән раслдым. Алар шик астына алына икән, каршы дәлилләр китерегез, мин шул чакта гына ышанам. Мине дөрес аңласагыз, сез болай да акларга тиеш. Мин әләк язмадым. Хәлимовка кагылышлы кайбер фактларны мисал итеп китергәнмен икән, бу бүгенге безнең җитәкчеләрнең эш алымын раслаучы буларак кирәк.

— Кызганыч ки, үзеңне аклау өчен башкаларга гаеп ташлау, яла ягу әләккә керә. Сиңа соңгы киңәшем шул: парткомиссиядә бу таләпләрең турында сүз кузгатма. Низамова мәсьәләсенә синең бөтенләй катнашың юк. Халимовка пычрак атарга тырышуың файдасыз, герой секретарьны сиңа алмаштырмыйлар.

— Кыскасы, мин башны иеп, булган-булмаган гаепне өстемә алып утырырга тиеш инде.

— Синең хәлдә бары шул гына.

— Мин монда хаклык эзләп килдем. Алай саныйсыз икән — минем язмыш ничек булган, шулай калсын. Тәкъдимнәрем гамәлгә ашса, миңа шул җиткән.

Партия комиссиясе утырышында үз шартларын куйгач, аны юньләп тыңлап торучы да булмады. Райком карарының гадел һәм дөрес чыгарылуын таныдылар. Ленар моңа нәфрәтләнде, әмма комиссиянең икеләнергә исәбендә дә юк иде. Җәвиданең кая барып эләгүен бер минутка да онытмаган Сафин эченнән: «Әле минем көрәшер мөмкинлегем бетмәгән, бирешмәскә генә кирәк!» — дип уйлады. Тоткын хәлендә булса да, ул иректә ич әле...

# НИЧӘДӘ СИН, ЙӨРӘК?

Шагыйрәләрнең яше белән кызыксыну һәм аны, кычкырып, дөньяга игълан итү — ярый торган фалмы?

Чыннан да, дөнья үзе яратылганнан бирле, Җирдә, һаман янып, каңгырып, кычкырып, даулап, йә тын гына елап, җырлап йөргән — кыскасы, яшәүнең үзе кебек мәңгелек бер йөрәк түгел микән ул — шагыйрә? «Ә йөрәк соң, йөрәк нишләсен?» дип, шушы хакта уйлап язгандыр Клара Булатова атлы каләмдәшебез дә... Әйе, кадимидәге Сафо, Коринналар, урысның Ахматова, Цветаевалары, үзебезнең Газизә Сәмитова, Мозаффария апаларыбыз, ниһаять, Саҗидәләребез... һәм бүгенге көндә шигырьгә шәрран-яра хис, йөрәк белән килгән яшь Рифә, Илсөярләребездәге кебек — дәвамлы, илаһи бу халәт... Хатын-кызга гына хас Наз һәм Моңны үзенә җыйган ягымлы, үзенчәлекле, самими җаннар шигърияте бу! Исемлекнең башында атаганыбыз — Лесбос утравының кабатланмас йөрәге Сафо да юкка гына:

— Пакьлегем, аһ! Син ник киттең миннән? — дип өзгәләнмәгәндер (кайбер тәрҗемәләрдә бу — сафлык, кызлыкка эндәшү!).

Мәхәббәтне иң тирән хисләрдә тоеп, кичереп язган шагыйрә «аһ»ы — безнең заманның туташ-ханымнарында да татарның борынгыдан килгән иң матур гадәтләрен, әхлагын — сафлыкны юксыну авазы булып кабатлана лабаса! Бүген дә шигърият шул ук: ул — йөрәк эше, мәхәббәтнең әрнү-рәнҗешләре, яшьлек узу, пакь вакытлар үтү, гомер кыскалыгы һәм Мәңгелек турында уйлар. Әйе, бәхет һәм кайгы янәшәлеге, Ил-ватан хәсрәтен дә сыйдыра алган нечкә, «назик» хисләр...

Клара Булатовада да — боларның барсы да бар дип әйтә алабыз: укучыларыбызга тәкъдим ителә торган, юбилее мөнәсәбәте белән сайланган бу шәлкеме дә — әнә шундый уйланулар «антология»се, кичерешләр «дисбе»се... Гомер турында фәлсәфи уйлар, Вакыт һәм Кеше, Халык һәм Заман, Дөнья турында әрнүле фикерләр... Шулар яктылыгында шәхси язмышы, стиле, шигъри дөньясы белән шагыйрә үзе дә күзаллана: тышкы кыяфәте белән дә әлеге антик дөнья героиняларын хәтерләткән, горур җан һәм чын татарча, милли Моң иясе...

...1965 елда безнең — берничә яшь шагыйрьнең шигырьләрен эченә алган «Дуслык» исемле бер китап басылды. Хәтердә: бу китап нәкъ менә Клара ханымның үзенчәлекле фотосурәте һәм ягымлы, җырга тартым лирикасы белән ачылган иде.

Әйе, Клара Булатова — безгә караганда тәҗрибәлерәк, инде көндәлек матбугатта, әдәби альманахларда («Үсү юлы», «Идел»), «Яшь үрентеләр» исемле кумәк китапта да исеме күренгән, шактый шомарган шагыйрь иде. Ул инде беркадәр вакыт Казанда яшәп, университетта укып та киткән һәм шул вакыт эчендә дә тере бер легенда-риваятькә әверелгән иде. Искиткеч хәтергә ия булуы, күп шагыйрьләрне, дастаннарны яттан белүе, фәнне «су урынына эчүе», яхшы оештыручы — әдәби түгәрәкләрнең җанына әйләнүе һәм үзендә матур сүз осталыгы, чичәнлек-импровизаторлык таланты булу өстенә, аның олуг шагыйребез Хәсән Туфан белән дуслыгы да гаҗәеп бер шигъри роман кебек иде. Шагыйрә соңрак үзе язган истәлекләрдән: бу дуслыктан икесендә дә күп шигырьләр, җырлар, хатлар, кадерле хатирәләр һәм... әлбәттә инде, нәкъ татар гадәтенчә, гайбәтләр-сүзләр калган. Тик, шунсы мәгълүм: Хәсән ага бу роман героинясы «Тәнәкә»гә, соңыннан ул яшәгән «Әлтәм» таңнарына гомер буе тугры калды — бу үзе генә дә шигъриятнең зур җиңүе түгелмени?.. Шәйхи ага Маннурга да шагыйрәгә карата шундый ук рыцарьлек, аны хатын-кыз буларак олылау, югары куя белү хас иде. Ә бездә — яшьрәкләрдә? Мөга-

ен, булмагандыр. Яшьлеккә артык таләпчәнлек, максималистлык юлдаш ич: мактауга да саранрак идек бугай... Хәер, бу яктан да Клара бәхетле чорга эләкте: 1965—1970 елларда университетта кабат укыганда аның дуслары, фикердәш-шигырьдәшләре — Рәшит Әхмәтҗан, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Харрас Әюпләр булды бит. Нинди матур мохит, нинди сиземләү!

1967 елда шагыйрәнең беренче мөстәкыйль китабы — «Язлар алда» дөнья күрде, бераз соңрак ул Язучылар берлегенә алынды. Башка китаплары (арада «Гел кояшка карап», «Печән өсте» кебек күләмлерәкләре дә, нәниләр өчен «Марс китабы» да бар) басылып чыкты... Урысчага һәм башка телләргә тәрҗемәләре булды, матур җырлары да иңгыраш тапты.

Иҗат, мәдәният һәм укыту эше (Клара ханым — атказанган укытучы да, мәдәният хезмәткәре дә!)... Үзе дә укытучы гаиләсеннән булган шагыйрә Сарман районы Татар Карамалысы авылында туган. Әмма үсүе, белем алуы — Югары Чыршылы, Ләке (менә кайдан аңарда керәшеннең «Чәчәк, Петрау бәйрәм»нәре!) авылларында була. Түбән Ләшәү — беренче укыткан авылы. Аннан — Әлмәт яклары, Яңа Кәшер, Колшәрип... Шигырьләре аша безгә дә таныш. Гомумән, нефть белән бәйле бу төбәк атрибутлары да бар шагыйрәдә. Әйе, шактый күп шагыйрьләребез, әдипләребез яшәп, иҗат иткән бер дөнья бу Әлмәт! Биредә яшәп, эшләп, канат ныгыткан Гариф Ахун, Равил Фәйзуллиннар өчен дә газиз һәм, бәлки, гыйбрәтле милли бер төяктер бу төбәк. Бу ноктадан караганда, шушы туфракта яшәп:

Шатлыгымда хәсрәт орлыгы бар,
Хәсрәтемдә — бәхет орлыгы,—

дип язган Клара Булатова иҗаты җанга тагын да аңлаешлырак, якынрак кебек. Шулай булмыйча! Озын, «ябык», болгавыр еллар аша Ил-ватан мәхәббәтен, халык фаҗигасе хисен үзендә йөрткән яралы, моңлы һәм назлы йөрәк сүзе бит ул!

Рәдиф ГАТАШ



# Клара Булатова

## БЕЗНЕҢ ГОМЕР СИРПЕЛГӘН ҖИР...

### Гел кояшка карап

Күз ачарга төнен теләмәгән
Яшь бөреләр иртән барсы да
Гел кояшка карап, гел кояшка карап,
Гел кояшка карап ачыла.

Ах, минем дә килә киң юлларның
Иң яктысын сайлап аласым.
Гел кояшка карап, гел кояшка карап,
Гел кояшка карап барасым.

*1960*

## Язлар алда

Төрле уйлар кила кайчак башка,
Соңгы чиккә килеп җитәсең.
Их, соң инде, бар байлыгы белән
Җирне ничек ташлап китәсең?
Чук тәлгәшле каеннары белән,
Камышлары белән ярдагы;
Кайнар яшьле кайгылары белән,
Сагышлары белән җандагы;
Яңа гына кар юрганын салган
Яшел уҗым белән кырдагы;
Яңа гына үргә менеп барган
Дәртле җырың белән юлдагы —
Ничек аны, ничек калдырасың?
Ничек шундый чиккә җитәсең?
Их, соң инде!
Уйла яз буласын,
Язны ничек ташлап китәсең?
Әнә, кара — апрель үтеп бара,
Ышык җирдә һаман кар әле.
Язлар алда, синең ул язларда
Яңгырасы җырың бар әле.

*1961*

## Ярларда учак көйрәтеп

Ярларда учак көйрәтеп
Җил йөри юлсыз гына.
Янымда үзең генә дә,
Күктә тын йолдыз гына.

Күлләрне тибрәтеп искән
Җил нинди йомшак, иркә.
Куаклар черем итсә дә,
Былбыллар таңны көтә.

Кирәкми, калдыр учакны,
Ял итсен таңга кадәр.
Йә, сау бул, яңадан шулай
Очрашуларга кадәр.

Салкын чык кунган гөлләргә
Хушлашып кул болга син.
Онтылмас тамчылар чыңы,
Кайда гына булма син.

Карлы тау сыртларындамы,
Йә зәңгәр диңгездәме,—
Онытмас сине таң җиле —
Тик туган илеңдәге.

...Ярларда учак сүндереп
Төн китә юлсыз гына.

Янымда үзең генә дә,
Күктә тын йолдыз гына.

Былбыллар инде уяныр,
Күр, шәфәкъ нинди якты.
Йә, сау бул, яңадан шулай
Очрашуларга чаклы.

*1965*

* * *

Еллар миңа миһербанлы булды,
Юк, зарлана алмыйм язмышка.
Яшьлек баерак, кыйммәтрәк була,
Икенче кат килсә тормышта.

Катламнарны күңел үтә күрә,
Тигәнәкне аера гөлләрдән.
Шытымдагы нечкә матурлыкны
Саклый белә саксыз җилләрдән.

Тәүге яшьлек — ул һәркемдә була.
Ул — тормышның тигез бүләге.
Ә бусын мин үзем яулап алдым,
Җаным аңа кыйммәт түләде.

Җаным аңа кыйммәт түләде шул,
Җыеп яшим барын берьюлы:
Шатлыгымда хәсрәт орлыгы бар,
Хәсрәтемдә — бәхет орлыгы.

*1969*

* * *

«Петрау үтте, җәйләр бетте», диләр
Безнең якта халык сүзендә.
Петраудан соң чәчәк атмый гөлләр,
Сары йөгерә кырлар йөзенә.

Петраудан соң яфрак бәйләмиләр,
Мәтрүшкәләр җыеп кайтмыйлар.
Үләннәрдә хуш ис бетә диләр,
Петраудан соң печән чапмыйлар.

Петраудан соң кош сайраудан туктый,
Ишетелми күккүк тавышы.
Җирләр сүрелә, Кояш көн балкытмый,
Салмаклана тормыш агышы.

Петрау үтте, димәк, җәйләр бетте,
Болыннарга сары йөгерде...
Бу тормышның петраулары җитте,
Кыл урталай бүлеп гомерне.

*1971*

## Аккаен

Аккаеным, назлы каенкаем,
Туган җирнең якты бизәге.
Чал шагыйрьләр җанын җырлатырлык
Чын матурлык, сафлык үрнәге.

Иңнәреңә кичен томан ята,
Иртән аны җилләр тарата.
Ак кәүсәңдә нурлар биетүче
Кояш сине бигрәк ярата.

Күр, көндезен ничек җемелдисең,
Нурландырып төбәк-йортымны.
Ватанымдай иркен күңелле син,
Халкым кебек каты токымлы.

*1975*

* * *

Еллар үткән, айлар үткән, көннәр үткән...
Ничек үлчи белмәгәнмен мин элгәре?
Ах, гомернең нинди кыйммәт, нинди кирәк
Минутлары, секундлары, мизгелләре.

Әйләнәм дә караш салам үткәннәргә,
Дисбе тарткан кебек саныйм ел, көннәрем:
Бурычымны кайтардыммы өлкәннәргә?
Алмашчыма килер өчен ни биргәнмен?

Бер карасам, бер чеметем гомеремнең
Бер чаткысы яктысыннан шатлык тоям,
Бер карасам, дисбе — гомер төймәсенең
Кителгәнен очратам да әрнеп куям.

Бары еллар үтү белән аңлашыла:
Үзкыйммәте ерак калган ел, көннәрнең.
Торган саен тирәнрәк эзе ачыла
Минутларның, секундларның, мизгелләрнең.

*1981*

## Ком сәгате

Ком сәгате...
          Һәр бөртеге
Гомерләрнең бер көне.
Бөртекләп тормады язмыш
Дәррәү тотып селкеде.

Әллә җиргә сыенасы,
Әллә күккә багасы.
Безнең гомер сирпелгән җир —
Җир белән күк арасы...

*1985*

* * *

И, ил генә, ил генә, дидек,
И туган ил, дидек бер генә.
Туган илдән — туйган җирләр эзләп
Күпме җаннар читкә сибелә.

Дус-туганнар булып гомер кичеп
Яшәгәннәр нигә үзара
Сугышалар бүген?
Синең өчен
И илкәем, йөзем кызара.

Хәйран дөньяларны вәйран итеп
Шушы хәлгә илне төшергәч,
Җәрәхәтле килер буын өчен
Җир-табигать безне кичермәс.

*1987*

* * *

Искән җилдәй, агып киткән судай
Үтеп бара гомер өзлексез.
Болан микән, әллә елан микән —
Кемнәр булдык икән элек без?

Хак-табигать тагын мәңгелектә
Бу җиһанда җанны кузгатса,
Агач микән, әллә бер таш микән —
Кем булырбыз микән ул чакта?

Ә бусында — якты җир йөзендә
Кеше булып йөргән гомердә
Туры килде күпне кичерергә,
Туры килде күпне күрергә.

Ачысы да булды, төчесе дә —
Нинди булыр тагын азагы?
Хак-тәгалә сөйгән кешесенә
Бу дөньяда бирә — газабын...

*1995*

* * *

Утырган да идем яр читенә
Бераз хәлләр алыйм дип кенә.
Бер карасаң елар сәбәп тә юк
Күңелем тулды әллә ник кенә.

Каршы якта ярлар сөзәк, түбән.
Яр өстендә яшел, яшь үлән.
Бер карасаң елар сәбәп тә юк,
Ярга ятып нигә яшь түгәм?

Сай җирләрдә сулар ага тыныч,
Борылышта упкын, кузгалыш.
Бер карасаң елар сәбәп тә юк —
Узган гомер генә кызганыч.

*1995*

* * *

Бер кулымда минем каләм булды,
Бер кулымда — энә.
Бер кулымда иләк, чиләк, көрәк —
Ә кул икәү генә.

Алда хыял инде, артта юллар,
Йөге иңнәремдә.
Гомеркәйне теткән, кискән шулар —
Ә ул бирәү генә.
Бик ерак та түгел кебек инде
Ул гомернең чиге...
Оныкларым өчен нидер эшләп
Калдырасы иде!

*1995*

* * *

Безнең дәвер, димәк, үтеп бара,
Үтеп бара, гасыр китеп бара.
Ил таралып, көн каралып бара,
Ил гаменнән чәч агарып бара.

Әй-йа, яшьлек! Кайда яшьнәп калдың?
«язлар алда», — диеп, «алдап» яздым.
Алданудан арган шагыйрь җанын
Ни ялганнар алда көтә тагын?
Атылып килә алтмышынчы язым...

Атылып килә алтмышынчы язым,
Мин тартышып азапланган булам.
Тик язмышка каршы торып булмый,
Кире кайтып булмый үткән юлдан.

Кайтмас идем кайта алганда да
Гел ялганнан торган заманнарга.
Бүгенгесе тагын... Хаклык кайда?

Шагыйрь җанын тетеп сугып бара,
Ил гаменнән шаулап чәч агара,
Безнең дәвер шулай үтеп бара, —
Үтеп бара, гасыр китеп бара...

*1995*

# ХАКЫЙКАТЬ ЭЗЛӘП...

Шагыйрь Әхмәт Рәшитов, гәрчә, беренче шигырен 16 яшендә үк — 1952 елда «Чаян» кебек мәртәбәле журналда чыгарса да, олы шигърияткә ул утыз яшен тутыргач кына, тормышның, ачысын-төчесен татып, кыйбласын билгеләгәч кенә ныклап аяк басты. Ул инде уңга-сулга бәргәләнүдән узган, кай тарафка юл алганын анык белеп бара иде. Моннан утыз еллар элек, без беренче мәртәбә танышканда ул әнә шундый ир-егет иде.

Шигърияткә соңарып килү — балачаклары сугышка һәм сугыштан соңгы авыр елларга туры килгән бу төркем өчен (буын дип әйтү дөрес тә булмас) уртак күренеш булды булса кирәк. Алар күбәү иде; соңыннан кайберләре тел йә әдәбият галимнәре, түрәләр, журналистлар, укытучылар, мәдәният хезмәткәрләре булып, төрлесе-төрле якка сибелделәр. Сибелделәр дисәк тә дөрес булмас, чынлыкта алар бер хезмәткә — халыкка һәркайсысы хәл кадәренчә хезмәт күрсәтүгә җигелделәр. Әдәбият тарихын өйрәнүче галимнәребезгә аларның исемнәре кирәксә, «Беренче карлыгачлар» тупламасендә чыккан беренче, икенче, өченче китапларны гына күзәтеп чыгу да җитә.

Быел алтмыш яшен түгәрәкләгән Әхмәт Рәшитов әнә шул төркемнән.

Үзләреннән бер ун елга элгәрерәк чыккан буын — Шәүкәт Гали, Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Хисам Камалов, Рәшит Гәрәйләр иҗади эзләнүләрендә Такташка, Фатих Кәримгә, Әхмәт Фәйзигә, Гали Хуҗинга, Сибгат Хәкимгә, Зыя Мансурга, Шәрәф Мөдәрриската таяндылар.

Әхмәтләр төркеме дә тырышып-тырмашып, инде шактый чарланып, әнә шул эздән килде...

* * *

Шулай бервакыт Әхмәтнең туган авылына кайттык. Гаҗәп үзенчәлекле, гаҗәп күпкырлы төбәк бу...

...Буа... Яңа Чәчкап авылы... Миннән ун яшькә өлкән каләмдәш дустым Әхмәт Әхәт углы Рәшитов әнә шунда туып үскән. Шунда җидееллык мәктәпне тәмамлаган. Әнисенең чардуганын бизәклибез. Байтак кына еллар үткәч, «Йөрәк кыңгыраулары» (1986) китабыннан шагыйрь дустымның әнисенә язган эпитафиясен укып сискәнеп киттем:

Бар ачысын татып ятимлекнең,
Күп еладым күңелләрем тулып.
Яшем тамган җирдә гөлләр үссен,
Әнием, сиңа соңгы ядкарь булып.

Һәр яз саен җир гөлгә, чәчәккә күмелә икән — бу безнең күз яшедер. Бу — халкымның күз яшедер. Әхмәт изге күңелле зат. Әгәр ул «яшем тамган җиргә гөлләр үссен» дигән икән, безнең бабаларыбыз да шул теләктә булгандыр. Югыйсә, каргышлардан җир кара көйгән булыр иде. Гел болай яшәрмәс, чәчәк-гөлгә төренмәс иде.

* * *

Шигърияткә кереп килә торган Әхмәтләр агымы — куәтле агым иде. Татар халкының үз язмышы сыман — күз-яшьле агым иде. Алар инде менә-менә ияргә менәбез дип кенә торганда, империя тормышында гаҗәеп хәлләр булып алды.

Сталин үлеме...
XX съезд...
Хрущев докладьı...
...Әдәбият мәйданына бер-бер артлы титаннар кайтты. Әлбәттә, аларның күпчелеге шагыйрьләр иде.
Дәрдемәнд, С. Рәмиев, Ш. Бабич, Н. Думави, С. Сүнчәләй... Үз аягы белән легендар Туфан...

...Меңнәр кайтты, меңнәр тегеннән —
Тарих төбеннән.
Һәркайсысы безгә мең кат кыйммәт
Культның барлык мөритләреннән,
Культ догмасы өтекләреннән,—

дип язды ул.
Әхмәтләр төркеме бу вакыйгаларны алкышлап каршылады. Әгәр дә бу үзгәрешләргә Җәлилнең кайтуын, аңа Герой дәрәҗәсе һәм Ленин премиясе бирелүен дә искә алсак, чыннан да башлар әйләнерлек иде.
Әнә шул вакыйгалар агышында әле мәктәп парталарында, ВУЗ аудиторияләрендә утырган яңа бер буын камилләште. Алар ялган патриотизм белән агуланмаган, яңа яшь көчләр иде. Һәм алар яшен тизлеге белән «Әхмәтләр төркеме» менәчәк әзер ияргә сикереп атландылар. Талантлылар, чисталар, яктылар...
Равил Фәйзуллин, Ренат Харис, Рәдиф Гаташ, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт. Каушап калырлык та иде. «Төркем» чигенеп куйды. Берничә елдан соң гына аңнарына килеп, иң талантлылары, Әхмәт кебек шигърияткә фанатикларча бирелгәннәре генә әнә шул буынга кушылып, ияреп китте.

* * *

Балачаклары орыш елларына туры килгән бу агымның кичерешләре бердәй иде. Әхмәт Рәшит аны бер шигырендә искиткеч төгәллек белән сурәтләп бирде:

Хәтерләмим, илгә дошман кергәч,
Әтием ничек солдат булганны да,
Билләренә каеш буганны да,
Күзләремә яшьләр тулганны да,
Ул киткәчтен койма ауганны да,
Соңгы хатын аның алганны да.
Дүрт ел үтте. Бер көн әни әйтте:
«Зарыктырып көткән җину килде,
Ир затыннан йортта хәзер инде
Син бер үзең генә калдың»,— диде.
Мин малайчак белән саубуллаштым.
Койма төзәтергә чыгып бастым.

Әхмәт — һөнәр иясе! Аның кулыннан килмәгән эш юк. Симей (Семипалатинск) якларында мич чыгарып йөрүләре безгә мәгълүм. Шуның өстенә ул тынгысыз сәяхәтче дә. Шуңа да ул бер китабын «Сәяхәтнамә» дип атый. Ташкент, Алма-Ата, Кавказ тавы, Кырым — ул якларда яшәүче татар гаиләләре аның өчен авылдашлары кебек үк таныш, якын. Сингапур, Һиндстан, Малайзия һ. б. дистәләгән илләрнең җилләре дә аның шигъриятенә үз эзен салып үтте.

Карыйм да, гыйбрәт алыйм, дип
Дөньялар йөрим гизеп.

Юк, шагыйрь өстән күзәтеп кенә йөрүче, экзотика белән хозурланып кына ләззәт алучы түгел. Ул бит әле бик һәйбәт журналист, публицист та. Менә утыз елдан артык инде көндәлек матбугатта булсын, радио-телевидение аша булсын ул үзенең саллы сүзен әйтә килә. Һәм алар тематик яктан кешеләр язмышына кагылган бөтен өлкәләрне иңлиләр. Барыннан да бигрәк, татар милләте язмышын...

Татар иҗтимагый хәрәкәтенең бүгенгесе!..

Кырым татарлары язмышы!..

Бүгенге эстрада җырларының сыйфаты!..

Санап китсәң, аны борчымаган, ул кызыксынмаган бер генә өлкә дә юктыр сыман.

Менә «Азатлык» радиосын ачабыз. Аннан берничә көннәр инде татар әдипләренең фаҗигале язмышы турындагы тапшырулар тезмәсе бара. Тукай фаҗигасе, Исхакый фаҗигасе, Такташ фаҗигасе...

Аның шулай ук ерак илләргә ясаган сәяхәтләреннән соң биргән язмалары да беркемне дә кабатламый. Бүген дә искермәгәннәр. Кызганыч, мин югарыда санаган дөньяви хезмәтләр бер төпләмә — аерым китап булып тупланмаганнар. Югыйсә, без үзебез өчен әр-яңа Әхмәт Рәшитне ачкан булыр идек.

* * *

Шагыйрьнең иҗатында тагын бер якты сәхифә — ул да булса җырлар.

> Хәтердә ул тыныч айлы кичләр,
> Хәтердә бормалы су юлы.
> Онтылмый беренче саф мәхәббәт —
> Онтылмый Агыйдел сылуы.

1966 елны язылган бу җыр утыз ел эчендә дөньяны урап чыкты. Булды бер заман, радио ачсаң — ул, ресторанга керсәң — ул, урамга чыксаң — ул. Әйтерсең лә, бар дөнья үзенең беренче мәхәббәте белән яшәде. Күпме генә, кайда гына яңгырамасын, җыр ялыктырмады, туйдырмады. Бу могҗизалы җыр бүген сәхнәгә менгән яшь җырчыларның да репертуарын бизәрлек. Киләчәктә ул, әлбәттә, үзенең яңа З. Басыйрова, Н. Теркулова, Р. Рәхимкуловларын табачак.

Гадәттә, радио-телевидение тирәсендә эшләүче шагыйрь-шәгарәнең, атнага ук булмаса да, айга берничә яңа җыры яңгырап тора. Бу басымчалык туктаусыз дәвам итә. Әхмәт ярты гомерен шул сферада эшләсә дә, бу яктан чиста булды.

Шагыйрьнең халык хәтерендә уелып калган җырлары байтак. «Язгы гөлем», «Зәңгәр күлмәк», «Әле кичә генә», «Җырым белән эзләп табармын», «Ашкынулы яз», «Тәрәзәләр язга елмая» һ. б. Әмма «Беренче мәхәббәт», барыбер, беренче мәхәббәт инде.

* * *

Әхмәт Рәшит балачагыннан ук хакыйкать эзләп юлга кузгалган зат.

10—11 яшендә үк ул, сугыш калдырган ятимнәрне кайгыртуын сорап, Сталинга хат яза.

Студент дәверендә, әле Җәлилнең беренче шигырьләре басыла башлагач, шагыйрьгә Герой исеме бирелсә, хакыйкать тантана итәр иде, дип Хрущевка хат юллыйлар. Халыктан шул хат астына Әхмәт меңләгән имзалар җыя. Димәк, әгәр бүген — шагыйребез Муса Җәлил Герой исемендә икән, бирелә шагыйрь Әхмәт Рәшитнең дә өлеше бар. Елмаймагыз! Елмаймагыз! Хакыйкать эзләп юлга чыккан Әхмәт ул!

Хәтерем ялгышмаса, җитмешенче елларда булса кирәк, СССРда милли сәясәтне юлга салуны үтенеп Брежневка да мөрәҗәгать иткән Әхмәт ул!

«И шагыйрьлек!.. И сабыйлык!.. И Әхмәтлек!..»— дияр идем. Бөтен яшәеше белән әнә шундый ул. Алтыдагы — алтмышта. Шагыйрь алтмышка якынлашканда да хаклык эзләүдән туктамады. Тапты ул аны. Чынлап тапты. Ышанмасагыз, аның соңгы поэма-өчлеген укып карагыз. «Колшәриф», «Сөембикә», «Мөхәммәдъяр»... Хаклык — халкының тарихында исән. Хаклык — халкының көрәшендә. Дини (Колшәриф), сәяси («Сөембикә), әдәби-мәдәни (Мөхәммәдъяр) куәтен саклап корбан булган бөек шәхесләр көрәшендә.

Хаклык эзләүдән туктама, Әхмәт туган!

Остазыбыз Туфан әйтмешли:

> Иң ихлас иҗат, иң зур иҗат
> Алтмышлардан узгач башлана.

**Мөдәррис ӘГЪЛӘМ**
1995, 10 декабрь



# Әхмәт Рәшит

## Карлар ява

Тәңкә-тәңкә карлар яуган кичтә
Яңа елны каршылаган истә;
Син ап-актан киенгәнгә мәллә
Чумган иде дөнья ап-ак төскә.

Чыршыбызга хәтта аклык иңде,
Табын төрләрендә шатлык иде,
Без биедек икәү ул чагында
Бөтерелеп моңнар кочагында.

Телләргә тик татлы сүзләр килде,
Иреннәрдә тик елмаю иде,
Онытылмаска күңелләргә сеңде
Шул кичәнең матур истәлеге.

...Бер ел гомер кичкән — ядкарь исән,—
Ак тылсымлы кичә чыкмый истән;
Тик нигә соң кабат сагыш җанда,
Сүнү белмәс утлар яна анда...
Күр, уйларга безне сала-сала,
Тагын... былтыргыча карлар ява.

## Бәхетсезләрне кызганып...

Бу дөньяда иң бәхетсез җаннар —
Тоткын, әсир вә кол җаннардыр;
Эчләрендә күпме адәмнәрнең
Дөрли-дөрли утлар янадыр.

Күкне иңләп оча азат кошлар,
Черки булып черки — иректә.
Ә адәмнәр ник соң газап чигә,
Ходай яшәр гомер биреп тә.

Чәнечкеле тимер чыбыкларга
Җил кагылып моңнар тарата;
Өзеләдер лә һай үзәкләре,
Ерак йолдызларга карап та.

И бу дөнья, ник ул тәмуг кебек
Тоткыннарга, әсир-колларга?!
Елмаерга туган мескеннәргә
Туры килә үксеп еларга.

Иртән торсам, ихлас күңелемнән
Дога кылам сөенеп көн саен:
— Яраткансың мине азат итеп —
Мең-мең рәхмәт сиңа, ходаем!

## Таптыңмы?..

*Россия шовинистларына*

И ватансыз кавем, әрсез кавем,
Җанда яман уйлар уятып,
Кая барып бәрелергә белми,
Йөгерәсең дөнья буйлатып.

Варяглардан грекларга барган
Олы юлда талап йөрсәң дә,
Византия таҗын кимәкчесең,
Шөкер итми башың исәнгә.

Дәгъва итеп Тмутораканьга,
Скиф курганнарын актарып,
Өлешенә кереп башкаларның,
Язмакчысың үзеңә ак тарих.

Оныклары бүген Урартуның —
Кавказ җире «тырный эчеңне»;
Акылын җуйган илсез илбасарлар
Кол итмәкче горур чеченны.

Җитмәгәнме яулап алганнарың?!
Җитмәгәнме талап җыйганың?!
Килер бер көн... тотмас дисең мәллә
Күз яшьләре ярты җиһанның?!

Белми дисең мәллә Хак тәгалә
Һәрбер гамәл, һәрбер актыңны?!
«Бәхет эзләп» җир читенә чаптың —
Бәхетеңне әмма... таптыңмы?!

## Рәшит Әхмәтҗан истәлегенә мәрсия

Язлар килә... кабат язлар килә...
Зәңгәрләнә бара аяз күк...
Бар тарафны назлап кояш көлә —
Дөнья матур... бары Рәшит юк.

Мәйданнарда кайнар чакырулар —
Йөрәкләрдә, димәк, сүнми ут;
Татар өчен мөстәкыйльлек даулап
Көрәш дәвам итә... Рәшит юк.

Шигарь булып яңгыраса шигырь,
Күңел таша, шаша шактый ук;
Илдә сирәк кунак — шатлык та бар,
Тик сөенеп булмый — Рәшит юк.

## Нәрсә булды миңа

Күзләремә никтер йокы керми —
Хәлләремне белеп тора тик ай;
Нәрсә булды миңа, нәрсә булды —
Ахрысы мин гашыйк булдым бугай.

Ай мөлдерәп карый күзләремә —
Күңелемдә сәер моңнар тулы:
Көләсе дә килә, елыйсы да —
Нәрсә булды миңа, нәрсә булды?

Беренче кат бит бу барысы да,
Ничек аңлыйм соң мин бөтен серен;
Ничәнче көн инде мин дөньяда
Әллә нинди уйлар белән йөрим.

Тик ул дәшсен генә, мин сүземне
Күз карашым белән аңлатырмын.
Ай да әйтер аңа уйларымны —
Яратырмын кебек, яратырмын.

## Ходай ярлыкасын...

...Әхлак читәннәрен урый-урый,
Күз төштеме бирәр матурга,
Иблис белән икәү култыклашып,
Йөргәләдек гыйшык сатырга.

И урланган бәхет — татлы җиңү.
Ә соңыннан... яну кирәктә
Пүртәнкәңне киптерерлек кенә
Мескен бер ут пыскый йөрәктә.

Цезарь хатыны да гыйффәтлеккә —
Беләсез бит! — дәгъва итмәгән.
Байлык һәм дан — һәммә нәрсә булган,
Тик барыбер... нидер җитмәгән.

Баш очында кояш елмайсын да,
Тәннәрдән дәрт ташып торсын да,
Кыен үтеп китү кызыкмыйча
Таза бәдән, зифа буй-сынга.

Патшаларны хәтта сугыштырып
Һәм мәхәббәт татып законсыз,
Күпме фаҗигага сәбәп булган
Гайрәтле ир, назлы хатын-кыз.

Югыйсә бит бу дөньяда бары
Пар аккоштан үрнәк аласы...
Гөнаһларны ходай ярлыкасын —
Без бит фәкать Адәм баласы.

Оҗмахлардан куып чыгарылган
Атам Адәм, анам Һава да;
Бер алманың серен белгән өчен
Дучар ителгәннәр җәзага.

Ә безгә соң... безгә ни эшләргә —
Яшәүнең бит бар үз кануны;
Адәм гөнаһлары — мирас икән,
Кирәк бары шуны тануың.

Гөнаһларны юып булмасмыни,
Ходай каршысына барып та...
Без, кешелек яралганнан бирле,
Ялварабыз:
— Үзең ярлыка!

## Ялгызлык

*Эчеңдә нәрсә янганын үзең бел,*
*Үзең кайгыр, үзең егъла, үзең көл.*
Г. Тукай

Бу дөньяда гел ялгыз мин —
Чүлдә адашкан сыман;
Эчемдә бер өн... туктаусыз
Кабатлый: «Сынам... сынам...»

Сынарга минем хакым юк,
Ничекләр сынамасын,
Якын дип йөргән кешеләр
Ничекләр кыйнамасын.

Ышанып ихлас дуслыкка,
Бушатсам күңелдәген,
Башыма төшә таш булып,
Китереп моңлы чагын.

Югыйсә минме язмышка
Баш игән, җайга торган?!
Озатты юлга олуг уй,
Ышанып ныклыгыма.

Җандагы хәтәр авазга —
Әүвәлге хәлгә кайтып —
Пышылдап кына эндәшәм,
Сынма, дип, сынатма, дип.

Пышылдыйм... ишетмәсеннәр
Җанымның йомшак чагын.
Сынаулар булыр — сер бирмә,
Биектә канат кагын.

* * *

Үзгәрә дөнья, диләр дә...
Үзгәрми әле бик үк...
Бүгене кичә кебек тә,
Иртәсе бүген кебек.

Сукрана-сукрана кеше
Гел дөнья куа тора.
Бер яман үлсә, урынына
Яңасы туа тора.

# МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘРЕМ

Әле күптән түгел генә арабыздан киткән мәшһүр язучыбыз Мөхәммәт Мәһдиев турында соңгы вакытларда инде күп язылды. Табигый ки, беренче чиратта аларда әдәбиятыбызның зур югалтуына офтану, зур язучыбызны сагынып әрнү, аны юксыну хисләре булды. Мин дә бу язмаларымда күренекле якташым турында кайбер истәлекләрем белән уртаклашмакчы булам.

1948 елда безнең Сеже мәктәбенә яңа өлкән пионервожатый килде. Озын торыклы, чандыр гәүдәле, зур башлы, күрер күзгә килбәтсезрәк яшүсмер. Үзенә курач гимнастерка өстеннән муенына ике аерчалы кызыл галстук асып йөргән «ата пионерга» без — яңа гына комсомолга кабул ителгән сигезенче класс малайлары — өстәнрәк, кәперәеп, масаеп карыйбыз: «Һи, ир заты эше булдымы инде вожатый булып селкенеп йөрү. Безнең мәктәптә элек-электән пионерлар белән хатын-кызлар кайнаша иде.

Пионерларның яңа командиры Мөхәммәт исемле икән, фамилиясе — Мәһдиев. Эшлекле, тынгысыз булып чыкты вожатый егет: иртәдән кичкә кадәр укучылар белән була, озын тәнәфесләрдә мәктәпнең зал-коридорында төрле уеннар оештыра, тәртип бозучыларны шелтәли, хәтта безгә — югары класс укучыларына, комсомол кешеләргә! — искәртү ясарга җөрьәт итә!

Мәһдиев мәктәптә стена газитен чыгаруны җайга салды, аның өстенә ул тагы «Яшен» дип аталган листовка чыгара башлады. Атна саен яңарып торган «Яшен» укуда ялкауларны, тәртип бозучыларны, усал хулиганнарны рәхимсез көйдерә башлады. Өлкән пионервожатый листовкага мәкаләләрне үзе яза, рәсемнәрен дә үзе ясый икән. Андагы үткен тел, юмор-сатира белән язылган тәнкыйть-парчаларны мәктәп балалары гына түгел, укытучылар да яратып, елмаеп-көлеп укыйлар иде.

Мин классташларым Мидхәт, Гата исемле малайлар белән мәктәпкә күрше Мөрәле авылыннан йөри идем. Без еш кына беренче дәрескә соңга калабыз. Шулай бер көнне мәктәпкә беренче дәрес бетәр алдыннан гына килеп кердек. Кыңгырау шалтырады, хәзер класслардан укытучылар чыга башлар. Алар күзенә чалынмас өчен без коридорда торган шкаф эченә чумдык (анда мәктәп җыештыручылар чиләк-себеркеләрен тоталар иде). Безнең класстан биек үкчәле түфлиләрендә кәс-кәс атлап шәһәр кызы, урыс теле укытучысының чыгып китүе булды, өчебез берьюлы шкафтан атылып чыгып класска ташландык. «Аһ, бәла, безне казый күргән имеш!» — Мәһдиев карап калган икән!

Икенче көнне мәктәпкә килсәк, залда бер көтү малайлар-кызлар этенә-төртенә «Яшен»не укып торалар. Безне күреп алгач: «Әнә, әкияттәге өч баһадир килә», — дип, кычкырып көлә башладылар. Мәһдиев «Яшен»дә безне суктырган икән, мәкаләсен «Әкияттәге өч баһадир» дип исемләгән, үзебезгә охшатырга тырышып рәсемнәребезне дә ясап куйган: ишекләре каерылып калган шкафтан өч гайрәтле малай атылып чыгып классларына ташлана, идәндә аунап чиләкләр, себеркеләр кала.

Без бик гарьләндек, әлбәттә. Бигрәк тә Мидхәт чәпчеде (болай да буйга тәбәнәк малай листовкада юан, карсак юлбасар рәвешле сурәтләнгән иде): «Яшь комсомолецларны болай мәсхәрә итәргә ни хакы бар аның?!» һәм шул ук Мидхәт тотты да Мәһдиевне авылына кайтканда сагалап торып, эт итеп кыйнап ташларга, дигән тәкъдим кертте. Мөхәммәтнең Гөберчәк малае икәнлеге, өйләренә кайтканда Мөрәле аркылы йөргәнлеге безгә билгеле иде инде.

Карсак Мидхәтнең мәкерле планын тормышка ашыруга һич кенә җай чыкмады, шулай уку елы да узып китте. Без икенче көздә 9 класска укырга килгәндә пионервожатый Мәһдиев мәктәптә юк иде инде, ул кайсыдыр авылга укытучы булып киткән икән.

Сәләт дигән нәрсә кешедә тумыштан буладыр, ягъни ул — Алла бүләге, Шәхеснең бер сыйфаты, потенциаль мөмкинлеге буларак, аның кайчан булса да шытып, ачылып китүе кешенең үзенә, тормыш шартларына бәйледер. Меңнәрнең сөекле язучысы, күренекле әдәбият галиме, студентларының абруйлы остазы булып җитлеккән Мөхәммәт Мәһдиевнең дә Ходай биргән күпкырлы, сокангыч сәләте Сеҗе мәктәбендә ачылмадымы икән?

Без Мөхәммәт Мәһдиев белән алтмышынчы еллар башында, янадан очраштык, бу юлы инде Казан университеты китапханәсенең фәнни хезмәткәрләр, аспирантлар залында. Мин аны таныдым, өстәле каршына килеп кулымны суздым: «Исәнмесез, өлкән пионервожатый Мәһдиев иптәш!» Мөхәммәт торып басты, аның кыяфәтенә кызыксыну, сорау галәмәтләре чыкты: «Гафу итегез,— диде ул,— төсмерлим, ләкин кем икәнегезне өзеп кенә әйтә алмыйм»...

Без коридорга чыктык. Сүзне янә мин башладым: «Хәтерлисезме, Сеҗе мәктәбен, «Яшен» листовкасын?! Бер вакыт анда сурәтләнгән «Әкияттәге өч баһадир»ның берсе мин булам инде — Тәбриз Мөбарәков»... Аңыша башлап, «өлкән пионервожатый» елмаеп тынлап торды, вакыйганы вагы-төяге белән, сөйләп биргәч, башын артка ташлап шаркылдап көлде. Минем каршымда инде теге чактагы чандыр яшүсмер малай түгел, яше утыздан ашкан, буе уртачадан калку, таза гәүдәле ир-егет басып тора. Болын хәтле киң, биек маңгай, аз гына кылычлырак борын, мул гына авыз. Кара, калын чәчләре артка таралган...

Без сөйләшеп киттек. Авылда туып үскән кешеләргә хас булганча, әңгәмәбез ихлас, эчкерсез булды. Мөхәммәт, Сеҗедән киткәч, Керәнле мәктәбендә тарих укыткан. Дүрт ел флотта хезмәт иткән, аннан кайткач тагын мәктәптә эшли башлаган. Читтән торып укып Казан педагогия институтының тарих-филология факультетын тәмамлаган. Соңгы елларда Арча районының Казанбаш мәктәбендә эшләгән. Өйләнгән, бер кызы бар. Үзе хәзер университетта аспирантурада укый, татар филологиясе буенча белемен күтәрә икән. Әнисе әлегә Гөберчәктә яшәп тора икән. Үз чиратымда мин дә бүгенгәчә булган хәл-әхвәлемне сөйләп бирдем: Казан университетын тәмамлагач, ерак көньяк Сахалин пединститутында берничә ел математика укыттым, «материкка» кайткач, университетның математик анализ кафедрасында аспирантурада укыдым, хәзер кандидатлык диссертациясе өстендә тир түгәм, эшләвем Алабуга пединститутында, янәсе.

Яше белән Мөхәммәт миннән өлкәнрәк булса да, без кордашлар-чордашлар идек. Биографиябездә, тормыш юлыбызда нindидер уртаклыклар, охшашлыклар булганы ачыкланды. Аяныч ки, Мөхәммәт белән без икебез дә — «халык дошманы балалары», һәр төрле кыерсытуларга, кимсетүләргә дучар булып үскәнбез икән. Минем әтиемне 37 елда алып китеп юк иттеләр. Мөхәммәтнең әтисе, зур укымышлы, акыллы, дөньяви вәгазьләре белән Гөберчәк мәхәлләсендә генә түгел, бөтен тирә-якта дан тоткан Сөнгатулла мулла, шул ук елда Сталин төрмәләрендә каза тапкан. Дөньяның кая таба барганын чамалаган зирәк хәзрәт, муллалыгын ташлап, үзенең ишле гаиләсен инде күп еллар хәләл игенче хезмәте белән туендырып торган, югыйсә. «Халык дошманы хатыны» булып калган аналарыбызның сәвит хакимнәре тарафыннан каһәрләнеп, җәберләнеп, кан-яшь түгеп яшәгәннәрен күреп торып, безнең дә яшь җаннарыбыз газапланган, үрсәләнгән икән.

Мунчадай кечкенә җир идәнле, салам түбәле өйдә тереклек итеп яткан, аты-сыеры түгел, саварга кәҗәсе булмаган хәерчеләр, илдә сәвитләр власте урнашкач, авылларда колхозлар оешкач, сәнәктән көрәк булып китеп, һәртөрле хакимият башына утырып алырга өлгерештеләр. Надан, хөсетле әтрәк-әләмнең бүресе улады — ниһаять, дөнья алар кулында! Һәм бу үчле, көнчел кавем утызынчы елларда ил өстенә кара афәт булып иңгән җинаятьчел сәясәтне үткәрүдә беренчеләрдән булдылар. Бер гаепсез әтиләребезне дә авылның шундый томана, йолкыш куштаннары чаккан икән, без ул бәндәләрнең кемнәр икәнен дә беләбез булып чыкты...

Мөхәммәт белән минем арада дустанә мөгаләмә урнашты. Без көн саен диярлек уку залында очрашабыз, бергә ашханәгә йөрибез. Мин ул яшәгән тулай торакта булгалыйм, ул минем фатирыма килгәләп йөри. Галимнәр йортында

уздырылган кичәләргә йөрештерәбез, билет юнәтә алсак, мәшһүр Илһам Шакиров концертларын тыңлыйбыз, шундый талантлы җырчы биргән милләтебез өчен горурланабыз.

Без икебез дә — бик яшьли тормышның ачысын-төчесен татып үскән кешеләр, азмы-күпме ил-җир күргән кешеләр, дөньядагы һәр нәрсәгә инде үзебезнең анык карашыбыз бар, дип санаган беркатлы адәмнәр, бер-беребезне тапканга, заманы өчен шактый кыю, көфер уй-фикерләребезне яшермичә сөйләшә алуыбызга куанып бетә алмый идек шикелле.

Ул чакларда әле ил башында энергиясе кайнап торган, булганны бик тиз җимереп ташларга сәләтле, мактанчык Н. Хрущев тора иде. Ун ел хакимлек иткән дәверендә, кабинетына кереп дәүләт эшләре белән шөгыльләнергә ун көн дә вакыт тапмаган генсек, туган-тумачалары, иярченнәре белән самолетларга, диңгез лайнерларына төялеп, халык чутыннан кәеф-сафа корып, ил, дөнья гизеп йөрергә хирыс җитәкче дәүләтне, халыкны тәмам бөлгенлеккә төшерде. Сугыш туктаганнан соң 15 ел вакыт узгач, азык-төлеккә янә талон системасы кертелде, бушап калган кибет киштәләре аракыдан сыгылып тора иде. Шәһәрләрдә икмәк магазиннарына ярты чакрым озынлыкта чират тезелде. Яңа хаким әдәбият, сәнгать әһелләре белән җәнҗаллашты, үзенең тыйнаксызлыгы белән халыкара җыеннарда илне хур-рисвай итте. Коммунистлар партиясенең шапырынкы планнары, нәтиҗәсез эшчәнлеге, банкрот сәясәте һәм идеологиясе әлеге төп юлбашчысы белән күзаллана, гади халыкның гына түгел, партиялеләрнең дә ачуын кабарта иде.

Без М. Мәһдиев белән менә шундый вәзгыятьтә очраштык. Белгечлеге буенча тарихчы, авылда үскән, күп еллар авыл мәктәпләрендә укыткан Мөхәммәт үзенә аеруча таныш булган колхоз тормышы турында, илнең, дәүләтнең терәге булган колхозчы игенчеләрнең ярым ач, ярым ялангач яшәп, борынгы Рим колларыннан да битәр җәфа чигеп, мәҗбүри хезмәт итүләре турында ачынып сөйли иде. Илебездә күкләргә чөеп макталган социалистик строй һәм... коллык! Бу хурлыклы хәлләр турында без, әлбәттә, икәүдән-икәү генә, як-ягыбызга каранып, шыпырт кына сөйләшә идек. Совет кешеләренә Иблис токымы Сталин иңдереп калган, ләгънәт төшкән курку хисе безнең дә бөерләребездә утыра иде. Хрущев заманында көннәр бераз «җылынып» җибәрсә дә, аның опричниклары тагы да узына төште шикелле. Ил, халык алдында абруен югалткан хуҗа КГБның тагы да көчәюенә мохтаҗ булгандыр, күрәсең.

Безнең телебездә гел сәясәт кенә түгел иде, әлбәттә. Тормышта үзебез күргән-күзәткән кызыклы вакыйгалар, көлкеле маҗаралар, мөмтаз уртак танышларыбыз һәм, ниһаять, мәзәкләр — болар барысы да безнең тел азыгы була иде. Мөхәммәт сөйләргә ярата һәм яратып сөйли иде. Ул затлы башын бераз артка таба чөяр, очкынланып торган коңгырт-кара күзләрен тыңлаучысына төбәр дә, беткәнче аны сүз тылсымында тотар. Сөйләме җанлы, егәрле, җөмләләре төзек, тулы булыр — иясе дә, хәбәре дә үз урыннарында. Хикәячене битараф тыңлый алмыйсың — аның күзләрендә, йөзендә, бөтен кыяфәтендә бәян иткән вакыйгаларына үзенең мөнәсәбәте чагыла. Һәм син бөтен асылың белән ишеткәннәрең шаукымында — елмаясың, көләсең, нәфрәтләнәсең... Әйе, Мөхәммәт Мәһдиев сөйләү сәнгатенә оста, аның «сөйләмият парчалары» хикәя-шедевр итеп кабул ителә иде. Мөхәммәткә бераз артистлык та хас иде. Шулай булмыйча соң, ул бит ун елга якын мәктәптә укыткан кеше. Берничә ел аның белән бергә эшләгән апамның сөйләве буенча, тарих укытучысы Мәһдиев үзенең укучыларын авызына каратып тотып, аларга төрле илләр, халыклар турында мавыктыргыч дәресләр биргән, укыту эшләре буенча җитәкче булапак, еш кына: «Укытучы күпмедер дәрәҗәдә артист та булырга тиеш»,— дип кабатларга яраткан.

Моннан берничә еллар элегрәк «Казан утлары» журналында чыккан мәкаләсендә бер абруйлы гына әдибебез: «Мәһдиев — кыланчык» дигәнрәк мәгънәдә әйтеп узган иде. Автор бәлки Мөхәммәтнең сөйләгәндә артистларча «кыланмышын» күздә тоткандыр, бу сыйфатлары аңа ошап бетмәгәндер. Һәрхәлдә, язучының шәхесен өнәмичәрәк язылган бу сүзләр, белгәнемчә, матбугатта беренче мәртәбә күренде һәм, иншалла, соңгысы булыр, бәлкем.

...Әниләребезнең хәлен белеп килергә кайчакларда без юлга бергә чыгабыз. Курса станциясында поездан төшеп калгач, очланмаган сүзебезне тәмам итәр өчен, җәяү кайтыр юлыбызны озайтабыз: ике юл чатына җиткәч, һәркем турыга, үз авылына кайтып китмичә, йә Мөхәммәт Мәрәле аркылы әйләнеп кайта, йә мин — Гөберчәк аша (ярый әле авылларыбызның арасы өч чакрымлап кына).

Без бер-беребезгә кунакка да йөрешә идек. Шулай бер җылы, матур август кичендә Гөберчәккә барып чыктым. Мөхәммәтләрнең җыйнак кына йорты урамнан шактый эчкәре, тирәли агачлар үскән ишек алдында. Өй эчендә чисталык, пөхтәлек. Әнисе Рабига абыстай тормыш авырлыкларыннан сыгылмаган, горур кыяфәтле, сабыр холыклы, мөлаем карчык иде. Аеруча җылы, йомшак итеп әйткән «әни» сүзендә улының анасына булган зур хөрмәте, аны олылавы, яратуы сизелеп тора иде.

Без кичке аштан соң утын лапасында төнозын яшел борчак кузагы ярып, иртән кояш чыкканчы сөйләшеп утырдык. Шулчак, Мөхәммәт көтмәгәндә, бик җитди әйтеп куйды: «Тәбриз, мин авылларда мәчетләр торгызылып, манараларыннан мәхәллә халкын иртәнге намазга чакырып мөәзиннәрнең азан әйтер чаклар, Май, Октябрь тантаналары шикелле, мөселманнарның да Ураза, Корбан гаетләрен ачыктан-ачык бәйрәм итәр вакытлар килер әле, дип уйлыйм, шулар турында хыялланам»,— диде. Мин бер мәлгә өнсез калдым: миңа, имансыз Советлар илендә туып үскән, мәктәпләрендә, вузларында укып инде дәһригә әйләнә язган бәндәгә, шундый ук шартларда тормыш юлы үткән, өстәвенә әле коммунистлар фиркасендә торган кеше авызыннан мондый сүзләр ишетү (60 нчы еллар башында!) бик тә сәер, хәтта хәвефле тоелды. Үзенең партиягә керүен дә Мөхәммәт, бик күпләр шикелле: «Дөньясы шулай ие»,— дип кенә аңлатмады. Бу адымын ул флотта хезмәт иткән чагында, озак, газаплы икеләнүләреннән соң гына, вөҗданына хилафлык кылып ясаган. «Мин тормышка җайланучы да, карьерист да түгел. Партиягә керүемнең сәбәпләреннән берсе — фиркасезләр өчен ябык җыелышларда партия әгъзасы исемен күтәреп йөрергә лаек булмаган бәндәләр кайчан да булса минем исемемне төрләндерүләрен теләмәдем. Гаебем бар икән, сөйләшүләре, сүгүләре ачыктан-ачык, үз алдымда булсын!»

Әйе, мин аны аңладым. Ул үзенең киләчәген алдан ук күргән, аңа үзен хәзерләргә мәҗбүр булгандыр. М. Мәһдиев — тарихчы, димәк, коммунистлар жаргонында әйткәндә — идеология фронты солдаты — мәктәптә завуч. Компартиянең уставына язылмаган, ләкин мәҗбүри үтәлергә тиешле бер шарт бар: җитәкче кадрларның мотлак партия члены булуы таләп ителә. Өч класс белемле миңгерәү дә министр булып утыра ала, коммунист кына булсын! Идеология хезмәткәрләре турында әйтеп тә торасы юк инде. Киресенчә, партиясез кеше җитәкче урында эшли башладымы, аны икенче көнне үк партиягә димли башлыйлар.

Үземнең баштан үткәнне искә алыйм әле. Диссертациямне яклап кайткач, мине Алабуга пединститутының физмат факультеты деканы итеп билгеләделәр. Күп тә үтмәде, яңа гына табадан төшкән деканны парткомга чакыртып алдылар. Анда мине партбюро әгъзасы көтә икән, элек райкомның беренче секретаре булып эшләгән кеше, үзеннән түбәнрәкләр белән өстәл төеп кенә сөйләшкән адәм. Вакытында дәүләт салымнарын түләп өлгермәгән колхоз рәисләрен, хөрмәткә ия, олпат агайларны, тәмам йөгәненнән ычкынган ошбу самодур үз кабинетының почмагында бастырып тотып җазаларга яраткан. Диктаторча кыланмышларына түзәр хәле калмагач, обком аны эшеннән куган, шул ук обком таләбе буенча институтка эшкә урнаштырылган бәндә, менә шул «иптәш» каршы алды мине парткомда, «Тәбриз Мөбарәкович»,— диде бюро әгъзасы.— Сез хәзер номенклатурный работник булдыгыз, димәк, партиягә керергә тиешсез. Әзерләнегез, мин сезгә рекомендация бирермен». «Рәхмәт,— дидем мин,— Сезгә мәшәкатьләнергә туры килмәс, мин беркая да керергә җыенмыйм, теләмим дә. Сезнең партиягезгә күптән халыкның ышанычы, иманы бетте, шул җөмләдән, минем дә. Сәбәпләре санап бетергесез, аларны Сез миңа караганда да шәбрәк беләсездер»...

Димчемнең башына күсәк белән ордылармыни! — аның күзләре йомылып-ды, йөзе агарынды-күгәрде, тыны кысылды. Йөгереп барып ишекне бикләп алгач, курыккан-каушаган «бывший первый» каршыма килеп басты, буылып-ыслап мине акылга утырта башлады: «Товарищ Мубараков! Бу антипартийный сүзләрне бүтән җирдә сөйли күрмәгез, башыгызны бетерерләр, точно! Мондый настроениеләр белән факультет башында... Ярар инде, мин бер юлга... Аннан соң...»

Үзе шикелле үк тупас, мин-минлекле, туңбаш малае миндә укый иде, тиздән экзаменнары. Югыйсә, әти кеше үзе үк «башымны бетерер» иде. Бу фанатик коммунисттан институтның күп мөхтәрәм кешеләре җәфа күрде. Алланың дәргаһыннан сөрелгән бу адәм һәрчак кешеләргә җәбер-золым кылып яшәде.

Дөресен әйтергә кирәк, боргаланмый-сыргаланмый гына үз фикеремне әйтеп сала торган гадәтемнән бу тормышта бәлага торган чакларым күп булды минем. Ул җәһәттән Мөхәммәт акыллырак иде — беркайчан да кызып китмәде, чәпчемәде, төптән уйлап эш итте, мәгәр үз принципларыннан тайпылмады. Шуны хәтерлим: 1988 елның җәендә Казанга кайткач Мөхәммәтнең өенә шалтыраттым, телефонны алучы булмагач, аны эзләп университетка киттем. Ул утырышта, диделәр. Килгәнемне ишеттергәч, Мөхәммәт коридорга чыкты, без шатланышып күрештек. Анда татар теле, татар әдәбияты кафедраларының берләштерелгән җыелышы бара икән, Мәһдиевнең элеккеге фәнни җитәкчесе булган пенсионер профессорның юбилеена туры китеребрәк җыелышканнар икән. Утырышларының эшлекле өлеше беткәч, юбилярны котлау тантанасына Мөхәммәт калмады. «Әйдә, Тәбриз, киттек,— диде ул,— күңелем, җаным тартмаган нәрсәне эшли алмыйм»...

Профессор белән аның шәкерте арасында соңгы вакытта киеренке мөнәсәбәт урнашканы миңа мәгълүм иде. Мәһдиевнең дуслары сөйләве буенча, бар нәрсәне үзенчә, яңача күрергә сәләтле яшь галимнең һәм картая төшкән шефның тормышка, фәнгә карашлары бик тә үзгә булып чыккан. Инде дәрманын җуя барган һәм агым уңаена агуны кулаерак күргән җитәкче кеше, кирәкле урыннарга барып, шәкертенең докторлык диссертациясе нигезләрен тәшкил итәчәк китабын бастырмауга (!) ирешкән. Әлбәттә, профессорның мондый «ярдәмен» М. Мәһдиев «кабул итә» дә, гафу итә дә алмаган. Шундый-шундый хәлләрдән соң ничек итеп «шеф»ның юбилеенда утырмак кирәк!

Мин алдарак Мөхәммәтнең татар авылларында мәчетләр торгызылып, авылларга янә иман нуры иңүенә инанганын язган идем. Бу аның юравы гына түгел, ә нииндидер илаһи эчке сиземләү белән әйткән сүзләре булгандыр. Һәртөрле революциянең иң әүвәл халык аңын әзерләүдән башланганы мәгълүм. М. Мәһдиев тә ерактан башлады. Вакытын, көчен кызганмыйча, архивларда утырып, элеккеге мәдрәсәләрнең тарихын, алардагы уку-укыту программаларын җентекләп өйрәнде, мәдрәсә бетереп чыккан шәкертләрнең тормыш юлларын барлады, шулар турында хәзер инде бөтен ислам дөньясына диярлек билгеле булган зур күләмле әсәрен язды. Юк, мәдрәсәләрнең барысы да реакцион учак булмаган, аларның күбесендә дини сабаклар белән янәшә, шактый киң программа нигезендә дөньяви фәннәр дә укытылган. Мәдрәсә тәмамлаган шәкертләр арасыннан исемнәре тарихка кереп калган, төрки дөньяга билгеле булган мәгърифәтчеләр, галимнәр, дин әһелләре, шагыйрьләр, язучылар, дәүләт эшлеклеләре, хәрбиләр, хәтта социал-революционерлар да чыккан икән. Алтмышынчы еллар азагында болар турында язып чыгу «баш бетерерлек» эш булмаса да, кыюлык, тәвәккәллек таләп итә иде. Әлбәттә, М. Мәһдиев җәзасын алды — иҗат кешесе, язучы өчен иң рәхимсез җәза бирделәр аңа — язганнарын иркенләп нәшер итү хокукыннан мәхрүм иттеләр! Газета-журналларда исеме күренми башлагач, мин аңа Алабугадан хат язып җибәрдем: «Бу араларда нигә күзгә-башка күренмисең?» Озак көттермичә аннан җавап килде: «Мәдрәсәләр белән яндым»... Аның «янды»сы ике-өч елга сузылды! Соңрак, бер очрашканда ачынып әйтте: «Һай, йөрәкләремә төште обком, анда главлит булып утырган Шакирҗанова дигән хатын бигрәк тә... Җанымны талаган нәрсәләр турында язып бастырыр чаклар килер микән?!.»

Мөхәммәт Мәһдиев ни күрсә күрде, әмма коточкыч 37 нче еллардан соң беренчеләрдән булып, дини мәдрәсәләрне аклап, аларны яклап чыкты, илдәге мөселман, шул җөмләдән татар җәмгыятьчелеге алдында аларның абруен күтәрде. Һәм, моны үзе телиме-теләмиме, ул, соңгы елларда татар илендә бик күркәм башланып киткән рухи яңарышның чишмә башында торган шәхес булды, дисәм, ялгышмыймдыр.

Мин Алабугадан еш кына кайтып йөрдем. Вакыты булганда мине озатырга аэропортка Мөхәммәт тә килә иде. Безгә кечкенә самолетлар гына оча, һавалар начарланып китсә, очулар тоткарлана, икенче көнгә кичектерелгән чаклары да була иде. Бервакыт шулай озатучым белән аэропортта төнката сөйләшеп утырганыбызны хәтерлим. Бу хәл студентлар тулай торагында яшәп яткан аспирант Мәһдиевнең әле беркемгә дә диярлек билгесез чагында булды. Әмма мондый хәлләр ул инде күренекле язучы булып танылгач та булгалаган икән. Алабуга пединститутының элеккеге ректоры Тәлгат Галиуллин да, аэропортта һава ачылганын көтеп, аны озата килгән Мөхәммәт Мәһдиев белән төн уздыруларын сөйләгән иде. Хәзер мин болар турында уйлыйм да, мәрхүм күңеленә хуш килгән, фикердәш булырдай, сер сыярдай кешеләргә мохтаҗ булгандыр,

андыйларга юлыкса, туйганчы сөйләшеп калырга омтылгандыр, дип фараз кылам. Ә Т. Галиуллин Казанга кайтып эшли башлагач, Мөхәммәтнең соңгы көненәчә алар дус булып калдылар.

Безнең гәп сукканда хәлебездән килгәнчә, аз-маз «кәефләнеп» утырган чакларыбыз да булгалады, әмма табындашым Мөхәммәт хәмергә ваемсыз иде. Мин аның бервакытта да теле көрмәкләнгәнче эчкәнен, өстәл артыннан торгач, кыек-мыек атлап киткәнен хәтерләмим. Бервакыт шулай, аның бу «начар гадәте» турында әйткәч, ул авызын ерып елмайды да, шукланып: «Ә Бәшир бабам минем бу гадәтемне күп матур сыйфатларымның иң асылыннан саный!» — диде.

«Татарның кайбер күренекле романнарын мин урысча да укып карарга яратам, кызыксынып, ничегрәк «яңгыраганнарын ишетү» өчен. Оригиналга житәме соң инде! Тәржемәче никадәрле тәҗрибәле булмасын, кыр, болын чәчәкләре бәйләме урынына урыс укучысына кәгазь чәчәкләр букеты тоттыра. Милләтебезнең җанын, рухын, моңын, телебезнең аһәңен тәржемә кылу мөмкин түгелдер шул.

Тәржемәчегә ике телне дә бик шәп белү генә җитми әле, ул һәр ике милләтнең фикер йөртү ысулын, аң сөрешен тоярга тиеш. Кайбер очракта сүзгә-сүз тәржемә итү бөтенләй мөмкин түгел, ә мәгънәне яки фикерне шактый тәңгәл китереп әйтеп була икән. Мәсәлән, Шишковның «Угрюм-река»сы, А. Толстойның «Хождение по мукам» романнарының исемнәре үк тәржемәчене кәкере каенга терәр кебек. Ә менә Кыям Миңлебаев беренчесен «Хәсрәт дәрьясы», икенчесен «Михнәтле заманалар» дип тәржемә иткән. Какой молодец! Кыям бу романнарның татарча исеме турында бер генә көн уйламагандыр. Искитмәле табышлар! Рус әсәрләрендәге төп фикерне, идеяне саклап калып, аларга милли аһәң биреп иркле тәржемә кылу безнең Тукаебыздан килә»...

Мөхәммәтнең бу кечкенә генә лекциясе минем өчен зур ачыш булды.

Язучы үзенең повесть, романнарын тормыштан алып язды. Аларда ул зур осталык белән Арча ягы табигатен тасвирлады, җылы юмор, яратып-көлеп сурәтләнгән персонажлар, нигездә, Гөберчәк, бүтән тирә-як авыл кешеләре булды. М. Мәһдиев авылның көзге айлы кичләрен, катканак урамнарын тасвирлаганда шундый сүзләр-бизәкләр таба ки — син елның бу фасылына сокланасың, авылда туып-үсеп тә вакытында шул матурлыкларны күрә, тоя белмәвенә офтанасың. Хәтта йорт хайваннарының, кош-кортларының кичерешләрен, әйтергә ярәса, психологиясен сурәтләгәндә дә Мөхәммәт адәми затның күңеленә тиярлек итеп яза: кояшлы, каткаклы яшел уҗым басуында утлап йөргән бәхетле буаз сыерлар... Беренче кырпак төшү белән сөйгән бәбкәләрен җуйган, җанын кая куярга белмичә, очына-кагына ишек алдында бәргәләнгән, сабыйларын чакырып өзлексез кыйгаклаудан күзләре кызарган ана каз...

Юк, юк! Болай язу өчен илаһи тамгалы Мөхәммәт Мәһдиев булу кирәк, билләһи!..

1967 елда бугай, М. Мәһдиев миңа, Алабугага «Соавторга автордан» дигән бүләк язуы белән үзенең тәүге күләмле әсәрен — «Без — кырык беренче ел балалары» повестен җибәрде. Хикмәт шунда ки, башыннан ахырынача ямансу-күңелле юмор белән язылган повестьның персонажлары — «яхшы сортлы тәмәкегә» мөкиббән киткән география укытучысы, һичкайчан боекмас Әлтафи — минем иске «танышлар»: мин укыган Сеҗе мәктәбендә өзлексез «тәмәке ашаучы» ирле-хатынлы укытучылар эшләгән иде. Әлтафи исә — безнең Мөрәле шалапае. Язучы аның исемен дә үзгәртеп тормаган. Болар турында Мөхәммәткә мин сөйләгән идем. Ә нинди онытылмас образлар «койган» язучы!

Мин «Торналар төшкән җир»не дә чамалыйм — безнең авыл басулары ызандаш. «Ут чәчәге»нең кайсы болын сазында үскәне дә миңа сер түгел.

Ә «Фронтовиклар» романында сәрхүш Гатаның университетта кыланмышлары!.. Дөньяда булырдай хәлме соң бу?! Шту син, гармун уйнап, акырып җырлап, бер исерекбаш фәннәр храмын рисвай итеп йөрсен әле! Бу эпизодны каләм ияләре дә төрлечә кабул иткән икән, «Бу — җәнҗал!» — диючеләр дә булган. Язучылар җитәкчелегеннән берәү жалу белән обкомга чапкан. Анда аңа «за неслыханную дерзость нахальный Магдеевны «строго наказайт» итәргә» кушканнар...

Дөнья булгач, андый хәлләр дә була икән шул. Минем авылдашым-сабакташым, әлеге дә баягы, Гата исемле егетне, вак хулиганлык өчен бер елга утыртканнар иде. Шулай бервакыт, лекция тыңлап утырганда, университет коридорында «Арча көен» сузып җибәрмәсеннәрме! Гармунга кушылып берәү җыр-

лый: «Без бит Арча яклары...» Тавыш аудиториягә якынлашкач таныдым: Гата тавышы. Гата җырлый, мондый әкәмәтләрне ул гына булдыра ала... Мин арткы ишектән чыгып, Гата дустымны боргычлап алдым һәм без тиз генә «фәннәр храмыннан» чыгып сыздык. Тышта чатнаган суык, ә Гата яланбаш, өстендә төрмә сырмасы, кулында гармун, яхшы гына салмыш. Гата шундыйрак, чуар йөрәкле, кыланчыграк егет иде инде. Иреккә чыккач, ул бер яртыны «сындырган» да, Казанда яшәгән абыйсының гармунын асып, университетка, үзенең «корешын» күрергә килгән икән.

Авылдашымның бу әкәмәтләре турында ишеткәч, Мөхәммәт эчен тотып көлде, «әгәр рөхсәт итсәң, Гатаның бу тарихи тамашаларын берәр әсәремә кыстырам әле»,— диде. Һәм «кыстырды» да, ләкин вакыйгаларны шактый шомартып, язучы фантазиясе белән баетып. Хәтта романда Гата унай геройларның берсенә әверелгән. Ә Мөхәммәт «күпме тал чыбыгы ашады» героеның университеттагы кыланмышлары өчен.

Әйе, фәндә дә, язучы буларак та М. Мәһдиев кыю булды, тая-егыла булса да, ул үз сукмагыннан атлады, борынын кара канга батырып тукмасалар да, үҗәтләнеп үз юлыннан бара бирде.

Байтак еллар язучы фатир мохтаҗлыгы чигеп яшәде, иҗат кешесенә бик тә мөһим булган телефонлы аерым эш бүлмәсе турында хыялланды. «Шуларга ирешкәч,— диде ул бервакыт,— минем кабинетымда, йомшак кәнәфиләргә арка терәп, ат күзе кадәрле генә йомырылардан биш йолдызлы әрмәнски коньяк йоткалап, урычча шөйләшеп тәмәке тартып утырырбыз әле («урычча шөйләшеп тәмәке тарту» — Мөрәле егетләре иҗаты!). Кирәксә-кирәкмәсә дә, мин кул астында гына торган телефоннан берәр җиргә чылтыратып алырмын»...

«Телефоннан чылтырату» да Мөхәммәт керткән яңалык бугай, чынлап та, телефон шалтыр-шолтыр шалтырамый бит инде.

М. Мәһдиев әдәбиятка шактый соң килде, яше белән ул әдәбиятыбызда якты эз калдырып, вакытсыз дөнья куйган мәгълүм шагыйрьләребездән, язучыларыбыздан өлкәнрәк иде инде. Аның иҗат гомере дә кыска булды — нибары 25 ел тирәсе. Әмма шул вакыт эчендә күпме эш эшләргә өлгерде ул! Әдәбият галиме, публицист, яратып укылган дистәдән артык повесть, романнар авторы, «Халык язучысы» дигән зур дәрәҗәгә ирешү... Шулар өстенә, тагы доцент Мәһдиев 30 еллап университетта укытты, анда җәмәгать эшләрендә актив катнашты. Татар радиосы, телевидение аша бетмәс-төкәнмәс чыгышлар ясау, ниһаять, үзенең меңнәрчә укучылары белән очрашу... Татарстанда язучы Мәһдиевнең аяк басмаган төбәге калмагандыр. Клубларда, мәктәпләрдә — һәркайда ул бик яратып каршыланган кунак иде.

Искитмәле! Боларның барысына да аның ничек вакыты җитте икән?! Хәер, Мөхәммәт вакыт дигән нәрсәнең кадерен белә иде инде. Шулай бервакыт, Бауман урамындагы матбугат йортында, Фәрваз Миннуллин кабинетында сыйланып утырабыз. «Мин хәзер Маркснең «Вакыт — кешенең иң зур байлыгы» дигән афоризмын аңлый башладым»,— диде Мөхәммәт. «Таза булган кешенең»,..— дип өстәп куйды Фәрваз.

Без урамга чыккач, Мөхәммәт, соклануын яшермичә: «И дә тыйнак, и дә акыллы, порядочный егет инде,— диде үзенең дусты турында,— тик соңгы елларда бер дә тазалыкка туйганы юк...»

И язмыш, язмыш!.. Бер-берсенә бик тә игътибарлы, ихтирамлы бу ике күркәм кешенең бер ел эчендә берсе артыннан берсе якты дөньядан китеп барыр дип кемнәр уйлаган...

Мөхәммәт студентларының яраткан укытучысы иде. Аның сабагын тыңлаган шәкертләре программа кысаларына сыешып бетмәгән, тормышны, тарихны, әдәбиятны тирәнрәк аңларга өйрәткән фәһемле лекция-вәгазьләрен сагынып искә алалар. Үзендә укыган, хәзер инде танылган шагыйрь, язучы булып өлгергән шәкертләре белән Мөхәммәт горурлана иде. Иҗат юлын сайлаган өметле яшьләргә ул ихлас киңәшләре белән ярдәм иткән, үзенең бай күңел хәзинәләре белән юмарт уртаклашкан. Казаннан читтә яшәгән башлап язучыларга хәерхаһлы, шул ук вакытта бик таләпчән, кырыс хатлар язгалап торган икән. Элекке студенты, бер яшь язучыга җибәргән хатларында мин мондый юллар укыдым: «...Синең иҗатың тагын да үссен, тармаклансын иде, сиңа ходай биргән бер нәрсә бар, ул — «взлет мышления». Шәп егет син! Әдәбиятта сине зур мәйдан көтә». Аннан тагы: «Синдә видение мира» бар, син телисеңме аны, теләмисеңме, әдәбиятка киләчәксең. Мин сиңа ышанам». Шул ук «шәп егетне» икенче бер хатында остаз мондый сүзләр белән сыптырып ташлый: «Әдәбиятка яңа тема килде,

дисәм, сине алдаган, һәм, димәк, сине ихтирам итмәгән булыр идем...» «Язучы булып формалашмый торып псевдонимга ташланма. Башта танылу, аннан соң — псевдоним...»

Бу юллардан өлкән язучының татар әдәбияты, аның иртәгесе өчен борчылуы да, сәләтле яшьләр килүенә шатлануы да күренә. Шул ук вакытта ул яшьләрне үзләренә карата таләпчән булырга, әдәпкә, тыйнаклыкка өйрәтә.

«Дөньяның ачысын-төчесен татымый үскән кеше зарына, бәхетсезләрнең кайгы-хәсрәтләренә, күз яшьләренә битараф була. Андыйлардан юньле шагыйрь дә, язучы да чыга алмый». Бу бәхәслерәк фикерне (чыгармасыз, ташламасыз кагыйдә булмый) мин Мөхәммәттән ул әле «яшь язучылар» рәтендә йөргәндә үк ишеткән идем. Үзенең бу хакыйкатен Мөхәммәт бөтен иҗаты белән аклады кебек.

Чын зыялы, гали шәхесләр күп мәгънәле, күпкырлы, катлаулы булалар. М. Мәһдиевнең дә характерында миңа ачылып җитмәгән яклары булгандыр. Аннан соң заманалар, еллар, тормыш та кешене үзгәртми калмый. Эшләгән коллективында, язучылар даирәсендә ул да, аны да өнәп бетермәгән затлар булгандыр, әмма ваклар белән вакланмады Мөхәммәт, дәрәҗәлеләр алдында тәлинкә тотып үз дәрәҗәсен төшермәде, рәнҗеткәннәргә рәнҗегәнен белдермәскә дә көче җитте аның.

«Без — кырык беренче ел балалары» белән М. Мәһдиев әдәбиятыбызга балаларга хас самимилек белән килеп керде һәм бик кыска вакыт эчендә халкыбызның сөйгән язучысына әйләнде. Аны яратып укучыларның берсе буларак әйтә алам: М. Мәһдиев соңгы ике дистә ел дәверендә татарның иң яратылган язучыларыннан иде.

Алла биргән сәләте, таланты өстенә ул кеше буларак та матур шәхес иде: буе-сыны күркәм, акылы, фигыле-холкы күркәм. Гадилеге, ихласлыгы, җорлыгы белән ул меңләгән тыңлаучыларының, укучыларының күңелен яулап алды, аларның мәхәббәтен казанды.

Әйе, гали зат иде Мөхәммәт. Сөнгатулла мулла үзенең төпчек малаена юкка гына пәйгамбәребез исемен кушмагандыр. Мөхтәрәм хәзрәт үзе дә әүлиялардан булгандыр, күрәсең, улының татар милләтенә игелекле кеше булырын алдан ук белгәндер...

Мин Уфага күчеп киткәч, безнең аралашуларыбыз сирәгәя төште. Якташымны соңгы мәртәбә күрүем 1992 елның җәендә булды. Ул университетның төп бинасыннан чыгып барганда без кара-каршы булдык. Дусларча күрештек, хәл-әхвәлләребезне сорашып алдык. Һәрвакыттагыча аның вакыты санаулы иде. «Нәкъ бер сәгатьтән мин Язучылар берлегендә булырга тиеш, мөһим эшләрем, әйтәсе сүзләрем бар,— дип кулындагы күрмәшен күргән папкасына чиртеп алды.— Әйдә, Тәбриз, мине озатып куй, сөйләшә-сөйләшә җәяү генә барабыз». Без ашыкмыйча гына бардык, юлда күп сүзләр башына җителде. Хәтерлим, беренче чиратта сүзебез һәркемнең тел очында торган Татарстанның мөстәкыйльлеге турында барды. «Мин үзем митинговать итеп йөрүчеләрдән түгел,— диде юлдашым,— әмма һәртөрле үзәкләрнең, фиркаләрнең, җәмгыятьләрнең уртак кыйбласы юклыгы җаныма тия. Безнең татарда гомер-гомергә бердәмлек булмаган, шул харап иткән, шул бүгенге хәленә калдырган татарны,— диде ул, офтанып.— Болар аяк өсте генә сөйләшә торган сүзләр түгел, Тәбриз, форсат табып, бер бик иркенләп сөйләшеп утырырбыз әле»...

Тагын бер нәрсә исемдә калган: мин тәкбир сүзен урынсыз кулландым, Мөхәммәт мине төзәтте. «Ничава-а, диде ул бик татарча итеп,— син математик, сиңа бата ул, безнең «тәкбир»дән»тәгъбир»не аермаган доцент филологларыбыз да бар әле, шөкер»...

Без сөйләшеп бара-бара киракле йортка килеп тә җиткәнбез икән. «Син, Тәбриз, тиз генә китмисеңдер бит әле, әйткәнемчә, бер ашыкмыйча гына сөйләшеп утырырбыз әле, сөйләр сүзләр бик күбәйде»...

Без хушлаштык. Мөхәммәт дустанә кул изәп ишектән кереп китте. Нииндидер мәшәкатьләр чыкты, без бүтән очраша-күрешә алмадык. Тиздән мин Уфага кайтып киттем. Йа Хода! Безнең бу очрашуыбыз соңгысы булган икән!..

Мин Мөхәммәт белән соңгы мәртәбә Уфадан телефон аша сөйләштем. «Кәефләр шәптән түгел,— диде Мөхәммәт,— менә ничә айлар инде түенчек өстендә утырабыз. Яңа фатир вәгъдә иткәннәр иде, әле һич очы-кырые күренми. Аннан, соңгы вакытларда авыртмый-сызламый гына бик күп теш-

ләрем төште, әллә нервланганга, әллә инде картлык галәмәте... Казанга килеп чыксаң, чылтырат, Тәбриз»... Бу соңгы сүзләрен ул ниндидер моңсулык белән әйтте...

Аның үлеме турындагы кайгылы хәбәрне мин Уфада ике-өч көннән соң гына ишеттем. Килеп чыктым мин Казанга, Мөхәммәтнең яңа фатирына чылтыраттым... Хатыны Лилия ханымның хәсрәтен уртаклаштым инде...

Мөхәммәт Мәһдиевнең табигать фонында төшкән бик мәһабәт фоторәсеме бар («Казан утларының 1995 елгы 7 — санында басылып чыкты). Ул пиджагын иңнәренә генә салган, арыслан ялыдай озын, калын чәчләре җилдә тузгыган... Көчле, матур, мәгърур ир! Бу фоторәсем генә түгел, портрет-панорама, символ! Аның акыллы, ачык йөзендә авыр, михнәтле тормыш тәҗрибәсе, милләтнең киләчәге турында хәвефле уйланулар, нәрсәгәдер үкенү, әрнү, нәрсәгәдер рәнҗү чагыла; шул ук вакытта ул нигәдер көлемсери дә шикелле.

Калган гомерем буена минем күз алдымда шундый Мөхәммәт басып торыр.

Мин язмышыма рәхмәт укыйм — ул безнең юлларыбызны кисештерде, күп еллар буена миңа күренекле якташым белән дустанә мөгамәләдә аралашып яшәргә насыйп итте.

Үзең киттең, җырларың калды. Сине белгән, әсәрләреңне укыган меңнәрнең күңелендә якты истәлегең, гыйбрәтле, моңсу җырларың озак, бик озак сакланыр!

Хак Тәгаләгә бар гозерем шул: и Раббым! татарның бу олуг баласының урынын җәннәттә кыйл, амин!..

**Тәбриз МӨБАРӘКОВ**,
физика-математика фәннәре кандидаты,
Уфа авиация, техника университеты доценты.

## Хөрмәтле укучыларыбыз!

**Билгеле булганча, 1996 ел өчен «Казан утлары» журналына язылуда без еллык подписка игълан иткән идек. Бер ел өчен язылып куйган әбүнәчеләрнең өенә безнең журнал, көтелгән кунак һәм дус булып, ел дәвамында килеп торачак.**

**Ярты елга гына язылып калучыларның исә исенә төшерәбез: «Казан утлары» журналы алга таба да өегезгә даими килеп торсын дисәгез, икенче яртыеллыкка да язылырга онытмагыз, дуслар! Подписка быелның 1 апреленнән башлана.**

**Язылу бәясе — 13 мең 200 сум.**
**Журналыбызның индексы — 73210.**

**Журнал битләрендә сезне алга таба да кызыклы сәхифәләр көтә. Язылыгыз, укыгыз, гел бергә булыйк!**



**Илсөяр Иксанова**

## Мин

Мин — йөрәк кенә бары,
Йөрәк кенә!
Акылым да йөрәгемдә тибә.
Мин —
сулкылдап торган йөрәк кенә,
Мин —
кагынып торган йөрәк кенә,
Мин —
кабынып торган йөрәк кенә.

Тыннар каба бу йөрәккә,
Шатлык кага бу йөрәккә,
Әрнү сара бу йөрәккә.
Ал кан тама бу йөрәктән
Тормыш тамырына,—
Кагынырга,
Кабынырга,
Сагынырга!
Мин —
йөрәк кенә бары.
Сулык-сулык йөрәк кенә.
Йөрәгемне белми торып,
Мине беләм димә!

*1995*

* * *

Уяттылар...
Шундый рәхәт иде,
Шундый тәмле иде бу йокым.
Авызымнан өзгән бал шикелле
Татлы төшем калды бер йотым.

Күзләремне чытырдатып йомам,
Төшми күзгә,
        кунмый керфеккә.
Качып киткән инде татлы йокым,
Уятучым килеп өркеткән.

Бу елларым татлы йокы төсле,
Баллы төшләр кебек сөюем.
Үзем кадәр алтын китерсә дә
Уятмасын мине беркемең!

Уятмасын!
Татлы сөюләрем
Томан кебек эреп таралыр.
Сөю белән бергә китәр йөрәк,
Китәр өмет...
Миннән ни калыр?

*1995*

* * *

Бүре булып улыйсылар килә,
Улап булмый,
        булмый үкереп.
Бәгыремне йолкып алганнармы,
Эчем яна,
        яна үтереп!

Бүре булып улыйсылар килә,
Урманнарның тапмыйм ешлыгын.
Күз яшенең ачы тозы гына
Ала алмас җанның юшкынын.

Бүре булып улыйсылар килә,
Бүреләргә ят шул бу халәт.
Күкләр ярлыкамас гөнаһларны
Кичерә күр безгә,
                и хәят!

*1994*

* * *

Аңлый алсаң, аңла,
Аңламасаң,
Гаепләмә!
Кәфер булыр уең...
Ахыр чиктә онытырга мөмкин
Керәшеннең төнге сабантуен.

Куе үлән арасына поскан
Оялчан ул алсу җиләкләрне.

Кичерергә
Рөхсәтсез-нисез
Урыныннан купкан йөрәкләрне!

Гаҗәпләргә калган дөньялык та
Гафу итәр ул гөнаһсыз төнне.
Аңлый алсаң, аңла,
Аңламасаң,
Гаепләмә.
Аклама да мине!

*1990*

## Өмет сорыйм

Караңгы төн минем тәрәзәмнең
Сары уты белән туена.
Кайта, кайта!
Күзләремнең нуры
Сузылып ята кайтыр юлына.

Аһ, син түгел!
Күзләремнең нурын
Таптан-сытып үтә җиде ят.
Җиде кабат рәнҗи сиңа күңел,
Күктән гафу сорыйм җиде кат.

Ярлыкый күр ялгыш уйларымны,
Хәвефләрдән сакла, кадерлем!
Таң сызыла ап-ак офыкларда.
Сыза,
        сыза әрнеп бәгырем!

Караңгы төн минем күңелемнең
Өмет уты белән туена.
Алданганын сизеп өметләрнең
Ашкындыра шайтан туена.

Вәсвәсәдән арындырчы җанны!
Мин күкләргә карап ялварам.
Кайтырсың дип, иртән
Ышанырга,
Өмет сорыйм, өмет...
Алламнан!

*1995*

## Киләчәктән шигырь

Соңгы кышның соңгы кары төсле
Соңгы яры булып дөньялыкның,
Бар өметләр сүнеп беткән мәлдә
Соңгы яра булып син калыктың.

Яңгыр җиле белән килдеңме син,
Әллә сине буран китерде.
Кыш идеме, җәйме...
ахрысы яз —
Яшеннәрнең угы кителде.

Кыш белән җәй аерылмый калды,
Яңгырлы кар яуды сибәләп.
Ак чәчкә дип
Ап-ак кар өстенә
Килеп кунган ап-ак күбәләк
Өшеп үлде...
Әллә пешеп үлде,
Ярылдымы әллә йөрәге?!
Язган яры — кышкы кар булган ла,
Әйтәм җирле җәйдә килмәде.

Соңгы кышның кары булып тамды
Соң сөюнең салкын яшьләре.
Мәхәббәттән йөрәк ярылганда
Угы сынган яшен яшьнәде...

*1996*

# МИСЫР ШАГЫЙРЕ ШӘРИФ АМИДЛЕ

Мәмлүкләр Мисыры дәүләтендә (1250—1517 еллар) яшәп иҗат иткән һәм гомумтөрки әдәбиятта сизелерлек эз калдырган әдипләр байтак. Кызганыч ки, әсәрләре уртак мирас буларак татар әдәбияты тарихында да хаклы рәвештә өйрәнелергә тиешле булса да, мәгълүм сәбәпләр аркасында алар галимнәребез игътибарыннан һаман читтә кала килде.

Шундый каләм ияләреннән берсе — Шәриф Амидле тәхәллүсе белән билгеле булган Хөсәен ибне Мөхәммәд әл-Хөсәени әл-Хәнифи исемле шагыйрь. Дөрес, аның тәрҗемәи хәленә нисбәтле мәгълүмат әлегә күп түгел. Ул Амид, ягъни хәзерге Диярбәкер шәһәрендә (1515 елга кадәр мөстәкыйль Амил дәүләтендә) туган (елы ачыкланмаган). Әдип XV йөз азакларында мәмлүкләр Мисырына күчеп килгән һәм вафатына кадәр шунда гомер кичергән. Аның үлгән елы чыганакларда төрлечә, ягъни 1519; 1520; 1523 еллар дип күрсәтелә.

Шәриф Амидле үз чоры өчен мәгълүм дәрәҗәдә гыйлем иясе, тирән фәлсәфи фикер йөртүче, күп телләр белүче шәхес булган. Аның тарафыннан язылган «Нәфаисел-мәҗалис әс-солтанийа» («Солтан мәҗлесләренең энҗеләре») дигән тарихи истәлектән күренгәнчә, ул сарайда сәркәтип вазифасын да башкарган. Әлеге ядкярдә Мисыр солтаны әл-Әшраф Кансау әл-Гаури (1444—1517) үзенең ярдәмчеләре белән үткәргән киңәшмәләрдән сөземтәләр бәян ителгән.

Шагыйрьнең безгә билгеле булган иң зур иҗади казанышларыннан берсе — Фирдәүси «Шаһнамә»сенең тәрҗемәсе. Аны ул 1501—1510 елларда солтан Кансау әл-Гаури фәрманы буенча башкарган һәм әлеге хөкемдарга багышлаган. Тәрҗемә әсәр күләме ягыннан оригиналдан аз гына калыша, ул илле алты мең бәеттән гыйбарәт.

Тикшеренүләрдән күренгәнчә, Шәриф Амидле төрле жанрларда иҗат итүче шагыйрь булган. Укучылар игътибарына аның өч газәлен һәм бер мәдхиясен тәкъдим итәбез. Алар 1957 елда төрек галиме Шәүкәт Бәйсәноглы тарафыннан Истанбулда нәшер ителгән «Диярбәкерле фикер вә сәнгать адәмнәре» дигән китаптан алынды.

Әсәрләрнең транскрипцияләре мөмкин кадәр аңлаешлы итү максатыннан чыгып эшләнде һәм хәзерге татар әдәби теленә сүзгә-сүз тәрҗемә ителде.

**Рәмил ИСЛАМОВ,**
филология фәннәре кандидаты,
Г. Ибраһимов исемендәге Тел,
әдәбият һәм тарих институтының
өлкән гыйльми хезмәткәре.

## Газәлләр

* * *

Әй күңел, гыйбрәт күзилә кодрәте Мәүлайә бак,
Мәүҗ орган һәфте зәмин үзрә йиде дәрйайә бак.
Вөҗүдең мөлкене бәхре хәйат үзрә кыйлып,

Нәкъде гомре әленә вирмеш дорыр сәрмайә бак.
Гәр тиҗарәт идәр исәң сән дә рухани сәфәр,
Дөррә шәһварә назар кыйл, гәүһәре валәйә бак.
Та сәхәр вактыйн керәрсәң вослате гөлзарына,
Дидәи мәхкуль илә сән ул гөле рәгънайә бак.
Җәннәте багый биһиштә гәр гөзарын вар исә,
Сидрә-ү-Туба ку(й), дорсын, у(л) кадде баләйә бак.
Әй Шәрифи, булмадың туфане кодрәтдән нәҗат,
Та ки шиддәтлә рәһадасенә ул Мәүләйә бак.

**Тәрҗемәсе:**

Әй күңел, гыйбрәт күзе белән Мәүланең кодрәтенә кара,
Җиде җир өстенә дулкын каккан җиде дәрьяга кара.
Барлыгын милкен тереклек диңгезе өстенә куеп,
Гомер милкеңне кулыңа биргән байлык маясына кара.
Әгәр син дә рухани сәфәрдә сәүдә итәр исәң,
Зур энҗегә игътибар ит, мәһабәт гәүһәргә кара.
Сәхәр вакытына кадәр кавышу бакчасына керсәң,
Сөрмәле күзең белән син ул матур гөлгә кара.
Оҗмах бакчасы җәннәттә әгәр буласың бар исә,
Сидрә һәм Тубаны куй, торсын, ул буй-сынга кара.
Әй Шәрифи, кодрәт туфаныннан читтә калу юлын тапмадың,
Котылганга кадәр куркып тетрәнү белән ул Мәүлагә кара.

---

Мәүла — Аллаһының эпитетларыннан берсе. Җиде җир — борынгыда кешеләр дөньяны җиде өлешкә бүленгән дип караганнар. Сидрә — күкнең иң югары каты, аннан өстә фәкать Аллаһы гына. Туба — җәннәттәге гадәттән тыш агачның исеме.

* * *

Ишеткел: «Нәфсе әммарә кем, анда күр, бәлаләр чук,
Аңа бу даре дөньяның эчендә мөбтәләләр чук».
Зөләйханың сүзедер бу, Йосыф хаккыйнда димешдер.
Бу нәф(е)с-әммарә бер ивдер, эчендә аждаһалар чук.
Сәвеп ул Йосыфың хөснене рисва(й) улды Мис(ы)р эчрә,
Хосуса(н) Йосыфа кыйлмышдыр, аның чөн җәфалар чук.
Бонның кәйденә кайд улмыш ничә Дара-у-Кәйхөсрәү,
Бонның мәкренә уграмыш ничә бай-у-гәдалар чук.
Әгәр дәрвиш, әгәр мөнгыйм бу нәфсең дәменә уграр,
Боңа хезмәт кыйлыр җана парсалар чук.
Нәбиләр, гәр вәлиләр чөн дөшәр бонның дозагыйна,
Пәрәстәр улдылар нәфсә, күрерсең, мәхликалар чук.
Шәрифи аның әлендән халәс улмады бер сәгать,
Тәманна әйләйеп Хакка кыйла күрде догалар чук.

**Тәрҗемәсе:**

Ишеткел: «Нәфес әмеренә буйсынучыларга, анда күр, бәлаләр күп,
Бу дөнья йорты эчендә аңа тарыганнар күп».
Зөләйханың сүзедер бу, Йосыф турында әйткән,
Бу үзенә буйсындыручы нәфес бер өйдер, эчендә аждаһалар күп.
Сөеп ул Йосыфның чибәрлеген бөтен Мисырга рисвай булды,
Хосусан Йосыфка кылган, аның өчен җәфалар күп.
Моның мәкеренә ничек Дара һәм Кәйхөсрәү эләккән,
Моның мәкеренә ничек тарыган бай һәм ярлылар күп.
Әгәр дәрвиш, әгәр юмарт бай бу нәфеснең тозагына төшсә,
Моңа чын җаны белән хезмәт кылучы изгеләр җиһанда күп.
Пәйгамбәрләр дә, әүлияләр дә чөнки төшәр моның тозагына,

Нәфескә табындылар, күрерсең, һәлакәткә юлыгучылар күп.
Шәрифи аның кулыннан бер сәгать азат була алмады,
Хакка быгшылап күп догалар кылды.

---

Зөләйха, Йосыф — «Кыйссаи Йосыф» әсәрендәге, Дара, Кәйхөсрәү — Фирдәүси «Шаһнамә»сендәге каһарманнар.

* * *

Йазмага Коръән шәрхене бең буйлә дәфтәрләр кәрәк,
Йаре пәйам иләтмәгә җана кәбүтәрләр кәрәк.
Диде Ходайи ләмйәзәл: «Ди, йә Мөхәммәд, сән боны:
«Әлхәмдү лил-ләһил-ләзи», бу сүзә шөкерләр кәрәк.
Уйлә Ходадыр ул Илаһ, итмәз һич әулад иттиһаз,
Өмрән у(л) тәзвиҗ эстәмәз ки: «Дилбәрләр кәрәк».
Әһлү-гыйалдан ул Илаһ ди кем, мөнәззәһдер бу көн,
Димәз ки, өмрән ул Хода: «Зөлфе моганбәрләр кәрәк».
Йукдыр шәрик-ү-назыйре, мөлкен йалыңыз забт итәр,
Арз-у-сәмайе йарадыр, димәз ки: «Дөлгәрләр кәрәк».
Һәм йукдыр аңа бер вәли, идә тасаррыф халикы,
Йукдыр боның кеби кәләм, манәнде җәүһәрләр кәрәк.
Һәр кем бу садрә әһ(е)л ула, беләә хакыйкать йулыны,
Ул шаһдыр, аңа кимәгә алтынлы әфсәрләр кәрәк.
Бина улып ач күзләрең, гарыз ула (һәм) йөзләрең,
Шәрифи, сәнең сүзләрең йазмага дәфтәрләр кәрәк.

**Тәрҗемәсе:**

Коръән шәрехен язарга мең мондый дәфтәрләр кирәк,
Дуслык хәбәрен илтергә җанга күгәрченнәр кирәк.
Мәңгелек Ходай әйтте: «Әйт, йә Мөхәммәд, син моны:
«Әлхәмде лил-ләһил-ләзи», бу сүзгә шөкерләр кирәк.
Шундый Ходайдыр ул Илаһ, һич нәселгә мохтаҗы юк,
Өйләнергә мохтаҗы юк, әйтмәс: «Гүзәлләр кирәк».
Хатын, бала-чагалардан ул Илаһ бу көн арынгандыр,
Ул Ходай өметләнеп әйтмәс ки: «Хуш исле толымлылар кирәк».
Юктыр иптәше һәм охшашы, милкенә ялгыз үзе хуҗа,
Җирне һәм күкне яратыр, әйтмәс ки: «Осталар кирәк».
Һәм юктыр аңа бер житәкче, халыкны идарә итә,
Юктыр моның кебек сүзләр, җәүһәргә охшаш (сүзләр) кирәк.
Һәркем аның юлында булса, хакыйкать юлын таба,
Ул шаһтыр, аңа кияргә алтынлы таҗлар кирәк.
Тотанаклы булып ач күзләреңне (һәм) юнәлт йөзләреңне,
Шәрифи, синең сүзләреңне язарга дәфтәрләр кирәк.

## Мәдхия

Ике галәм мөлкенең солтаны улмыш Мостафа,
Гашыйк улан җанларың җананы улмыш Мостафа.
Бер назар кыйл, күр аны дареш-шифаи шәргыйдә,
Хаста дилләр дәрденең дәрмане улмыш Мостафа.
Чөнки дәгъвайи рисаләтеңдә Хак шаһид дорыр,
Әнбийанең хөҗҗәт-ү-борһане улмыш Мостафа.
Галәме золматдә кыйлмыш иде көф(е)р илә җиһал,
Бәзме шәргың шәмгындә ләмгане улмыш Мостафа.
Даре исламе Хода бер у(л) йаратды шөбһәсез,
Ул әүең, бел, шөйлә чар әркәне улмыш Мостафа.
Шул шәбе әсрарда бер аң хозуры Хәзрәтә,
Хак Тәгаләнең, варып, миһмане улмыш Мостафа.

Рахмәтән лилгаләминдер, шөбһә йукдыр, ул сираж,
Кем сәхабе рахмәтең баране улмыш Мостафа.
Ул дугалдан бире галәм күрмәде каһр-ү-җәфа,
Хәзрәте Хаккың безә ихсане улмыш Мостафа.
Калзуме гыйшка сәфәр итмәгә газем идәр күнел,
Дөрре гыйльмең бәхре бипайане улмыш Мостафа.
Канда калдың сән, аны Хак кәндүсе мәд(е)х әйләде,
Әй Шәрифи, делләрең дастаны улмыш Мостафа.

**Тәрҗемәсе:**

Ике галәм милкенең солтаны булган Мостафа,
Гашыйк булган җаннарның сөйгәне булган Мостафа.
Бер күз сал, күр аны шәригатьнең шифалы йортында,
Авыру күңелләр газабының дәвасы булган Мостафа.
Чөнки пәйгамбәрлегең дәгъвасендә Хак шаһит торыр,
Пәйгамбәрләрнең дәлиле һәм таныклыгы булган Мостафа.
Золмәт галәмендә көферлек белән кара наданлык (өстен иде),
Шәригать мәҗлесе шәменә нур сибүче булган иде Мостафа.
Ислам йортын Ходай бер ул яратты шөбһәсез,
Ул өйнең, бел, шулай дүрт терәге булган Мостафа.
Шул серле кичәдә бер мизгел Аллаһы хозурына,
Хак Тәгаләнең, барып, кунагы булган Мостафа.
Исламга Аллаһының рәхмәтедер, шөбһә юк, ул якты зат,
Рәхмәт болытының явымы булган Мостафа.
Ул туганнан бирле галәм каһәр һәм җәфа күрмәде,
Хәзрәте Хакның безгә шәфкате булган Мостафа.
Гыйшык дәрьясына сәфәр итәргә ният итәр күңел,
Гыйлем энҗесенең иксез-чиксез диңгезе булган Мостафа.
Кайда калдың син, аны Хак үзе мактады,
Әй Шәрифи, телләрнең дастаны булган Мостафа.

---

Мостафа — Мөхәммәт пәйгамбәр эпитетларының берсе.



**Мәхмүт Әхмәтҗан,**
педагогия фәннәре кандидаты

# ГАЛӘМ. МӘХӘББӘТ. ГАИЛӘ. БАЛАЛАР

Шулай бервакыт Алабуга шәһәреннән хат алдым. Аны авылдашым Зәйнәп ханым язган. Ул шәһәр мәктәпләренең берсендә (әлбәттә, урыс мәктәбендә) татар теле укыта икән. Гомере буе авылда яшәгән бу тәҗрибәле педагог Алабугага килеп «Америка ачкан». Хатында мондый сүзләр бар: «Без авылда эшләп кенә берни дә белмәгәнбез. Татар халкы бетә язган икән бит. Фаҗига кебек нәрсә: балалар ата-анасы телен тамчы да белмиләр. Бөтенләй урыслашканнар. Урыс малайлары кызларны: «Татарка! Татарка!» — дип үртәгәндә, тегеләре елардай булып: «Нет, мы — не татарки!» — дип кычкыралар. Үзләренең татар булуларыннан бик нык хурланалар». Менә шундый хәлләр. Ә бит бу очракта сүз Татарстан атын йөрткән мәмләкәт татарлары турында бара. (Ә анда татарларның 25 проценты гына яши.) Башка җирләрдә көн итүче милләттәшләребезнең хәле тагын да мөшкелрәк. Күрше Башкортостан Республикасында кимендә 1 миллион 300 мең татар бар. Әмма алар күпмегә кадәр татар булып калырлар, әйтүе кыен. Чөнки бу республикада татарларның милли ихтыяҗларына бөтенләй әһәмият бирмиләр. Билгеле сәбәпләр аркасында үз вакытында Татарстанда да, Башкортостанда да татар мәктәпләрен урысча укытуга күчерделәр (бик күп татар мәктәпләрендә укытуны башкортча алып бару турында сүз дә юк инде. Һәм бу үзе махсус өйрәнүгә лаек мәсьәлә). Татарстанда соңгы вакытта күп кенә татар мәктәпләре ачылса да, Башкортостанда бу эш бөтенләй алып барылмый диярлек. Ә без монда: «Күршеләр эшенә тыгылмыйбыз»,— дип, башын комга тыккан мескен тәвә кошы кебек яши бирәбез. Гафу ителмәслек хата бу!

Балаларның туган телне белмәвендә ата-аналарның да гаебе зур. Австралия, Финляндия, Швеция, Кытай, Болгария, Румыния һ. б. илләрдә яшәүче татарлар, ят-чит мохиттә гомер итүләренә карамастан, ана телен бик яхшы беләләр, өйдә гел татарча гына сөйләшәләр икән. Сәбәбе дә уч төбендәге кебек ачык: алар бөек татар халкының балалары булу белән горурланалар! Икенче төрле итеп әйткәндә, аларның милли үзаңнары бик югары. Ә бу халәт исә — яшәү өчен бөек көч. Яһүдләрнең ачы язмышы, бөтен дөньяга сибелү сәбәпләре тәгаен билгеле. Әмма милли үзаңы югары булган бу халык тарих борылмаларында югалып калмады. Алай гына түгел, мең ярым елдан соң милли дәүләтен аякка бастырды, чәчәк аттырды. Инде бөтенләй онытылган дип исәпләнгән ивритны дәүләт теле итте. Монда да гаилә мөнәсәбәтләренең роле әйтеп бетергесез зур. Яһүд кайда гына, нинди генә шартларда яшәмәсен, үзенең кайсы кавемнән икәнен онытмады. Лион Файхтвангер бер китабында бу хакта болай дип яза: «Рим легионерлары яһүд

дәүләтләрен юк иткәннән соң, ничек тә халыкны саклап калу теләге белән, раввиннар һәм тар-мар ителгән армия житәкчеләре яшерен рәвештә съезд үткәрәләр. Шунда тиешле карарлар кабул ителә. Шунын ин әһәмиятлеләре түбәндәге пунктларда чагыла: 1. Әй син, яһүд кешесе, кайда гына яшәсәң дә, шуны бел, синең үз туган илең-ватаның бар, килер бер вакыт һәм син үз илеңә кайтырсың. 2. Әй син, яһүд кешесе, кайда гына, нинди генә шартларда яшәсәң дә, һәммә яһүдне якын туганың итеп күр һәм аңа һәръяклап ярдәм ит».

Тормыш тәҗрибәсе һәр яһүднең әлеге карарларны тулысынча, төгәл итеп үтәвен күрсәтә. Бервакыт Франциянең иң бай кешеләреннән берсе — магнат Ротшильд: «Минем туган илем Израиль, Франциядә вакытлыча гына яшим»,— дип язып чыкты. Яһүдләрнең бер-берен батырган очраклары гомумән юк. Алар үзара бик дуслар. Бер-беренә ярдәм итәләр. Мин моны һәрчак белеп-тоеп яшәдем. Ә безнең татар кешесе күршесенең уңышларына көенеп йокыдан кала. Бу — безнең халыкның иң начар ягы. Башкалардан үрнәк аласы, каләмдәшләребезнең... яңа романнары, повестьлары, поэмалары чыкканга куанасы гына иде дә бит. Юк шул, эчебездә көнчелек уты дөрли...

Еш кына гаиләне дәүләт белән чагыштыралар. Һәм монда үзенә күрә логика-мантыйк та бар. Гаиләнең башлыгы — премьер-министры — ир, финанс министры, гадәттә, хатын-кыз; киңәшчеләре — әби-бабайлар; гади гражданнары — балалар була ич. Шуңа күрә нык, таза гаиләләрдән генә көчле дәүләт төзелә дип әйтәләр дә инде күрәсең. Бу — аксиома. Рим империясе җимерелер алдыннан гаиләләр дә эчтән череп таркалганнар. Кешенең уртача гомере 26 ел гына булган... Моны һәркем белә: тормышта кеше нинди генә югарылыкларга күтәрелмәсен, ул нигездә балачакта, гаиләдә алган гадәтләрен ташламый диярлек. Әйтик, бүген бөтен армия эчә, диләр. Ә ул нигә эчмәскә тиеш соң? Эчүче гаиләләрдә тәрбия алганнар хезмәт итә бит анда...

Ата-ананы, гомумән, өлкәннәрне хөрмәт итү, сафлык, пакълек, эшчән булу, һәммә нәрсәдә җаваплылык хисе тою кебек сыйфатлар безнең халыкка гомер-гомергә хас булган. Бу хакта VI гасырда кытай тарихчылары да язып калдырган. Иманлы татар бервакытта да: «Эш бүре түгел, урманга качмас», «Эш тиләләрне генә ярата»,— дигән принципларга таянып яшәмәгән. Анын бихисап колонияләре дә булмаган. Шулай да соңгы елларда халкыбызның әхлак йөзе «кире якка» үзгәрә башлады. Моның җитди сәбәпләре дә бар, әлбәттә, бу хакта алда сүз булыр әле...

Гаилә җәмгыятьнең үзе кебек үк бик борынгы иҗтимагый институт ул. Күп кенә белгечләр билгеләп үткәнчә, аерым алганда, Америка галиме Р. Морганның фикеренчә, гаилә төрле чорлар, үзгәрешләр кичергән. Борынгы ыруг шартларында бүгенге мәгънәсендә гаилә булмаган әле. Икенче төрле әйткәндә, ул чакта ирләр «уртак булган». Балаларның атасын эзләп маташмаганнар, анасын гына белгәннәр. «Ул атасы — утыз» дигән мәкаль шул заманнан ук килмәде микән? Гаиләнең бу формасы хатын-кызның җәмгыятьтә хәлиткеч роль уйнавы — туендыручы булуы белән билгеләнгән. Чыннан да ана, балалары белән бергә, тамыр-азык, җиләк-җимеш, орлыклар җыйган. Шулай итеп ул, «җан кисәкләрен» ач үлемнән саклап алып калган. Ирләр ау белән шөгыльләнгәннәр. Әмма бу шөгыль куркыныч та, еш кына уңышсыз да булган. Мәгълүм булганча, бу чор тарихта матриархат дип атала. Мин бүген кайчак йөз меннәрчә исерекләрнең эшләмичә эчеп йөреп, хатыннар җилкәсендә утыруларын күреп, әллә тагын матриархат кайта микән дип шикләнеп тә куям...

Шул рәвешле еллар гына түгел, гасырлар уза торган... Кешеләр — дөресрәге, ир-атлар кыргый хайваннарны кулга ияләштерә башлаганнар. Һәм тора-бара җир эшкәртеп иген игү өчен шартлар туган. Табигый ки, «дөнья тоткасы» ирләр кулына күчкән. Парлы никах та шул вакытта барлыкка килгән. Тарихи чыганакларга мөрәҗәгать итсәк, парлы никах өчен иң элек хатыннарның көрәшүен күрербез. Һәм моны аңларга да була. Халык та юкка гына: «Ир аркасы — кала аркасы»,— димәгәндер. Парлы никах, дөресен генә әйткәндә, ике якның да психологиясенә туры килә. Әмма башкача уйлаучылар да бар. Мәсәлән, күренекле урыс язучысы В. Солоухин: «Ирне бер хатынга бәйләп кую — гаделсезлек, бу аның табигатенә туры килми. Әтәчне генә карагыз, ул күпме тавыкның күңелен күрә. Ир дә шул ук әтәч бит инде»,— дип матбугат битләрендә язып чыкты. Гаҗәбе шул: бу фикерне Афанасьева, Кузнецова, Баскина кебек «белгечләр» дә яклый. Йә, шулай да булсын ди. Әмма башка төрле мисаллар да бар ич: парын югалткан аккошларның үз-үзләрен юк итүләре күпләргә мәгълүм. Күгәрченнәрнең дә үзара дус яшәүләренә карап сокланырга була... Кайберәүләрнең «ирекле мәхәббәт теориясе»нә карап кына, патриархат юкка чыгарга җыенмый кебек.

Чөнки яшәешне саклап калу өчен әлегә шуннан да кулайрак гаилә мөнәсәбәтләре уйлап табылмаган. Гомумән, кешелек яшәешен хайваннарның «инстинктка корылган» (аның нигезендә бары бер нәрсә — нәселне саклау инструменты ята) «тормыш» белән бутамаска кирәк. Әйе, бүген дә гаилә төзүнең төрле форма-вариантлары бар. Мәсәлән, Непалда яшәүче аборигеннарның бер гаиләдә үскән ир балалары һәммәсенә уртак бер хатын алалар. Бер журналда шундый гаиләнең рәсеме дә урнаштырылган иде: алдан хатын атлый, аның артыннан — ирләре. Сәбәп менә нәрсәдә: Непал — биек таулар иле. Эшкәртүле җирләр бик аз. Анда кешәрлек һәм, җире булган кеше генә өйләнә ала, югыйсә шунсыз ул гаиләсен туйдыра алмаячак. Өстәвенә, ире ничәү генә булмасын, биредә бер хатынның бала табуы сан ягыннан чикләнгән була. Бер ирнең берничә хатын белән яшәгән халыклар да бар (сүз уңаенда гына әйтеп үтик: христиан динендәге грузиннарның, абхазларның парламентлары күптән түгел бер иргә берничә хатын алырга рөхсәт итә торган закон кабул иттеләр. Мотивы: балалар аз, милләтне саклау ихтыяҗы дини кануннардан өстенрәк...). Бу хакта сүз чыкса, авыз ерып, күп хатын алалар дип, мөселманнардан көлүләр китә. Чөнки андый гафиллар бу традициянең сәбәпләрен белмиләр. Ә ул бик гади: ислам дине тарала гына башлаган чорда гарәпләргә бик күп сугышлар алып барырга туры килә. Алар — хәтта Европага барып чыгалар, Пиреней ярым утравында (хәзерге Испания җирендә) Кордово халифәте төзиләр. Шунда VIII гасырда гарәпләр тарафыннан дөньяда беренче университет ачыла. Европада исә университетлар XII—XVII, Россиядә XVIII гасырда гына барлыкка килә... Гарәпләр Һиндстанда Бөек Могол дәүләтенә нигез салалар. Индонезиягә, Малайзиягә кадәр барып җитәләр. Табигый, сугышта бик күп ирләр һәлак була. Кыскасы, гарәп милләтенә юкка чыгу куркынычы яный башлый. Алар моннан котылу юлын эзлиләр һәм тиздән табалар да: бер иргә берничә хатын алу рөхсәт ителә. Әмма бу йоланың катгый таләпләре була: хатыннарыңны, аларның балаларын карап тәрбияләрлек мөмкинлегең булса гына өйлән һәм һәр хатынга барлык мәсьәләләрдә дә бертөрле караш-мөнәсәбәт булырга тиеш!

Бервакыт көнбатыш журналистлары: «Артта калган халыкларда женси азгынлык көчле»,— дип язып чыктылар. Моңа Гана республикасының беренче президенты Кваме Нкрума түбәндәгечә җавап бирде: «Әйе, бездә берничә хатын белән яшәү гадәте бар. Әмма бу хатыннарның берсе дә язмышларыннан зарланмыйлар. Ә сездә, Европада, яшерен рәвештә күп хатын белән яшәү юкмени? Өстәвенә, сез әхлаксызлык күрсәтәсез, хатыннарны зина кылу юлына бастырасыз. Бездә андый тыйнаксызлыкка юл куелмый».

Әткәй мәрхүмнең сөйләвенә караганда, революциягә кадәр безнең авылда да ике-өч кеше (әлбәттә, байлар) ике хатынга өйләнгәннәр. Әмма ике хатын белән яшәү җиңелдән булмагандыр, ахры. Бервакыт, кышкы буранда, ике кеше урманнан утын төяп кайтып килә икән. Алар моңсу гына капка баганасына сөялеп торган Гариф абзыйны күреп болай дигәннәр: «Гариф абзый, без утын булмаганга шундый буранда интегәбез. Ә сиңа ни җитмәгән, нишләп бу күз ачкысыз көнне өеңдә утырмыйсың?» Ә Гариф абзый ачуланмыйча гына аларга: «Әй, агай-эне, тыштагы буран буранмыни ул! Әнә өйдә минем ике хатын сугыша, бу, ичмасам, буран дисәң дә буран, көчкә чыгып котылдым» — дип җавап кайтарган. Менә тагын бер вакыйга. Бөтен авылның желегенә төшкән хәйләкәр карт бүрене, ниһаять, бер аучы атып алып кайткан ди. Аны карарга дип бөтен авыл халкы җыелган. Алар арасында Гариф абзый да бар икән. Шул чакта, бүренең борынына төртеп, ул: «Атып ялгыш эшләгәннәр. Ике хатын белән яшәтеп каратасы иде аны, тиешле җәзасын алган булыр иде»,— дигән тирән көрсенеп.

Минем әле генә университетны тәмамлап, Әгерҗедәге тимер юл мәктәбендә эшли башлаган чагым иде. Бер-ике ай үтте микән, «Белем» җәмгыятенең район бүлеге рәисе итеп сайладылар. Шулай берчак Сарсак-Омга авылының Соловьев атлы бер кешесе белән сөйләшкән сүзләр хәтергә сеңеп калган. Ул болай дигән иде: «Чукындырылган удмуртлардан тыш, мәҗүси удмуртлар да бар. Элегрәк алар, урман эчендә учак тергезеп, утка табынганнар. Хәзер дә «ут-алланы» андый удмурт авылларында еш күрергә була. Бу көнне һәркем мунча яга. Гыйбадәт беткәч, кызлар күзләре төшкән егетне мунчага алып кереп китәләр. Моңа беркем дә каршы килми, чөнки йоласы шундый. Кыз бала кияүгә чыкмаган килеш тә берничә бала табарга мөмкин, моның өчен бер кемне дә гаепләмиләр, кызның да абруе төшми. Тора-бара кияү дә табыла. Ул да, болар кем балалары дип, хатынының тенкәсенә тими. (Бу йола үзе үк матриархатның ерак чагылышы түгел микән? Болай уйлавымның бер сәбәбе дә бар: көнкүрештә удмурт хатыннары ирләренә караганда күпкә тырышлар.) Бу сөйләшү Американың атаклы

рәссамы Рокуэл Кентның «Гренландский дневник» дигән китабын укыганда да искә төшкән иде. Р. Кент эскимосларның җенси тугрылык мәсьәләсенә бармак аша гына караулары, көнләшү кебек хиснең бөтенләй булмавы турында яза. Ялгышмасам, эскимослар да фин-угыр халыклары группасына керәләр. Чукчалар тормышын тасвирлаганда, шундыйрак фикерне Юрий Рытхуэй да үткәрә... Күпләрнең «фин мунчасы» дигән төшенчә турында ишеткәне бардыр. Мин дә Мәскәүнең авиабилетлар сата торган үзәк кассасында фин мунчасы күренешен тасвирлаган бер рәсем күргән идем: анда әллә никадәр ирләр, хатыннар, балалары белән бергә юыналар иде. Хәер, бу фани дөньяда бөтен нәрсә дә шартлы ич: әйтик, су буенда комда кызынганда бөтенләй шәрә яки ярым шәрә ятучылар бар ләбаса. Моңа беркем дә әһәмият бирми. Ә эш урынына алар шулай килсәләр, нинди реакция булыр иде икән?

Бу уңайдан Һиндстанда брахманнарның (дин әһелләренең) җенси теләген үтәүче махсус хатын-кызлар булуын да искә төшерергә була. Алар Буддага хезмәт итүче изге җаннар итеп саналалар. Урыс күрше әйтмешли, «чем дальше в лес — тем больше дров». Мондый мисалларны күпләп китереп булыр иде әлбәттә, ләкин безнең максат ул түгел.

Гаиләне ике кеше — ир белән хатын төзи. Һәм аның ныклыгы күп нәрсәләргә, мәсәлән, мәхәббәткә, халык традицияләренә бәйләнгән. Элегрәк бу мәсьәләдә дин хәлиткеч роль уйнаган. Никах укыганда поп та, мулла да, раввин да бергә сүзне әйтәләр: «Никах эше — Аллаһ кулында. Аның гозерендә. Чын никах күктә, Ходай Тәгалә янында укыла. Җирдә — шуның күчермәсе генә. Димәк, ир белән хатын булуыгыз — сезнең язмышыгыз. Бер-берегезне яратыгыз, хөрмәт итегез. Күп итеп балалар үстерегез...» Тарихка мөрәҗәгать итсәк тә, элегрәк гаиләләрнең, бүгенге белән чагыштырганда, күпкә ныклы, озын гомерле булуын күрербез. Мәсәлән, Рим империясендә (б. э. к.) 510 елга нибары бер гаилә таркалган. Урысларда 1911 елда 144 гаиләнең берсе генә җимерелгән-таркалган. Гарәбстанны, башка мөселман илләрен әйтеп тә торасы юк. Кытайда, Һиндстанда да аерылышу дигән нәрсә бик аз яки бөтенләй юк. Революциягә кадәр татар гаиләләре дә тотрыклы булганнар. Чөнки татар агай-эне Мөхәммәт пәйгамбәр хадисендәге түбәндәге сүзләрне колагына алка итеп таккан: «Өйләнегез, ләкин аерылышмагыз, чөнки талактан хәтта Аллаһе Тәгаләнең пайтәхете дә тетрәнә». Әнә шундый ышану тормыш кыенлыкларын ничек тә җиңелрәк кичерергә булышкан. Ә авырлыклар булган да булган инде. Кимендә 10 баланы ашатып-киендереп, кеше итеп тәрбияләп, олы тормыш юлына кертеп җибәрергә кирәк булган ич. Татар гаиләләрендә берсеннән берсе матур, таза балалар үскән. Чөнки аларның ата-аналары аракы, тәмәке дигән явызларга сәлам бирмәгәннәр. Ә хәзер киресенчә. Шуңа күрә дә бүген яңа туган балаларның 85 проценттан артыгырагы — авыру. Һәм бу процесс көчәя генә бара.

Ә ата-анасы исән-сау килеш күпме балалар ятим үсә! Моны үзе татыганнар гына белә: бала өчен ятимлектән дә авыр берни дә юк! Әтине-әнине беркем дә алыштыра алмый: баланың табигате шундый. Балалар бакчасы тормышын күзәтсәң, утырышлар еларлык: бәхетле балаларны әтисе-әнисе килеп ала. Бала әтисен ерактан ук күреп кулларын чәбәкләп кычкыра: «Әти, килдеңме?!», — ди. Шул гади генә сүзләр әтисез сабыйның йөрәгенә хәнҗәр булып кадала. Олырак булса, бәлки ул әтисенең ни өчен үзләре белән тормавын аңлар иде. Әмма нәни җан, өлкәннәрнең шул кадәр кансыз, эгоист булу сәбәпләрен аңламый. Һәм ул моның өчен гаепле дә түгел: табигать законнары һәммәбездән дә өстен. Әтиле ятим бала үз хәлен яшерергә тырыша, әйтерсең лә моның өчен ул үзе гаепле инде! Төрле сәбәпләр уйлап таба: әти еракка, озакка командировкага киткән, кайтыр да ул мине килеп алыр», — ди. Бәлки ул үзе моңа ышанадыр да, бала бит, мәкерлекнең чиге юк икәнен белми әле ул...

Галимнәрнең әйтүенә караганда, аерылышу факты үзе генә дә организмга, нерв системасына искиткеч зур зарар китерә икән. Якыннарыны, әти-әниене югалту да бу кадәр кире йогынты ясамый кешегә диләр психологлар, психиатрлар. «Юк, аерылганыма кайгырмыйм, үкенмим, котылдым, үземә генә тыныч», — дип сөйләнүләр «шагыйрәнә» ялган ул. Әмма сүз аек кешеләр турында бара. Төзәлмәслек һәм төзәлергә-дәваланырга теләмәгән сәрхүш белән хушлашу, этик яктан караганда, әлбәттә, дөрес булачак. Чөнки андыйлар — шәхес түгел... Шулай да Казан кебек шәһәрләрдә яңа гына барлыкка килгән гаиләләрнең яртысына якыны бер-ике елда таркала икән, бу инде бертөрле кысаларга да сыймый. Бу үзенә күрә ниндидер афәт, эпидемия сыман күренеш. Ата-ана бурычка батып («Бала өчен ни дә кызганыч түгел, кешедән ким-хур булмыйк» дип...), туй ясый, балам бәхетле булсын дип уйлый-юрый. Ләкин күп тә үтми (бурычлар озак

түләнми...), яшьләр аерылышалар. Гадәттә, гариза бирүчеләрнең 90 процентка якыны — яшь ханымнар була. Төп мотив түбәндәгедән гыйбарәт: «Яратышабыз дип ялгышканбыз. Без бөтенләй башка кеше икән. Ул (ир) эгоист, мине кер юучы, аш пешерүче итеп кенә күрмәкче. Кирәк икән, үзе эшләсен, пешерсен дә ашасын, юсын да кисен. Мин аңа стряпка түгел». Менә шундый хәлләр... Әмма шагыйрь Степан Щипачевның, тормыш көтү — кырны үтеп китү генә түгел — ул, дигәнен онытмаска иде... Шатлыкларына караганда, тормышның мәшәкатьләре күп һәм бу үзе нормаль хәл. Зур галим Монтень дә бер дә юкка гына: «Хәтердә калырлык татлы мизгелләр кичергән кешене бәхетле дип санарга була»,— димәгән инде. Моның шулай икәнен уч төбендә «өф-өф» итеп үскәннәр аңламыйлар да, белмиләр дә. Шул уңайдан заманында «Крокодил» журналында басылган берничә рәсемгә тукталып үтәсе килә. Беренчесе — яшь кенә егет белән бөтенләй сабый гына бер кыз каядыр чабалар. Кызның битләре урынына — контурлар гына! — бу җиңел акыллылык билгесе. Алда бер бина, язуы да бар: «ЗАГС бюросы» дип язылган. Димәк, бу ике яшь язылышырга баралар икән. Юлда бер кыз елап тора. Егет аңа: «Елама, бу юлы сүземдә тора алмадым шул, икенче мәртәбә синә өйләнермен»,— ди. Икенче рәсем — кыз өенә егет ияртеп кайткан. Ишекне зур итеп ачкан, кыз артында — озын буйлы ир заты. Әнисе бу хәлгә бик гаҗәпләнә, шулай да үзен кулга алып болай ди: «Ул кеше кем була инде»? Кыз горур рәвештә болай дип җавап бирә: «Таныш булыгыз, бу егет сезнең киявегез, минем ирем булыр»,— ди. Әтисе эндәшми генә почмакта басып тора, димәк, бу гаиләдә аның белән исәпләшмиләр... Телгә килгән әнисе кызына тагын бер сорау бирә: «Ә сез үзара күптән танышмы?» Кыз, күкрәген киереп: «Күптән. Иртә белән үк танышкан идек»,— ди. «Крокодил» журналының нинди басма булуы, гротесклар яратуы мәгълүм. Әмма бу очракта ул һичбер арттырмаган, безнеңчә.

Кызганыч һәм үкенечле, бүгенге яшьләрнең шактые гаилә тормышына бөтенләй өйрәтелмәгәннәр. Ә бит бу институт — гаилә шактый катлаулы организм. Ике төрле мохиттә тәрбия алган ике төрле характердагы кешегә уртак тел табу һәрчак җиңел дә булмаска мөмкин. Әмма һәркем «үз урынын» белсә, аларга вак-төяк низаглардан котылу авыр булмаячак. Еш кына яшь гаиләләр юктан гына да таркалалар: ир дә, хатын да өй эшен, бала карау, аш-су хәзерләү кебек «юк-бар»ны бөтенләй белмиләр. Китә шуннан соң авыз тәмен җибәрү, ике яктан ике якның ата-анасын гаепләү. Тора-бара бу нәрсә гаилә таркалу белән бетә. Беркем дә каршы якка юл куярга теләми. Ә гаилә тормышы туктаусыз компромисслар-килешүләрдән генә тора — бу Америка ачу түгел... Яшьләр гаилә тормышына хәзерләнмәгән икән, моңа да без — өлкәннәр гаепле. Кыз баланы, гадәттә, анасы тәрбияли, кирәкле «серләрне» чишә, аңлата, эшкә һ. б. өйрәтә. Шул уңайдан бер гаилә турында сөйләмәкче булам, чөнки аның әгъзалары белән берничә дистә ел аралашып яшим. Гаиләдә кыз бала да, малай да бар иде. Анасы кызын һәрчак җәлләп килде. Тормыш болай да изә, әйдә, уйнап калсын, диде. Аннан соң кызыбыз урта мәктәптә дә, музыка мәктәбендә дә укыды, балам арый, диде. Ана үзенең балачагын бөтенләй онытты, ахырысы. Югыйсә эшкә, гаилә тормышына өйрәтмичә кызын бәхетсез итмәс иде... Дөнья тәҗрибәсенә мөрәҗәгать итсәк, немец хатын-кызларының яхшы хуҗабикә булуларын шәйләргә була. Чыннан да, немец кызы һәммәсен дә эшли белә: өйне гөл кебек итеп тота, бик яхшы итеп аш-су хәзерли, бәйли, тегә, юа һәм тагын әллә нәрсәләр эшли. Бу эшләргә немец кызларын өйдә дә, мәктәптә дә өйрәтәләр. Швеция, Норвегия мәктәпләрендә кызлар өй хуҗалыгын алып баруга берничә ел буена өйрәнәләр һәм шуңа имтихан тоталар. Ир балалар да читтә калмый: Европа илләре гаиләләрендә юк-бар өчен дә слесарь, монтер чакырып тормыйлар. Андый өй эшләренең һәммәсен дә ирләр эшли. Норвегия короленың өй җыештыручысы юк икән, димәк, өй эшен һәркем белә дигән сүз бу. Ләкин хакыйкать өчен шуны да әйтик: цивилизацияле илләрдә хатын-кызга хөрмәт зур. Ирләр белән бертигез итәбез дип, аларга бездәге кебек берьюлы ике камыт кидермиләр. Хәер, ике камыттан әлләни рәт чыкмый, мондый очракта хатын-кыз ике аякка да аксый башлый. Шуның аркасында бала табу да ныклы кими. Башка илләрдә баласын өйдә тәрбияләгән хатыннар яхшы пособие алалар (балага 8 яшь тулганчы). Бу һәммә яктан да отышлы. Бездә әлеге хакта сүз чыкса, пособие түләргә дәүләтнең мөмкинчелеге юк дип акланырга керешәләр. Төрле саннар китерәләр. Мәсәлән, укытучыларның 76, врачларның 80—82, инженерларның 52 проценты — хатын-кыз, дәүләт аларны эшләтмичә булдыра алмый, диләр. Монда үзенә күрә логика бар. Чит илләрдә дә хатын-кызлар эшләргә мөмкиннәр. Әмма башта алар балаларын сау-сәламәт итеп тәрбияләргә тиешләр, тик шуннан соң гына, әгәр ул үзе моны кирәк дип тапса, эшкә урнаша алалар.

Гаилә тәрбиясенә махсус тукталуымның сәбәбе шунда ки: еш кына шәхеснең формалашуында аның урыны хәлиткеч рольне уйный. Моңа бөек чех галиме-педагог Ян Амос Косменский аеруча зур әһәмият биргән. Хәтта «Аналар мәктәбе» дигән китап та язган. Аның әһәмияте әле дә югалмаган. Әгәр минем кодрәтемнән генә торса, әлеге хезмәтне һәр яңа гаилә төзүчеләргә бушлай бүләк итәр идем... Коменский бала өйдә нинди тәрбия алса, киләчәктә дә шулай булачак, дигән. Бу чыннан да шулай: ананың балага мәхәббәте, баланың да анага туктаусыз тартылуы тәрбия өчен чиксез мөмкинлекләр ача. Күренекле инглиз галиме философ һәм педагог-психолог Джон Локкның фикеренчә, иң дөрес тәрбия гаилә шартларында гына бирелә ала. Аның «джентльмен тәрбияләү» (итагатьле кеше формалаштыру) теориясе әнә шуңа нигезләнгән. Монда сүз нигездә аристократ балалары турында барса да, галимнең тәрбия принциплары һәм методлары дөрес һәм урынлы. Чөнки 40 укучы белән бер укытучыга эшләү искиткеч авыр, һәм бу очракта баланың табигать биргән сәләт алшартларын сәләткә әйләндерүе кыен һәм еш кына мөмкин дә түгел.

Балалар бакчалары турында сөйлисе дә юк. Кышкы каты салкыннарда мәктәпләрдә укулар булмый. Әмма бу кагыйдә балалар бакчаларына кагылмый. Ана караңгыдан елатып баласын уята, ашыга-ашыга бакчага алып бара. Һәм менә шуннан соң 3—6 яшьлек сабый авырмый нишләсен ди. Әмма бу хакта уйлаган, сүз кузгаткан беркем дә юк. Чөнки бу илдә адәм җаны чебен җаны кадәр дә тормый. Авыру һәм тиешле тәрбия алмаганнарның төрмә юлыннан кайтмауларын, йөзмеңнәрчә яшьләрнең эшкә өйрәтелмәү аркасында трай тибүләрен, көн-төн урлашу, өй басулар, кеше үтерүләрне исәпкә алганда (болар һәммәсе дә тәрбиясезлек нәтиҗәсе), хатыннарның өйдә бала тәрбияләве, икътисади яктан, күпкә файдалы булыр иде. Әмма безнең җәмгыять моңа әһәмият бирми, ул халыкларны сугыш, көчләү юлы белән генә тәрбияләмәкче була. Бу — «совет» кешеләренең канында...

Күпләрнең геологлар турында мавыктыргыч кинофильмнар караганы бардыр. Читтән караганда ал да гөл кебек, гел романтика. Шуңа күрә бу профессияне кызлар да сайларга атлыгып торалар. Пропаганда шулай куелган. Ләкин чынбарлык шуннан гыйбарәт: бу эш — хатын-кызлар өчен кулай түгел. Айлар буе сусыз чүлләрдә, окопларда, сазлыкларда, тауларда йөреп мунча күрмәү тормыш мени инде? Бу уңайдан сүзне Әрмәнстанның (Айастанның) халык шагыйрәсе Сильва Капутикянга бирик әле. «Литературная газета»га язган бер мәкаләсендә ул түбәндәгеләрне әйткән иде: «Табигать хатын-кызны иң элек бала табу, аны тәрбияләп кеше итү, димәк, адәм кавемен дәвам иттерү өчен яраткан. Бу хатын-кызны кимсетми генә түгел, киресенчә, аның дәрәҗәсен бик нык күтәрә. Шуңа күрә иң яхшы әсәрләр, дастаннар — хатыннарга багышланган. Ләкин совет власте елларында хатын-кызга караш нык үзгәрде. Җәмгыять эшләре күп йөкләнгәч, хатын-кыз төп изге вазифасын начар үти башлады. Бу аның гаебе түгел, фаҗигасе. Минем дә яраткан киленем бар. Улым белән бик тату яшиләр. Үкенечлесе шул: балалары бераү генә. Бер бала бала түгел инде ул. Сәбәбе шул: киленем югары белемле музыкант, бөтен гомере шул музыка белән үтә. Минемчә, хатын-кызның һәммәсенә дә югары белем бирү кирәкми. Хөкүмәт кызларга югары белем бирәм дип әллә никадәр чыгымнар тота. Ә моның файдасы аз. Мәсьәләне шулай итеп хәл итәсе иде: ирләрнең хезмәт хакы, чит илләрдәге кебек, гаиләне һәрьяклап тәэмин итәрлек булсын. Ә хатыннар балаларны әйбәт итеп тәрбияләсеннәр. Аларны аякка бастыргач, теләкләре булса, хөкүмәт эшендә дә эшләсеннәр.»

Бу сүзләргә мин аңлатма бирергә алынмас идем. Чөнки хатын-кызларның дөрес аңламавы, мине «феодаль булуда» гаепләүләре мөмкин. Әлбәттә, теләге, мөмкинлеге, сәләте булган хатын-кыз югары белем алырга тиеш. Атаклы шпион хатыннар булмаса да (моңа аларның нерв системасы көйләнмәгән), күренекле галим, язучы, дәүләт эшлеклеләре арасында шактый гына хатыннар бар. Бүгенге Төркиянең, Шри Ланканың, Норвегиянең, Гватеманың, Пакистанның премьер-министрлары — хатын-кызлар. Англиянең, Польшаның премьерлары булып та хатын-кызлар торган иде. Бу үзе генә дә күп нәрсәләр хакында сөйли ләбаса. Ләкин ни генә булмасын, хатын-кызсыз кешелек дәвам итә алмый. Әмма дә ләкин бездәге кебек мескен хатыннар дөньяда юк. Бездә генә хатыннар тимер юлга шпал салалар, урамнарга асфальт җәяләр, урман кисәләр, кем әйтмешли, адәм типкесендә йөриләр. 40 яшенә кадәр трактор белән «көн иткән» Паша Ангелинаның күкрәгенә ике Алтын Йолдыз таксалар да, хатын-кыз организмы ирләр эшенә түзмәде, бу тырыш хатын дөньядан бик иртә китеп барды. Хәер, бу илдә ирләргә дә, хатын-кызларга да кеше итеп карау бармыни?

Шагыйрьләр даими рәвештә мәхәббәткә мәдхия җырлап дөрес эшлиләр. Чөнки мәхәббәт — дөнья тоткасы. Бу үзенә күрә Бөек Табигатьнең яшәеш законы, формасы. Кояш Җирне өзелеп сөя, иркәли, үз итә. Без дә Кояшка гашыйк. Язгы, шифалы кояш нурлары үзләре генә дә ни тора! Хисләр ташый башлый, Гомер мәңгелек булып тоела. Яшь кызлар үзләре дә сизмәстән гыйшык утында яна башлыйлар. Шагыйрь әйтмешли, дөнья матур, дөнья киң, яшә дә яшә генә! Балалар да: «Кояш та, әни дә һәрдаим булсын»,— дип җырлыйлар. Бу җырны һәммәбез дә яратып тыңлыйбыз. Л. Н. Толстойның үзе төзегән әлифба китабы өчен язган бер кечкенә хикәясе күпләрне уйландырырлык: «Кояш җирне җылытканга үләннәр үсә, шуны ашап сыерлар безгә тәмле сөт бирәләр. Кояш нурларын алып агачлар үсә. Агачны утын итеп мичкә ягабыз һәм кышкы салкыннарда җылы өйләрдә яшибез»,— ди әдип. Бик тә үкенечле: «Бүген кибернетика заманасы, житди нәрсәләр белән шөгыльләнергә кирәк»,— дигән булып, кайчак Л. Н. Толстойның хикәясендәге әлеге хакыйкатьне онытып җибәрәбез түгелме?! Экологик һәлакәтләр ваемсызлыктан, нигилизмнан килә. Без — өлкәннәр еш кына «Малайлар агачларны сындыралар, кош ояларын туздыралар»,— дип сөйләнгән булабыз. Ул әхлаксызлар, исерек баш балалары, кулларыннан килсә, Кояшны да өзгәләрләр иде. Әмма «Озон проблемасын» тудыручылар да беркем дә түгел, үзебез ләбаса. Сүз уңаенда гына әйтеп үтик: чит илләрнең уку программаларында төп урын гуманитар фәннәргә бирелә. Һәм бу аңлашыла да, чөнки кеше шәхесен техник фәннәр түгел, гуманитар фәннәр, беренче чиратта, әдәбият, сәнгать, тарих формалаштыра. Машинада, физика, химиядә җан да, уйлар да юк. Ә, бер галим әйтмешли, бөек ачышларны тирән хискә ия булганнар гына ясый ала. Шул ук Кояшка кайтсак та, адәм баласының бу күк җисеменә мәңгелек мәхәббәте нигезендә сүнми дә, сүрелми дә торган хисләр ята. Бүген дә шулай бу, элек тә шулай булган. Борынгы египтлыларның Алласы — Ра-Кояш. Ул иң зур, баш алла. Халыкка тормышны, яшәешне Ра белән аның чибәр кызы Нил елгасы биргән. Шуңа күрә Нил дә изге саналган. Хәер, бүгенге һиндстан халкының күпсанлы аллалары арасында Ганг елгасы — иң изгеләрдән, хөрмәтлеләрдән. Үлгән кешене яндырып, көлен Ганг елгасына салып агызуның мәгънәсә бер генә: адәм затының яңадан терелеп, теге дөньяда яшәве өчен эшләнә бу... Зороастра (Заратуштра) динендәгеләр дә утка, Кояшка табыналар (андыйлар хәзер дә Иранда, Һиндстанда яшиләр. Индира Гандиның ире дә Зороастра аллага (пәйгамбәргә дә дияргә буладыр) табынган. Хакыйкать өчен тагын бер нәрсәне искәртик: борынгы дин булуына карамастан, Зороастра дине, христиан дине белән чагыштырганда, мәҗүсилектән шактый ерак тора... Япон кешесе уртача 11 Аллага табына. Әмма баш Аллалары — Кояш кызы — Аматэрасу алиһә. Япониянең дәүләт әләмендә символика булып Кояш сурәте тора. Кыскасы, адәм затының Кояшка мәхәббәте мәңгелек һәм иксез-чиксез. Ләкин мәхәббәтне — илаһи бөек көчне космогония, күк җисемнәре белән генә чикләү дөрес булмас иде. Югарыда әйтелгәнчә, мәхәббәт кешелекнең үзе белән бергә туган. Шуңа күрә ул мәңгелек категория булудан туктамаячак. Такташ әйтмешли:

Мәхәббәт
Ул үзе иске нәрсә,
Ләкин
Һәрбер йөрәк аны яңарта,
Тиле яшьлек ярты гомерен бирә
Аның хисе белән янарга.

Әйе, гомер-гомергә шулай булган. «Нибелунглар турында җыр» дигән борынгы немец дастанында сеңелләренең абыйларына гашыйк булып кияүгә чыгулары турында әйтелә. Т. Г. Шевченконың «Патшалар» дигән поэмасында да шундыйрак хәлләр тасвирлана. Амозонкалар, куртизанкалар турында да тәгъбирләр аз түгел. Урта гасырларда синьорларның сөйгәннәре тәрәзәсе төбендә серенада җырлаулары үзе генә ни тора! Менә ничә йөз ел инде «Декамерон» китабы, төрле телләрдә басылып, халык кулыннан, теленнән төшми, чөнки анда үзәк герой — Мәхәббәт!

Мәхәббәт турында сүз кузгатуның төп бер сәбәбе шуннан гыйбарәт: бүгенге яшьләрнең күпкенәсе аерылышуны мәхәббәт юклык яки булып та каядыр китүе белән аңлатырга тырышалар. Әмма шунысы гаҗәп, шагыйрьләр һәм социологлар күпме генә мәхәббәткә мәдхия җырламасыннар, нәрсә ул мәхәббәт дигән сорау әле дә җавапсыз кала бирә. Даль, Ожеговның мәгълүм сүзлекләрендә дә моңа төпле аңлатма бирелмәгән. Һәм, мөгаен, моңа гаҗәпләнмәскә дә кирәктер. Чөнки һәркемнең гыйшык тотуы үзенчә, фәнчә әйтсәк, индивидуаль характерда.

Бу кешеләрнең дөньяга карашлары, уйлары, интеллектуаль үсешләре һ. б. күп факторлар белән аңлатыла булса кирәк. Америкада чыккан бер китапта укыганым бар: «Дөньяда иң чибәр хатын-кызлар — полинезийкалар (кытайлылар белән коньяк Америка кешеләре каны кушылудан яралган затлар) һәм алар бары бер нәрсә белән — мәхәббәткә бирелү белән көн итәләр. Бай америкалылар шул утрауларга (Полинезия кечкенә утраулардан — атоллардан тора) барып, полинезийкалар мәхәббәтен татыйлар. Яшь кыз бала тапса, аны карамый, анасына тапшыра, үзе мәхәббәт белән шөгыльләнүен дәвам итә икән... Л. Н. Толстой: «Мәхәббәт ул яраткан кешең өчен яшәү»,— ди. В. Г. Белинский: «Мәхәббәт ул тормышның кояшы»,— дип әйтү белән чикләнә. Ә болар һәммәсе дә — гомуми сүзләр генә... Анна Каренина исә мәхәббәтне бөтенләй үзенчә аңлый: аныңча Вронский көн-төн Аннаның күзләренә карап торырга тиеш була. Әмма моның мөмкин түгеллеген белгәч (аңлагач түгел!), поезд астына ташлана. «Социалистик мәктәптә» улын һәм ирен ташлаган бу хатынны буржуаз гаилә кануннарына каршы чыгучы дип аңлатырга тырышсалар да, чынлыкта исә Аннаны аклап булмый...

Гадәттә, мәхәббәтнең «бөек ноктасы» итеп «Йосыф — Зөләйха», «Таһир — Зөһрә», «Хөсрәү — Ширин» дастаннарын, «Ромео — Джульетта» трагедиясен китерергә яраталар. Ярар, шулай да булсын ди. Бу мәхәббәтләрнең нигезендә олы фаҗига ятканын аңламаучылар һәм аңларга теләмәүчеләр дә күп әле. Беләсе, күрәсе иде, унар еллар бергә гомер итсәләр, Таһир белән Зөһрәнең мөнәсәбәтләре ничек булыр иде икән? Халыкта, мәхәббәтең сүнсен дисәң, гыйшык тоткан кызыңа өйлән (егетеңә кияүгә чык), дигән әйтем бар. А. П. Чехов та, төн башлану белән мәхәббәт бетә, дигән. Француз Ж. А. Массэның да, мәхәббәт сырхавыннан дәвалану чаралары күп, тик иң ышанычлысы — никахлашу, дигән мәшһүр сүзләре билгеле. Мондый мисалларны бик күпләп китерергә булыр иде, әмма шунысы бәхәссез: мәхәббәт булган һәм булачак. Әмма бу илаһи көч гомер буе, һәрвакытта да бердәй көч белән дөрли алмый. Дөресен генә әйткәндә, кеше организмы аңа көйләнмәгән, аның үз үзенчәлекләре бар. Моны аңламыйсың икән, бәлаләргә тарыйсыңны көт тә тор...

Хәтердә: мөгаен, авылыбызда бу үтә дә гайре табигый хәл булгандыр: беренче класста безне укыткан Әкълимә апабыз урыс егетенә кияүгә чыкты да, ире белән Урта Азия якларына чыгып китте. Авыл халкыннан оялды, ахрысы. Ул булачак ире белән Бөре педучилищесендә танышкан. Сергей да, мин татарларны бик хөрмәт итәм, татарча сөйләшә дә беләм, дигән. Апа бик тә чибәр, тыныч характерлы иде. Яшәргә дә яшәргә иде дә бит аңа, әмма язмыш эше микән, аның гомере фаҗига белән тәмамланды. Бер ел үтте микән, Сергей авылыбызга кайтып төште. Әкълимә апа бала табудан үлгән икән. Ире аны жирләү белән юлга чыккан. Авыл халкына Әкълимә апаның зурайтылган рәсемен күрсәтеп йөрде, үзәк өзгеч жырлары да хәтердә сакланган:

Сары, сары, сап-сары
Сары пәке саплары,
Кая гына китте икән
Әкълимәнең исән чаклары.

Сергей шулай бер атналап авылда йөрде дә, юкка чыкты. Күп тә тормый хәбәр килде: Мөрсәлим станциясендә (Коньяк тимер юлы, безгә 30 чакрым) поезд астына кергән, кайгысына түзә алмаган...

Безнең эрага кадәр яшәгән Рим комедиографы Плавт: «Гашыйк булган кеше кыядан ташланган кешедән дә авыррак язмышка дучар»,— дип язып калдырган. Чыннан да шулай икән шул... Безнең эрага кадәр V гасырда яшәгән грек язучысы (шагыйрь һәм драматург) Еврипидның киңәшләре дә урынсыз түгел: «Кешеләрнең бер-берсен бик көчле яратулары кирәкми. Бәйләнешләр иркенрәк булсын, тартып китерергә дә, йомшартырга да җай калсын...»

Мәхәббәтнең күп нәрсәләргә бәйләнешле булуы бәхәссез. Отто Вайнингерның «Җенес һәм характер» дигән китабын укыгач, моңа тагын бер кат ышанасың. Ирләр мәхәббәте хатын-кызларныкыннан бик үзгә, рациональрак характерда. Халык та юкка гына: «Ирләрнең йөрәге — ашказанында, хатын-кызларның — колагында»,— дип әйтмәгәндер инде. Моның якынча мәгънәсе шулайрак: ирләр хатын-кызның чибәрлегеннән тыш, чиста, пөхтә булуларына, хуҗабикә ягына да әһәмият бирәләр. Ә хатын-кыз өчен, беренче чиратта, матур, татлы, «серле» сүзләр кадерле. Әмма дөнья үзенең коррективларын да кертә. «Крокодил»да текстлы мондый рәсем бар иде: Егет: «Мин сине кулымда гына күтәреп йөртер-

мен»,— ди. Кыз моңа каршы: «Мин моңа риза, әмма син мине машинаңа утырт һәм машина белән бергә күтәреп йөрт...» — дип җавап кайтара.

«Мәхәббәт — илаһи хисләр дөньясы» дигән тезис көнчыгыш әдәбиятында төп лейтмотив ролен уйный. «Мирас» журналы ел әйләнәсендә урта гасыр шагыйрьләренең әсәрләрен биреп бара. Һәм аларда, әлеге дә баягы, төп тема — мәхәббәт. Шулай шул, көтмәгәндә, рәссамнар ясарга яраткан матур кечкенә Амур малай, очлы угын йөрәккә китерә дә кадый. Һәм шул мизгелдән башлана адәм затында тамаша, әйтерсең лә аны алмаштырып куялар. Ул матурлана, йөзенә нурлар иңә. Канатлар үскәндәй була. Үлем, фани дөнья турында бөтенләй оныта. Күзенә ак-кара күренми. Беркемнең дә, шул җөмләдән ата-ананың да сүзе колакка керми... Әлбәттә, бәхетле мәхәббәт бәхетле гаилә төзүгә китерә. Һәркемнең үз мәхәббәте, үз язмышы. Мәсәлән, бөек француз дәүләт эшлеклесе генерал Шарль де Голль бер кичәдә чибәр генә кыз белән таныша, аның белән бии. Аз гына сөйләшеп тә алалар. Икенче көнне ул кызга гаилә төзү өчен тәкъдим ясый. Күп тә үтми туйлары була. Бу гаилә гомер буе тату, бәхетле яши. Норвегиядә, Швециядә, Финляндиядә һәркем тәпи йөри башлауга чаңгыга баса һәм гомер буе чаңгыда шуа. Шулай бервакыт булачак атаклы котыпчы (ул беренче булып Төньяк котыпны ача) Фритьоф Нансен, чаңгысы белән таудан шуып төшкәндә, бер кызның йөзе белән капланып карда ятуын күрә һәм туктап аны күтәреп торгыза. Караса, свитер кигән бу кыз бик чибәр һәм мөлаем икән. Чаңгысы сынган да, карга чумган булган. Әнә шул очраклы очрашу бу ике йөрәкне бер иткән: кыз да, егет тә бер-беренә гашыйк булганнар. Кызның әтисе профессор, ә үзе опера җырчысы икән. Бу гаилә дә гомер буе бик бәхетле яши. Берничә бала үстерәләр. Шуларның берсе — кыз бала — «Минем әтием» дигән китап язган. Ул китапны миңа да укырга насыйп булган иде. Анда чын, олы мәхәббәт турында сөйләнә...

Икенче төрле мисаллар да бар. А. С. Пушкин, М. Е. Салтыков-Щедрин кебек әдипләрнең хатыннары турында күп яздылар. Һәм тагын да язарлардыр. Пушкинның вакытсыз һәлак булуында хатыны Натальяның гаебе зур булган дигән фикерләр йөри. Хатыны аркасында Пушкин Дантес белән дуэльгә чыгарга җыенганын В. А. Жуковский ишетә һәм булдырмый кала. Шуннан соң да Наталья Дантес белән очрашуын дәвам итә... Салтыков-Щедринның хатыны да үзен әйбәт тотмый... Инде И. С. Тургеневка килгәндә, аңлашылмаучылыклар тагын да арта. Чыгышы белән ярым испан, ярым француз булган балерина Полина Виардоның никахлы үз ире була. Аларда, шул ук вакытта, кем сыйфатындадыр, әйтүе кыен, И. С. Тургенев та яши... Бөек француз язучысы Оноре де Бальзакның бай украин алпавыты хатыны пани Ганскаяга булган мәхәббәт тарихы да күпләргә аңлашылмый һәм ул фаҗига белән тәмамлана. Бу «мәхәббәт эпопеясе» 27 елга сузыла. Әдип башта панининың ире үлүен көтә. Ул үлгәч, аның туганнары Ганскаяга тигән малны бирмиләр. Бу да күпкенә вакытны һәм көчне ала. Ниһаять, ике йөрәкнең бер булып тибүенә юл ачыла. Оноре де Бальзак сөеклесен Парижга алып китә. Әмма юлда каты салкын тидерә һәм Парижга кайтып керү белән үлә. Кызганыч, чөнки ул әле артык карт та булмый. Ләкин гомер буена тәүлегенә 18-әр сәгать иҗат эше белән шөгыльләнү, ял күрмәү, көн-төн кофе эчү (йокламас өчен) әдипнең сәламәтлеген бөтенләй какшата. Беркатлы гына сорау туа: «чибәр ханымнар оясы» булган Парижда (Бальзак алар хакында да күп яза) пани Ганскаяга тиң булырлык берәрсе юк иде микән?

А. Моруаның «Александр Дюма» («Отец Дюма») дигән китабында «Өч мушкетер» һ. б. уннарча яхшы таныш романнар авторы Александр Дюманың бихисап санда (400 гә якын дип раслаучылар да бар) сөяркәләре булды, әмма законлы бер хатын белән дә тормавы әйтелә. Тик шуны да онытмыйк: ул язган романнарның саны да берничә йөз ... Чыгышы да үзенчәлекле. Революцион Конвент 27 яшьлек генерал Дюманы Вест-Индия (Америка) утрауларының берсенә комендант итеп җибәрә. Ул шунда бик чибәр, акыллы, тыңлаучан негр кызына өйләнә. Ул — Александр Дюманың әнисе... Дюма бик кунакчыл кеше була. Аның Париждагы зур өеннән кеше өзелеп тормый. Туктаусыз музыка яңгырый. Бииләр, җырлыйлар. Ә шул арада күрше бүлмәдә, әдип үзенең чираттагы романын иҗат итә. Ул шул кадәр кызу яза ки, үзе дә сизмәстән үлгән геройларны яңадан «терелтеп» китапка кертеп җибәрә. Шулай да дуслары аны бу бәләдән коткаралар: геройларының исеме язылган картон «кешеләр» ясарга тәкъдим итәләр. Ул шулай эшли дә, герой «үлү» белән, аны өстәлдән алып куя. Ярый, кайберәүләрнең уйлавы дөрес тә булсын ди, Александр Дюмада негр каныдыр да ди, шуңа күп хатыннарны яраткан ди. Ә бит «француз канлы» Виктор Гюгоның сөяркәләре дә сан ягыннан Дюманыкыннан әлләни ким бул-

маган, 80 не уздыргач та, яшьләрдәй яраткан... Жорж Сандның кыланышларына, туктаусыз сөяркә алмаштыруларына ни дияргә? М. Горькийның «Малайлыкта» («В людях») китабында Екатерина II нең мәһабәт гренадер солдатны — мич ягучыны — «күңелен күргән өчен» — таң атканда генерал итеп билгеләве турында сүз бара. Ирләрне бик яраткан шул императрица гализҗәнаплары... Бәлки кайберәүләр: «Мәхәббәт белән җенси мөнәсәбәтләр арасында нинди бәйләнеш бар?» — диярләр. Мондый сорау урынсыз. Бик күп яшь хатыннар ирләре белән аерылышуларының төп сәбәбе итеп интим тормыштан канәгать булмауларын, димәк, аларча, мәхәббәт бетүен, күрсәтәләр.

Гитлерның пропаганда министры Йозеф Геббельсның хатыны Магдалинаның тарихы да күпләрнекенә охшамаган. Ул беренче ирен — Германиянең иң бай магнатларыннан берсен ташлап, аягы зәгыйфь, чатан Геббельска кияүгә чыга. Кем әйтмешли, мәхәббәтен «идеологияләштерә». Шулай шул, кайбер хатыннарның үз логикасы-мантыйгы. Француз актрисасы (Сергей Есенинның хәләл җефете дә булып ала ул...) Дункан, «мәсәлән»: Дзержинскийны кан эчкеч дип атыйлар, бу дөрес түгел, чөнки ул белемле, тәрбияле кеше»,— дип язган. Бөек Британия фашистларының башлыгы сэр Мослиның хатыны үзенең бер китабында болай ди: «Гитлерны миллионлаган гаепсез кешеләрне концлагерьларда интектергән, крематорийларда яндырган дип сөйлиләр. Буш сүз бу. Чөнки фюрерның куллары ак һәм йомшак иде, ә андыйлар палач була алмый». Менә ханымнар мантыйгы!

Шулай да ир затларын да күккә чөеп булмый. Мәсәлән, христиан дине кануннарын бозып, Явыз Иван бик күп хатыннар белән «шаярган». Петр I дә, беренче хатынын ташлап, Балтыйк буе немецы кызына өйләнгән (тарихка ул Екатерина I булып кереп калган).

Шунсы да бар, туры мәгънәсендәге олы мәхәббәт һәркемгә дә килмәскә мөмкин. Әмма моңа карап кына дөнья җимерелми, үз юлы белән бара. В. Г. Белинский һәммә нәрсәне мәхәббәткә генә кайтарып калдырсаң, җир өсте шартлаган йөрәкләр тутырылган табутлардан торган куркыныч чүлне хәтерләтер иде дип язган. Ул мәхәббәт — тормышның поэзиясе, кояшы дип әйтсә дә, тик мәхәббәткә генә исәпләп төзелгән гаиләләрнең бәхетле булмавын яшерми. Яшьләр, ир белән хатынга әйләнгәч, үз өсләренә искиткеч зур бурыч алганнарын — балалар тәрбияләп үстерергә зарур икәнлекләрен бик яхшы белергә тиешләр. Моңа аларны өлкәннәр, ата-аналар өйрәтергә тиеш. «Бүгенге яшьләр тегеләй дә, болай»,— дип әйтергә ашыкканчы, үзебезнең кем икәнлегебезне, яшьләрне гаилә тормышына әзерләвебез дәрәҗәсен искә төшерергә тиешбез. Инде болайга китсә, В. Шекспирның, дөнья — театр, ә без аның актерлары, дигән сүзләре бик урынлы. Кем генә булмыйбыз без бу фани дөньяда: ата-анага — бала, бабай-әбигә — онык, аннан — балалар бакчасында — тәрбияләнүче, мәктәптә — укучы, вузда — студент, кияү-килен, кайнага, кайнигәч, балдыз, кайнеш, һәм ниһаять, үз балаларыбызга — әти-әни, эштә — тагын кемдер һ. б. һ. б. Боларның, һәммәсе дә мөһим, әмма ир белән хатын, әти-әни булу — аеруча җаваплысы. Нигәдер нәкъ әнә шул «рольләргә» яшьләрне өйрәтү бик начар куелган. Югарыда әйтелгән миллионнарча ятим балалар — әнә шуның нәтиҗәсе. Бүгенге җәмгыятьне ике аякка аксатучы ике нәрсә бар. Бу — егылып эчү һәм гаиләләрнең күпләп таркалуы. Кайчак мин беркатлы гына итеп эчтән елмаеп куям: әлеге проблемалар белән шөгыльләнүне милиция органнарына тапшыралар. Акыллы эш түгел бу. Милиция төзәтә алмый, кулга алып, төрмәгә утыртып куя гына ала. Ә әхлак мәсьәләсе белән мәктәп, гаилә шөгыльләнергә тиеш. Мәктәп тә, гаилә дә әлегә бу эштә көчсезләр. Ни өчен? Чөнки аларга таяныр терәк юк. Дөресрәге, алар бар, әмма тоткын хәлендәләр. Мин дини кануннар һәм шулар белән сугарылган халык традицияләрен күз алдында тотам. Гонаһтан, ата-ана зарыннан курку, «язмыштан узмыш юк, никах күктә укыла, моңда шуның күчермәсе» дигәнгә ышанулар — әхлак сыйфатларын формалаштыруда зур роль уйнаганнар. Мин беләм, бүгенге педагог галимнәрнең шактые дингә, халык традицияләренә бармак аша гына карыйлар. Аларны да аңларга була: большевик юлбашчыларны мактап диссертация язганнар ич алар. Әмма тормыш кануннары — һәммәсеннән дә өстен. Ничек тә әлеге галимнәрдән тизрәк котылу юлын эзлисе иде...

Бу уңайдан тагын бер мәсьәләгә тукталырга туры килә. Революциягә кадәр яшьләрне көчләп өйләндергәннәр, кияүгә биргәннәр дип сөйләнүләр әле дә яши. Ләкин принципта бу фикер белән килешү авыр. Чөнки бер генә ата-ана да баласына начарлык теләми. Гадәттә, алар үзләренең, башкаларның тормыш тәҗрибәсеннән чыгып, балаларының «яхшы нәселгә» кушылуын күздә тотканнар. Бүген шулай түгел мени? Әлбәттә, байлык артыннан куучылар да булгандыр. Ләкин андыйлар күп түгел. Алдан «кыз-киленнең» «колагын тешләп кую»

казакъларда гына түгел (кара: Г. Ибраһимов. «Казакъ кызы»), Европа илләрендә дә киң таралган булган һәм моңа беркем дә гаҗәпсенми У. Теккерейның «Ярмарка тщеславия» дигән әсәрнең төп героинясе — Ребекке. Ул бай катламнан түгел. Шуңа күрә туу белән аның колагын тешләп куймаганнар. Кыз затлы гаиләгә килен булып төшәргә кирәк дигән уйга килә һәм, зур тырышлыклар куеп, үз теләгенә ирешә дә. Автор Ребекке ягында. «Колак тешләү» традициясе инглиз гаиләсен һәрвакыт ныгыткан. Бу илдә аерылышуга да юл куймыйлар... Кайчан Франция турында сүз чыкса, «мәгънәле итеп» елмаялар. Янәсе, Французлар никах мәсьәләсенә җиңел карыйлар. Мин шул уйлаучыларга Эрве Базенның «Анатомия одного развода» дигән китабын укырга тәкъдим итәр идем. Ул бездә генә хатын аеру, ирне ташлап китү шалкан бәясенә дә тормый. Ә башка илләрдә бу — бик җитди мәсьәлә. Католицизм дине никахны Ходай эше дип карый һәм гаиләләрне саклауга зур өлеш кертә. Мөселман илләрендә, Будда дине хөкем сөргән җирләрдә хатын язмышы белән шаяру гадәте гомумән юк. Сүз уңаенда гына: саф, пакъ кызлар Америкада да, Европа илләрендә дә бик югары бәяләнә. Без генә бу мәсьәләдә дә чокырның иң төбенә тәгәрәп төштек, ахрысы... Бүген меңнәрчә ларек-киоскларда тәүлек әйләнәсендә яшь кызлар эшли, алар эчәләр, тәмәке көйрәтәләр. «Хуҗалары» аларны кимсетеп «телки» (тана) дип атыйлар. Бу «таналар» үзләренең киләчәген ничек күз алдына китерәләрдер, әйтүе кыен. Шуларның берсе дустына болай сөйләп тора иде: «Эш җиңел түгел, әмма хуҗа кадерне белә, ресторанга чакыра. Шулай итеп көн артыннан көн үтә».

Һиндстанда, Иранда һ. б. көнчыгыш илләрендә хатын алу бик күп чыгымнар сорый, шуңа күрә бөтенләй өйләнми калучылар да була икән. Хәзер бу илләрдә чыгымнарны киметү өчен күмәкләп туй үткәрү гадәте оешып килә.

Төрле җирдә төрле гадәт, традиция яши. Мәсәлән, Иранның рухани башлыгы имам Рухулло Хөмәйни 20 яшендә 11 яшьлек кызга өйләнә һәм гомер буе бәхетле булып яши. Африка илләрендә, бигрәк тә негрларда кызларны 11—12 яшьтән кияүгә бирү гадәте бар. Индонезиядә дә гади халык кызын тизрәк «урнаштыру» ягын карый. Заманында Урта Азиядә дә кызлар кияүгә шактый иртә чыкканнар. Совет чорында ул гадәткә «чик куелды». Бары тик украин кызлары гына 16 яшьтән кияүгә чыга алалар иде. Шулай да «социализм чорында» да үзбәк, төрекмән, таҗик кызларын, мәктәптән алып, укуларын өзеп, кияүгә бирүләр булды... Революциягә кадәр татар, башкорт кызларын да «чәчәк аткан чакларында» кияүгә бирергә тырышканнар. Гаяз Исхакыйның бер хикәясендә бөтенләй бала гына булган башкорт кызын кияүгә бирүләре вакыйгасы сурәтләнә. Сугыш вакытында 2 ел миңа Әлкә дигән башкорт авылында (Башкортстанның Салават районы. Салават батыр шул тирәдә тирмәдә туган) комбайнчы булып эшләргә туры килде. Безгә авылдан җылы ашны бер бабай (исеме Сирай, димәк, Сиражетдин) ташый иде. Бервакыт, сүз ара — сүз чыгып, бабайдан ничә яшьтә өйләнүен сорадым. Ул: «14 яшьтә мин олан атаһы инем инде»,— диде. Моңа әлләни гаҗәпләнәсе юк. М. Горькийның яраткан әбисе Акулина Ивановна (ул атасыз туган) 14 яшендә 28 яшьлек Василий Каширинга кияүгә чыккан. М. Горький үзенең бер истәлегендә Л. Н. Толстой әйткән сүзләрне китерә: Урыс кызына 14 яшьләр булдымы, ул иргә чыгу турында гына уйлый»... Булгандыр, ярый ла граф Толстойның байлыгы иксез-чиксез булган. Ә гади крестьянның (ул өстәвенә эчә әле) 10—12 балалы гаиләсеннән кызның тизрәк котылырга теләве гаҗәп нәрсә түгел. Инде бүгенге Европа илләренә килгәндә, егетләр уртача 27—28 яшьтә (гаиләне карарлык мал-фәлән җыйгач) өйләнәләр. Кызлар 19—20 яшьтә кияүгә чыгалар.

Бүген яшь гаиләләрнең саны, моннан 3—4 ел элекке белән чагыштырганда, күпкә ким. Моның сәбәпләре күптөрле һәм алар беркемгә дә сер түгел: икътисади яктан халык нык интегә. Өстәвенә халык егылып эчә. Шуның аркасында бер яктан, яңа туган балаларның саны бик азайды. Икенчедән, халык эчүдән күпләп үлә. Җәмгыять туры мәгънәсендә деградация юлына басты. Россия хатын-кызларының уртача гомере 60—62, ирләрнең 54—56 ел. Европада бу сан 75—78, Японияда 82—84. Күптән түгел «Азатлык» радиостанциясеннән бер галим чыгыш ясады. Ул болай диде: «Горбачев керткән «коры законның» бер елы эчендә халыкның гомере 4—6 елга озайды. Миллионнарның сәламәтлеге күзгә күренеп уңай якка үзгәрә башлады». Кызганыч, бу закон озак яшәмәде. Аракы ясаучы монополистлар аны «демократлар» кулы белән бүдылар. Шундый тәэсир кала: халыкны махсус, аңлы рәвештә эчерәләр. Аракының хакы элекке вакытлар белән чагыштырганда 4—5 мәртәбәгә арзанрак. Екатерина II: «Өйдә теләгәнчә эчсеннәр, эчкәннәр белән идарә итүе җиңел»,— дигән. Ахры, бүгенге житәкчеләр әлеге киңәшне тоталар... Безнең өчен иң аянычлысы шул: күршеләргә ияреп, татар

халкы да бик нык эчү юлына басты. Бу олы бер фаҗига! Күптән түгел бер халык язучысы: «Болай булмый, татар халкы бетә, президентыбызга кирәм, ул эчүчелеккә каршы закон чыгарсын»,— дигән иде үзара сөйләшкәндә. Әйе, бу идея һәртөрле яклауга, мактауга лаек. Әмма ул идея бүгенге шартларда — утопия. Ни өчен? Россия безне үзенең субъекты итеп саный гына түгел, безнең күршеләребез — Чувашия, Мари-эль, Удмуртия, Башкортостан республикалары Ульяновск, Оренбург, Киров өлкәләре дә Россия составында! Алардан аракы ташуы берни дә тормый. Хәтта бу бәладан безне таможня да коткармаячак. Алай гынамени: бездә аракы сатылмаса республикада йөрештә булган акчаларның күбесе әлеге җирләргә күчәчәк. Ә нишләргә соң? Бер укытучы мондый «киңәш» бирә: «Балаларны мәктәп шартларында ук культуралы итеп эчәргә өйрәтергә кирәк». Ул аны ничек эшләргә икәнен әйтми. Әгәр әлеге киңәш тормышка ашырлык булса, бу педагогка кимендә Нобель бүләге бирерләр иде. Мәсьәлә башкада: исерткеч бер генә төрле дә мәдәнилек, культура белән исәпләшми. Шул ачы шайтан суы, яшел елан аркасында күпме талантлар әрәм булды.

Яшәешкә, мәхәббәткә, гаиләгә кагылышлы проблемаларның һәммәсенә дә бер язмада тукталу мөмкин түгел. Козьма Прутковның «Необьятного не обнять» дигән сүзләре дә шул хакта. Әмма да ләкин йөрәккә ширпы булып кадалган бер мәсьәләне читләтеп үтеп булмый. Бу — катнаш никахлар проблемасы. Узган ел миңа Казанда чыга торган бер журнал битләрендә «Катнаш никах аркасында татар бетә!» дигән шактый күләмле публицистик материал белән чыгыш ясарга туры килгән иде. Әмма күпчелек агай-эне аны укымады, әллә күрмәмешкә салындымы, һәрхәлдә, бу хакта тел тибрәтүчеләр күренмәде. Ләкин каршы як йокламый. Премьер-министрыбызның никах эшләре буенча җаваплы хезмәткәре Р. Шәмсетдинов рус матбугатында берничә мәртәбә чыгыш ясап, катнаш никахны күкләргә чөйде, аның нигезендә мәхәббәт ята, шуңа күрә алар нык булалар дип дәлилләп маташты. Татарстан буенча миндә мәгълүматлар юк. Әмма үзбәк галимнәренең фикеренә караганда, христианнар белән мөселманнар кушылып төзелгән никах озак гомерле булмый, башка никахларга караганда, өч мәртәбә ешрак таркала. Моның булуы бик ихтимал: бер мохиттә, бер диндә тәрбия алып та, һәрвакыт уртак тел табып бетереп булмый. Инде моңа милли аерымлыклар, төрлечә фикер йөртүләр дә килеп кушылса, эшләр тагын да харап бит...

Гадәттә, катнаш никахны яклаучылар, андый никахтан сау-сәламәт, акыллы балалар туа диләр һәм мисалга Ленинны китерәләр. Без дә кайбер мисаллар китерә алабыз: К. Маркснык, А. Эйнштейнның, Л. Файхетвангерның, З. Фрейдның, Г. Гейнының, С. Цвейг һ. б. бик күпләрнең әти-әнисе — яһүдләр. В. А. Жуковский, А. С. Пушкин, М. Ю. Лермонтовта «ят каннар» булса да, йөзләрчә бөек рус язучылары, галимнәре, композиторларының әти-әнисе — урыслар. Болар гына ышандырмаса, тагын бер-ике мисал: Япония — утраулардан торган ил. Анда бары тик японнар гына яши. Һәм японнар дөньядагы иң алдынгы, тирән белемле, тәрбияле, сау-сәламәт халыкларның берсе. Корейлеләр дә шулай. Тагын бер мисал: Николай II нең әнисе — Даниянең крон-принцессасы, хатыны немец кызы (Алиса, сәнгать фәннәре кандидаты...) булган. Шулай да бу гаиләдә туган тәхет варисы Алексей гомергә терелмәслек каты авыру белән авырган. Инде татарларга килгәндә, «кан яңартасы» килгәннәрнең 4 ягы кыйбла: Әстерхан, Сарычин, Нижгар, Сарытау, Уфа, Себер, Болгар, румын һ. б. татарлар бар.

Балалар — безнең киләчәгебез, һәм бу үзе турыдан-туры тәрбиягә, бигрәк тә милли тәрбиягә бәйләнгән. К. Д. Ушинский: «Тәрбия милли характерда булса гына уңышка китерер»,— дигән. Кызганыч, совет тоталитар системасы вакытында әллә ничә буын яшьләргә дөрес тәрбия бирелмәде. Бөтен нәрсә «сыйнфый тәрбиягә», «бөек урыс» халкын мактауга корылган иде. Яшьләрне эшкә өйрәтү дә бик нык аксады. Моңа гаилә дә гаепле. Дөрес, «яшьләр проблемасы» элек тә булган. Безнең эрага кадәр Мисырда, Ассириядә, Грециядә язып калдырылган «таш дәфтәрләр» сакланган. Анда мондый юллар бар: «Яшьләр, балалар бөтенләй бозылды. Өлкәннәрне хөрмәт итмиләр, аягүрә басып каршы алмыйлар. Ахырзаман җитә, ахрысы». Ләкин кешелек яшәүдән туктамаган. Иң мөһиме: яшьләребезне чын мәгънәсендә Кеше итеп формалаштыру бу тәрбиягә бәйләнгән. Бу проблема аерым сөйләшүләрне таләп итә торган җитди мәсьәлә һәм ул киләчәк эше.

ПУБЛИЦИСТИКА

## Нәгыйм Сабиров

# МӘМДӘЛЛӘРДӘ ГЕНӘ УТЛАР ЯНА...



Әтиебезнең гомере тормышка зур планнар белән янып яшәгәндә кинәт өзелде... Коточкыч авыр хәсрәт безне тетрәндерде, зиһенебезне томалады. Безнең өчен дә яшәү тукталыр, тиешле эзеннән чыгып, тормышыбыз буталыр төсле тоелды. Шундый авыр көннәр кичергәндә, матбугатта басылган һәм кульязма формасында сакланган күп төрле хезмәтләре арасыннан аның көндәлек дәфтәрләренә тап булдык. Унбиш калын дәфтәр. Безнең өчен үтә газиз бу язмаларны әтинең васыяте итеп кабул иттек. Ул көндәлекләрне хәзер аны сагынган саен алып укыйбыз. Үзебез исән чакта аңлап бетермәгән нәрсәләрне ачыклыйбыз. Күбесеннән гыйбрәт алабыз. Ялгышларын кабатламаска кирәген искәрәбез.

Әтиебез Нәгыйм Сабир улы Сабиров элеккеге Дөбъяз районының Мәмдәл авылында туып үскән. Унөч яшеннән авыл укытучысы булып эшли башлаган, гомеренең соңгы көннәренә кадәр педагогик эшчәнлеганнән аерылмады. Белгечлеге буенча химик-биолог иде, әмма ул кызыксынмаган, ул белмәгән өлкә булмагандыр, мөгаен. Үзе яшәгән төбәктә әле дә сагынып, яратып искә төшерәләр аны, тикмәгә генә мактаулы исемнәр, әллә никадәрле дәүләт бүләкләре алмагандыр. Тормышының һәр мизгеленнән тәм табып яши белә иде ул, аны белән дә әкияттәгедәй матур гомер кичерделәр.

Әлеге көндәлек дәфтәрләре әтиебезнең дөньяны танып-белә башлаганнан алып вафатына кадәр тормышын эченә алган. Илебезнең сигез дистә елга якын тарихының чагылышы да анда, шул вакыйгаларның эчендә кайнаган авыл зыялысының аларга мөнәсәбәте дә. Бүгенге укучы өчен ул чор кешеләренең фикерләве, тормышка карашы сәеррәк булып тоелырга да мөмкин. Әмма шул инану, якты киләчәккә ихластан ышану яшәткән бит аларны.

Әтием көндәлегеннән бер өзекне мин укучылар игътибарына тәкъдим итәргә булдым. Кемнәрнеңдер анда үз язмышын яисә якыннарының тормышын тоемлавында шигем юк.

*Ләлә Сабирова-Гыймадиева,*
Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы

**1914** ел. Җир йөзен, өлгереп житкән иген басуларын кояш кызуы көйдерә, кешеләрне хәсрәт уты яндыра. Тормыш чыгырыннан чыкты, күңелләрне өметсезлек, караңгылык каплады.

Ул көнне без дә гаиләбез белән уракта идек, сугыш башлану хәбәрен шунда ишеттек. Әтиемә, беренче чираттагы запас солдат булганлыктан, шул көнне үк чыгып китәргә кирәк иде. Елаш, аһ-зар! Өлкәннәр — улларын, бала-чага атасын, абзасын озата. Муллалар да, куштан мәчет картлары да килгән, алар сугышка китүчеләрне үзләренчә юаталар, үгетлиләр: газиз ватаныбызны, падишаһ әгъзам хәзрәтләрен сакларга барасыз, диләр.

Мин ул чакта сугышны нәрсә дип тә күз алдына китерә алмый идем. Кем белән кем сугыша? Кул белән суккалашалармы? Таяклар белән үк сибешәләрме? Нинди кеше икән ул Герман? Кыска булса, безнең әти озын аяклары белән тибеп кенә очырачак аны!

Халыкның аһ-зары бәләкәй йөрәгемдә мәңге онытылмаслык булып уелып калган. Ул хәтеремә әтиемнән аерылып калу белән беркетелгән. Ятим калуымның тәүге минутлары белән...

Авылда ирләр аз калды, калганнарының да эшкә булган дәрте сүнде. Күзгә каршы явымнар башланып китте, бик яхшы уңган игеннең күп өлеше яңгыр астында череп, харап булып бетте. Ил өстендәге хәсрәт сөреме күз караңгылыгы белән кушылып, киләчәкне өметсезләндерә, йөрәкләргә авыр шом сала иде. Суык килә, яңгыр ява, җил исә, менә инде кар да оча. Сугыш бара...

Шул рәвешчә, ундүртенче елгы сугыш әнине өч бала белән тол калдырды, безне (миңа — өлкән балага — алты яшь) үксез итте.

Кышны үз йортыбызда үткәрергә булсак та, язмыш үзенекен итте. 1915 елга кергәндә әни икенче энем Гыйльмеханны тудырды. Үзе тиф белән авырый башлады. Дәү әти йортына күчеп төшәргә мәҗбүр булдык. Әнинең Шәяхмәт абыйсы гаиләсе белән дәү әти ишегалдындагы йортта яши иде. Мин Нургаяз энем белән шуларда торырга тиеш булдым. Әни дәү әтинең ак өендә авырып ята, яшь бала — Гыйльмехан — әни янында. Ул аны үзе карый алмый, башкалар баланы кагалар, тизрәк үлүен телиләр...

Ул чакта дәү әти сәүдәгәрлек итә иде, авылда аның «двор өе» һәм урта өенә терәтеп салынган кибете бар иде. Тормышлары мулдан булса да, безгә — онык-ларына ачык чырай күрсәтмәде. Өстәвенә Шәяхмәт абыйларның шау-шулы тормышларының тәртибен белми идек.

Тамак тәмугка кертә, диләр. Без дә Нургаяз энем белән хәтәр эшкә күнегеп киттек: урта өй аркылы дәү әни янына барабыз. Беребез шунда качып кала, икенчебез, ак өйгә кереп, дәү әнидән сату өчен әһәмияте беткән клиндер ватык-лары сорый. Ул кибеткә кереп чыга да, озатып, урта өй ишеген эчтән бикләп куя, үзе ак өйгә кереп китә. Шунда урта өйдә качып калганыбыз, кибеткә кереп, хәлвә, йөзем җимеше, прәннек ише нәрсәләр төйнәп чыга...

Уналтынчы елның көзендә сабак укый башладым — иске киез катаны сөйрәп, Нурмөхәммәт мулла өенә йөрим. Киез итегем кипми, мич башына куйсам да, Шәяхмәт абыйның кызлары аннан алып ыргыталар. Юеш итекләр суыкка чыккач шыкырдап ката, таеп китәм дә, лапылдап барып төшәм. Аякларым туңа, сызлый. Нургаязның исә аягына бөтенләй юк, урам чыраен күрми утыра, мескенем.

Озакламый дәү әти безне дә башка чыгарды: без яши торган өен икенче урамга күчереп салдырды. Абзар сыман нәрсә дә ясатты. Капка-койма булмаса да, үз йортыбыз бар дип әйтерлек хәзер. Атыбыз юклыктан, авыл хуҗалыгы эшләрен дәү әти белән бергә алып барырга мәҗбүр идек. Ашарыбызга да дәү әти нормалап — паеклап кына биреп тора. Әмма аның безнең кулга керү юлы бик катлаулы. Чөнки без хәзер паразит дип исәпләнәбез. Ашарыбызга бетеп, сорап барырга туры килсә:

— Әле бетте дә мени, бирәннәр! — дип кычкыралар...

Шау-шулы заманнар... Дөнья актарыла, Рәсәй Казан кайнагандай кайный. Унсигезенче елның август башында Казанга аклар бандасы — чехословаклар керүе хакында хәбәр килеп житте. Кызыл гаскәрнең чигенеп баручы бер кечкенә төркеме безнең Мәмдәлгә килеп керде. Авылның кансыз, таш йөрәкле бандит-лары шатлыктан шашындылар. Кызылларның кайсын талап, кайсын үтереп йөрделәр. Ай ярым вакыт үтте микән, Мәмдәлгә кызыл җәза отряды килде, теге бандитларны тотып, берәм-берәм атып үтерделәр...

Шушы канлы вакыйгалардан соң авыл халкы төрле катламнарга бүлгәләнә башлады. Кемнәрдер Советларга дошман карашта тора, кемнәрдер кызылларны хуплый, өченче берәүләр (болары күпчелек) уң белән сулны аера алмый буталып интегәләр иде...

Шушы елның уналтынчы октябрендә Бөтенроссия үзәк Башкарма Комитетының «Берләштерелгән хезмәт мәктәбе» турындагы положение»се игълан ителде. Авылда мәктәп ачылганда кыш җиткән иде инде. Аны «эш мәктәбе» дип аңлаттылар. Иркенләп укый-яза алганлыгымнан, мөгаллим Габделхәй абый мине икенче сыйныфка язып куйды. Бер атна укыдыммы, юкмы, өченче сыйныфка ук күчерделәр. Фән предметлары арасында безгә көнгә бер сәгать дин дәресе дә бирәләр иде. Шулай булмаса, халык борчылачак иде.

Караңгы татар авылында туып, үсеп килә торган яшь буын өчен бу мәктәп бер могҗиза булды. Безгә, дин китапларыннан башкасын күрмәгән малайларга, дөнья белеменең исе хәйран керде. Минем иң мавыкканым арифметика булды. Җәгърәфияне аңлыйм. Харита (карта) өстендә яхшы йөрим. Шигырь дигән нәрсә дә бар икән ләбаса. Коръәнне тәҗвид белән укыйбыз. Аятьләр ятлыйбыз.

* * *

**1919** ел.

Мин — йортыбызның төп хуҗасы. Унбер яшь тулып китте бит инде. Җәен хуҗалыкны үзем алып барам. Җир сукаларга чыгу өчен иртүк торып, дәү әтиләргә менеп китәм. Күп очракта әни мине ашатмый гына чыгарып җибәрә. Дәү әтиләрдә тамагы үтәр дип өметләнә. Әмма анда да иртәнге чәй миңа бик эләкми, эләккәндә дә табындагы икмәкне җир сукаларлык итеп тешләп булмый.

Менә бүген дә йокыдан уяна алмый җәфаланам. Көндез кырда ачлы-туклы эшләп йөреп арыган, талчыккан гәүдәм эреп, камыр кебек таралып ята. Арбада утырып барам, имеш, үзем тыныч, ә аягым селкенә. Уяна башлыйм да, тагын саташа-саташа йоклап китәм. Ниһаять, айнадым. Янымда әни басып тора икән, аягымны йомшак кына итеп ул селкетә. Көтү куарга җыенган, мине уятып калдыруы.

Матур май иртәсе, кояш күтәрелеп килә, өй эче яп-якты. Минем янымда, сәкедә, аяк-кулларын як-якка ташлап, үтә татлы бер тәм белән энеләрем йоклап яталар. Тып-тын. Нургяаз куенына кереп бөгәрләнгән песиебезнең генә тәмләп мырылдавы ишетелә. Оекбашларым, чабаталарым кичә кич салып калдырган урыннарында моңаешып мине көтеп утыралар иде. Башымда — әлү кагына охшаган иске кәләпүш, өстемдә — киндер күлмәк, ыштаным тагын да тупасрак киндердән булса да, өстемә ябышып тора.

Киендем. Ишек алдына чыгып, яшел чирәмгә бастым. Җәй дисәң дә, җәй! Иртәнге саф һава бөтен гәүдәне гаҗәеп бер дулкын эчендә калдырып сыйпый. Шул рәхәтлек әллә нинди зур эшләргә ашкындыра, әмма бер усал көч итәгемнән тоткан, җибәрми... Их, таза киенеп, тамагың тук булып, үз ат-туның белән, үз әтиең җитәкчелегендә йөрсәң иде аны!

Капкадан чыгып, уңга борылуга, тыкрык башланып китә. Шуның буйлап югарыга таба атлыйм, дәү әтиләргә йөз тотам. Баш аңкы-миңке, гәүдә авыр, бөтен тәнем үз алдына салынып тора, аякларыма таш такканнар төсле. Иртә белән ашыйсы килми, диләр, кая ул килмәгән, бер бөтен икмәкне кабып кына йотар идем әле. Һай, йокы да бик тәмле шул, шунда сукмак буендагы кычыткан төбенә булса да ятып чымырдап китәсе иде, их!..

Дәү әтиләр иртәнге чәйне эчеп бетереп, аш өстәлен җыештырып та куйганнар иде инде. Ашау өйдә дә юк, монда да насыйп булмады. Кичә дә ач карынга ятып йоклаган идем.

Дәү әти — ябык чытык йөзле, кәҗә сакаллы, аякларына читек өстенә чабата кигән кечкенә генә гәүдәле карт — гадәтенчә, сукранып, ишек алдында кайнаша иде. Минем ялгышларыма исе китмәгән шикелле, җылылык та күрсәтми, «улым» дип дәшкәнен ишеткәнем булмады, исемемне дә сирәк әйтә, анда да «Нәгыймҗан» дип түгел, бозып, «Наемҗан» дип атый.

Башта икәү балта кайрадык. Аннары арба төзәттек, күчәр-тәгәрмәчләрне майладык. Без кайнашкан арада күк йөзенә көнбатыштан килеп чыккан төтен сыман болыт җәелә башлады. Дәү әти сизми калды, мин өйгә элдерттем. Явым-төшем булса дип, өскә кием-салым алырга иде исәбем.

Ишек эчтән бикле, пәрдәләр төшерелгән, әни, көтүен куып кайткан да, йоклап киткән.

Ул чакта елның бу вакытында татар хатын-кызларының әллә ни эшләре юк иде. Урыс авылларында гына ул, хатыннар көтү куганчы ук бакчаларында кайнаша башлыйлар. Ә татар хатыны яшелчә үстереп мәшәкатьләнми, көтүен куып кайта да, ак беләгенә башын куеп, кабат йоклап китә. Мари басуларына карасаң да, ирләр арасында тигез санда хатын-кызлар, болында да печән чаба...

Өйалды ишегенең keләсен, бавыннан тартып, акрын гына чакылдаттым. Әни уянуын тиз уянды, әмма ишек ачарга сукранып кына чыкты:

— Әле генә яткан идем, кинәт уяндым, уф, башыма капты,— диде.

Мин, сәләмә бишмәтемне тиз генә җилфердәтеп алып чыгып, дәү әтиләргә элдерттем.

Кичә караңгыга чаклы җәфаланып та, сөреп бетерә алмый калган җиребез бар иде. Туры шунда килдек. Атларны арбадан тугарып алып, сабанга җиктек. Калдык җир генә булганга, бу эшебез әллә ни озакка сузылмады. Эше бетеп торсын дип, сабанны көчәнә-көчәнә (беребез — карт, беребез — малай) күтәреп, арбага салдык. Атларны тырмага җиктек. Мин пар ат белән өч-дүрт кат әйләнгәнче дәү әти карап, күзәтеп торды. Тырмаларга оста идем, бу юлы да сынатмадым, җиренә җиткереп эшләдем. Дәү әти эшемне ошатты гына түгел, соклан-ды да бугай. Дөрес, ул моны беркайчан да сүз белән белдерми, әмма мин аның гадәтен өйрәнеп бетергәнмен инде: өйрәтеп бер ни дә дәшмәде. Туктагач, ар-бадагы төенчеккә төртеп күрсәтте:

— Менә, ашыйсың килсә, капкаларсың,— диде.

Килмәгән кая ул! Авызга соңгы мәртәбә ризык кергәнгә нәкъ бер тәүлек була бит инде. Икмәк кыерчыгына ике куллап тотынганда күз алларым тәмам караңгыланган иде.

Дәү әти, ике кулын артына куйды да, акрын гына атлап, су тегермәненә таба китеп югалды. Мин дә, аякларымны һәйбәтләп сузып, ызанга утырдым. Эскәтерне җиргә җәеп салып, икмәк кыерчыгын суыра-суыра чәйнәп ашадым. Тамак туймаса да, хәл керде. Күз алларым яктырып, күңелләрем күтәрелеп китте. Эшкә тотындым. «Алмагачы» көенә җырлап та җибәрдем:

Карлыгач кара була, муены ала була,
Атадан яшь калган бала бәхетсез бала була...

Аннары: «Ничава, бәхетсез булмабыз әле!»— дип, җилпенеп тә куйдым.

Озакламый вак яңгыр сибәли башлады. Ул арада дәү әти дә күренде, янында башка чыккан улы Шәяхмәт абый да бар иде. Акрын гына атлап, сөйләшә-сөйләшә киләләр. Алма үз агачыннан ерак төшми, диләр. Шәяхмәт абый да дөнья куу ягыннан дәү әтигә охшаган. Сәүдә белән, төрлечә алыш-биреш эше белән көн күрә торган хәлле кеше.

Мин, атларым янында кайнашкан килеш, аларга карап:

— Абый, исәнме,— дип кычкырдым. Ул, минем сәламемне алып, елмаеп, озаклап карап торды. Мине кызгандымы, эшкә яравыма сокландымы, әтием турында уйландымы, үз кызларының бәхетен минеке белән чагыштырдымы? Аның карашы мине үртәп, елатырга тырышкан кебек тоелды. Юк, еламадым!

Яңгыр яхшы ук көчәйде. Җилли дә башлады. Дәү әти белән абый арба өстенә брезент капладылар. Арба астына атлардан калган печәнне түшәделәр дә шунда кереп чумдылар. Башларын калкытып, мин эшләгәнне күзәтеп яталар.

Тәки тырмалап бетердем. Кайтканда мин бөтенләй су эчендә идем. Ару, ачыгу, туңу тәмам үзәккә төште. Ничек кайтып җиткәнмендер, бөтен тәнем уттай кызып сәке өстендә ятканда, күз яше аралаш тирән уйларга — өметсезлекнең төпсез чоңгылына чумып, бу газаплы тормыштан котылу юлларын эзләдем. Әмма таба алмадым. Китеп кая барыйм? Өстәвенә, әнине, энеләремне калдырып, ничек чыгып качыйм? Ул чагында минем урынымны Нургаяз алачак, ул тагын да сабый бит әле. Ул да шулай яшенә тыгылып: «Абый ташлап качты шул»,— диячәк.

Мин — гаилә өчен җаваплы кеше, шулай булгач, һәммәсенә түзәргә кирәк иде.

Саташулы уйлар төшемә ялганып китте. Әнинең йомшак кына аягымны селкетүенә уянып киттем. Көн туган, кабат эш иртәсе башланган икән...

* * *

Кышын мәктәптә укып йөргән булдым. Әмма бу уку мине канәгатьләндерми, программалар артык гади, барысын да укытучы аңлатканчы ук белеп барам. Рус телен бөтенләй өйрәтмиләр. Уку белән кызыксынуым бик көчле, бигрәк тә математиканың тәмен белеп алдым. Гади вакланманы бүлү-тапкырлау бәхете миңа юлдан табылды. Берәр сәүдәгәрнең товар төреп сату өчен әзерләнгән кәгазедер инде ул, төшеп калган, күрәсең, урамда җил белән очып йөри. Табылдыгым хисап китабының берничә бите булып чыкты. Шатлыгым эчемә сыймады.

Белемне үз ихтыярым белән эскәкләп чүпләдем. Нәрсәгәдер кирәк булыр дигән уй башыма сеңәрлек дәрәҗәдә түгел идем. Күнел эзләнә, дөньяда тагын нинди гыйлемлекләр бар икәнлеген беләсе килү тынгы бирми. Әмма өйрәтүчем дә, киңәш бирүчем дә юк...

Адәм баласы көчле, табигатьне үзгәртә ала, җәмгыятьне дә сүтеп яңадан ясый, әмма дөнья, табигать, диалектика, язмыш ничек тә үзенекен эшли.

* * *

**1921** елның җәе бөтен өметләрне сүтеп ташлады. Кар сулары һәм язгы ләйсәннәрдән соң, бөтен җәй буена яңгыр таммады. Яшеллек тернәкләнә алмады, күтәрелә башлау белән көйде, корыды. Кырда кереш ашы пешереп, узган-барганнарны салкын су белән коендырып йөрүләрнең дә, төрле ырымнар белән юрауларның да, хәзрәтләр җитәкчелегендә кырда намаз укуларның да файдасы булмады. Ачлык килеп басты, хәл кот очарлык иде. Халык алдында, авызын зур ачып, ерткыч тешләрен ыржайтып, тырнакларын батырырга әзерләнеп, рәхимсез әҗәл үзе басып тора иде... Шундый заман килде: бирәүләр ачтан үлә, икенчеләр урлап карый, тотыла, аны кыйнап үтерәләр; үз авылдашлары, үз милләттәшләре, мөселманнар үтерә. Өченчеләр, халыкның ачлыгыннан файдаланып, баеп калырга тырыша. Махсус әзерлекле жуликлар пәйда булды...

Шулай да ачлыкның иң яманы икенче җәйгә чыккач — яңа икмәк көткән чагында иде. Явым-төшем күп булганлыктан, шобагасына биш пот урынына бер генә пот чәчелгән җирләребездә иген котырып уңды. Арышның өлгереп җиткәнен дә көтеп бетерә алмадык, бер йөк көлтә урып алып, кояшта киптереп суктык. Аны кул арбасына салып, су тегермәненә тартып төштем. Чират зур, халык күп, һәркемдә бер хәл бит. Ниһаять, ике пот арышымны онга әйләндерү бәхетенә ирештем. Ул ике пот онны сөяп куйгандай текә таудан тартып менәсе бар иде. Хәлем юк, ачмын. Өстәвенә, йокламыйча чират саклаган бит әле. Арбаны тауга каршы өстерим, ә он капчыклары мине аска тартып төшерә...

Ул көнне өй эче барыбер яңа арыш икмәге исе белән тулды. Шул рәвешле, бәхетле көнгә үлмичә килеп җиттек.

Быел (1922) үз игенебезне дәү әтидән аерым иктек. Көзне ярыйсы гына мул каршыладык. Тамак тук булгач, миндә янә уку дәрте кабынып, дөрләп китте. Әмма кая барасың? Авылда башлангыч мәктәп кенә, анда җитәрлек утырдым инде. Читкә китәргә чама юк. Акча кирәк, акча табарлык үнәрем юк. Кемгәдер ялланып, хезмәт хакы алырлык чамам юк. Шулай да бер нәрсә уйлап таптым: кырда игене җыеп алынган җирләрдән башак җыям. Сатарлык арышым булды. Әни белән киңәшкәннән соң, күрше Яңавылга барып укырга ниятләдем. Анда да башлангыч мәктәп, әмма укытучысы бик галим кеше икән, урысчага да әйбәт өйрәтә, ди. Миңа нәкъ менә шунысы кирәк тә.

Уку тиз башланмады, көзне үз ирегемдә үткәрдем. Каралтыга терәп төз лапас ясадым, чабата тукыдым, уйнадым, таба алганда, китап укыдым. Төнлә уянып, йоклый алмыйча, төрле уйларга чумып яткан чакларым күп булды. «Педагогик эшчәнлегем»не башлап җибәрдем: энеләремне укытам. Дин дәресләре бирәм, ана телендә укырга-язарга өйрәтәм. Әмма алар минем өчен дип кенә укыйлар, уенга чыгып таярга гына торалар.

Яңавылга да уку беткәнче йөри алмадым. Әни алып кайтып китте.

— Үлсәк, бергә үләрбез,— диде.

Коточкыч хәбәр таралган: күктән иксез-чиксез зурлыкта койрыклы йолдыз төшеп килә, ди. Бөтен дөнья берьюлы һәлак булачак икән. Әни ышангач, мин дә аның дөреслегенә шикләнмәдем. Шунысына гына акылым җитмәде: аерым үлсәң ни дә, бергә үлсәң ни?

Хикмәти хода, ул койрыклы йолдыз төшмәде тагын, һәлакәт булмыйча калды. (Бу хәбәр соңга калып таралган булса кирәк. Егерме икенче елда комета күренгән бит. Беркатлы халык аның турындагы хәбәрне шул комета узып киткәч тә, таратуын дәвам иткән булса кирәк).

1923 елның көзендә авыл мәктәбенә договор белән ялланып укытырга кеше кирәк булды. Шундый «гыйлемле» һәм төрле шартларга җиңел күнә торган кеше табылмагач, авыл башлыклары миңа тәкъдим ясадылар. Хәйран калам: ни уйлап риза булдым икән мин? Акчасыннан да бигрәк, эше кадерле иде шул: халык арасында булам, кирәкле кеше булам, дип, күндем. Өмет белән дәртләнеп әзерләндем.

Шулай итеп, мөгаллим булдым. Укытам. Рәтен белеп эшләвем түгел, әлбәттә. Нәрсә ул программа, план — берсен дә белмим. Предметларның дәрес саны хакында да берәүнең дә аңлатканы юк. Әмма укытам. Үземчә балаларны сыйныфларга да бүлеп куйдым.

Унбиш яшь тулмаган үсмер идем әле ул вакытта, шулай да үзем белгәннең күп өлешен укучыларга бирә алдым шикелле. Бала баланы яхшы аңлый. Мин бу «ачышым»нан педагог булып үсә барган саен киңрәк файдалана башладым: дәрес материалын балаларга үзләре аркылы бирәм. Мәсәлән, булачак дәрес материалын үзләре әзерлиләр, класста үзләре сөйлиләр, миңа төзәтергә, тулыландырырга, шомартырга, кабатлап, ныгытырга гына кала.

Укучыларымның күбесе үземнән бер-ике яшькә генә кече, араларында хәтта яшьтәшләрем дә бар иде. Бер үк мәктәптә төшкә кадәр мин фән дәресләре укытам, төштән соң ишан мөрите дин сабагы бирә иде. Анысын әти-әниләре мәҗбүр иткәнгә тыңлыйлар, ә минем сабаклар балаларның үзләре өчен кызыклы. Күпчелек минем якта. Әмма ишан мөрите Гәрәй абзый бит сыпырып сәдака җыя, мин исә бер тиенсезгә селкенеп йөрим. Договор дигән нәрсәнең көче юк, ата-ана акча бирми.

Гәрәй абзый дөньяны кочаклап алган кеше. Хәлфәлек итсә дә, күп вакытта өйдә булмый. Андый чакларда аның урынына үзем керәм. Дин белеме ягыннан куркыныч юк, мин аны Гәрәйнең үзеннән шәбрәк беләм. Моны балаларның үзләренә дә ачык итеп сиздереп куям. Бу инде: «Атна-кич Гәрәй абзыйга бирә торган сәдака акчагызны миңа тамызсагыз да ярый», дигән сүз. Чынлап та, бер-ике очракта шулай җыйдым. Әмма бервакыт үз дәресемдә Тукайның «Авыл мәдрәсәсе»н («Мәдрәсә дип, нәрсәдер асрый агайлар җилкәсе») укып, «сәдака эше»н боздым. Хәер, минем хәйләне Гәрәй абзый болай да сизгән иде инде: сәдака көнен ташлап, беркая да китми башлады.

Тиешле хезмәт хакымны башкача тәки ала алмадым. Болай булмас, ахры, дип, теләнче кебек булса да, договор акчамны җыярга чыктым. Бераз булды булуын, тик бик аз шул. Аннары алай соранып йөрүемне дә ташладым. Бер ишләреннән тормыш хәленә кереп үзем алмадым, икенчеләре, төрле сылтаулар табып, үзләре бирмәде. Кара фикерле Шәрифә Тажие, ишек алларына килеп кергәч, каршыма үзе чыкты. Сәламемне дә алмыйча, мыскыллап елмайды:

— Син сәвит сабагы укытып йөрдең, акчасын да сәвиттән сора,— диде. Төкердем дә чыгып киттем. Башкаларга кереп тә тормадым. Өйгә кайттым да акча җыю өчен төзелгән исемлекне ерткалап, учакка аттым.

...Мин үземне кар-буран эчендә адашып калган мосафир кебек хис итәм. Максатым ачык — укымышлы кеше буласым килә. Әмма юлдашым, киңәшчем юк, юл күрсәтүче маягым юк. Укый торган урын бардыр ул, тик хәерче килеш сәләмәләремне җилфердәтеп кая барыйм?

* * *

**1925** елның җәендә авылда китапханә ачу минем өчен бик сөенечле вакыйга булып истә калган. Буш вакыт килеп чыгу белән шунда чабам. Китапханә хуҗасы Фатыйма апа китапларны өйгә дә биреп җибәрә. Ул үзе авылда комсомол ячейкасы секретаре хезмәтен дә алып бара иде. Бервакыт Фатыйма апа мине комсомолга керергә үгетли башлады. Мин күндем. Бик матур иде шул ул Фатыйма апа.

Шулай итеп, ике дөнья эчендә бутала башладым. Комсомол җыелышларында катнашам, дингә каршы докладлар тыңлыйм. Үзем җомга намазын да калдырмыйм. Әнине рәнҗетәсе, елатасы килми бит.

Ул җәйне минем өчен тагын бер зур вакыйга булды: кем инициативасы белән булгандыр, Арчага укытучыларның җәйге курсларына укырга җибәрделәр. Әнине ничек күндергәнмендер, ниләр әйтеп көйләгәнмендер, әмма мин бу вакыйганы зур шатлык белән кабул иттем. Тик өйдән чыгып китү шартлары коточкыч иде: печән чабып җыярга кайтып китәргә тиешмен; кием-салым, урын-җир, ашау-эчү сорамыйм. Баласының яшьлек ярсуына гаҗәпләнеп, әни: «Ике ай буе ничек яшәрсең икән соң син?»— дип тә сорый алмады.

Укулар тоткарлыксыз башланып китте. Ит күрмәгән бичарага үпкә-бавыр да тансык, дигәндәй, миңа монда бар да гаҗәп, бар да кызык. Әмма мин ач! Юлда килгәндә үк ач идем, курслар башланып, ашханәдә ашый башлаганчы монда да авызыма ризык кергәне булмады. Ашханәдә унбиш көн саен исәп-хисап ясыйлар. Шуннан файдаланып, мин бер унбиш көннең туенуын акчалата алдым — чөнки



*Арча. Укытучыларның белемен күтәрү курсларында. Әти — беренче рәттә, сулдан беренче. 1929 ел.*

кайтырга юлга акча кирәк иде. Шул унбиш көн дәвамында көнгә ярты кадак икмәк ашап, су эчеп яшәдем. Өстәвенә, алыштырырга күлмәгем, каралганын юарга сабыным юк. Иртән халык йокыдан уянганчы (без Арча мәктәбенең классларында урнашып яшәдек) мичләрдән көл дә эзләп карадым. Юк. Иске сандалиларым да тәмам эштән чыкты. Базар мәйданыннан, эзләнеп, җеп, тимерчыбык кисәкләре табып, тегештереп куйдым. Чәчем котырып үсте, чәчтарашка барырга акчам юк...

Курсларны, ниһаять, тәмамлап, авылга кайту юлым да истә калырлык булды. Казанга төнлә килеп төштем. Кая да булса фатирга керергә кыяфәтем юк иде, вокзалда калдым. Әмма вокзал хуҗалары — ватандашларым мине урамга куып чыгардылар. Кешелекле булырга өйрәтмәгәннәрдер шул аларны. Кем белә, Ленинны да укымаганнардыр әле. Вокзал эчендә кешеләр күп калды, бары тик мине һәм агач аяклы бер теләнчене генә куып чыгардылар.

Вокзал каршысындагы эскәмиядә төн уздырырга булдым. Кечкенә мендәр белән тастымал хәтле генә киез салынган капчыгымны яныма куйдым. Ничек йоклап киткәнемне белмим. Уянып киткәндә, кояш шактый күтәрелгән, урамда хәрәкәт башланган иде инде. Әйләнә-тирәмдә йон-мамык оча. Капчыгым ярылган, аңа, күрәсең, пычак тыгып чыгарганнар. Мендәр йоны бөтен тирә-юнемне тутырган.

...Ул җәйне күргән газапларым бушка китмәде — көзен мине авылда штатный укытучы итеп билгеләделәр. Тормыш рәтләнеп китте. Уңыш та яхшы булгач, тамак та тугая, өс-баш та бөтәя төште. Күңел күтәренкеләнде.

Әмма монда минем дус-иш юк. Тол хатын малаеның, йолкыш-хәерченең кемгә кирәге булсын! Хәзер исә авылның бердәнбер интеллигент кисәге, гүя, ят-чит кеше, өстәвенә, комсомол...

Беркөн шулай әни өйдә авырып ятканда, безгә берәү килеп керде: башында фуражка, аякларында итекләр, өстендә шинель.

— Комсомол ячейкасының эшләре синдә икән,— диде.

«Миндә» дисәм, моны авыру әни ишетеп, «диннән язгансың икән»,— дип ачуланачак.

— Юк, миндә түгел,— дип ялганладым.

Бу кеше волком секретаре булачак Солтан Игъламов булып чыкты. Мин аңа соңыннан хәлне аңлатып бирдем. Ул бу мәсьәләне партиянең волость комитеты

алдына куйган. Утырыш барышында волком секретаре тәмам чыгырыннан чыкты, мине котырып-котырып сүкте, нәсел-нәсәбемне дә искә төшерде. Мәгариф бүлеге мөдире коммунист Зәйнәп апа Мостафина тизрәк беддерү белән чыгарга ашыкты: мине укытучы итеп тотмаячак. Тавышка куелды — мин «очтым»...

Ишкәкләре сынып, җилкәннәре давылга очып, су уртасында калган көймәче кебек, тормыш дингезе уртасында утырып калдым. Хәзер минем хезмәт хакы килә торган эшем юк.

Әмма бу вакытлы халәт кенә булды. Волкомдагы иптәшләр әллә миңа җәза кискенрәк бирелде дип уйладылар, әллә мине алыштырырга кеше табылмады — күрше Олы Кавал авылына кабат укытучы итеп дәштеләр.

Минем янга икенче укытучы булып Лотфи Насыйбуллин дигән егет килде. Минем белән чагыштырганда аның тышкы кыяфәте үк «фәләнчә» иде: кирәге булмаса да күзлектән йөри, башында мех фуражка, өстендә шәп якалы пальто, кыш көне дә ботинкадан йөри, үзен бик өстен куеп сөйләшә, бик белемле булып кыланырга ярата. Бервакыт истә калырлык вакыйга булып алды. Авылга агроном килде. Рус кешесе. Актив җыелышы ясадык. Агроном авыл хуҗалыгы темасына доклад укыды. Халыкның күпчелеге русча аңламый иде, татарчага тәрҗемә итәргә кирәк булды. Шунда вәкарь белән генә Лотфулла чыгып басты:

— Үзем тәрҗемә итәрмен,— дип белдерде. Мин хәйран калдым. Чөнки зур эш. Русча белү генә дә җитми, авыл хуҗалыгын фән буларак аңларга кирәк.

Лотфи «тәрҗемә итә» башлады. Сүтә, малай, ялганлап. Агроном сөйләгәннәрне бөтенләй әйтми, үзе ясап сөйли.

Герман сугышында бер кулы өзелгән Заһир абый почмакта елмаеп кына утырып тора иде. Лотфиның кыланышы чамадан аша башлагач, түзмәде, каеры тунының кулсыз җиңен биленә шап итеп сукты да, берәүдән дә рөхсәт-фәлән сорап тормыйча, урыныннан сикереп торды:

— Ю-ук, Лотфулла нәнә, алай дими ул,— дип, агрономның сүзләрен халыкка аңлатып бирә башлады.

Лотфиның болай да кызыл йөзе ахакка әйләнде.

* * *

**1926** ел.

...Авылның избачы Хәйрулла Вәлиуллин белән активлашып киттек. Булдыра алганча кичәләр үткәрәбез, докладлар әзерлибез, яшьләрне туплап, спектакльләр куябыз. Хәйрулланың тырышлыгы белән радиоалгыч алуга ирештек. Күмәкләшеп радио тыңлыйбыз. Әмма авыл халкы тавышның Казаннан ук килгәненә ышанмый. «Килер бер көн,— дим мин,— ерактан сөйләүченең тавышын ишетү генә түгел, үзен дә күрә башларбыз». Бу сүзгә берәү дә ышанмый, мыскыллы көләләр генә.

Без мондый нәрсә уйлап таптык: авыл егете Шакир абый Зариповны Казанга, радиостудиягә барырга үгетләдек.

Кичен кабат уку өенә җыйналдык. Хәйрулла радиоалгычны көйләп куйды. Халык шыгрым тулы булса да, шул тикле тынлык, кырмыска кыштырдаганы да ишетелер иде.

— Тыңлагыз, Казан сөйли...

Халык «әһ» итеп куйды. Радио Арча кантоны Мәмдәл волосте Зур Кавал авыл кешесе Шакир Зариповка сүз бирде.

— Исәнмесез, каваллар!

Берничә генә сүз әйтә алды Шакир абый. Әмма безгә шул җитте. Шуннан соң радиога ышанмаган кеше калмады. Хәзер радио бер кызык нәрсәгә генә түгел, чын документка әйләнде. «Радио болай дип әйтте, радио тегеләй дип әйтте»,— дип, төрле вакыйгаларга дәлил итеп йөртә башладылар.

Безнең өстә культура-агарту эше генә түгел, хуҗалык кампаниясен дә волком безгә тапшыра. Икмәк әзерләүдә катнашабыз, заем таратабыз, үзара ярдәмләшү комитетын җитәклибез. Вәлиуллин белән Насыйбуллин — комсомоллар, ә мин — билетсыз. Алар арасында догадан мәхрүм калган әрвах сыман булып йөрим. Ә авылда сыйнфый көрәш бара, зур көрәш, куркыныч көрәш. Дошманның кем, кайда икәнлеген белеп булмый. Политик белемебез сай, ә партия политикасын аңларга кирәк. Крестьянга батракка таянып эшли белегез, дип өйрәтәләр безне. Урта хәллесенә Ленин күрсәткәнчә карагыз, диләр. Аны кулактан аера белергә кирәк бит әле. Кулак алдында каушап калмыйбыз анысы, налогын да, икмәген

дә суырып кына алабыз. Җитәкче органнарга алай да ярап булмый. Волость үзәгенә, җыелышка чакырып алалар да, аяк өсте бастырып сүгәләр. Нинди генә мыскыл сүзе ишетмибез!

Бу заманда телефон юк әле, волость үзәге Мәмдәлдән кантон үзәге Арчага сузылган чыбык кына бар. Авыл арасында хәбәрләр кеше аркылы йөри. Бер көнне миңа волостьтан язу китергәннәр: кичке унга волбашкармага килеп җитәргә.

Килеп җиттем. Түрдә ике-өч начальник утыра. Артта ят бер кеше — кантон вәкиле басып тора. Залдагылар күп түгел: авыл советларыннан биш-алты кеше, шулкадәр үк укытучылар. Беренче итеп, рәислек итүче миңа дәште. Исем-фамилия белән дә, «иптәш» дип тә түгел:

— Кавал!

Сикереп торып бастым. Үземне суд алдындагы җинаятьче итеп сизәм.

— Соң, кулаклар бик рәхмәт укыдымы үзенә? — ди рәис дорфа гына.

Ачуым бугазыма утырды, хурландым. Шулай да сабырлыгымны җыеп:

— Берни аңламыйм, — дия алдым.

Теге урыныннан ук сикереп торды, кызып-кызып сүгәргә тотынды:

— Аңламассың шул, ачык авыз булып, сыйнфый сизгерлегеңне югалткач! — диде.

«Кантон вәкиле гайрәтлелегемне күрсен әле», дигәндәй, акырып-кычкырып тирги, политик сүзләрне урынлы-урынсыз сибә. Чыннан да, кантон вәкиле аңа «молодец» дигән төсле карап алды, «Бу егет кайсы авыл советы рәисе?» — дип сорады.

— Рәис түгел ул, укытучы, — диде теге.

Вәкил артка таба чайкалып китте:

— Укытучы?! — дип гаҗәпләнеп сорады. — Укытучының эше бик зур һәм җаваплы — укыту һәм коммунистик тәрбия бирү. Ә сез икмәк әзерләү эшен аңа тапшырып, аны төп хезмәтеннән аерасыз. Волость үзәгендә — үзегез, авылларда — авыл советы кул кушырып утырасыз... — дип башлап китеп, тетмәсен тетте рәиснең.

* * *

**1927** елга аяк бастык. Бер заман телгә Солтангалиев исеме килеп керде. Кем ул, кайдан килеп чыккан, нинди гаебе бар? Без моңа җавап бирә белмибез. Сораганнарга: «Начар кеше ул!» — дип кенә әйтә алабыз.

Солтангалиевчелеккә каршы җыелыш арты җыелыш булып тора, аның хакында газеталарда языла, әмма нинди гаебе барлыгын барыбер аңлый алмыйбыз. Аңа каршы җыелышларда чыгыш ясамасаң, сине дә солтангалиевчелектә гаеплиләр. Кулга алулар да ишетелә.

...Җыелышларда президиумда утыручыларны күрә идем дә, болай уйлый идем: «Бу кешеләр үзләренең шәхси тормышлары хакында бер дә кайгыртмыйлар, җәмәгать эше буенча туктаусыз йөреп торалар. Керсез, саф кешеләр, партия эшенә, власть эшенә бөтен гомерләрен багышлаганнар». Соклана идем шуларга, шуңа күрә үз тормышымны уйларга ояла идем...

Бу җәйдә Кинешма шәһәренә — әнинең энесе Галим абыйларга кунакка бардым. Аның белән бер заводта теге чакта мине комсомолдан алып очыруда ярдәм иткән Солтан Игъламов та эшли иде. Алар икесе дә хәзер — эшче сыйныфы вәкилләре. Хезмәтләре, бәхәсләшмим, авырдыр. Анысы миңа күренми. Минем өчен кызыклысы шул: өйгә кайткач, гел үз тормышларын гына кайгырталар: ашау-эчүне планлаштыралар. Тәмле дә булсын, арзанга да төшсен, кайбер нәрсә бушка да эләксен, ягулык дәүләт исәбенә булсын, өс-баш киемен дә арзангарак эләктерергә кирәк... Өйдә завод хәле, гомумән, иҗтимагый тормыш турында сөйләшү бөтенләй юк. Хәлбуки, абый да, Солтан да — коммунистлар.

Менә шундый капма-каршы күренешләр, аларны аңларга тырышу белән бәргәләнеп көннәрем уза.

Энергиям ташып тора. Педагогик эшкә вакытны да, көчне дә күбрәк куям. Шулай булырга тиешлектән генә түгел, омтылышым, мәхәббәтем шуны таләп итә. Җәмгыять системабызны өйрәнәм. Партия, совет, комсомол, пионер нәрсә — үзем өйрәнеп, балаларга өйрәтәм. Үз ягыбызның тарихын өйрәнү эшенә дә керештем. Дәрестән тыш вакытларда укучыларыма җырлар өйрәтәм. Халык көйләренә сүзләрен үзем язам — иске халык җырларын өйрәтүне югарыда «дәү абыйлар» яратмый, тыялар.

**1929** елның кышына кергәч, эшләр тагын да житдиләнеп китте: колхоз оештыра башладык. Авылда иң төп ярдәмчеләребез — Габит Вәлие белән Нәмәтә Ярулласы иде. Әмма алар да колхозны үзләренчә аңлый: аның төп максаты крестьянның хезмәтен жиңеләйтү, тормышын яхшырту һәм баету булырга тиеш, диләр. Берничә генә хужалыкны ияртеп, авылдан чыгып китәргә дә, таба кебек тип-тигез Бәйрәт басуына күчеп утырырга хыялланалар. Ягъни эксплуатациясез генә янача кулак булалар. Бу хакта әйткәч, Вәли абый кеткелдәп көлде:

— Ник, кеше көченнән файдаланмагач ярый ул,— диде.

— Юк, Вәли абый,— мин әйтәм,— элек дәүләт интересын карарга кирәк,— дим.— Партия өйрәткәнчә, илне — азык белән, промышленностьны чимал белән тәэмин итү өчен товарлыклы эре социалистик авыл хужалыгы производствосы кирәклеген, вак крестьян хужалыгының илне тәэмин итә алмаячагын аңлатам. Колхоз системасы аша крестьянның үз тормышы да хәл ителәчәк. Хезмәт жиңеләячәк, чөнки заман тудырган зур техниканы колхоз хужалыгының ызансыз кырларына гына кертеп була.

Эш авыр барды. Менә колхозчы булып эшләрлек, үз кул көче белән әйбәт кенә дөнья көтә белгән агайларны өстерәп тә колхозга кертеп булмый. Әйе, агайның иманы булып жанына һәм канына сеңгән хосусый милекчелек, шәхси тормыш аны тотып тора. Шуннан аерылса, аңа дөнья жимерелер, шул дәһшәт эчендә имансыз калыр төсле. Ә без теләмәгәннәрне колхозга алуны сорап, үзләре гариза күтәреп киләләр, йөдәтеп бетерәләр.

Без, актив, ике көннең берендә волкомга чакырылабыз; төн йокысы юк: теләсә нәрсә эшләргә, теләсә ничек аңлатырга, әмма колхозны булдырырга! Аңлаттык. «Галиябану»дагы Бәдри әйтмешли, «аңлаткач, аңладылар». Кайберсен шүрләттек, куркыттык, янадык, кайберсен, үзе теләмәсә дә, колхоз әгъзасы иттек. Колхоз оешты. Әмма... төзелеп бетеп, бер-ике көн торгач та таралды, пыр тузды. Безнең хезмәт тә жилгә очты.

Ат, арба-чана, дирбия, сабан-тырма кебекләрнең исәбен алырга билгеләнгән Кырый Газизулласы сыер-сарыкларны һәм кош-кортларны да санап йөргән. Шуның өстәвенә кемнеңдер авызыннан «алтмыш метрлы юрган» сүзе дә таралган. Шул хәлләрдән соң халык курыккан, котырган. Авыл советына груһ-груһ булып киләләр, чыдап кына тор!

— Гаризамны кире бирегез!

— Калхуз булыр хәлем юк!

— Бирегез гаризамны!

Авыл советы секретаре Каюм абый Әкбирев барлык гариза кәгазьләрен учлап алып тәрәзәдән томырды.

Авылда партия оешмасы юк. Булырга тиеш дигән төшенчә дә юк.

Партиялеме син, партиясезме — ижтимагый жаваплы эш авылдагы укытучыларның берсе өстенә төшә. Олы Кавалда мин инде ул. Авыл советы ул миннән кала гына. Һәр жирдә шулай.

Менә волисполком бинасында чираттагы жыелыш. Икенче кеше итеп мине бастырдылар.

— Колхозны ник тараттың?!

Ниләр генә ишетмәдем. Соңгы сүз итеп шуны әйттеләр:

— Йоклама. Кайт та колхозыңны яңадан оештыр.

Йокламадым. Эшне әр-яңадан башлап жибәрдем.

**1930** елның 5 февралендә коллективлаштыруның темпы хакында Үзәк Комитетның карары булды. Урыннарда шул карарның үтәлешен тикшерү башланды. Мин, волком исеменнән, ике колхозчыны ияртеп чыгып, тау башы Әхмәтжанны раскулачивать иттем: бер бозау, бер дини китап табып чыктым. Димәк, кулак Үзәк Комитет карарын бездән алда ук белгән, Әхмәтжан йортында сәнәк белән айкасаң да, башка бер нәрсә дә эләкмәячәк. Хатыны, фонарь яндырып, идән астында бәрәңге чүпли, бармак башы хәтле ул бәрәңге идән астының төбенә генә җәелгән. Әхмәтжан үзе тунын кигән дә түр башында утыра, бүрәнә күк бармаклары белән өстәл өстен тыпырдата: әнә, тапсагыз алыгыз, янәсе. Ә малны бик оста яшергән. Кыскасы, Әхмәтжан кебекләргә, һичшиксез, карарны алдан белеп торган коммунистлар үзләре үк ярдәм иткәннәр, башкача булуы мөмкин түгел.

Авылдагы ике мәчетнең берсен мәктәп иткән идек. Вакытлар тагын үзгәреп китте, чигенү килде. 2 мартта Сталинның «Уңышлардан баш әйләнү» исемле мәкаләсе басылып чыкты. Почта, гадәттә, туры үземә килә, әле ул миңа газеталарны китереп житкермәгән иде, авылның ата контры — Сүтә Сабиры капкама шакыды. Кулында — газета, шаккатып калдым. Сабир:

— Нәгыйм әфәнде, безгә мәктәп ачкычын бир әле, без, мөселманнар, шунда җыелып, иптәшебез Сталинның сүзләрен укыйбыз,— дип вәземләде. Миндә бер төрле дә информация юк иде, ни дип тә җавап бирә алмадым. Өстәвенә, капка астындагы ачыклыктан ун пардан артык аяк күренә. Волость белән сөйләшеп алырга телефон да юк.

Ачкычны Сабир кулына бирмичә, үзем алар белән бергә мәктәпкә киттем. Хурланам, үземне әсир төшкән солдат хәлендә сизәм. Мәктәпне ачып керттем. Тегеләр, үтерелгән бәрән янына җыелган бүре өере шикелле тупланып, миңа карап торалар.

— Мәкаләне бозып укымагыз, провакация таралырлык булмасын,— дигән булдым да кайтып киттем. Өйдә үземә дә газета китергәннәр. Мәкаләне бөртекләп укып чыктым. Нишләргә дә белмим, киңәшләшер кешем юк. Ат җигеп, волкомга киттем. Әмма анда да халыкны җыеп әлеге атаклы мәкаләне аңлату эшен минем үземә йөкләделәр.

Эшләр кабат кирегә сүтелә башлады. Мәчетнең урта ишегендә ай итеп кисеп ябыштырылган клеенка кисәге бар иде, аннан укытучы Рәүф абый чебен үтерергә чапалак ясаган икән. Мәчет куштаннары шуны таптыра башладылар.

Мәннәф Мәрданов дигән егет авылда Осавиахим оешмасын җитәкли иде. Оешма әгъзаларын винтовкадан атарга өйрәткән. Атып, мәчет манарасының гөмбәзен тишкәләгәннәр. Мәннәф хәзер картлар каршында суд хөкеме көткән җинаятьче кебек басып тора. Тегеләр манарага яңа гөмбәз куюны таләп итәләр. Бәхеткә, оешма әгъзаларының икесе әлеге мәчет куштаннарының малайлары булып чыкты, бу тавыш озакка бармады.

«Уңышлардан баш әйләнү» колхозны дер селкетеп алды. Крестьяннарның бер өлеше тагын колхоздан күтәренеп чыгып китте. Без дә көчләми башладык.

Шундый «бураннар»ны үткәреп, язга килеп чыкканда, эшләр кабат җайга салына башлады. Халыкның байтагы кабат колхозга керде. Мәчет тә җинел генә яңадан безнең кулга күчте. Әмма шул көннәрдә авылда бер гаҗәп хәбәр таралды:

— Һәр таңда манарада фәрештәләр азан әйтә!

Бу ни хәл? Эзләнәм, койрыгы пешкән мәче сыман чабам. Мәктәпне (мәчетне) ике йозак белән биклим, «фәрештәләр» керергә юл юк. Ә азанны һаман ишетәләр. Мәктәп эчендә кунып та карадым. Соңыннан гына белдем: үземнең фатир хуҗасы Сәфәр карт, чорма тәрәзәсеннән башын тыгып, азан кычкыра имеш!

* * *

Мин үземне бик зур кеше итеп сизәм хәзер. Ник, шулай булмый ни! Ел саен җәйге каникулда Арчада укытучылар курсында укыдым. Быел менә җидееллык белемем барлыкка документ алып кайттым. Читтән торып педагогия техникумына укырга кердем. Хәйран барам. Яхшы беләм: бәхет ул мине үзе эзләп йөрми, мин аны үзем эзләп табарга тиешмен. Әмма бәхет эзләү алымын миңа өйрәтүче юк. Үземне үзем белә башлаганнан бирле үз тәрбиямдә яшим. Киңәш бирүчем дә, тормышның хәтәр сукмакларыннан җитәкләүчем дә юк. Хәятем диңгезендә алга таба да йөздем, артка таба да киткәләдем. Бата башлаганда үземне үзем коткарып та калдым. Тормыш сорауларын кайсын дөрес, кайсын ялгыш-йолгыш чиштем. Дәресләре белән гомер итә тордым, ялгышлары үкенечкә кала бирде...

* * *

**1931** ел минем өчен истәлекле вакыйгаларга бай булды. Гаилә кордым, романтика эзләп, шәһәргә чыгып киттек. Яшь йөрәк исәрлеге, дөнья җитми! Эш табылды, «Кызыл Татарстан» газетасына әдәби хезмәткәр булып кердем. Редактор Исхак абый Еникеев гайрәтле карашы белән миңа күз ташлады:

— Укытучы, дисең? Алайса, грамотный инде син, яхшы язасың?

— Булдырам!— дип ярып әйттем.

— Авыл хуҗалыгы бүлегендә эшләрсең,— дип, Исхак абый ризалыгын бирде.— Хезмәт хакың алты айга кадәр 60 сум булыр, шуннан соң күрербез. (60 сумга бер генә ай эшләдем. Шуннан соң 120 сум ала башладым, бераз каләм хакы да керә иде).

Редакция булгач, төрле кеше керә-чыга йөри. Менә атаклы шагыйрь булып үсеп җиткән Һади Такташ җилфердәп килеп керә, җаваплы секретарь Әхмәт Исхакның өстәл башындагы урындыгына килеп утыра, эшенә комачаулый. Кәрим Тинчурин да керсә, шул урындыкка килеп утыра. Ул аз сүзле, безнең эшләгәнне тыныч кына күзәтеп утыра. Астагы каттан, чыркылдап, «Азат хатын» журналы редакторы Гөлчирә апа Гафурова менә. Татиздат управляющие Самат абый Шәрәфетдинов та бездә еш була. Такташтан зарлангалый. Дон Кихот итеп ясалган мундштугына папирос кыстыра да, үпкәләгән бала тавышы белән сөйли:

— Такташтан качып кердем,— ди.— Язылмаган, кайчан язылачагы да билгеле булмаган шигырьләренә акча сорый. Үзәккә үтте инде...

Кави Нәҗми һәрчак хәрби мундирдан йөри. Тыйнак, гади кеше. Очраганда таныса-танымаса да, сәламләшмичә китми...

Түгелеп-чәчелеп, зур портфелен тотып, Фатих Сәйфи-Казанлы килгәли.

Бу вакытта редакциянең игъланнар бүлегендә Галиәсгар абзый Камал эшли иде. Драматурглык шөһрәте беткән иде инде, үзен бик кимсетәләр иде. Эчкәли иде, шул кимчелеген сылтау итеп, гел кага килделәр. Бигрәк тә Фатих Сәйфи-Казанлыдан зарланганы исемдә. Ялга чыгарганнан соң, кабат эшкә алмадылар. Әмма аның урынында зур булмаган хезмәт хакына эшләрлек кеше юк. Мине куйдылар. Игъланнар күп килә, барысы да рус телендә, ятышлы итеп тәрҗемә итәргә кирәк. Өстәвенә, наборщиклар белән дә талашырга туры килә.

...Әмма күпме генә тырышсам-тырмашсам да, эшемә инде күнегеп, яратып өлгерсәм дә, шәһәрдә озак мантый алмадым. Мин үзем генә түгел, хатыным, нәни кызым бар, аларны туендырырлык акча эшли алмыйм. Һәр җирдә коточкыч кыйммәтчелек, өстәвенә, төпле генә торыр җиребез дә юк, тегендә күченеп, монда куылып йөрибез. Шул рәвешле, тормыш безне кабат авылга куып кайтарды. Бу юлы Дөбъязга кайттык, ШКМга укытучылар кирәк икән. Мин нинди дә булса фәннең белгече түгел бит, ни тәкъдим итсәләр, шуңа риза идем. Хатыныма математика эләкте, ул аны әйбәт белә. Миңа тарихтан башка предмет калмады. Тырышсам,укысам, булдырырмын, дип уйладым. Әмма завуч Тәкый ага Бәдигъ авыр мәсьәләне чишә алмый тилмергән кебек:

— М-м... да,— дип куйды.

Тарих — «политический предмет» икән, ә мин билетсыз гына большевик, беспартийный. Олы Кавалда минем белән бергә эшләгән Лотфи Насыйбуллин — комсомол, шулай булгач, тарихчы булып ул калды. Миңа аннан химия белән биологияне күчерделәр. Лотфи тарихның «т»сын да белмәгән кебек, мин дә химиянең «х»сын, биологиянең «б»сын белмим. Фәннәрнең үзләрен белмәгәч, методикасын каян белим? Ничек укытыйм? Моны кычкырып әйтмәдем, билгеле, үземне геройларча тоттым. Ары кагылдым, бире сугылдым, химия-биология буенча нинди китап тапсам, бәясе дип тормадым, барын да җыйдым. Ирле-хатынлы төн йокламыйча укыдык, өйрәндек, хезмәт күрсәтергә тешебез-тырнагыбыз белән ябыштык.

Мәктәптә җыелышларның башка төрле исемнәре юк, ике көннең берендә «педсовет» дип җыелабыз. Төн буе утырабыз. Мөдир Хәйрулла Вәлиуллин (теге вакытта Олы Кавалда избач булып эшли иде) берүзе сөйли: «Әгәр дә если...» — дип башлап китә дә, заводной механизм төсле сыптырып кына тора. Сөйләве һәр җыелышта бер үк эчтәлекле: укытучыларны сүгү. Һәр укытучыны берәмләп сүгеп чыга, куркыта, яный. Чөнки ул бик шикләнүчән, аның карашынча, мондагы укытучылар партиягә һәм хөкүмәткә дошман күз белән карыйлар, корткычлык эшләргә генә торалар. Аныңча, партиясез булу — соң дәрәҗәдә хурлык, андыйлар коточкыч хәтәр кеше булып исәпләнәләр. Вәлиуллин янына партияле кеше килеп, икесе бер бүлмәдә сөйләшеп утырганда партиясез кеше килеп керсә, «Мөмкин түгел, чыгып тор»,— дип, борып чыгаралар.

Мин исә партиясез, әмма чын күңелдән җәмгыять өчен эшлим, социализм булачагына тулы иман белән яшим.

* * *

Тырыштым. Хәзер мине районда таныйлар. Мин — белемле (техникум тәмамлап кайттым бит!), нык ышанычлы кеше. Шулай саналам. Әмма мин партиясез, шуңа күрә үземне кимчелекле кеше итеп сизәм...

1936 елда эш шартлары бик авыр булды. Без инде туган авылым Мәмдәлдә яши идек, ике бала белән мәктәп фатирында торабыз. Ул елны начальникларның

рядовойларны сүгүе, янавы, куркытуы, юк өчен гаепләве модага керде. Рядовойлар арасында куштаннары да, тәлинкә ялаучылары да бар. Кечкенә генә ялгыш сүз ычкындырсаң, берсе эләктереп ала, икенчесе үзгәртә, өченчесе югарыга ирештерә. «Иптәш Сталин», «остазыбыз Сталин», «Иосиф Виссарионович» сүзләре диндар кешенең тәсбихына әйләнде, «сөбханалла»дан да артыграк кабатлана иде.

Шундый заманның бер төнендә, тәвәккәлләп, хатынымның әтисенең хәлен белергә барып кайттык. Ул Орнаш Башының (хәзерге Әтнә районы) элекке мулласы, «мулла белән мөнәсәбәткә керәсез» дип гаепләнүең дә бар. Шуңа күрә без моны бик тә яшеренеп эшләргә мәҗбүр булдык.

* * *

**1941** елның 22 июне. Сугыш!..

Сәгать суккан — минут үткән саен берсеннән-берсе күңелсез хәбәрләр килеп тора.

Фашист илбасарлар безнең бөек Ватаныбызга бик тирән кереп өлгергәннәр икән. Дәһшәт белән киләләр, ди. Илебезне пычраталар. Кайда безнең сугышка каршы әзерлегебез, бик гайрәтләндек, бик мактандык лабаса? Юлбашчыбыз Сталин ни әйтә? Аны, мөгаен, алдаганнардыр. Ә ник алдансын, даһи бит ул?!

Көн саен хәрби комиссариаттан чакыру килә. Авылның типсә тимер өзәрлек, басса бакыр изәрлек егетләр груһ-груһ чыгып китәләр. Күп тә үтмәде, үлгән хәбәрләр дә килә башлады. Кайтучылар да булды: кайсы култык таяклы, кайсы кулын марля белән муенына аскан, күзен бәйләгән...

Менә китәм, менә китәм, дип йөреп, бер эштә дә күңел юк. Инде җәй үтеп бара, әле һаман военкомат мине чакыртмый. Минем бертөрле дә сугыш һөнәрем юк, шуңадырмы, югары белемле укытучылар исемлегендә торгангамы икән...

Куркыныч дәһшәт, хәсрәт көннән-көн арта бара. Тылда ятуыма — хурланам, үземне җинаятьче итеп хис итәм. Куркак, җебегән бәндәнең качып ятканы кебек бит. Сугышка үзем теләп китәргә әзерләнәм, үзем винтовка рәтен дә белмим. Шуның өчен бик кайнарланып винтовканы өйрәнә башладым: сүтү тәртибен, частьларның исемнәрен, җыю, кору, ату...

Фронт файдасына ике данә мех куртка тапшырдым. Ләкин соңыннан белдем: җыелган әйберләрнең яртысы да авылдан чыгып китмәгән, коммунист-түрәләр бүлешеп алып бетергәннәр!..

Мин — партиясез гади гражданин. Шуңа күрә коммунистлардан чын күңелдән оялам. Әмма алар миннән бик күпкә түбәннәр, вак җанлылар, оятсызлар икән ләбаса! Чын йөзләрен партбилет һәм коммунист дигән исем генә каплап тора икән. Сугыш башланыр алдыннан гына менә бер өү офицер киеменнән авылда кукыраеп йөрде. Сугыш башланган көнне үк мундирын салып ыргытты. Штатски киемгә күчте, аксаклап, таякка таянып йөри башлады. Коммунист буларак, райкомны ышандырды, врачын да җайлады, сугышка яраксыз кеше булып калды. Бөтен сугыш дәверенә райком аны авыл советы рәисе итеп куйды.

...Военкоматка сугышка алуларын сорап баргач:

— Тылда эшләү кыенлыгыннан качасың,— дигән мөһер суктылар.— Вакыты җиткәч, чакыртып алырлар,— диделәр.

Алай гына да түгел, фронтка киткән Петров урынына мәктәп директоры итеп билгеләндем. Бу минем өчен дәрәҗә, зурлык түгел, хурлык. Җәһәннәм газабына тагын берсе өстәлде. Укучыларда уку дәрте, укытучыларда укытуга ихлас бөтенләй юк. Әмма эшне тартырга кирәк. Чумдым эшкә, үземне үзем аямыйм. Мәктәпне кышка әзерләргә, укытучыларны утын белән тәэмин итәргә кирәк. Мораль яктан да, физик яктан да әйтеп бетергесез кыен. Чыдар хәлем калмады, китәргә дигән ныклы карарга килдем. Монда да фронт, монда да мин кирәк, әмма мондагы газап патриотлыкка саналмый.

Карарымны тормышка ашырам дигәндә, 1942 елның мартында бронемны военкомат үзе сорап алды.

Авыр... Яшәгән, гомер иткән җирләр кала... Кадерле, газиз гаиләм кала. Вакытлыча гына дип әйтеп булмый бит.

Шулай икән ул дөнья дигәнең, үлем ерактан ук күренеп килә башласа, башта бик куркыта икән. Килеп җитәрәк курку да акрынлап басыла икән. Чөнки ышанган инде — барыбер бетәбез.

Товар поездында Казаннан чыгып киттек. Менә шунда инде «яңа тормыш» башланды. Вагон уртасында тимер мич яна. Ятып түгел, ичмаса сөялеп йоклап барырга да җай юк. Кемдер мине кызганырга тиеш шикелле, кемгәдер ир-

кәләнәсе килә, ләкин берәү дә юк: әнием дә, хатыным да, балаларым да... Бу минутта алар нишлиләр икән? Без артык тыйнак яшәдек, запас юк. Кышны ничек чыгарлар, ә язгы су вакыты өчен балаларның аяк киемнәре бар идеме икән? Җылылар башланганчы утын житәр микән?

15 мартта Арзамаска барып життек. Станциядән шәһәргә таба берничә чакрым тәпиләргә туры килде. Ачык кыр. Көнбатыштан гайрәтләнеп-гайрәтләнеп март җиле исә, кыр өстеннән җәяүле буран йөгерә, шактый югары күтәрелеп бара торган кояш болыт артыннан чыгып бер елмая да, кереп кача. Яз килә, янәсе. Хәсрәтле яз. Күңел аны да килеп җитә алмас кебек сизә, кояшның елмаюы да авыру кешенең үләр алдыннан булган бер җиңеләюе шикелле генә булып кала.

Менә Арзамас. Шәһәрчек. Башта кызган аяк белән шәһәрне бер айкап чыктык. Иске заманнан калган чиркәүләр, монастырьлар, соборлар белән тулган икән.

Менә ишегенә Александр Пушкин портреты куелган ике катлы таш бина. Мәктәп икән. Тукта, бу ни хәл? Рус шәһәрендәге рус мәктәбе эченнән татар милли моңы ишетелә! Коридорга уздык, чытыр-чытыр китереп пыяла ватыклары өстеннән үттек. Әнә химия кабинеты, ул туздырып ташланган, идәндә — пробирка, көпшә ватыклары. Шәһәр дошман оккупациясендә булмаган ләбаса, бу ник болай? Кем вәхшилеге бу? Минем кабинетым да шундый хәлдә микән? Аһ!..

Бүлмәләрдә идән калын пычрак катламы белән капланган. Димәк, мәктәпнең төп хуҗалары биредә күптән юк инде, көзге пычрактан ук ниндидер затсызлар хуҗа булып алган.

Тавыш килгән якка барып, җырлаучыларны эзләп таптык. Үзебезнең Татарстан егетләре, алар да безнең кебек килгәннәр. Шул пычрак идәндә җырлый-җырлый ауныйлар. Күбесе — укытучылар. Шатландык, кардәшләребезне тапкандай булдык. Алар белән бергә пычракта аунарга уңайсызлануым өчен үземнән-үзем көлдем.

— Әрсезлектә — эт, шакшылыкта — дуңгыз. Солдат әнә шул инде,— диде җырлаучыларның берсе.

Әйе, дуңгызга әверелеп барабыз бугай.

Күңелсез. Һәркемнең карашы моңсу, өметсез. Җиңүен җиңәрбез, анысында шик юк, өч йөз елдан артык тиранлык иткән Романовлар сәләмәсен себереп түккән халык власте бездә!.. Әмма яшисе килә, тынычлык сагындыра. Ярар, хәерле булсын, изге юлда йөрибез, Ватан өчен үләбез, шуның белән горурланабыз. Сугыш белеме алып, үлгәнче оста итеп сугышып та карыйсы килә. Бәлки... сугыш туктар, дип тә өметләнәбез.

Безнең урын «пулеметно-минометное училище» дип атала, без шул юнәлешнең офицерлары, иң кимендә лейтенант булып чыгарга тиешбез.

Минем монда иң беренче шатлыгым шул: винтовканы бик яхшы үзләштердем. Бар хурланганым — шуны белмәү иде. Гомумән, минем өчен теория бик җайлы. Әмма строевой фән һәм тактик занятиеләрне авыр кичерәм. Өстемдәге киемем җылы, хәрәкәтләнгәндә тирлим, аннары шул килеш март кары өстендә сәгатьләр буе ятарга туры килә. Организм алҗый, самсырый, су сорый. Чәй дигән нәрсә юк, кайнаган суның ни икәнен белмибез, хәтта салкынына да тилмерәбез. Су колонкасының үз эшләү вакыты бар, шуны туры китереп, кисмәккә салкын су хәзерләп куя башладык.

Тәнем кызыша, төннәрен саташып чыга башладым. Актык көчем белән аяк өстендә йөрим. Авыруым көчәйгәннән-көчәя бара. Взводташларым хәлемне аңлыйлар, мине стройдан качырып, санчастька җибәрделәр. Икенче каттагы салкын бүлмәгә меңгереп салдылар. Бөтен дәвалаулары — кереп, температураны үлчәп чыгып китү.

— Шушында ял итеп яту — үзе дәва инде ул,— ди врач.

— Мин арымадым,— дим.— Занятиеләрем кала, миңа тазарырга кирәк.

Бу — кылану түгел, ихластан әйтелгән сүзләр. Планым чуалды, укырга, офицер булырга иде бит. Үлсәң, күпләр белән бергә бетәсең, исән калсаң, Ватанга керткән өлешең белән горурланасың. Миңа исә болай хастаханәдә ятып, эзсез югалырга туры килер микәнни?!

Хәлем авырайганнан-авырая. Күкрәк чәнчи, сулап булмый, саташам, йоклап китә алмыйм, күземә әллә ниләр күренә. Ишек ачылды. Кап-кара шәлгә төренгән зур гәүдәле бер карчык килеп керде. Күзләрен миңа текәп, караватым янына килде, кулымнан тотып тарта башлады. Мин:

— Таня!— дип кычкырып җибәрдем, аңыма килдем, сестра Таня да яныма килеп, юатып китте. Бик әйбәт кыз ул, авыруларны чын ихластан тәрбияли.

Беркөнне мине дубырдап бара торган ләҗәнкә арбага утыртып рентген кабинетына җибәрделәр. Урамда яз, кар эри, чылтырап сулар ага, җилпенеп-җилпенеп сыерчык сайрый, тургай җырлый-җырлый күккә күтәрелә. Яз матур, Арзамас урамы гына ямьсез, пычрак, урам уртасындагы тирестә сикерә-сикерә карга оча...

Рентгеннан соң авыруым ачыкланды: уң як үпкәмдә абсцесс икән. Врачның әйтүенә караганда, мине монда гына дәвалый алмыйлар икән, каядыр башка җиргә озатырга тиешләр.

Алатырга икән. Товар поездының салам түшәлгән салкын вагонында өч тәүлек теркелдәргә туры килде. Ул ватык үпкәм ни күргәндер. Сызлануымны һәм ютәлемне җиңә алсам, уйларым үткәннәремә тоташа: нинди хыяллар белән яши идем бит, һәм хәзер кем булып калдым? Кем булыйм — имгәк. Гаиләм өчен дә, Ватаным өчен дә — имгәк!

Хәлем авырайганнан-авырая бара. Үпкәмнән кан килә, ашап булмый, гәүдә хәрәкәтем белән идарә итә алмыйм, авырту һәм температура белән җәфаланам. Мондый хәлдә терелүемә өметләнү күктән йолдыз чүпләргә сузылу белән бер булыр иде. Күзем ачык, ә дөньяга саташып карыйм, уйларым буталчык, өметсезлек зур, апатия көчле.

Җылы көннәр башланды. Мин саташудан айнып карап ятам. Май таңы ата. Тәрәзәм каршындагы нарат болыт-болыт сап-сары серкәсен очыра. Палата тәрәзәсе башында күгәрчен гөрли. Минә кояшның тәүге нурлары нарат агачлары арасыннан кысылып кына бүлмәгә төшә...

Ә беркөнне палатага госпиталь начальнигы керде, мине карады һәм озакламый «комиссовать» итәчәкләрен әйтте.

И адәм угылы, яшәү ул башыңа теләсә нинди хәлләр килергә мөмкин генә түгел, килергә тиеш дигән сүз. Бәхетле яки бәхетсез булсаң да, табигатьнең теге яки бу продукциясеннән (мәхәббәттән, талантган, матурлыктан, көчлелектән...) өлешле яки өлешсез булсаң да... бернигә дә гаҗәпләнмә, яисә шатланып күккә сикермә, хәсрәтләнеп аһ-ваһ итмә, уңаен да, тискәресен дә тыныч күңел белән кабул ит! Чөнки син — Кеше!

6 июнь көнне «авыруы дәвалап булмый торган» дигән документ тотып, авылыма, өемә кайтып егылдым. Сугыш башлангач, мин болай булырмын дип, күз алдыма китердем мени? Инде менә башкалар фронтта сугышканда, батырларча һәлак булганда, син өйдә үлем көтеп ят, имеш...

Тормышны алып бару бер Зәйнәп өстенә төште. Балаларны карый, колхоз эшенә йөри, укыта, тамак туйдырырга җай эзли. Аның хәле чиктән тыш авыр, әмма ярдәм итәрдәй көчем юк. Милкебездән кеше алырдайларын сатабыз. Ә алучы бар!

Зәйнәп үзен аямыйча мине дәвалый. Сыерыбыз булмаса да, сөт табып, катык ясый, шәһәргә илтеп сата, «спекуляция» ясый, азык таба, дуңгыз мае алып кайтып эчерә. Шулай өметләнеп йөргәндә, моңа кадәр күренмәгәнчә озак һәм каты йөткердем, үпкәмнән көчле кан китте, чишмәдәй шаулап акты. Хатын больницага йөгерде. Врачлар Романов белән Ошанина да мине күреп каушап калдылар.

Бу юлы да исән калуыма хатыныма бурычлымын. Җир йөзендә тиңе булмаган кыйммәтле зат ул!

Шушы хәлдән бер айдан да азрак вакыт узган иде — хәрби комиссариатка чакырдылар. Биредә язып утыручыларның чиге юк — таза, нык, матур ирләр. Бу эшкә хатын-кыз яисә гарип-гораба ярамый микәнни?

Миңа: «Суслонгер»,— диделәр.

Суелырга хәзерләнгән малларны бер урынга туплаган шикелле җыеп, Суслонгер командасын оештырдылар.

* * *

Мин унтугыз ел буена совет укытучысы булып хезмәт иттем, унтугыз ел буена һәрьяклап агитация алып бардым. Ә менә монда, Суслонгер лагеренда, үзем сөйләгәннәрнең киресен күрдем. Без, совет солдатлары, безне монда каршы алучылар да совет командирлары, шулай булгач, без һәммәбез дә бер гаилә кешеләредәй булырга тиеш. Тик командирлар безне дошманнарча каршы алдылар, безгә качып йөргәндә тотылган дезертирлар итеп карыйлар. Җылы сүз, якты караш, иптәшләрчә мөнәсәбәт юк.

— Быстро приготовим вас пулеметчиками и отправим прямо на фронт!— Әнә шулай, аерым бер тәм белән куркытып сөйләргә яраталар. Без әле дөнья

күрмәгән, янәсе, куркабыз. Болар исә «дошманнарыннан» үч ала, алар сугышта чакта без тылда ятканбыз!

Миңа нәрсә, өйрәнермен пулеметын да, сугышырмын. Мондый куркытулар миңа энә очы кадәр дә тәэсир итми. Мин генә түгел, күпләр кырылды. Өйгә исән-сау кайтырмын дип өмет тә итеп килмәдем, балаларымны соңгы тапкыр дип сөеп, бәхилләшеп килдем. Ватаным өчен сугышып үләргә дип килдем.

Без көне буе занятиедә. Миңа хәлсез килеш егерме сигез килолы пулемет «тело»сын күтәреп йөрергә туры килә. Кичен урманга утынга барабыз. Ашханәдә бәрәңге боламыгыннан башка нәрсә юк, гомумән, анда бару җан газабы. Күршедә генә офицерлар ашханәсе, аннан тәмле ашларның хуш исе борын түрен кытыклый, ашказанын котырта. Офицерларның солдатларга мөнәсәбәте әшәкеләнгәннән-әшәкеләнә бара. Әйтерсең, бу хәрби әзерлек урыны түгел, ә нииндидер зур җинаять эше белән тотылганнарны җыеп җәзалау лагере. Акырып кычкыру, сугу, мыскыллау — берсе дә калмый. Нииндидер явызлык бармы монда? Мөмкин кадәр азапларга, эштән чыгарырга, фронтка яраксыз итәргә тырышалар диярсең.

Менә беркөнне «преодоление препятствий»га чыктык. Мин тирән, киң чокырга кадәр барысын да үттем. Ә бу чокыр аша сикереп чыга алмыйм, хәлем җитми. Шап! — уртасына.

— Отставить! — ди офицер. Мин тагын кабатлыйм. Тагын — шап! Тагын... Командир сүгә, акыра. Мин соңгы көчемне җыеп сикердем, чокырның аргы стенасына килеп бәрелдем. Үпкәмнән гөрләп кан китте, бер генә минуткадыр, аңым югалды. Күземне ачканда кан эчендә ята идем.

Гарнизон комиссиясенә баргач, өлкән яшьтәге врач күкрәгемә имән бармагы белән берничә мәртәбә төртте дә:

— Патологического ничего нет, — дип взводыма кайтарып җибәрде.

...Ач тамак белән корбанын әләктерә алмаган карт бүре кебек, сөйрәлеп кенә казармага кайтып барам. Октябрьнең суык җиле исә, ялангач урман үлем хәсрәтен көчәйтеп, ямьсез итеп улый, кар күбәләкләр оча. Үзем ач, үлемгә барам, өйдә әниләре янында балаларым ач.

Мине ротадагы төрле халыклар арасында агитатор итеп куйдылар. Беркөнне политработникларның җыелышында да катнаштым. Миңа сүз биргәч, тыңлаучыларым турында ни сөйләгәнемне хәтерләмим, шушылай тәмамлаганымны ачык беләм:

— ...все готовы, чтобы отдать последнюю каплю крови за Родину, за Сталина! — дип трибуна артыннан төштем. Залда — Ура! Ура! Барабан бәреп алды, тынлы оркестр Салих Сәйдәшевнең маршын уйнап җибәрде.

* * *

...19 октябрьнең таңы, сәгать өч. Сигнал уйный башлады, сикерешеп тордык. Тиз генә чыгып тезелдек. Караңгы. Өстебезгә төн аша ак яфраклар шикелле җепшек кар төшеп тора. Абына-сөртенә станция юлында барганда ул кар яңгырга әверелде. Юешләнеп беттек, дуңгыз булып пычрандык. Кием юка, сыгылып, бөтен тәнгә су үтә. Туңам, калтыранам. Каны саркып торган җәрәхәтле үпкәм сыкрый, шулай да һаман да исән бит әле мин. Шул юеш көйгә товар вагоннарына төядек.

27 октябрьдә Сталинград өлкәсендәге урманга урнаштык. Берничә көннән походка чыгып киттек. Донга җитәргә илле чакрымлап бар, диделәр. Чиләкләп яңгыр коя башлады. Якында печәнлек бар иде, ике взводның дүрт пулеметын коры печән белән капладым. Гаскәр китте, без — взвод командиры Свистунов һәм тагын бер пулеметчы белән — шуларны саклап калдык.

Мин землянка алдына качырып кына ягылган учак яктысында пулемет тасмаларына патрон тезәм. Урман юлыннан Сталинград юнәлешенә танклар агыла... Икенче көнне безне алырга машина килде, шуңа төялешеп, чыгып киттек. Бервакыт моржа улавына охшаган гүелдәү тавышлары килә башлады, алар акрынлап көчәйде. Башыбызны күтәреп карасак, безнең өстә — бер көтү немец бомбардировщиклары. Алар шаян каргалар шикелле уйнаклашалар, сиреналарын улатып, уктай түбән атылалар да, җиргә төшеп җитәм дигәндә генә кинәт күккә таба борылалар, хәрәкәтләренә күз иярми. Без юлдан читтәге урман эченә ыргылып, әзерләп куелган чокырларга төшеп утырганчы, шартлата да башладылар. Тел белән әйтеп, аңлатылмый торган дәһшәт купты...

Донга килеп җитеп, машинаны туктатырга өлгермәдек, тагын бомбалау башланды. Коточкыч шартлаулар, ыңгырашулар, акырулар, чинап-чинап атлар

кешнәве... Обозлар яңа, машиналар яңа. Мин ерак китә алмадым, бака булып җиргә яттым. Башымны күтәреп караганда алдымда тездән өзелгән итекле бер аяк басып тора иде... Бомбежка авышты, җир өстендәге кыямәт тетрәндергеч иде: яралanучылар акыра, үлем хәлендәгеләр ыңгыраша, җирдә канлы кул-аяк кисәкләре аунап ята... Обоз атлары тырпылдаша, машина кисәкләре, арба ватыклары кайсы кая аунап ята. Нәрсәләрдер гөрләп яна. Кайдадыр зенит тубы түпелдәгән була...

Дон өсте инде тәмам туңды, өстен юка гына кар да каплап алды. Боз өстеннән җәяүләп елганың аргы ягына чыктык. Менә әрәмәлек. Туктарга, пулеметларны көйләргә боерык булды. Без икәү — беренче һәм икенче номерлы пулеметчылар, «максим»ны куак төбенә алып килеп урнаштырдык. Ул арада дошман ягыннан «фие-фие фие» дип, пуля да оча башлады. Иптәшем:

— Ох, руку! — дип кычкырып, артка егылып төште, берүзем калдым. Яныма патрон тартмаларын китереп ташладылар. Икенче номерлы булып яныма ятучы юк. Менә алда, җиргә сибелгән чәүкәләр төсле, кара нокталар пәйда булды, безгә таба хәрәкәт итә башладылар. Замокка лентаны да үзем тыгып, «чәүкәләр»гә озын гына очередь бирдем. Тегеләр юкка чыкты. Тагын күренә башладылар, минем икенче очередь тагын тыкылдап алды. Өченчесенә әзерләнгәндә уң флангта миналар шартлый башлады. Арттан ачы итеп:

— Держись! — дип кычкырдылар да, аягымнан тотып артка өстерәделәр, мин «Максим»ны хоботыннан эләктереп алырга өлгердем. Шулчак бая гына пулеметым белән яткан урынга мина килеп төште. Менә ничек куып йөри икән ул әҗәл!

19 ноябрь таны ыгы-зыгы белән башланды. Һәммәбезне дә сафка тезделәр. Гомуми һөҗүм башлана торган көн икән. Майор нык тәртип таләп ителәчәген аңлатты, походта барганда өч адым да читкә атламаска, дип кисәтте. Кулындагы ялангач наганын һавада айкый-айкый сөйләде:

— За малейшее нарушение... — дип гайрәт чәчте дә: «Үз кулым белән атып үтерәчәкмен», — дип янады. Әмма болар миңа әллә ни тәэсир итмәде: мин тәртип боза белмим, үлемнән исә гомумән курыкмыйм. Бу минем шапырынуым түгел. Фронтка килеп, аннан исән-сау кайтырмын дип өметләнмим, авыруым да бик житди.

Озак бардык. Дошман туктаусыз чигенә, шуңа күрә безгә эш юк. Чират безнең взводка килеп җиткәндә аларда урын бетте. Каршыга машиналар килә, җәяү бара торыгыз, диделәр. Төн иде инде. Бераз ял итәргә туктаган җирдә башымны күтәреп карасам, тирә-юнемдә берәү дә калмаган. Сарайлар артына кереп баручы икәүне шәйләп алдым. Үзебезнең взвод егетләре икән. Бер фатирның ишеген ялына-ялына ачтырып, винтовкаларыбызны кочаклап йокладык.

Икенче көнне юлыбызны дәвам иттек. Без үтәсе урынга туктаусыз снаряд төшә. Алларында бүре күргән сарыклар кебек аптырап торабыз да, тагын алга атлыйбыз. Юлыбыз безне үргәрәк алып менеп китте, аннары сөзәкләнеп төшә башлады. Алда каплаулы машинаны күреп алдык, каршысында берничә хатынкыз һәм ир кеше май ягылган ак икмәк ашап торалар. «Майор!» — дип пышылдаштык та, куркышып туктап калдык. Димәк, безнең часть. Димәк, артта калганыбыз өчен майор безне үз куллары белән атып үтерәчәк. Иптәшләрем мине алга таба этте. Мин уң кул бармакларымны чигәмә тиереп:

— Товарищ майор, мы... — дип әйтә генә башлаган идем, майор күн перчәткәле кулын безгә таба селтәде:

— Брось! — диде, үзе шунда ук эш тә тапшырды: төнне ачык кырда сакта торып үткәрдек. Мин теземне чәнчеп утырып, винтовкамны аркылы сузып салдым да, уйга чумдым. Менә адәм баласының язмышы. Сугышка кергәнгә әле бер ел тулмаган, ә минниләр генә күреп бетермәдем инде! Училище, коточкыч авыру, госпитальләр, комиссияләр, фронт, мин инде — гарип бер солдатмын...

Без юкка курыкканбыз: ярты юлда калуыбыз командование гаебе белән булган икән. Без юк чагында бер һөҗүм ясарга өлгергәннәр. Сугыш бик каты булган, батальонда ярты гаскәр кырылган.

Наступлениегә! Әмма ахмакларча барабыз да инде! Баштан-аяк коралланган фашист-ерткычка каршы аяк өстендә көе винтовканы «наготове» тотып барабыз. Бу — хәрби эштә бер алымммы, әллә безнең командованиенең ахмаклыгымы?

Без каршы килә торган танкны күреп алып, җиргә ятып кына өлгердек, фи-и-и иткән пулемет уты астында калдык. Ул арада танк алдагы хуторга кереп китте, без — аның артыннан. Немец безне монда да ут белән каршы алды. Пуля яңгыр булып ява. Баш тыгарга урын юк. Артка чигенергә дә ярамый. Алга шуышабыз. Янымнан гына:

— Держи левее! — дип, взвод командиры шуышып китте. Ун секунд үтмәде, алдагы мәеткә башын куйды да... тынды... бетте.

Баш тыгарлык та чокыр заты юк, көрәгемне, винтовкамны баш очыма куеп карыйм. Әйләнә-тирәмдә пуля яңгыры җирне актара; ә мин һаман исән әле. Мин түкергән кан ак кар өстенә җәелә. Һич тә үләсе килми икән бит. Гаиләм кала, балаларым кала...

Күп югалтулар белән алдыбыздагы ике авылны алдык.

Гөрелдәгән тавышка алга, фронт ягына карадык. Бер-бер артлы тезелешеп, өч танк килә. Нәкъ минем өскә турылап киләләр. Миндә граната-фәлән юк, винтовкадан гына атам, танкның исе дә китми. Снаряд чокырына төшеп яттым. Миңа килеп житте... күп булса, ун метрлап калды... мине чокырым белән бергә сытып китә... дигәндә генә танк сул ягына кинәт борылып куйды, «кырт» итеп борынын күтәрде; көпчәк чылбыры өзелде дә, дөрләп яна башлады. Люк ачылып китеп экипаж чыга башлаганда, «атмаска»!— дигән приказ яңгыраганчы берәү атып өлгерде. Икенче немец, чыгуга, кулларын күтәрде. Аның артыннан килгән танк та шундый ук язмышка дучар булды. Өченчесе качып китәргә өлгерде. «Ур-ра!» кычкырып алга киттек.

...Үзәндә, дошман ягында калдык. Безнең тылга таба тагын бер калкулык сузылган. Шул ике калкулык култыгында, үзәндә, безнең взвод командиры Вересаев мәҗлес үткәрергә йөри. Безнең артта гына миномет ротасы ята. Вересаев кунакка шуның командирын чакырып килергә куша. Нишлисең, киттем. Калкулыкны иелгән көйгә җан-фәрман йөгереп үттем. Әмма «кунак» килә алмаячагын әйтте. Ерактан әйләнеп кайттым. Вересаев чыгырыннан чыгып тузынды, чөнки шактый ук кызган иде инде. Планшетыннан кәгазь тартып чыгарды да, хәрефләрен чыпчык башы хәтле итеп записка язды. Миномет ротасы командирына мин шул записканы илтеп тапшырырга тиешмен. «Есть!»—дидем дә киттем. Бараммы соң! Исерек кушуы буенча йөрсәң монда... Юлымда иске окоп бар, шунда төшеп ятачакмын. Әмма барып житә алмадым, көчле шартлау тавышы яңгырады. Вересаев тирәсендә ыгы-зыгы башланды. Янында гына мина төшеп ярылган, яраларын бәйлиләр иде.

2 декабрь иртәсендә тагын ыгы-зыгы. Һөҗүмгә әзерләнергә приказ бирелде. Хәлем авыр булса да, башкалар белән бергә булырга тырышам. Өч мәртәбә ятып, өч мәртәбә тордым. Дүртенчесендә сөртенеп барып төштем, авызымнан гөрләп кан китте. Шуннан арысын белмим, аңсыз ятканмын. Күзләремне ачканда, уң кулымның терсәге һәм кулбашым үтереп сызлый иде. Җәрәхәтемне бәйләгәндә тулысынча аңыма килдем...

* * *

Мин әтием көндәлекләрен укуны әлегә шушы урында туктатып торам. Каләмемне куеп, уйга бирелэм...

... Өлкән буын кешеләренә көнләшеп карыйм мин. Тырышканнар, тырмашканнар алар, каһәрләнгәннәр, рәнҗетелгәннәр, әмма иманнарын җуймаганнар, кыйблаларыннан язмаганнар. Ниләр генә күрсәләр дә, тормыштан суынмаганнар, якты киләчәккә өметләрен өзмәгәннәр. Мөгаен, нәкъ менә шуның белән дә бәхетле булганнардыр алар.

Без, сугыштан соңгы буын, мондый бәхетне алар аңлаганча беркайчан да кабул итә алмабыздыр шикелле...

Әтием сугыштан исән кайткан, әмма калган бөтен гомере буе шунда алган яраларыннан сызланып яшәде. Кырык җиде ел педагогик хезмәт стажы белән пенсиягә чыкты. Һәр мизгелнең кадерен белеп яшәде, туктаусыз хәрәкәттә иде. Шул еллар эчендә тормышның яңадан-яңа сынаулары аша үтәргә мәҗбүр булды. Шулай да без аның үз язмышыннан зарланганын, сукранганын, тормышны каһәрләгәнен ишетмәдек. Бүгенге болгавыр заманны, гомерләре буе ашкынып якынайтырга тырышкан якты киләчәккә булган өметләренең челпәрәмә килүен күрә алмады — кем белә, бәлки нәкъ менә шуның белән дә бәхетле булгандыр ул.

Авыр язмыш сынауларын, ихлас ялгышулар белән булса да, саф намус белән узган өлкән буын өчен горурлык хисләре, аларга ихтирам тойгылары уяна. Алар тормышы — безнең өчен гыйбрәт булырлык...

# БОРЫНГЫ ЧАЛЛЫ

**Котлы Бөкәш һәм Тәберде Чаллысы тирәсендә урнашкан бу борынгы шәһәрчекне — борынгы Чаллыны (Яр Чаллы түгел!) без һич тә шикләнмичә халкыбызның иң кыйммәтле тарихи җәүһәрләре исәбенә кертәбез. Кызганычка каршы, әле ул һаман да тарихчыларыбызның игътибарыннан читтәрәк калып килә. Археологлар да аны, нишләптер, тиз генә үз итә алмадылар... Шулай ук Тубылгытау, Кирмәнчек, Кашаннарыбыз да әлегә кадәр бөтенләй өйрәнелмәгән болгар калалары рәтендә йөри.**

**Бу хәл Балык Бистәсе районында туып үсеп, хәзерге көндә Биектау районының Дачный бистәсендә укытучы булып эшләүче Нурулла Гарифка озак еллар буена тынгы бирмәде. «Кала-Тау болай да җимерелеп беткән бит инде, йөрәгегез бер дә сыкранмый мыни шуңа, әйдәгез инде, бер карап кайтыйк, булганын, бәлки, саклап калырбыз»,— дип археологлар артыннан күп чапты ул.**

**Үҗәт егет булып чыкты Нурулла Гариф. Кулларыбыздан җитәкләп диярлек борынгы Чаллы каласына алып китте безне. Сүз тыңлап дигәндәй, бардык, күрдек һәм... кичекмәстән казу эшләрен башлап җибәрергә карар кылдык. Өч ел эшләдек инде бередә. Кызыклы гына ачышларыбыз да бар. Безнең белән үзе дә рухланып эшләде Нурулла дус, архивларда, китапханәләрдә казынырга да вакыт тапты. Борынгы Чаллы турындагы мәгълүматларның барысын да туплады, тәртипкә китерде.**

**Менә без укучылар игътибарына Нурулла Гарифның Борынгы Чаллы турындагы мәкаләсен тәкъдим итәбез. Дөресен әйтим, профессиональ булмаган тарихчылар, төрле дилетантлар тарафыннан язылган мәкаләләргә мин шикләнебрәк карыйм. Бик белдекле кыяфәттә ниләр генә язмыйлар алар кайвакыт! Ә менә Нурулла Гарифның түбәндәге мәкаләсе төрле характердагы чыганакларга нигезләнеп, профессиональ югарылыкта язылган. Тарихи хезмәтләргә хас булганча, фараз кылулар да бар, әлбәттә, әмма алары да ышандырырлык. Авторның максаты изге: борынгы тарихи һәйкәлләребезне нинди юллар белән булса да саклап калырга чакыра ул. Бу юлда аңа уңышлар телик!**

**Фаяз ХУҖИН,**
археолог, тарих фәннәре кандидаты.

Чаллы шәһәре дигәч тә, хәзер үзенең «КамАЗ»лары белән дөньяга танылган Чаллы күз алдына килергә мөмкин. Әмма без бередә бөтенләй башка Чаллы шәһәре турында сүз алып барабыз. Ул борынгы шәһәрчек, Балык Бистәсе районының Котлы Бөкәш авылы янында урнашкан.

Тарих кабатлана диләр. Мәшһүр Биләр-Болгар калалары, Яңа һәм Иске (Эчке) Казан шәһәрләре кебек, хәзерге Чаллының да тулы хокуклы үткән тарихы — Борынгы Чаллысы бар.

Чаллы шәһәре җөмһүриятебез тормышында үзенә игътибарны күбрәк җәлеп иткән саен, аның тарихы һәм атамасы белән дә кызыксыну көчәя. Бу турыда матбугатта «Нигә Яр Чаллы?», яисә «Чаллы шәһәренең тарихы» һәм шуңа

охшаш башка язмалар да урын алды. Артык «хисләләр» Чаллы атамасының борынгылыгын инкарь итеп, аны соңгы чор белән билгеләргә тырыша башладылар. Шулай да, ярый әле, соң булса да уң булсын дигәндәй, инкыйразга ук килеп җитмәдек. Алайга калса, чынлап та Чаллының (Н. Челны) атамасы җырларда аталган «Выезжали расписные Стеньки Разина челны» сүзенә кайтып кала иде. Иң яхшы очракта да Чаллы атамасы «Челны — көймә» мәгънәсендә Себерне яулап алучы Ермакка бәйләнгән иде. Мондый аңлауга һәм аңлатуга, әлбәттә, империядән калган руслаштыру өянәге» гаепле. Ә шулай да чынбарлык нидән гыйбарәт соң? Бу очракта алдан ук әйтеп узу әһәмиятлерәк, хакыйкатьне укучы үзе табар. Шулай да Чаллы атамасын без берничек тә аңа сулыш биргән Чулман елгасыннан аерып ала алмыйбыз.

Шул ук мәгънәдә бу атама беренче тапкыр 1184 (1183) елгы Ипатьев елъязмаларында искә алына. Анда Бөек Болгар дәүләтенә 1184 (1183) елда Владимир-Суздаль кенәзе тарафыннан оештырылган һөҗүмнәр уңаеннан борынгы елъязмаларда мондый юллар бар:

«Иделнең Болгардан астарак өлешендә урнашкан Исады утравында, урыс көймәләре тупланып, шуннан Олуг шәһәргә (Биләргә) һөҗүм ясадылар. Бу сугышлар вакытында Исады утравына көймәләр белән Сабакүлләр, Челматлар һәм дә алар белән Тәмте болгарлары — барлыгы 5 мең кеше берләшеп килеп һөҗүм иттеләр». Бу бәрелешләрдә кенәз Изяславның үтерелүе һәм шулай ук болгарларның Торак шәһәренннән атлы гаскәрнең ярдәме булуы да искә алына.

Әйтеп үтелгән вакыйгалар һәм язма безнең тарихыбызга караганга күрә, бездә сорау туа: бу исемнәрне йөрткән нинди аерым болгар халыклары соң болар, кайда яшәгәннәр һәм яшиләр? Кемнәр соң алар Сабакүл, Тәмте, Челмат кабиләләре? (Соңрак бирелгән язмаларда Сабакүл, Челмат шәһәрләре дип тә языла.)

Бу сорауны үзләренә күпләр куйган. Мәгълүм тарихчы В. Татищев балымар, биләр кабиләләре кебек үк Челматларны да болгарлар дип саный. Ул бу аталышның XVII гасырга чаклы кулланылуын күрсәтә. С. Ремезов картасында да «Шайтан каласы» хәзерге Алабуганы, Челматлар дип укыйбыз. Ә инде А. Спасский үзенең тикшеренүләрендә Лаеш, Кашан, Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллы, Кирмәнчек, Мамадыш (Алабуга) шәһәрләрен барысын да Челмата (Чаллы) кабиләләренеке дип искәртеп уза.

Бөек Болгар дәүләтенең бер өлешен хасил иткән бу болгар кабиләләренең тиз арада үзләренең башкаласы Олуг Биләргә ярдәмгә килүләре дә игътибарга лаек. Алар турындагы мәгълүматларның 1184 елда ук искә алынуы Чулман буендагы болгарларның тормышын күз алларга мөмкинчелек бирә. Беренчедән, аларның тиз арада мәгълүматлы булулары болгарларның күмәк, бердәм булуларын билгертсә, икенчедән, аларның тиз арада 5 меңлек гаскәр куя алулары, көймәләрдә һөҗүм ясау мөмкинлекләре игътибарга лаек.

Бу чорларда 20—30 сугышчы бирә алырлык авылларны да зур авыллар исәбенә кертергә була. XII гасыр ахырында алар күбесенчә Чулман буйларында яшиләр. Хәзерге чорда без атап узган җирләр тирәсендә XII гасырга караган дистәгә якын шәһәр: Кашан I, Кашан II, «Керпе угы» шәһәрчеге (XII—XIV), Урай, Ташкирмән, Имән Кискә һәм күп кенә борынгы авылчыклар һәм каберлекләр билгеле. Ә инде соңрак чорга караган тарихи һәйкәлләрнең саны күп тапкырга арта һәм аларның урнашу җирләре дә күпкә киңәя.

Әмма монгол яуларыннан соң Саба Күл, Тәмте, Чаллыларның бу чордагы яшәү урыннары күбесенчә хәзерге исемдәге авыл (шәһәр) исемнәре белән туры килми. Бу һөҗүмнәрдән соң төп халык та саклану чараларыннан чыгып, акрынлап үзенең хәзерге торган урыннарына якынлаша. XIV — XV гасырга караган Идегәй дастанында без «Урмандагы Сабаны» дип укып китәбез. Бу җирләрдә хәзерге чордагы күп кенә Чулман алдындагы атамаларның Чулман аръягы ягы Болгар дәүләтенең башлангыч чоры җирендәге атамалары белән үзара охшашлыгы да күренә. Мәсәлән, Әшнәк, Суба, Собакай, Суар, Урай, Биләр һәм башкалар. Атамалар алмашуы монгол яуларына бәйле. Кызганычка каршы, талау сугышлары тыныч тормыш көткән болгар халкын һәрдаим тетрәндереп, аның мәдәният, сәнгать, архитектура өлешенә караган үсешенә тоткарлык ясап торган.

1877 елларда алда әйтеп үтелгән язманы тикшергән профессор С. М. Шпилевскийның язуларына караганда, бу халыкларның берләшеп ярдәмгә килүләре аларның бер тирәдә тупланууларын аңлата һәм күмәк яшәүләре, тиз арада оеша алулары хакында сөйли. Ә инде картага карап, болгар дәүләтенең уртасында,

хәзерге Мишә белән Нократ арасындагы үзәк җирләрдә, без бу атамаларга бәйле күп кенә елга һәм авыл исемнәрен күрәбез.

Беренчедән, Тәмте сүзенә бәйле Мишә елгасына коя торган Тәмте елгасын һәм шул тирәләрдә булган Төрек Тәмте (Иске Йорт), Тәмте-Мәтәскә һәм Тәмте авылларын очратабыз.

Икенчедән, Тәмте атамаларыннан аз гына көнчыгышка таба борынгы Саба сүзенә бәйле Саба елгасын, шулай ук авыллардан Сабабаш, Иске Саба, Юл Саба (Балтач), Чәпки Саба, Байлар Сабасы, Шайтан Сабасы һәм башка борынгы авыл атамаларын әйтә алабыз.

Өченчедән, Сабалардан көньякка таба Күл исеменә бәйле атамалардан Иске Карабаян яисә Күл Башы, Зәңгәр Күл, Югары Күл һәм Күл (Кульга) авылларын санап китәргә була.

Дүртенче атамага киңрәк тукталып китәсем килә. Челматлар алар — Челман яисә Чулман кешеләре. Чулман хәзерге Каманың шул борынгы чаклардагы аталышы. Чулман атамасы үзе дә төрле гасырга караган елъязмалар һәм китапларда төрлечә язылa. Мамлүк чоры географы Әл Омари (XIV гасыр) аны Чулыман, икенче бер гарәп авторы Ибн Халдун (1332—1406) Җалыман дип атап уза. Шулай ук бу атама Елыман, Чалыман һәм башка исемнәрдә дә билгеле. Кыска гына тарихи экскурсия ясаганда Чулман атамасының төрләнү тарихы һәм географиясе шундый.

Ә Чаллы атамасының мәгънәсе нигә кайтып кала соң? Шунысы кызык, бу аңлатмада да һәркем үзенчә ачыш ясый. Аның беренчесе «Чаллы — ташлы» мәгънәсендә аңлатыла. Андагы «Чул — таш» чуаш теленнән алынган. Ләкин без элекке чорда Чулман тирәсендә бер генә дә чуаш авылын да таба алмыйбыз. Аннан соң «таш» ул төрки сүз һәм «таш» сүзен без инде «таш билге» язуында болгар чоры кабер ташларыннан ук укып беләбез. Акташ, Ташкичү, Ташлык, Ташкент һәм башка «таш» сүзенә бәйле борынгы атамаларда «чал» сүзе күренми дә.


Икенче бер аңлатмада Чаллы атамасы шул исемдәге болгар кабиләләре булу мөмкинлегенә ишарә ясый. Җитмәсә, «чал» сүзе Дунай болгарларында да очрый. Шулай да бу турыда борынгы язмаларда артык еш искә алынмый.

Ниһаять, тагын бер аңлатмада Чал сүзе борынгылыкны белдерә һәм ул күпкә киңрәк мәгънәгә ия. (Чал-лы, күптәнге.) Күптәнге, иске әйберләр, вакыты җиткәч агачлар да — саргаялар, соры төскә керәләр. Күп кенә яр буйлары да, тау башлары да аксыл соры ташлар, кипкән үләннәр белән каплана. Олайган саен чәчләргә дә олылык, ихтирам билгесен аңлатып чал керә. Гомергомердән милләтебезгә тереклек суы биргән Иделне олылаганда да «чал» Идел» дибез.

«Чал» — борынгы төрки сүз. Төркиләрдән ул күп кенә башка халыклар теленә дә күчкән. Урыс халкы да чал — «чалый» сүзен күп кенә сүзләрдән куллана. Мәсәлән, чалый — серый, чалый — седой, чалый конь, чалая погодка, чалая могила һәм башкалар. Кыргыз телендә «чал баш аска» — седоголовая скала мәгънәсендә кулланыла. Ә шул ук искә алынып узган Дунай болгарларындагы чал сүзе кар белән капланган тау башларын аңлата. Чал чәчләрне генә капламый, халык кабул иткән мәгънәдә тау башларын да, елга буйларын да, хәтта җәнлекләрне дә чал баса. Бигрәк тә аларның төсләре аксыл-соры төстә булса.

Хәзер инде Чаллы атамасының таралышына игътибар итик. Хәзерге чорда җөмһүриятебездә булган 20 дән артык Чаллы атамасындагы авылларның 75—80 проценты Чулман буйларыннан 15—20 километр ераклыкта урнашкан. Чулманның үзенә үк 5 Чаллы елгасы кушыла. Ә соңрак чорга карасак, Казан губернасы җирләрендә Чаллы атамасындагы барлыгы 33 авыл санап үтелә. Ә Чел, Чул атамалары белән алар 40 ка, авыллардан тыш атамалар белән 60 ка җитә. Аларның урнашуы да борынгы Чулман буйларында. Мәсәлән, шул чордагы Лаешта — 11, элекке Алабуга, Малмыж, Минзәлә өязләрендә 7 Чаллы атамасы була. Челматларның (чаллыларның) шул чордагы яшәү җирләре хәзерге Саба Күл, Тәмтеләрдән көнчыгыштарак Чулман һәм Чулманга коя торган Чаллы елгалары тирәсендә урнашкан була.

Инде кабат тарихка әйләнеп кайтсак, Ш. Болгари тарафыннан язылган, «Болгар тарихы» китабында бу яклардагы борынгы авылларның берсе Чаллы суы буенда урнашкан Тәберде Чаллысы дип әйтелә. Бу авылның каршы ягында гына XII — XVI гасырларга караган борынгы Чаллы шәһәре калдыклары әлегәчә сакланган. Хәзерге Балык Бистәсе районының көнчыгыш җирләренә кергән бу борынгы Чаллы авылы һәм шәһәрчеге тирәсендә генә дә 1871 елгы картада




*Каманың түбән агымындагы шәһәрлекләр һәм курганнар картасы.*

(К. Новоструев. Шәһәрчекләр турында. 1871 ел) Чаллы атамасы белән 11 авыл исеме санап үтелә. Алар — Яңа, Иске, Югары, Түбән Чаллылар, Чаллы башы, Бикчурай Чаллысы һәм башкалар.

Кызганычка каршы, хәзерге вакытта аларның күбесе инде күчерелгән, исемнәре үзгәртелгән һәм юкка чыккан авыллар исәбенә кимеде. Мәсәлән, әйтеп узылган җирләр тирәсендә 1619 елгы язма китапларда искә алынган Югары Чаллы — хәзер Казаклар, Яңа — Чаллы — Кадрәк, Түбән Чаллы —

Мәмле Казаклары исемнәре белән билгеле. Чаллы атамаларының таралуы яисә кимүе Казан ханлыгы яулап алынганнан соң татар авылларының шәһәрләрдән 30–40, ә зур елгалар тирәсеннән 15–20 чакрым ераклыкка куылу сәбәбендә дә. Инде Чаллы әйләнәсен күзаллап, аның үзәгенә күчсәк, шул тирә-яктагы Чаллылар уртасында безне Борынгы Чаллының (XII – 1556) әлегәчә сакланган ныгытма урыннары, саклану чокырлары, аның шул чордагы зиратлары каршылар.

Бу шәһәрне татар язмаларында еш кына Чаллы (Кала тау), Корым Чаллы, ә урыс язмаларында Чаллин, Чалым һәм Чалмат исемнәрендә күрергә була.

Күп кенә борынгы шәһәрләрнең төзелү, барлыкка килү вакыты бәхәсләре булган кебек, бу бәхәс Чаллы шәһәренә дә кагыла. Кайбер язмалар аның төзелү дәверен Казан ханлыгы чорында дисәләр, археологик тикшеренүләр вакытында Чаллы шәһәрендә табылган чүлмәк, савыт-саба ватыклары, аларның эшләнү алымнары һәм бизәкләренең XI – XIII гасырдагы болгар чоры бизәкләре белән тәңгәл килүен һәм шулай ук аларның башка Болгар шәһәрләре табылдыкларыннан аермалы буларак, бик күп төрле үзенчәлекләргә ия булуын да билгеләп узалар.

Шәһәр буларак барлыкка килүе Алтын Урда чорында дип уйланылса да, аның буш җирдә барлыкка килмәвен, казу вакытында табылган керамик материалларның шактый өлеше Монгол явына чаклы дәвергә каравын да әйтеп узарга була. Бу инде XII гасырның ахырына яисә атап үтелгән 1184 елларга, хәтта аннан да элгәрерәк чорларга карый. Әлеге шәһәр күп чишмәле, мул сулы елгалар, иркен яшел үзәнлекләр, кара урманнар буендагы борынгы авыллар җирлегендә барлыкка килгән дияргә нигез бар.

Шәһәрнең үзәге (Кремль) Чаллы елгасы белән Мәшләк елгасы кушылган урындагы үзәнлектән 24 метр биеклектәге калкулыкта булган. Ул хәзер дә, гасырлар буена җимерелүенә дә карамастан, тирә-ягыннан узганда уңайлы биек тау башыннан үзенең бөтен бөеклеген, мәһабәтлеген белгертеп тора.

Бу ханлыкның үзәге урнашкан биеклектән хәзер дә 7–8 чакрым ераклыктагы унлап татар авылы күренеп тора. Соңрак чорда бу тирәдә авылларның күп булуы һәм шәһәрнең тиз үсүе аларның борынгы Ногай юлы өстендә урнашуына да бәйле. Хәзерге Чаллы (КАМАЗ) юлы да борынгы Чаллыга тияр-тимәс уза.




Борынгы Чаллының схематик планы.

Алтын Урда чорына караган бу шәһәр вакытлар узу белән ныгый, көчәя, аның халык саны арта. Инде Казан ханлыгы оешу чорында, башка кечкенә ханлыклар кебек үк, Чаллы ханлыгының ханы яки әмире Хаҗи Гәрәй дә бәйсезлек һәм беренчелек өчен көрәшкә күтәрелә. Тарихта Алабуга ханы Сәүгән хан белән Чаллы ханының үзара (1518—1525) һәм берләшеп Казанга яу чабулары да билгеле. 1955 елларда Чаллы шәһәрендә казу эшләрен алып барган археолог Н. Ф. Калинин Чаллы шәһәрендә заманында сәяси үзәк булганлыгын турында ышанып яза. Казан ханлыгы чорындагы Чаллы шәһәренең як-ягында урнашкан ике борынгы авылларны кертеп, 57 гектар җирне биләп торуын (хәзерге вакытта Чаллы авылы астында калган өченче авылчык белән күпкә артып китә) һәм үзәндәге хан йортын, дәүләт биналарын саклау корылмаларының ныклыгы буенча беренче урынны алып торуын әйтеп үтәргә була.

Элекке чордагы дүрт рәт итеп салынган саклау ныгытмасыннан исән калганнарының биеклеге хәзер дә 3-4 метрга җитә. Ә борынгы чорда аларның биеклеге 6, чокырларының киңлеге 8 метрга җитүе билгеле. (М. Б. Заитов «Чаллы турында», 1884 ел.) Анда кайчандыр тимер кою булганлыгы, ташлар шомар-

тылганлыгы һәм Кремльдән 200 метрлап ераклыкта урнашкан борынгы зиратның шул чорда 4 гектар җир биләве әлеге шәһәрне ярыйсы гына тулы итеп күзалларга ярдәм итә.

Алтын Урда чорында элеккеге Болгар дәүләте феодал таркаулык кичерә. Төрле вак әмирлек, ханлыклар (Болгар, Җәүкәтау, Казан һ. б.) калкып чыга. Шулар арасында үзләренең мөстәкыйльлеге өчен көрәшүче, үзәктән читләшергә тырышучы бәкләр (яки әмирләр) дә була. Алар хәттә үзләрен ханнар дип тә игълан итәләр. Чаллы белән Казан ханнары арасындагы тарткалашулар шул нигездә килеп чыкканнар булса кирәк.

Бу вакытлардагы катлаулы чорны бүгенге күзлектән каравы бик авыр. Казан, Ногай, Кырым ханлыклары һәм аларның үзара гына түгел, һәрберсенең үзләрендә булган низаглары да бу хәлләргә сәбәптер. Чаллы төбәгендә якын гына урнашкан Ногай ханлыгы да үзенең күршеләре тормышына тәэсир итми калмаган.

Бу урында халыкта риваятьләр формасында сакланган бер сөйләм дә кызыклы. Ногай мирзаларының берсе Камай мирза, үзара тыныша алмагач, үз кешеләре белән Чулман суын кичеп, Чаллы төбәгенә килеп чыга (Камайның Исмәгыйль мирза улы булуына да ишарә бар.— «Идел», 1993). Аңа чаллылар тарафыннан яхшы мөгамәлә күрсәтелеп, тирә-яктан җир дә бүленеп бирелә. Бу — Чаллы ханлыгының кабат ныгып оешa торган вакытларына туры килгән, күрәсең. Казан белән аралар бозылгач, Камай мирзага да таяныч буларак өмет багланылгандыр.


Әмма чаллылар куеннарына кара елан яшергәннәрен аңышмыйлар. Чаллы ханлыгын кабат җимергәндә Камай мирза, Казаннарга ярдәм кылып, аларга сыена. Ул әле киләчәктә үзен Казаннарда да «танытачак». Чаллы ханлыгының юк ителгән вакыты әлегә билгеле түгел. Тарихи чыганакларда бу хәл Казан алынганчы берничә ел кала, Хафиз Гәрәй ханлык кылганда, дип тә әйтелә (Заитов М. Б.). Шулай да аның 1535—46 елларда, Казан ханлыгына икенче тапкыр утырган Сафа Гәрәйнең Кырым ханлыгына таянып Казан тирәсендә уздырган талау сугышлары вакытында иконлеген дә чамалавы кыен түгел. Бу тартышуларда баштарак ярдәм күрсәтергә өмет кылган Ногайлар да, вакыт җиткәч, дошмәүне яхшырак күрәләр. Бу да аларның үзара булган каршылыкларына: бер яктан Сафа Гәрәй дус булмаган кырымлылардан булса, икенче яктан Ногай кияве булуына да бәйледер.

Кырыгынчы еллар тормышы бу чорда актив иҗат иткән шагыйрь Мөхәммәдьяр иҗатында да ачык чагыла. Илдә тынычлык бетә, икътисад таркау хәлгә килә. Халыкның яшәү шартлары начарлана. 1531, 1545—46, 1549 елларда зур гына баш күтәрүләр дә була. Мөхәммәдьярның да Сафа Гәрәй һәм аның тоткан юлы белән теләктәш булмаганлыгы аңлашыла. Бу дәверне ул үзе өчен мәшәкатьле, авыр итеп хисаплый (Татар әдәбияты тарихы, 1 том, 297 б.). Үзенең көндәше булган Чаллы ханлыгын тар-мар итү — Казан ханлыгын ныгыту чаралары дип аңлашылса да, Казан ханлыгыннан кала икенче зур сәяси үзәк булган, җирләре Мишәнең түбән агымыннан алып Нократ буйларыннан арыга чаклы сузылган Чаллы ханлыгы гаскәренең юк ителүенә, шәһәрнең җимерелүенә, халыкның тирә-якка үчләнеп таралуына китерә. Кызганыч ки, бу хәл күңелләргә төзәлмәс яра булып кергән 1552 елда Казанны да, аның белән бергә Казан халкын да хәлиткеч вакытта ярдәмнән мәхрүм итә.

Эш сөючән, югары мәдәниятле, бер бөтен милләтнең һәлакәтен югары катлам арасында булган низаглар, тарткалашулар хәл иткәндер. Бу чорны күзалларга тырышу, өйрәнү никадәр авыр булса, бүгенге көндә боларны аңлау, белү шулчаклы кирәктер.

Чаллы шәһәре җимерелә. Шәһәр халкының күбесе тирә-якка күченә (Җөри, Сөн, Нократ якларына). Калган өлеше шәһәр тирәсендәге авылларга тарала. Шулар арасындагы икенче бер төркем Иске йорт (Би Йорт — шәһәрнең үзәгенә якын булганга шулай аталган), Пимәр (Би Әмир) һәм Шихаздә (Шәехзадә) авылларына нигез салалар. Казан алынып, аның тирә-якларыннан төп халкы куылгач, бушап калган бу якларга күченеп килүчеләр саны арта (Казаклар авыллары, «Казаклар» — читтән килүчеләр мәгънәсендә, элгәрәк «казаклар» татарлар мәгънәсендә, болгар халкы белән бутамау өчен дә кулланылган).

1619 елгы язма китаплардан күренгәнчә, бераз вакытлар узып, бу авыллар халкы күчеп килүчеләр тарафыннан кыерсытылгач, алар Мишә буйларына күчеп китеп, Пимәр, Шихаздә, Иске Йорт авылларына нигез салалар (Заитов М. Б.). Ә аларның бу чордагы Чаллы шәһәре тирәсендәге авыл атамалары шушы як халкы телендә хәзергәчә саклана, шулай ук элекке авыл һәм зират урыннары да билгеле. Борынгы Чаллыдан 70 чакрым ераклыкта Мишә буйларында хәзер дә Пимәр, Шихаздә, Иске Йорт атамасындагы авыллар бар.



*Өченче үр сурәте.*

Ләкин Чаллы шәһәренең атамасы әле тарихтан бөтенләй үк төшеп калмый. Казан шәһәре урыслар тарафыннан җимерелгәч тә, болгар-татар халкы үзенең дәүләтен торгызу максатында милли азатлык көрәшенә күтәрелә. Шул чорга караган документаль язмаларда 1556 елда баш күтәрүчеләрнең Чалым шәһәрен торгызулары искә алына. Чалым-Чаллы шәһәрен кабат торгызып, аның җирлегендә вакытлыча Казан ханлыгы торгызыла дияргә дә җирлек бар. Беренче хан итеп Ногайлы Исмәгыйль мирзаның угълы чакырыла (сатлык җан Камай мирзаның ир туганы). Аның ханлыктан баш тарту сәбәпләрен аңлавы кыен түгел. Алар бу чорда үзләренә тугандаш төрки ханлыкларының мәнфәгатен явыз Иван бүләкләренә сатып көн күрәләр. Шуннан соң, хан итеп Сөембикәнең энесе Гали Әкрамны утырталар.

Әмма эчтәлеге белән шушы чорга караган, ләкин соңрак язылган тарихи язмаларда төгәлсезлекләр дә күп. Аларга таянып язылган башка тарихи язмалар да тарихны төрләндерергә мөмкинлек бирә. Мәсәлән, Казан белән Түбән Новгород арасында урнашкан Сундыр тавындагы ниндидер бер шәһәрчекнең Чалым булуы мөмкин дип язалар. Бу фикерне беренче тапкыр «Казанские губернские ведомости» газетасының 1852 елдагы 30 санында, Казан алынуның 300 еллыгы уңаеннан татар халкын мыскыллабрак язган мәкаләсендә С. Михайлов әйтә. Кызганычка күрә, шул ук фикерне бары ихтирам белән генә искә алырлык тарихчыбыз М. Худяков та, күпләребезгә мәгълүм «Казан ханлыгы тарихы» дигән китабында кабатлый. Ә моның ялгыш булу мөмкинлеген, Чалымның Чаллы икәнлеген дәлилләүче күп кенә башка тарихчыларның фикерләре нишләптер файдаланылмый.

Чалымның кайда урнашканлыгы һәм аның чирмешләрнекеме-түгелме икәнлеге бер документта да әйтелми. Ә шул вакытлардагы вакыйларны өйрәнүдә төп чыганак булып саналган язмаларда баш күтәрүчеләрнең Мишә якларында шәһәр торгызулары билгеле. Бу турыда: «1553 елда Казаннан 70 километр ераклыкта Мишә буенда»...— дип искә алына. Шулай ук К. Новоструев 1871 елдагы «Шәһәрчекләр турында» дигән китабында «1556 елның язында баш күтәрүчеләргә каршы бояр Морозов үзенең казаклары, укчылары һәм яңа чукындырылган башка халыклары белән Чаллы шәһәренә (Чаллинский городок) барып, аны басып алды һәм яндырды, ә аннан кайтканда Мишә буенда очраган тагын күп

кенә кешеләрне сугышып юк итте» — дип яза. Болар бар да 1552—56 елларда бу якларда баш күтәрүчеләрнең азатлык өчен каты сугышлар алып баруларын күрсәтә.

Тарихи документларда баш күтәрүчеләргә Ногайларның ярдәм итеп торулары да билгеле. Шуңа күрә бу яклардагы Чаллы атамаларының охшашлыгын, Ногай юлы өстендә Чаллыдан бары 20 километр ераклыкта гына Чулман аша салынган Ногай кичүен (Чаллы — Җүкәтай кичүе), аннан соң башланган җирләрнең Ногай ханлыгына керүен искә алып, без әйтеп киткән Чалымның нәкъ менә Чаллы булуын раслау кыен түгел.

Чаллы шәһәрлеге әле үзендә күп серләрне саклый. Тик аның бүгенге халәте моннан 450 ел элек булганнан да аянычрак. Бүгенге көнгәчә анда археолог көрәге урынына бульдозер пычаклары ешрак ялтырый. Әйтеп үтелгән 4 гектар җир өстендә хәзер машина-трактор паркы, каберләр өстендә ындыр табагы булуын да әйтеп китү авыр мина. Ханлыкның үзәге — Калатау хәзерге көндә җимертелеп, аның уртасында ягулык саклау урыны оештырылган. Шулай да шәһәрнең үзәге, урыны-урыны белән ныгытма хәрабәләре әле дә сакланган. Иң соңгы чиктә аның калган өлешен булса да, шул табигый хәлендә киләчәк буынnarга тапшырасы иде. Чөнки тарих монда ул: китап битләре кебек, катлам-катлам, чорыныкы — чорга, елыныкы-елга урнаштырылган. Бар күңелеңне биреп, белемеңә таянып, укый гына бел. Хыяллар чынга ашса, аны элекке хәленә кайтару, торгызу мөмкинлеге дә бар.

Кайберәүләр тарихыбызга карата битарафлыкның бар сәбәпләрен бары тик читтән генә эзли. Ә минем күңелгә үз тарафыннан соңгы кабат җимерелүгә дучар булган Чаллы каласында казу эшләрен алып барган Н. А. Какорина, С. В. Кузьминыхлар искә төшә. Алдымда аларның 1980—85 елларда Чаллы һәлакәтен туктатуны сорап язган хатлары. Кемнәргә генә мөрәҗәгать итмәгән алар?! Чаллы өстендә ничәмә ничә еллар искән битарафлык җилләре исә соңгы елларда гына туктатылды.

1993—95 елларда Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты оештырган археологик экспедиция (житәкчесе Ф. Хуҗин) дәвамлы тикшеренүләр уздырды. Археологлар шәһәрнең тарихын һәм аның тарихтагы ролен билгеле бер югарылыкка күтәреп, Котлы Бөкәш авыл советы, республикабызның мәдәният министрлыгы каршында Чаллы шәһәрлеген җимерүне туктату таләбен бар кискенлеге белән куйдылар. Шулай ук 1994 елның 4 июнендә, алар катнашында, Чаллы кешеләренең 810 еллар элек искә алынулары хөрмәтенә Борынгы Чаллы буйларына таш куелуны да күркәм эш дип билгеләп узасы килә. (З. Гаянов эше.) Әмма Чаллыны тикшерәсе, өйрәнәсе, аның тулы тарихын, музеен төзисе бар... Зур эшләрнең барысы да алда әле.

Кызганыч, Казан ханлыгы үзенең аяныч һәлакәтенә якынлашкан чор да әле зур өйрәнүләр, тикшеренүләр таләп итә. Без бу чорны күбесенчә урыс тарихы, аның тарихчылары күзлегеннән генә күреп беләбез, өйрәнәбез. Алары да бары өзек-өзек юллар белән Тау ягы, Казан, Арча тирәләре турында гына. 1552 елда Казанның алынуы әле Казан ханлыгының тулысынча җимерелүен күрсәтми. Илбасарларга каршы сугыш дәвамы була. Бу чорда Казан шәһәре Казан ханлыгында төп рольне үз кулына алса да, аның төп халкының әле аерым төбәкләре, Казан белән бергә, башка элекке кечкенә ханлыкларының (билек, әмирлекләренең) үзәген тәшкил иткән башка төбәкләре дә була. Бу аерым төбәкләргә: Казан тирәсеннән башка Арча төбәген, Мишә елгасының югары һәм урта агымы буйларын Мишәнең аскы өлешеннән алып Нократ буйларыннан ары сузылган элекке Чаллы ханлыгы җирләрен, Тау ягын, аннан төньяктагы Ашыт буйларын һәм башка җирләрне кертергә була.

Бу элекке билек җирләренең үзәкләрен тәшкил иткән шәһәрләрне дә без Казан белән бергә Казан ханлыгы шәһәрләре исәбенә кертә алабыз. Алар: Арча, Чаллы, Өтернәс, Алат, Иске Җөри, Иске Казан, Алабуга һәм башкалар. Казан елъязмасында алар нығытылган кечкенә шәһәрчекләр белән бергә, утызга якын дип әйтеләләр.

Археологик тикшеренүләргә таянып Казан ханлыгы чорындагы тарихи һәйкәлләрне карасак та, без аларның күбесенчә шул ук 5—6 төбәктә урнашуын күрербез. Бу төбәкләрдә XVI гасыр уртасына караган шәһәр, авыл һәм зират урыннары күп. Бу вакыйгалардан соң ул зиратлардагы кабер ташларындагы язуларның еллары, ватылган сәгать телләре кебек, XVI гасыр уртасында туктап калган. Казан ханлыгының ул тирәләрендәге баш күтәрүчеләре рәхимсез бастырылгач, әле кайчан гына дөртле тормыш кайнаган бу җирләрне өметсезлек баса. Соңрак чорга караган язма китапларда бу урыннар бары «пустошь» буларак

кына искә алына. Хәзерге көндә аларының да күбесе бүгенге авыллар эчендә калып юкка чыккан.

Бу якларда чукындыру, урыслаштыру сәясәте алып барган Н. Ильминский да, гәрчә болгар-татарларга карата тискәре караштa булса да, ул яклардагы кабер ташларына карап, «Хәзерге ярлы татар авыллары урынында элекке Казан ханлыгы һәм аның алдагы чорларында халыкның бу тирәдә бик күп, бай һәм укымышлы булулары беленеп тора»,— дип язып калдырырга мәҗбүр була.

Тагын шунысы игътибарга лаек: бу төбәкләрдә борынгырак чорга караган күп кенә каберлекләр халык теленә «ханнар зираты» яисә «морзалар зираты» буларак кергән. Аларның икесе Мишә буеның Янсуар, Тәмте авыллары янында , XVI гасыр урталарына караган Өтернәс (1553) белән Чаллы (1556) шәһәрләре арасында урнашкан.


1553—54 елның кышында, Мишә буендагы баш күтәрүчеләр тарафыннан төзелгән шәһәр җимерелгәч, яулап алучылар акрынлап борынгы Чаллы төбәгенә якынлашалар. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, шул чакларда гына да урыслар тарафыннан 6 мең ир кеше, 15 меңләп хатын-кыз һәм бала-чага әсирлеккә алына. Аларның шул мәрхәмәтсез чорда, илбасарлар тарафыннан чукындыру, асу, кисү, мәсхәрә кылу һәм нинди авыр коллык авырлыкларын кичерүләрен чамалау кыен түгел. Авыр, тигезсез сугышлардан соң 1556 елның урталарында Казан ханлыгының соңгы терәге булган Чаллы да егыла. Хан Гали Әкрам һәлак була, соңрак азатлык сугышларының җитәкчесе Мәмеш Бирде дә кулга алынып, Мәскәүдә җәзалап үтерелә. Кайбер язмаларда, Гали Әкрамне тирә-як халкы яратмаган, дигән төрле ишарәләргә сәбәп тә бар кебек. Бу чорның кискенлеге аның абыйсы Юныс белән Явыз Иванга язылган ярлыктан да күренә (Һ. Атласи). Алар 1551 елда язган хатларында, кырымлылар ягында булган Казанга бергәләп һөҗүм итү турында фикер йөртәләр. Ул язмаларда Лаеш белән Чаллы кичүләре искә алына. Әмма явыз Иванга, Казанга Арча юлындагы калаларны җимереп барырга кирәк, дип киңәш бирелсә дә, Чаллы каласы инде искә алынмый.

Бу хат җизнәләре Сафа Гәрәйгә ачу белән сугарылган. Гали Әкрәм үзенең дә Казанга сугыш белән килеп (Сафа Гәрәй үлгәч) 8 көн аны камап торганнан соң кайтып киткәнлеген, алынган очракта Казанда зур урын биләргә өметләнгән булуын белгертә. Аның тирә-як халкы тарафыннан баштарак хуп күрелмәвенә җизнәсе Сафа Гәрәй белән кардәше Камайның да үткәндәге эшләре тәэсир итми калмагандыр. Гали Әкрамнең 1551 елда Казанга дустанә булмыйча яу килүенә — апасы Сөембикәнең алар тарафыннан урыслар кулына тапшырылуы сәбәпче. Апасына мәскәүлеләр кулыннан күрсәтелгән җәбер-золымнарны белеп, аның язмышын Казанда кабатлагач, Хан Гали аларның ярдәм сорауларын кире какмый. Әтисе Йосыф мирзадан да, Әстерхан ханлыгыннан да булышырга сүз алгач, ул үзенең коралланган 300 кешесе белән күптән түгел генә Мәмеш Бирде җитәкчелегендәге баш күтәрүчеләр тарафыннан кабат торгызылган Чаллы каласына хан булып килеп урнаша. Алар кул астында берләшкән баш күтәрүчеләр, тигезсез сугышларда батырларча көрәшеп, Мәскәү якларыннан берсе артыннан берсе килеп торган князь Н. Мстиславский, Юрьев, бояр Морозов һ. б. җитәкләгән, баштан аяк коралланган басып алучыларга каршы әледән-әле каршылык күрсәтеп, аларның хәрәкәтләрен тыеп торалар. Әмма тигезсез сугышлар нәтиҗәсендә баш күтәрүчеләрнең көчләре кимегәннән кими. 1556 елда Казан ханлыгының соңгы форпосты Чаллы шәһәре дә егыла.

Тирә-як авыл халкының хәзергә чаклы сакланган сөйләмнәре буенча, илбасарлар Чаллы шәһәренә элекке Кечек (Балхуҗа), хәзерге Биектау авылы ягыннан килеп чыгып, шул яктан һөҗүм итәләр. Бу як элекке чордагы кебек хәзер дә сазлык, тирән елгалар белән капланган. Беренче сугышларда зур уңышсызлыклар кичергәннән соң, илбасарлар зур авырлыклар белән Чаллы каласын әйләнеп узып, аның тау ягына үтәләр һәм урман ягыннан килеп, туплар белән ваттырып алалар.

Чаллы шәһәре яндырылганнан соң, өстенлек илбасарлар кулына күчә, әмма мөстәкыйльлек өчен көрәш әле тынмый.

Чаллы өчен сугышларда янә Камай мирзаның кулы уйнагандыр, дияргә җирлек бар. Казан алынганнан соң Арча төбәкләрендә барган азатлык сугышларына каршы киртә буларак элекке «яхшылыклары» өчен аңа Эчке (Иске) Казан тирәләреннән зур гына җирләр бирәләр. Казан ягын Чаллы төбәгеннән саклау өчен дә шул ук алым кулланыла. Җимерелгән Чаллы буйларын, аңа каршы актив сугышкан Камай мирзаның улы Кәдрәккә бүлеп бирәләр. Әмма ул бу якларда әледән-әле зур каршылыкларга очрый. Бары Чаллыдан Казан ягына таба 4—5



*Борынгы Чаллы янындагы кабер ташы.*

чакрым еракльпкка сузылган Югары Чаллы, Яңа Чаллы һәм башка берничә авыллар тирәсендә генә аларның кешеләрен куып, анда урыс казакларын һәм яңа чукындырылган үз кешеләрен китереп кенә ныгып урнаша ала. Шулай да монда тынычлык таба алмыйча, үзенең Казанда торуы мәгълүм. Бу җирләрдә хәзер дә шул чорларның эзе булып алда әйтеп узылган Чаллы авыллары урынында хәзерге Казаклар, Кече Кадрәк, Олы Кадрәк һ. б. авыллар гына утыра.

Бу чордагы вакыйгаларны ачыклауда ярдәм итәрлек, әмма әле файдаланылмаган телсез тарихи һәйкәлләрне санап китеп, Чаллыдан ерак булмаган, бу чорларда калын урманнар белән капланган хәзерге Чаллы баш авылы янындагы «изгеләр мәчете» дип аталып йөртелгән урын турында әйтеп китә. Ул әлегә чаклы археологик һәйкәлләр исәбенә дә кертелмәгән. Аннан ерак түгел генә изгеләр каберлеге дә бар. Авыл чишмәсеннән ерак түгел генә тирән елга ярына казып эшләнгән бу урын кешеләрнең шул чор вакытындагы тору урынын хәтерләтә. Авыл халкының күбесе аны Казан ханлыгы җимерелү, Чаллы вакыйгалары белән бәйли. Тирә-як авылларының иң борынгы, Чаллы баш авылы тарихын да, аның аксакаллары барысы да үзгәртүсез, бер төрле итеп сөйли. Имеш, элекке Лаеш кечүе белән Чаллы кечүе арасыннан зур юл узган. Аның Уракчы авылы тирәсеннән бер зур тармагы Борынгы Чаллы борыла. Менә шул юл уртасына Чаллы ханы утырта да инде үз кешеләрен. Алар юлда йөрүчеләрне барлап, булган бер үзгәреш, яңалыкларны вакытында Чаллыга хәбәр итеп торырга тиеш булганнар. Чаллы төбәгенең башлангыч җире булганга, аны Чаллы башы дип атаганнар. Тарихи язмаларда бу зур юл, дөрестән дә, билгеле. Тирә як авылларны талап, 1554 елда бу юлдан Чаллыга Н. Ф. Мстиславский килсә дә, аның сугыш хәрәкәтләре уңышсызлыкка очрый. (М. Худяков. Казан ханлыгы тарихы.)

Янә Чаллы шәһәре һәм аның тирә-ягын күзаллап, аның тарихын барлап әйтәсе килгәне шул: моннан 810 еллар элек исәә алынган, биредә яшәгән Саба Күл, Тәмте һәм Чаллы кешеләре — безнең болгар бабаларыбыз. Алар бердәм булып, үзара аралашып, ярдәмләшеп яшәгәннәр, кайгы-шатлыклары да уртак булган. Бу чорларга караган матур, бизәкле кебек ташлары аларның үзләренең әби-бабаларына да хөрмәтле булуларын белгертә.

Борынгы Чаллы һәм аның тирә-ягының тарихы — гаҗәеп бай һәм уникаль. Монда әйтерсең лә болгар-татар халкының борынгыдан килгән өзелмәс, дәвамлы тарихы ята. Бер тарихи урында Болгар, Алтын Урда һәм Чаллы, Казан ханлыгы чорлары урнашкан. Ул гына да түгел, Казан ханлыгы, Чаллы җимерелгәч тә аның халкы үзәкнең тирә-ягындагы авылларда ныгып урнаша.

Борынгы зират урыннары, изге каберләр, XVI — XIX гасырларга караган гаҗәеп бизәкле, язулы кабер ташлары бу чорны күзалларга, өйрәнергә мөмкинлекләр бирә.

Бүгенге көндә Татарстанда сакланып калган 3—4 татар төбәгенең берсе бу. Монда Борынгы Чаллы хәрабәләрен урап, бер җепкә тезелгән асыл ташлардай бер-берсенә терәлеп, мәчетле татар авыллары дистәдән артык утыра. Әмма, үкенечле булса да, әйтеп китми мөмкин булмас: Чаллы шәһәренең сакланышы

яхшы түгел. Тарих җилләре аның ныгытмаларын катлам-катлам көл итсәләр дә, соңгы елларда ул үзенең тирә-як халкы тарафыннан да җимерелгән. Әйтеп үтелгән 4 гектар мәйданлы зиратны урталай бүлеп, сугыш чыгар алдыннан гына (1939) актарып юл сузалар. Соңрак каберлекләр өстенә ындыр табагы, автопарк төзелә. Җитмешенче елларда ханлыкның 650 еллар элек төзелгән саклану урларын бульдозерлар белән ертып, ягулык майлар саклангычлары салалар. Аннан соң шул тирәдә юл ачып, карьер башлау һ. б. шуның кебек эшләр куба.

Ә бит әле революция һәм аннан соңгы елларда гына аның Мәмле Казакларының Вәли бае тарафыннан койма белән тоттырып алынганлыгы билгеле.

Менә шундый чагыштыру, язмыш һәм чынбарлык!

Язмамны тәмамлап, тагын да шуны әйтәсем килә: тарихыбызны барлап, өйрәнеп, үткәннәр белән бүгенгебезне чагыштырып, бик яхшы сабак алырга кирәк безгә. Эшләнәсе бу эшләрне озакка сузмаска, тарихыбызны битарафлыкта, үз тузанында ук күмеп калдырмаска иде! Безнең киләчәктәге өметле яшәячәгебез өчен бу бик мөһим. Галиҗанәп вакыт көтми...

Чаллыны күтәрү, дөньяга алып чыгу юлында, аның тарихына игътибарны юнәлтү бик тә мөһим. Монда борынгы Чаллының КамАЗ юлыннан бары 3—4 чакрым ераклыкта, Казан белән хәзерге Чаллының нәкъ уртасында урнашуы да күп уңайлыклар тудыра.

Хәзер борынгы Чаллы Кремль стеналары, аның эчендәге Хан йорты һәм мәчете торгызылып, тирә-яктагы изге чишмәләре чистартылса, янындагы мәһабәт табигате тагын да матураеп, үзендә булып киткән туристларда да онытылмас хисләр калдырыр иде.

Чаллы белән Казан арасында йөрүче эшмәкәрләр, туристлар да ике шәһәр арасындагы 4 сәгатьтән артык юлда интекмичә, ике сәгатьтән соң ял итеп, музей, тарихи урыннар карап, аннары үзләре теләгәнчә юлларын дәвам итә алачаклар.

Хәзерге вакытта тормышка ашырыла башлаган «Көмеш ай» проекты да киләчәктә Җүкәтаудан соң түбән Кама — Чаллы — Алабуга — Кирмән — Борынгы Чаллы — Кашан — Казан туктальшлары белән түгәрәкләнер иде. Борынгы Чаллы тирәсендәге авылларның халкы да гаҗәеп эшчән, игелекле булулары белән икътисади һәм рухи, мәдәни проблемаларны хәл итүдә булышырлар иде.

**Нурулла ГАРИФ**

# УЛ ИКЕ ГАСЫРНЫ ТОТАШТЫРА

(ГОСМАН БАКИРНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ)

Булды заман: башка әдәбиятларда балаларны аталарын саткан Павлик Морозовлар рухында тәрбияләүне алга сөргән әдәби әсәрләр мәйданга чыга башлады. Кешелекнең киләчәген имансыз, кансыз, дәһри итеп күрергә ниятләгән Иблис кануннарының өстенлек алу куркынычы туды. Дәрдемәндчә әйтсәк, «... канат какты мәләкләр, шашып, аң-таң булып шайтан тәкерде!..» Әмма, шөкер, ислам дине йогынтысында, мәдрәсә белеме алып үскән татар язучыларының күпчелеге әлеге шаукымга бөтенләй үк бирелмәделәр, балаларыбызны үз әсәрләрендә рәхим-шәфкатьле, иманлы, намуслы һәм башка кешелекле асыл сыйфатларга ия булган адәмнәр итеп тәрбияләү юнәлешен югалтмадылар.

Татар балалар әдәбияты өлкәсендә озак еллар тырышып иҗат иткән язучыларыбыздан Госман Бакир әнә шундый иманлы язучыларыбызның берсе иде. Тәрҗемәи хәленә күз салсак, без аның нинди тамырлардан сут алып үскәнлеген ачык күрербез. Госман Фәтхулла улы Бакиров татар әдәбиятына күренекле әдипләрне күпләп биргән Арча ягыннан, Тукай үсеп чыккан бәрәкәтле туфрактан. (Ул Югары Курса авылында 1896 елның 12 мартында укымышлы гаиләдә дөньяга килә). Заманында татар мәгърифәтчесе Габделнасыйр Курсави салдырган мәдрәсәдә белем ала. Уналты яшеннән үзе күрше авылларда мөгаллимлек итә башлый.

Госман Бакировка солдат шулпасын да күп татырга туры килә. Унтугыз яшеннән патша армиясенә алып, аны турыдан-туры сугыш кырына төртеп кертәләр. Австрия — Венгрия гаскәрләренә каршы сугышта катнашу, Тернополь шәһәрен азат итешү, шунда чолганышта калып, 1916 елдан 1918 елгача әсирлек ачысын кичерү...

Илгә әйләнеп кайткач, Госман Бакиров (инде Октябрь инкыйлабыннан соңгы гаять катлаулы шартларда) яңадан балалар тәрбияләү, аларга белем бирү эшен дәвам итә. Яңа шартларда белемен арттыру нияте белән, ул 1923 елда Казанга килә, Тукай исемендәге балалар йортына укытучы-тәрбияче булып эшкә урнаша. Шулай итеп, матди тормышын җайга сала һәм Җир төзү техникумының кичке бүлегенә укырга керә.

Шул елларда Госман Бакиров әдәби иҗат эше белән житди шөгыльләнә башлый: балалар өчен «Яшь ленинчы» гәзитен чыгаруны оештыруда актив катнаша, шунда үзенең беренче әсәрләрен, очерк һәм язмаларын бастыра.

Белемен күтәрүне дәвам итеп, ул Көнчыгыш педагогия институтының кичке бүлегендә укый башлый.

1927—29 елларда Госман Бакиров — Татарстан Мәгариф комиссариатында инспектор, аннары 1936 елга кадәр «Мәгариф» журналының җаваплы сәркатибе. Бу елларда ул аеруча актив иҗат итә. Аның «Беренче җиңү» (1928), «Яшәсен яшьләр» (1934), «Безнең рапорт» (1936), «Сафа балалары» дигән сәхнә әсәрләре, «Урак өсте» (1930) атамалы хикәяләр китабы, мәктәп һәм тәрбия мәсьәләренә багышланган күпләгән очерк вә мәкаләләре әнә шул елларда языла.

Күрүебезчә, Госман Бакиров, балалар язучысы буларак, яшь буынны киләчәккә әзерләү кебек игелекле эшне эзлекле вә нәтиҗәле алып бара, үзенең яшәү максатына әверелдерә. 1940 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлаганнан соң, аңа әлеге юнәлештә эшләү өчен тагын да киңрәк мәйдан ачыла. Ул Татарстан дәүләт китап нәшриятының дәреслекләр чыгару секторында мөхәррир вазыйфасын башкара башлый. Әмма немец-фашистлары башлаган сугыш, башка татар язучылары белән бергә, Госман Бакировны да кабат утлы өермә эченә илтеп ташлый. Башта ул — орудие командиры, аннары «Ватан намусы өчен» исемле фронт гәзитенең хәрби хәбәрчесе.

Шушы гәзиттә бергә эшләгән фронтовик шагыйрь Мөхәммәт ага Садри үзенең сугышчан дусты турында бик җылы итеп искә ала. «Госман абыйны без гәзит эшенә үзебез чакырып алдык. Ул, Беренче империалистик сугышта катнашкан тәҗрибәле солдат буларак, элек сугышып узган юлларыннан кабат безнең белән дә үтте. Ул куркусыз һәм, бер үк вакытта, искиткеч кешелекле, гади җанлы иде. Бер кулында — автомат, икенче кулында каләм булды. Дошманга каршы ут белән дә, ялкынлы сүзе белән дә сугышты. Биш телдә (урыс, украин, татар, үзбәк, казакъ телләрендә) чыга торган «Ватан намусы өчен» гәзитен туктаусыз материаллар белән тәэмин итеп торды, «Кызыл йолдыз», Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнарын аңа минем алда шул елларда тапшырдылар. Без Көнбатыш Украинадагы Тернополь шәһәрен (Госман абый икенче тапкыр), Праганы бергә азат итештек, фронт юлларын Берлингача бергәләшеп уздык...» — ди Мөхәммәт ага Садри.

Сугыштан соң, Госман Бакиров — яңадан Татарстан китап нәшриятында. Дәреслекләр редакциясе мөдире буларак, 1956 елга чаклы эшли. Берочтан, җиң сызганып, иҗат итә. Бу елларда аның иҗаты тематик яктан да байый, камилләшә. «Партизан малай» (1952), «Классташлар» (1954), «Укытучым» (1963), «Утлы тегермән» (1956) повестьлары, күпләгән хикәяләре әнә шуның мисалы.

Госман ага Бакиров революциягә кадәрге татар язучылары буынын безнең буын белән тоташтырган асыл затларның берсе иде. Аның «Татарстан яшьләре» гәзите редакциясенә салмак кына атлап килеп керүләре, матур гына елмаеп, кинәш-уңаш бирүләре, үзенең Тернополь шәһәрен ике тапкыр алуы, соңыннан үзен өченче тапкыр анда чакырып, кунак итүләре турында сөйләгәннәре әле дә хәтеремдә. Ә ул калдырган әдәби вә педагогик мирас — татар балаларын милли рухта тәрбияләүдә әле дә кадерле хәзинә.

**Шамил МАННАПОВ.**

## КОТЛЫЙБЫЗ!

Яңа туган баланың кендек әбисе була. Ул сабыйны дөньяга кабул итә, ап-ак биләүгә били. Аннары да онытмый: баланың хәле белән даими кызыксынып, язмышын белешеп тора.

Әдәбият хәрәкәтендә дә әнә шундый «кендек әбисе» сыман җаваплы кешеләр бар. Алар — китап редакторлары. Яңа әсәрен төгәлләгән әдип аны китап нәшриятына алып килә дә, редактор кулына тапшыра.

...Татарстан китап нәшриятында әдип хезмәтенә һәм тулаем әдәбиятка гаять зур хөрмәт белән карап, һәр сүзнең кадерен белеп эш итүче редакторлар байтак. Әмма **НАИЛӘ МИНҺАҖ** кызы **ВӘЛИТОВА** алар арасында үзенчә аерылып тора. Үзенең тырышлыгы һәм киң карашлы булуы, әдәбиятны да, тормышны да тирән аңлавы белән. Иҗат кешеләренә олы хөрмәте белән.

Наилә Вәлитова Татарстан китап нәшриятында 1971 елдан бирле эшли. Шушы гомер эчендә ул татар язучыларыннан кемнәрнең генә китапларына редактор булмаган икән?! Халык язучылары Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев әсәрләре, татар-башкорт әдибе Мостай Кәрим китаплары һ. б. лар.

Шул ук вакытта әдәби тәрҗемә өлкәсендә дә уңышлы эшли Наилә ханым. Бүген без яратып укый торган әсәрләрнең байтагы: мисал өчен В. Распутинның «Онытма, гомергә», Н. Думбадзенның «Мәңгелек канун», Э. Успенскийның «Крокодил Гена», А. Милонның «Виннипух мажаралары» һ. б. лар Наилә Вәлитова тәрҗемәсендә татарча дөнья күрделәр һәм безнең яраткан китапларыбызга әверелделәр.

Иҗади тынгысызлык рухында яшәүче тәҗрибәле редактор һәм тәрҗемәче Наилә Вәлитованы бу айдагы юбилее уңаеннан кайнар котлыйбыз! Аңа яңадан-яңа иҗат уңышлары, бәхет, сәламәтлек телибез!

Әхәт Сафиуллин

# ӘЛЛӘ НИШЛӘДЕ БУ ХАЛЫК!

Карап-карап торам да, тагын бер карап куям: әллә нишләде бу халык! Акча җене кагылды бугай, һаман акча сорый да акча сорый! Әллә ул агач акчаларны утын урынына якмакчы инде?

Урамда — май. Табигать уяна. Җан уйный торган чак. Ә халык шуны да сизми. Аңа акча давай! Былтыргының февраль аенықын давай, мартныкын давай! Әллә нишләде бу халык! Хәтта борынгыларның: «Ала каргада алачагың булсын, кыш кайтмаса — яз кайтыр!» — дигән сүзләрен дә онытты. Ә бит уйлап карасаң, юкка гына әйтмәгән аны безнең әби-бабайлар! Тир түгеп эшләгән акчаңны биш-алты ай буе бирмиләр икән, бу бит синең биш-алты каргадан аласың бар дигән сүз! Киләчәктә өметең арта дигән сүз! Яшибез дигән сүз. Тик шуның аңламый халык. Һаман акча сорый: янәсе, бер тиенсез ничек яшәмәк кирәк?!

«Ничек яшәмәк кирәк?» Декабрь акчасын алалмыйча, апрельдә ничек яшәдең, хәзер дә шулай яшисең инде. Нигә аны сорап торырга? Барыбер акча да, җавап та бирүче юк. Адәм рәтле илләрдә генә биреп баралар бит аны. Бездә түгел. Аласыбыз, чыннан да, ала карга кулында бит безнең. Ә ала каргадан сорадың ни дә, сорамадың ни! Ул барыбер адәм телен аңламый ич: аның үз карүз җыры.

Ала карга кешене аңлый дип уйлагандыр инде, әнә берәү биреп караган иде соравын. Соравы калды, үзен идән астына чумырдылар, ахрысы: үзе дә күренми, тавышы да ишетелми...

Әллә нишләде бу халык! Яхшылыкны да аңламый. Сәмән урынына кулына товар китереп тоттыргач та түшәмгә сикермәде. Акчаны акчалата бирергә кирәк, йәнәсе. Йә, әйтегез, өлешеңә тигән көмешең өчен бер кочак товар күтәреп кайту начар нәрсәме?

Әйтик, химкомбинат эшчеләренә былтыргының августы өчен быелның маенда кер юа торган порошоклар белән түләделәр, ди. Алар нишли? Шуларны күтәреп базарга элдертә. Хәрәкәттә — бәрәкәт, дигән борынгылар.

Тоз чыгаручыларга — тоз, шырпы ясаучыларга шырпысы белән түлиләр икән, димәк, аларда да базар башланды дигән сүз. Йә, әйтегез, базар начар нәрсәме? Башта гына уңайсыз тоела, ди ул. Товарыңны күтәреп бер йөри башласаң, аның берние дә юк, ди. Алтыга ал, бишкә сат — исемең булсын сәүдәгәр.

Әнә күршем Сәгыйдулланың әйләнеп карыйсы килмәгән иде шул базар дигән җиргә. Резин заводында эшли ул. Балалар өреп уйный торган шарга охшаган презерватив дигән нәрсәкәй ясыйлар икән.

Бер ай бирмиләр боларга акчаны, ике, өч ай... Шулай ярты ел да узып китә. Анда да халык әллә нишләгән икән. «Акчасыз ничек яшиек?!» — дип, хор белән каравыл кычкыра-кычкыра, директордан сәмән даулыйлар. Директор каравыл кычкырган эшчеләренә тыныч кына хөкүмәткә таба төртеп күрсәтә: ул акча түләми, янәсе. Ә хөкүмәт елмаеп, озын, нечкә бармагы белән серле итеп түшәмгә төртә. Монысы инде, безгә Рәсәй түләми шул, дигән сүзне аңлата. Аласыбыз ала карга кулында, янәсе.

— Әгәр дә сезгә акча шулай бик кирәк икән, товар белән алыгыз, үзегез акчага әйләндерерсез,— ди алар эшче халыкка. Йәнәсе, хәзер бар җирдә дә шулай эшлиләр. Һәм берәр кочак теге резин нәрсәкәйне биреп җибәрәләр.

Шуларны күтәреп кайткач, күршем башта кеше күзенә күренергә оялып йөрде. Күз алдында кара чәче агарды мескеннең. Акчалары да юк, бу резин нәрсәне дә кеше арасында сатып йөрергә кыенсына. Җитмәсә, шуны күтәреп кайткач, ай буе хатыны талаган. Болар белән кызлар янына кыякларга җыенасыңмы әллә, йәнәсе. Теткән генә тегене! Чөнки аның бу әйберләрнең иренең

ничә айлар буе тир түгеп алган эш хакы икәнен аңларга акылы житмәгән. «Ялганлама, акча урынына моның ише нәрсә бирәләрме соң?!» — ди икән. Бер ай буе тукый торгач кына тынычланган. Нишләсен мескен, оялып-оялып кына булса да, таныш-белешләренә үзе дә саткалый башлаган аннары: акча кирәк, яшәргә кирәк ләбаса!

Шуннан соң Сәгыйдулла күрше дә базар тирәләрендә чуалгалады. Йөри торгач, ул шул шау-шулы җиргә шундый ияләнеп китте, ял көннәрен гел шунда үткәрә торган булды.

Эшләр ничек, сәүдә ничек бара, дим мин аңа беркөнне, имезлегенне алалармы? «Алалар, хәзерге заман өчен бик кирәкле нәрсә булып чыкты ул,— дип елмая.— Хәзер бит бала үрчетүдән курка халык». Аннары СПИД зәхмәтеннән дә саклый икән бу нәмәрсә.

Тора-бара күршем базар мөнәсәбәтләренә муеныннан кереп чумды. Эшеннән ни ияреп кайта, шуны алып чыгып сата башлады. Хәзер Сәгыйдулла күршене күргән дә юк — һаман базар юлында ул. Менә шулай кешене үзгәртә дә куя икән базар дигән нәрсә! Базар тирәсендә кайнаштымы, кешене ачтан үтерә алмыйсың инде!

Әллә нишләде бу халык! Рәсәй белән төзегән Шартнамә дә күренми аның күзенә. Һаман үз туксаны туксан: «Эшләгән акчаны да бирмәгәч, ни кирәк ул Шартнамә?!» — дип шаулаша. Һич аңламыйм, нигә шаулашырга? Рәсәй безгә тиешле триллионнарын бирмәгәч, Баш министр кайдан алсын ди? Акчаны бездә түгел, Мәскәүдә сугалар бит. Бу инде тагын, безнең ала каргадан аласыбыз бар, дигән сүз. Димәк, өмет белән яшибез!

Йомшак кына барып кергән шул базар тирәләрендә кайнашсак, бәлки, исәнсау да калырбыз әле... Өмет белән яшик, өмет белән! «Карале, һаман яшәп ята бит болар!» — дип, бөтен дөнья шаккатсын!

## Кампрамис

Старший литинат Галявиев булам мин. Учаскувый инспектор. Тәртип сагында торам, ягъни. Эшме? Төрле чак була инде. Хәзер бит беркемгә бер сүз әйтеп булмый — ипи шүрлегенә менеп төшәргә дә күп сорап тормыйлар. Шуңа күрә безнең эштә иң главные — кампрамис. Кешегә патхут табу, ягъни...

Ә-ә-нә теге йортта Шәмсетдин исемле егет тора. Әле өйләнмәгән, ялгызак, ягъни. Чөнки өйләнергә вакыты юк аның — һаман төрмәдә, һаман төрмәдә. Сиңа сатучы булып эшләргә ярамый, дип тә карыйлар үзенә. Юк, тыңламый, кайта да тагын кибеткә барып керә! Керә-керешкә күп итеп умырырга тотына. Шунсыз яши алмый. Аннары тагын утырталар үзен.

Төрмәдән чираттагы срогын тутырып кайтканын ишеткәч, киттем мин монын янына. Кылларын чиртеп карарга. Дәльнейшем ничек яшәргә тели, ягъни. Учаскувый буларак, мин кешеләрне белергә тиеш.

— Җитәр, Шәмсетдин, сәүдә тирәсендә бүтән кайнашма инде син! Акылга утырырга вакыт! — дим моңа.

— Дөрес әйтәсең, гражданин нәчәлник, бу юлы ул тирәгә борылып та карамыйм,— ди бу.

Чыннан да, торды бит сүзендә: аракы заводына барып керде. Ярар, дим, селтәнеп йөргәнче, эшләве хәерле. Алай да күздән ычкындырмыйм моны. Ни әйтсәң дә, учаскувый үзенең кешеләрен белергә тиеш, участоктагы хәлләр өчен мин җаваплы. Күрәм, бераздан баһадирдай егетләр белән дуслашып китте бу. Тегеләрнең барысында да — машина! Аны эшкә дә илтеп куялар, машина белән каршы да ала болар.

Бер дә бер көнне карыйм: Шәмсетдин торган өйнең подвалын чистарта башлады егетләр.

— Шахмат клубы ачабыз,— диләр.

«Менә рәхмәт төшкере, бу юлы Шәмсетдин, чыннан да, акылга утырып кайткан түгелме?! — дип уйлыйм эчтән генә.— Маладис, нинди игелекле эшкә башы җиткән!»

Йөрим шулай, клубны кайчан ачарлар икән, дип, көтеп. Эшләре күзгә күренеп тәгәри кебек: тимер ишек, тәрәзәләргә тимер рәшәткәләр дә куйды болар. Төнлә дә эшлиләр — нидер китерәләр, нидер алып китәләр, подвалда төне буе ут янып чыга. Тик клуб кына һаман ачылмый. Туктале, дидем шулай беркөнне, нәрсәләр маташтыралар икән, барып карыйм әле.

— Кая, эшләрегез ничек бара? — дип кызыксынам Шәмсетдиннән.
— И-и, мондагы эшнең иге-чиге юк әле! — ди Шәмсетдин. Сизәм, минем килүне бик өнәп бетерми бу.— Алай да, әйдә, гражданин начальник, синнән яшереп булмас, сөйләшәсе сүзләр дә бар,— ди.
Кызык кеше бу Шәмсетдин: тегендә утырып өйрәнеп беткән, күргән саен «гражданин начальник» дип кенә дәшә.
Шалтыр-шолтыр итеп подвал ишеген ачып җибәрүе булды, борынга әллә ниткән тәмле ис китереп бәрде. Сизәм хәмер исә. Валлаһи, затлы хәмер исе! Әллә нишләп киттем. Кичә артыграк та җибәргәнмен бугай... Алай да, дәшми генә Шәмсетдин артыннан атлыйм.
— Менә монда чаң торачак, ә монысында бөке станогы бөкеләр шапылдатачак,— ди ул, ниндидер бүлмәләргә күрсәтеп.
— Нинди чан, нинди бөке, нинди станок?! — мин әйтәм.— Аларның шахматка ни катнашы бар?!
— Соң, гражданин начальник, хәзер бизнес заманасы лабаса. Аракы чыгарачакбыз без моннан,— ди бу. Күзен дә йоммый бит ичмасам! Каттым да калдым...
— Бизнесын бизнес та, тик тагын утырталар ич сине! — дим.
— Курыкма, гражданин начальник, хәзер алай мәтәштермиләр. Югарыда үз кешеләребез утыра. Хәзергесе көндә подвалны хосусыйлаштыру һәм аракы чыгару өчен рөхсәт кәгазе алу өстендә эшлиләр. Һәр нәрсә законга туры киләчәк, гражданин начальник...
— Алайса нигә шахмат клубы ачабыз дип баш катырдыгыз соң? — минәйтәм.
— Булачак анысы, булачак... «Шахмат клубы» — без чыгарачак яңа аракының исеме шулай булачак, гражданин начальник.
Менә сиңа мә! Болай булгач, хәзер үк эләктең бит син, Шәмсетдин туган! Ничек кенә әле! Менә хәзер башлыкларыма шалтыратам да, сезнең бу «завод»ыгызны чәлпәрәмә китерәчәкләр. Законный, имеш! Беләбез андый нәрсәләрне... Хәер, туктале! Үземне эләктереп куймасыннар тагын болар... Хәзерге заманны аңламассың: бизнесменнарның, каракларның югарыда үз кешеләре, ә югарыдагыларның түбәндәге үз бизнесменнары, үз караклары...
Шулай уйлана-уйлана Шәмсетдин артыннан атлыйм. Зур бер бүлмәгә килеп кердек. Кечкенә ресторан дип белерсең! Нәрсәләр генә юк! Идәндә — төрле агачлардан эшләнгән төсле паркет, стеналар да кыйммәтле агач плитәләр белән тышланган. Затлы, күн кәнәфиләр! Безнең район милициясе башлыгының кабинет дигән нәрсәсе моның янында чүп кенә!
— Монысы минем офис булачак,— диде Шәмсетдин, өстәлгә чит ил шешәләре тезеп.— Әнә теге ишек бассейнга чыга...
Шәмсетдин белән бик яхшы гына утырдык. Башым да җиңеләйде, яңадан туган шикелле булып киттем.
— Алай да сак булыгыз,— дидем мин аңа, бу изге эшендә уңышлар теләп.— Ходай саклаганны саклармын, дигән...
— Әлегә, аллага шөкер, чит-ят күзләрдән Ходай үзе саклап килә.
Уйлап карасаң, Шәмсетдин менә дигән егет икән, әй! По савмистительству мине үзенең тән сакчысы итеп алды, төшемдә дә күрмәгән акча түләп тора хәзер миңа хөрмәтле Шәмсетдин Вагыйзович. Саулык бирсен аңа Ходай һәм төрмә юлларыннан сакласын!
Менә шулай инде безнең эшләр. Кампрамис дигән нәрсәгә таянсаң, бүре дә тук, сарык та бөтен.

*РӘСМИ ХӘБӘРЛӘР*

### ФРАНЦИЯ ТАТАРСТАН БЕЛӘН КҮРЕШӘ

16 февральдә Франциянең Премьер-министры Ален Жюппе Казанга рәсми визит белән килде.

Франциянең зур кунагын Кремльдә үз резиденциясендә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев кабул итте. Ул Жюппе әфәндегә Татарстанга килергә чакыруны кабул иткәне өчен рәхмәт белдерде, республикадагы социаль-сәяси хәл белән таныштырды. Төрле тармакларда үзара хезмәттәшлек турында сөйләшү игътибар үзәгендә торды.

Татарстан Премьер-министры Фәрит Мөхәммәтшинның Ален Жюппе белән очрашуы үзара ышаныч һәм аңлашу шартларында үтте. Дәүләт Советында исә ике республика парламентарийлары очрашып сөйләштеләр. Аннары Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачевның Франция премьер-министры Ален Жюппе белән әңгәмәсе булды.

«Казан» милли-мәдәни үзәгендә Франция һәм Татарстанның эшлекле даирәләре «Түгәрәк өстәл» янында сөйләшү үткәрделәр. Соңыннан дәүләтара күп кенә килешүләргә кул куелды.

Франция белән Татарстанның кул кысышуы республикабызның халыкара мәйданда абруй яулавында яңа бер адым булып тора.

### ФӘН ОСТАЛАРЫ ЙОМГАК ЯСЫЙ

20 февральдә Татарстан Фәннәр академиясенең зур конференц-залында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең еллык гомуми җыелышы булды. Анда академиянең 1995 елдагы гыйльми-тикшеренү оештыру эшчәнлеге һәм 1996 елга бурычлары турындагы доклад белән Татарстан Фәннәр академиясе президенты академик М. Хәсәнов чыгыш ясады.

Фикер алышуларда күп кенә галимнәр, югары уку йортлары җитәкчеләре, завод һәм акционерлык җәмгыяте директорлары һ. б. катнашты.

Галимнәр алдында җөмһүриятебез Президенты М. Шәймиев чыгыш ясады.

М. Шәймиев республика алдында тора торган бурычларны хәл итүдә Академиянең роле һаман үсә баруын, республикада югары Фәнни үзәк булып әверелүен билгеләп үтте. Икътисад, сәясәт, авыл хуҗалыгы өлкәсендәге күп кенә проблемаларга тукталды.

Чыгышының ахырында М. Шәймиев җыелышта катнашучыларга үзен Татарстан Республикасы Президентына кандидат итеп күрсәтүләре һәм ышаныч белдерүләре өчен рәхмәт әйтте.

Конференция эшендә Татарстан Дәүләт Советы Рәисе В. Лихачев, Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары И. Хәйруллин катнашты.

### М. ШӘЙМИЕВ ТӘКЪДИМ ИТӘ

Чечен сугышының мәгънәсезлеге һәм аны нинди юллар белән туктату хакында Рәсәй җитәкчеләре дә уйлана башлады. (Чөнки «ике сәгатьлек» бәрелеш дигәннәре инде икенче ел дәвам итә...) Ичкерия мәсьәләсен җайга салу буенча Премьер-министр В. Черномырдин җитәкчелегендә эшче төркем оештырылды. Бу төркемдә Татарстан Президенты М. Шәймиев тә бар. Ул әлеге комиссия эшендә катнашачагын һәм анда берничә пункттан торган Татарстан Республикасы тәкъдимен яклаячагын әйтте.

20 февральдә М. Шәймиев РФдагы Ичкерия Республикасы парламенты вәкиле Р. Тутаковны кабул итте һәм Җ. Дудаевка һ. б. җиткерү өчен аңа белдерү текстын тапшырды. Очрашуда Президентның дәүләт киңәшчесе Р. Хәкимов катнашты.

### ЯЗУЧЫЛАР СУГЫШНЫ ГАЕПЛИ

Ичкериядә бер елдан артык барган сугышның әле һаман да тукталмавына борчылып, Татарстан Язучылар берлеге идарәсе белдерү белән чыкты. Анда Русия Федерациясе җитәкчелегенең канлы-коралл бәрелешне сөйләшүләр юлы белән хәл итәргә теләмәве, кеше хокуклары һәм халыклар азатлыгы белән исәпләшмәве тәнкыйтьләнә.

Аерым алганда, белдерүдә мондый юллар да бар: «Язучылар берлеге идарәсе Ичкериядәге конфликтны тыныч юл белән хәл итү буенча Татарстан Республикасы җитәкчелеге һәм иҗтимагый хәрәкәтләребез башлап җибәргән эшне хуплый, милли мәсьәләләрне тупас рәвештә хәрби көч кулланып хәл итүне гаепли. Шуңа күрә без, Татарстан әдипләре, Кавказдагы барлык сугыш хәрәкәтләрен һич кичекмәстән туктатуны, Русия гаскәрләрен Ичкерия Республикасыннан чыгаруны таләп итәбез».

*ЮБИЛЕЙЛАР*

### ФАТИХ ӘМИРХАНГА БАГЫШЛАП

Татар әдәбияты классигы Фатих Әмирханның тууына 110 ел тулу уңаеннан Татарстан Фәннәр академиясе, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институ-

ты, Казан дәүләт педагогия университеты фәнни-гамәли конференция уздырдылар.

Конференцияне кереш сүз белән Татарстан Фәннәр академиясе президенты М. Хәсәнов ачты. Берләштерелгән утырышта академик Ф. Мусин «Ф. Әмирхан һәм 1917 елдан соңгы татар әдәбияты», КДПУның татар әдәбияты кафедрасы мөдире Ф. Галимуллин «Совет чоры тәнкыйтендә Ф. Әмирхан иҗатын бәяләү» дигән темаларга доклад белән чыктылар.

Аннары конференция үзенең эшен «Ф. Әмирхан һәм XX гасыр татар әдәбияты», «Ф. Әмирхан — сүз сәнгате остасы», «Ф. Әмирхан һәм татар мәгарифе» дигән секцияләргә бүленеп эшләде.

Әдипнең тормыш юлын, иҗтимагый эшчәнлеген, аның шәхесен һәм әдәби мирасын өйрәнүгә конференция үзеннән зур өлеш кертте.

## ГЕРОЙ-ШАГЫЙРЕБЕЗ ХӨРМӘТЕНӘ

5 февральдә Казанда М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында татар халкының горурлыгы — каһарман шагыйрь Муса Җәлилнең тууына 90 ел тулуга багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәне кереш сүз белән Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ринат Мөхәммәдиев ачып җибәрде. Ул кичәнең кадерле кунакларына — Муса Җәлилнең хатыны Әминә ханымга, кызы Чулпанга һәм оныгы Таняга чәчәкләр тапшырды. Аннары сүз М. Җәлил турындагы дистәләгән китаплар авторы, язучы Рафаэль Мостафинга бирелде. Ул ике телдә шагыйрьнең батырлыгы турында сөйләде.

Тантана каһарман шагыйребезнең либреттосы буенча куелган «Алтынчәч» операсы белән тәмамланды.

Тантаналы кичәдә Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ренат Харисов катнашты.

* * *

Мәскәүдә Халыкара Язучылар берлеге оешмасында (СССРның элекке Язучылар союзы) әдипләрнең, әдәбият һәм сәнгать эшлеклеләренең татар патриот-шагыйре Муса Җәлилнең тууына 90 ел тулуга багышланган очрашуы булды. Аны Бөтенроссия татар мәдәният үзәге һәм татар әдәбияты советы Татарстан Республикасының Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиллеге катнашында оештырган иде.

Очрашуда Муса Җәлил һәм аның иҗаты турында шагыйрьләрдән Р. Гамзатов, С. Михалков, тәрҗемәче шагыйрьләр В. Галиев, Я. Козловский, В. Гончаров, В. Вәлиева, дирижер һәм композитор Ф. Мансуров, шагыйрьнең кызы Чулпан сөйләделәр.

## ӘДӘБИ КИЧӘ

15 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында язучы Мәгъсум Насыйбуллинның 70 яшьлегенә һәм иҗатына багышланган әдәби кичә булды. Юбилярны әдипләр, сәнгать әһелләре һәм Кукмарадан килгән якташлары котлады. Язучының тормыш юлы һәм иҗаты турында Мансур Вәлиев, Фоат Галимуллин, Кыям Миңлебаев сөйләделәр.

## *ӘДӘБИЯТ-СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ*

## КАЗАН КИТАПХАНӘЧЕЛӘРНЕ ҖЫЯ

12—18 февраль көннәрендә Казанда Русия төбәкләрендә яшәүче татарларга хезмәт күрсәтүче китапханәчеләр өчен атналык укулар үткәрелде. Аны Татарстан Республикасының Милли китапханәсе һәм мәдәният хезмәткәрләренең белемен камилләштерү курслары оештырган иде.

Җиде көнлек уку дәвамында китапханәчеләр татар халкының тарихы, әдәбияты, мәдәнияте белән таныштылар. Галимнәр, фән һәм җәмәгать эшлеклеләре, язучылар, артистлар белән очраштылар. Курста катнашучылар башкалабыз Казан шәһәренең тарихи урыннарында, театрларда, концерт залларында, күп кенә музейларда булдылар.

Алар белән очрашуга «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре дә килгән иде. Баш мөхәррир урынбасары Рашат Низамиев, бүлек мөхәррирләре Рәдиф Гаташ һәм Шаһинур Мостафин журнал турында сөйләделәр, үзләренең шигырьләрен укыдылар.

## ТАТАРНЫҢ ЯШЬ ҖЫРЧЫСЫ — БЕРЕНЧЕ!

Мәскәүдә «Иртәнге йолдыз» телеконкурсының суперфиналы үткәрелде. Татарстанның яшь җырчысы Муса Маликов анда татарча һәм итальянча җырлар башкарды. 9—15 яшьтәгеләр арасында чыгыш ясап, ул конкурста беренче урынны яулап алды.

## ТАТАР ҖАНЛЫ РӘССАМ

Быел 9 гыйнварда Татарстанның халык, Рәсәйнең атказанган рәссамы Виктор Иванович Кудельскинга 85 яшь (1911—1995) тулган булыр иде. Татар җанлы бу рәссам «Кечкенә Габдулла Өчиле авылында бабасы белән», «Политрук җыры» («Муса Җәлил») картиналарын һәм милләттәшләребездән күп кенә әдәбият-сәнгать эшлеклеләренең портретларын иҗат итте.

Талантлы рәссамны искә алу йөзеннән, шушы елның мартында Татарстанның сынлы сәнгать музеенда В. Кудельскинның зур күргәзмәсе ачылды.

## ТАТАРСТАН МУЗЫКАНТЛАРЫ УҢЫШЫ

Санкт-Петербургта «Төньяк Пальмирада музыкаль очрашулар» дигән III Халыкара фестиваль кысаларында ике көн дәвамында профессор Фоат Мансуров җитәкчелегендәге Татарстан дәүләт симфоник оркестры чыгыш ясады. Солистлардан Рубин Абдуллин, Флора Хәсәнова, Ариадна Анчевская һ. б. тамашачыларның олы мәхәббәтен яуладылар. Концертларга Санкт-Петербургта яшәүче татарлар да күп килгән иде.

## ЯҢА БАСМА

Мәскәүдә шул төбәкнең Татарлар җәмгыяте тарафыннан мәдәният, мәгариф хезмәткәрләре һәм эшмәкәрләр басмасы — «Татарские новости» («Татар яңалыклары») исемле айлык яңа газета чыга башлады. Инде ул бу өлкәдә яшәүче татарлар арасында популярлык казанып та өлгерде. Газета даими рәвештә татар халкының социаль-икътисади, сәяси тормышын яктырта, татар тарихы, аның данлы вәкилләре турында материаллар биреп бара. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, М. Җәлил юбилейларына карата да кызыклы мәкаләләр чыга, бүгенге әдипләр иҗаты да киң яктыртыла. Җөмләдән, газетаның 22 нче санында журналыбызның бүлек мөхәррире шагыйрь Рәдиф Гаташ иҗаты турында филология фәннәре кандидаты Г. Хантимерованың «Рәдиф Гаташ — мәхәббәт җырчысы» дигән мәкаләсе һәм шагыйрьнең шигырьләре урнаштырылган иде.

Рус телендә чыга торган бу газетаның баш мөхәррире — К. Дәүләтшин; газетаны гамәлгә куючы — татар яшьләре «Мирас» клубы, финанс директоры — мәгълүм эшмәкәр Р. Абдуллин.

## БАЛАВЫЗ СЫННАР КҮРГӘЗМӘСЕ

Казанның К. Маркс урамындагы сынлы сәнгать музеенда бер ай дәвамында Санкт-Петербургның Кучмә балавыз сыннар музее күргәзмәсе эшләде. Борынгы грек философы Аристотель, Чыңгыз хан, Петр I, патшабикәләрдән Анна, Екатерина II, полководец А. Суворов, Е. Пугачев, К. Маркс, В. Ленин, И. Сталин, Н. Хрущев, Л. Брежнев, М. Горбачев, Б. Ельцин кебек киң билгеле шәхесләрнең табигый төстә һәм үз зурлыкларында ясалулары бик күпләрдә зур кызыксыну уятты.

*ТАМЫРЛАРЫ — БЕЗНЕКЕ!..*

## ИКЕ ХАЛЫКНЫҢ ОЛЫ ЗЫЯЛЫСЫ

Тумышы белән татар булган күренекле үзбәк язучысы, Хәмзә исемендәге Үзбәкстан Дәүләт бүләге иясе Әсгать Мохтарга үткән ел азагында 75 яшь тулды. Үзбәкчә язылган роман һәм повестьлары, шигырь һәм поэмалары белән дан казанган якташыбыз татар әдәбиятына да бирелеп хезмәт итте. Илленче-алтмышынчы елларда Үзбәкстанда аның тырышлыгы белән Г. Тукай, М. Җәлил җыентыклары дөнья күрде. Ә. Мохтар ул китапларны туплаучы да, кереш сүз авторы да, кайбер шигырьләрнең тәрҗемәчесе дә иде. Аның татар язучылары белән якыннан аралашып яшәве һәм мәрхүм әдибебез Г. Әпсәләмов белән туганлык мөнәсәбәтендә булганлыклары да мәгълүм.

Ике халыкның олы зыялысы саналган мәшһүр шәхесне — Әсгать ага Мохтарны — Татарстан язучылары, күпсанлы әдәбият сөючеләр олуг юбилее белән котладылар.

## Ч. АЙТМАТОВНЫҢ БАБАСЫ — КУКМАРАДАН

Атаклы кыргыз язучысы Чыңгыз Айтматовның бабасы — Татарстанның хәзерге Кукмара районында туып-үскән татар эшмәкәре Хәмзә Абдувәлиев турында Бишкек шәһәрендә фильм төшерелде. Хәмзә ага Каракол шәһәрендә иң дәрәҗәле кешеләрнең берсе булган. Ул биш кибет тоткан, шулай ук аның чүлмәкләр ясый, тире эшкәртә торган ике остаханәсе булган. Шәһәрдә үз хисабына кыргыз мәктәбе ачкан, татар басмаханәсе оештырган, мәчеткә ярдәм итеп торган.

Фильмның режиссеры — Рахилә Җамабаева, ә сценарий авторы — Хәмзә аганың оныгы Ринат Абдувәлиев. Кыргыз телендәге бу фильм татарчага да тәрҗемә ителәчәк.

*КОТЛЫЙБЫЗ!*

## МАКТАУЛЫ ИСЕМНӘР

Россия Президенты Б. Ельцин Указы белән, сәнгать өлкәсендәге зур казанышлары өчен, Татарстан Республикасының Дәүләт җыр һәм бию ансамбленең сәнгать җитәкчесе Лима Гали кызы Кустабаева, «Россия Федерациясенең халык артисты», Татарстан Республикасы Композиторлар берлеге идарәсе рәисе Рәшит Фәһим улы Кәлимуллин «Россия Федерациясенең атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән мактаулы исемнәргә лаек булдылар.

* * *

Татарстан Президенты Указы белән, әдәбият-матбугат өлкәсендәге казанышлары өчен, язучы Солтан Сәлах улы Шәмсетдинова «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде.

## *Тышлыктагы сурәтләр*

**Тышлыкның беренче битендә:** рәссам Миләүшә Нуруллина картинасы.


**Тышлыкның дүртенче битендә:** танылган язучы һәм публицист Миргазиян Юныс.

# ЯҢА КИТАПЛАР





Танылган шагыйрь һәм җәмәгать эшлеклесе **Равил ФӘЙЗУЛЛИН**нең 3 томлык сайланма әсәрләре басылып чыкты.

I томга 1958—1971 елларда иҗат ителгән шигырьләр тупланган. Китап — 416 бит булып, аңа «Үсмерчак дәфтәреннән», «Яшьлек дәфтәреннән», «Солдат дәфтәреннән», «Әмәт дәфтәреннән», «Әлмәт дәфтәреннән» һәм «Кыска шигырьләр» дигән бүлекләр кергән. Томлык шагыйрь Ркаил Зәйдулланың кереш мәкаләсе белән ачыла.




II томда шагыйрьнең 1972—1982 елларда язылган шигырьләре, балаларга багышланган әсәрләре һәм поэмалары урын алган. Беренче томдагы шикелле, икенче томда да шигырьләр хронологик тәртиптә, ягъни аларның төгәл язылу вакыты һәм урыны күрсәтелеп урнаштырылган. Томлыкның күләме — 504 бит.




«Сайланма әсәрләр»нең III томына 1983—1995 елларда иҗат ителгән шигырьләр һәм миниатюралар кергән. Томлыкта, шулай ук, шагыйрь иҗаты турында күләмле библиографик күрсәткеч (төзүчесе — Г. Бәйрәмова) һәм иллюстратив материаллар урын алган. 320 бит күләмендәге бу күпьеллык хезмәт — томлыкларның мөхәррире Наис Гамбәрнең «Шигъри дөньяга сәяхәт, яки 3 томлык фонында иҗади портретка штрихлар» дигән фәнни мәкалә-очеркы белән тәмамлана.

«Сайланма әсәрләр» Татарстан китап нәшриятында 1993—1995 елларда нәшер ителгәннәр. Томлыкларны үзләрендә булдырырга теләгән укучылар әлеге нәшриятка мөрәҗәгать итә алалар. Адресы: 420111. Казан, Бауман урамы, 19.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARЬ
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен в центральный каталог